

# КАЗАН УТЛАРЫ

4
АПРЕЛ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4
АПРЕЛЬ
1981

## *Бу санда*

КОЯШЫБЫЗ — ЛЕНИН

А. ВЕЛЮГИН. Давыл алдыннан. Шигырь . . . . 3
Э. МАЙТЕНИ. Ленинны онытмыйбыз. Шигырь . . 5
Д. ВӘЛИЕВ. 1887 ел. Пьеса . . . . . . . . 6

Н. АРСЛАНОВ. Дулкыннарга карап. Шигырьләр . 47
Ш. БИКЧУРИН. Тирән катлам. Роман . . . . . 55
Ш. МАННАПОВ. Гипноз сеансында уйлану. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 141
Л. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Бар дөньяның. Шигырь . . . 144
Х. ӘЮПОВ. Тукай клубы. Шигырь . . . . . . 145
Ф. ЯРУЛЛИН. Фаҗига. Хикәя . . . . . . . . 146
Р. ИДИЯТУЛЛИН. Бүген минем туган көнем. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 154
Бездә кунакта: «Звезда» журналы авторлары. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 157

ТӨРЛЕСЕННӘН

Х. БАДАМШИН. Биш хатирә . . . . . . . . 163
З. РӘСУЛОВА. Еллар истәлеге . . . . . . . 167
Р. ШӘЙХИЕВ. Төбәкчелек . . . . . . . . . 169

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. КУКУШКИН. Шигъри бишек . . . . . . . 172
Б. РӘХИМОВА. Без кемнәр! . . . . . . . . 182
Р. ӘХМӘТОВ. Сез кем, шагыйрь! . . . . . . 184

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**С. ИБРАҺИМОВА.** Сәрвәр Әдһәмованың тууына 80 ел . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 189

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 24/XII-1980 ел. Басарга кул куелды 23/III-1981 ел. ПФ 09007. Кәгазь форматы 70×108$^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 103 644 экз. Заказ У-531. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

*Мактаулы эшкә яз*
*тырышып керешә.*
*Адымнар, агымнар —*
*барчасы ашыга...*
*Күңелләр төбәлгән*
*ягымлы Кояшка —*
*Һәркайда Ул атлый,*
*Ул килә каршыга.*

## Анатолий Велюгин,

белорус шагыйре

## Давыл алдыннан

«ИДЕЛДӘН ИСКӘН ЖИЛЛӘР» ПОЭМАСЫННАН ӨЗЕК

Болытка да, жилкәнгә дә охшап
Күренә күзгә сирень куагы.
Хуш исләре башны әйләндерә...
Матур шомырт!—иң саф, иң агы.

Иске флигель. Тын һәм аулак урын.
Сирень аңкый тәрәз каршында.
Яз жылысы белән тулы күңел
Якын итә шуның барсын да.

Сириус калкыр — дәү һәм якты йолдыз,
Каникулга кайтыр Саша да.
Жәйге бакча белән кавышырга
Күңел инде күптән ашыга.

Спиртовка, колба һәм китаплар —
Зур химия тора киштәдә...
Көне буе эшләп утырдылар,
Ә эш әле калды кичкә дә.

Петербурдан кышын алып кайтып
Саша биргән калын том кулда.
Завод үче, эшче сыйныф көче
Зур икәнен күрде ул шунда.

Сөйли китап шундый хакыйкатьне:
Эшче кулы — шундый нык металл,
Ишәчәк ул синең нигезеңне,
Законыңны синең, капитал!

Володяның, Миша Кузнецовның
Шушы китап хәзер кулында.

һәрбер сүзе — биеклеккә баскыч,
Җиңелмәс көч — һәрбер юлында.

Рус теленә шулай күчергәндә
Рейннан килгән сүзләрне,
Ачык итеп күрә төсле алар
Якты таңга илтәр эзләрне.

Язгы җил дә гүя тынып кала
Чәчәкләрне коймас өенгә.
Ике үсмер нишләп утырганын
Шушы язда, шул май кичендә.

Миллионныйда[1] кем һәм каян белсен?!
Байлар йоклый, буржуй симерә.
Чиркәү чыңлый «гөнаһ кылма!» диеп,
Ә динчеләр — хәмер чөмерә.

Губернатор үрдәк атып йөри,
Жандармнар аны саклыйлар.
Нужа — болыт. Фәкыйрь Сембер күген
Зур болытлар әле каплыйлар.

Сембер надан, Сембер йомык әле,
Якты түгел әле иртәләр.
...Гимназистлар исә «Капитал»ны
Рус теленә тәрҗемә итәләр.

Күтәргәндә шундый авыр йөкне
Көч җитәрме, куллар түзәрме?
Ульяновы яттан әйтеп тора,
Кузнецовы яза сүзләрне.

Бер ай буе утырып бары биш бит
Күчерделәр әле егетләр.
— Сизәсеңме шуны син, Володя,
Бу сүзләр бит шигырь кебекләр.

Миша үзе — официант улы,
Миша үзе ярлы нәселдән.
Аңлый Миша: сүзләр буржуйларны
Җиңә торган яшен яшергән.

— Масаерга һич тә кирәкми дип
Сөйләштек бит, Миша, кичә без...
Кирәк безгә бераз җилләнергә,
Әйдә тагын бераз очабыз!

һәм очалар, әйтеп: «Артка калма!»
«Кем өскәрәк менәр!» диеп тә —
Елмаешып таган атыналар,
Күтәрелә дуслар биеккә.

[1] Сембер шәһәрендә урам исеме.

Оча дуслар!.. Ярсу дулкын булып
Яз җилләре исә каршыга.
Болытлы күк, җилкән сыман сирень —
Ачык күренә өстән барсы да.

Яшьлек оча... Яшьлек күккә менә
Куанып та, бөркет булып та.
Юк, кояшны томан яшерә алмас,
Каплый алмас аны болыт та!

Шаулаячак җирдә көчле күкрәү,
Хәнҗәрләрен яшен сузачак.
Куандырып барча заводларны
Дөнья буйлап давыл узачак!..

## Эрик Майтени,

венгр шагыйре (Румыния)

### Ленинны онытмыйбыз

Еллар үтә. Бик күп матур таңнар безнең
Истән чыга узган заман җыры булып.
Ә ул яши йөрәгендә һәммәбезнең
Кояш сыман якты булып, тере булып!

«Бездә шундый партия бар! Бар ул!»— диеп
Әйткән иде. Әйе, бар ул! Һәм ул — бөек.
Зурлау сүзен йөрәкләрдән күккә чөеп,
Җирдә аны бик күп халык котлый сөеп.

«Бөтен власть — Советларга!»— диеп язып,
Мәңге сүнмәс изге байрак күтәрде ул.
Җирдә туды Азатлык һәм Ирек язы,
Күңелләрен аяз итте күпләрнең ул.

Яктылыкны җирдә Ленин иҗат итте.
Мирас итеп, Ленин тиңсез көч калдырды.
Аның сүзе планетаны урап үтте,—
Хәтерләтеп лачын булып очкан җырны.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре.

# Диас Вәлиев

# 1887 ел

ФАҖИГАЛЕ ХРОНИКА

ӨЧ БҮЛЕКТӘ

КАТНАШАЛАР:

Никонов
Фадеев
Ульянов
Звонарская
Смелянский
Португалов
Людмила Бааль
Шелонов
Бронский
Гангардт
Потапов
Масленников
Овсянникова
Мангушевский
Ульяновның сеңелесе
Хуҗа хатын
Студентлар, жандармнар, хезмәткәрләр, понятойлар

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

**Яшәү өчен вакытлыча бирелә торган почмаклар һәм бүлмәләр, тыкрыклар, чиркәү тәресе һәм мәчет манарасы. Кемнеңдер сыкранып кычкыруы, томан эченнән күренгән тәрәзә... Үткәннәрдән Россиянең — яшеренеп эш итүче, киләчәккә омтылган Россиянең сулмаган йөзе күренеп тора. Һәм кайчак рухымның чын ватаны да кайдадыр шунда кебек тоела. Ә алар белән бергә — мин үзем дә.**

**Тәрәзә янында — китапка иелгән Ульянов. Әмма китап битләре кыштырдаганы ишетелми. Карашы ачык китаптан читкә, каядыр еракка төбәлгән.**

Ольга *(кереп)*. Чәеңне ник эчмисең? Үзең сорадың лабаса.

Ульянов *(чынаяктан бер йотым каба, өстәлгә куя)*. Бераз жылытмассыңмы икән? Салкын чәйне өнәп җиткермим.

Ольга. Ничә кат җылытырга мөмкин? *(Ульянов аны тагын тыңламый инде.)* Тукыйсың сине, тукыйсың... *(Күл селти.)* Әнкәй бик борчыла. Нишләп барлык иптәшләрең дә синнән өлкәнрәк соң, ди.

Ульянов. Аларның күбесе Сашаны күреп белгән.

---

Спектакль Казандагы һәм Ленинградтагы Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театрлары, Мәскәүдәге Ермолова исемендәге театрда уйнала.

Ольга. Әти вафат. Сашаны үтерделәр. Аня сөргендә. Бер елда никадәр үзгәреш. Тагын берәр нәрсә булса, әнкәй түзә дә алмас! *(Тынлык.)* Кинәт картаеп китте ул, әйеме?

Ульянов. Чәй китерсәң икән. Син боларны барыбер аңлап житкермисең әле.

Ольга. Ник житкермим ди? Әнкәйне кызганам. *(Тәэсирга бирелеп.)* Социалисткага әйләнеп, минем үземне корбан итәсем килә!

Ульянов. Нәрсә?

Ольга. Социалистканың яшәү максаты — үз-үзеңне корбан итү.

Ульянов *(көлә)*. Нишләп әле һичшиксез һәлак булырга тиеш ди ул?

Ольга. Чөнки яңа тормышны корбаннар биреп кенә пропагандаларга мөмкин. Иң дөресе дә шул! Ә сезнең теге барлык сүзләрегез, барлык чыш-пышларыгыз — бөтенесе буш нәрсә! Менә шул!

Ульянов. Шулай укмыни?

Ольга. Әйе. Корбанлык — анысы бөтенләй башка эш ичмасам. Кешене үлгәч мактый башлыйлар. Ни өчен җәзалаганнар икән? Нинди сүз сөйләгән, ни эшләгән икән, дип төпченәләр. Сүз китә, гайбәт китә. Меңләгән кеше кызыксына башлый. *(Яңадан тәэсирга бирелеп.)* Саша кебек үләсем килә минем. Әни генә кызганыч.

Ульянов. Бар, дәресеңне әзерлә! Миңа да комачаулама!

Ольга. Ә син әзерләмисең бит.

Ульянов кинәт көлә башлый.

Ни булды? Нидән көләсең син?

Ульянов. Өченче көн Смелянскийның сеңелесе халык арасына киткән. Ә бүген инде әйләнеп тә кайткан. Пычранып беткән, карарга куркыныч. Әйттем мин аңа, уйлап кара, Вера, акылсызлык бит бу дидем. Шул хәлеңдә ялгызың кая бармакчы буласың, күз алдыңа китер, адашырсың, я булмаса ир-ат бәйләнә башлар дидем. Смелянский күпме үгетләде. Юк, тыңламады, крестьян киеме киде дә... һәлак булырга китте.

Ольга. Соң, шуннан?

Ульянов. Смелянский белән икәүләп көлә-көлә чак аяктан егылмадык. Беренче көнне үк адашкан, кая килеп эләккәнен үзе дә белми икән. Яңгыр, караңгы төн, ачык кыр. Аннары бер елгага килеп чыккан. Нинди елга икәнен дә белми, яр буйлап киткән. Мин югарыга таба барамны, әллә түбәнгәме икәнен дә белмәдем ди. Чынлап та, Володечка, елганың кая таба акканын ничек беләләр аны, дип сорый.

Ольга. Ә син ни дидең?

Ульянов. Берәр йомычка ташларга иде, йомычка кая таба акса, түбән ягы шул булыр иде, дим.

Ольга *(көлә)*. Ә ул?

Ульянов. Ә ул әйтә, йомычка юк иде бит, ди. Халык арасына баруы әнә шулай тәмамланган.

Ольга. Ник сөйлидең син моны миңа?

Ульянов. Мораль мәсәлләрдә генә була. Анда да начарларында гына. Ә без синең белән, иң яхшысы, шашка уйныйк. Биш тапкыр маңгайга чиртештән. Кечкенә кызларны аларның башына барып житмәстәй нәрсәләрдән биздерергә кирәк. Маңгаена чиертеп.

Ольга. Биштән түгел — ун чиертештән! Карарбыз кемнең кемне отканын! *(Шашка уйный башлыйлар. Шаулашу, көлеш. Сеңелесе ота. Ульянов, урыныннан кубып, аннан кача. Ольга аны өстәл тирәли куып йөри, тота.)*

Каты һәм озак итеп ишек шакыйлар.

О л ь г а *(куркып).* Кем булыр бу?

У л ь я н о в *(каушап калуын җиңеп).* Россиядә кеше гаебе аз булган саен күбрәк курка. *(Акрын гына.)* Бар, ач.

Ольга чыгып китә.

О л ь г а *(тыштан).* Кем бар?

Ишек дөберди.

Т а в ы ш *(дорфа).* Полиция! Тизрәк ачыгыз!

О л ь г а *(керә).* Полиция.

У л ь я н о в. Куркырлык берни дә юк. Ач.

Сәхнәсе янадан чыга. Ишек ачылганы ишетелә. Һәм кинәт көлеш башлана. Ишектән, көлә-көлә, шат күңелле Португалов керә.

П о р т у г а л о в. Нәрсә? Куркыттыммы?

У л ь я н о в. Кретин. Мондый мәзәгең өчен!..

П о р т у г а л о в. Реакциягезне тикшердем. Ярый, ярый, гаеп миндә, миндә! Кәеф әйбәт чакта да шаяртырга ярамыймы әллә?!

О л ь г а *(Португаловның аркасына сугып).* Менә сиңа! Менә сиңа!

П о р т у г а л о в. Сез, Олечка, иң яхшысы, миңа ашарга бирәр нәрсә бирегез. Көне буе аякта.

У л ь я н о в. Чишен. Утыр.

П о р т у г а л о в. Ай, идәнегезне пычратканмын лабаса!

О л ь г а. Үзең үк сөртеп тә ал!

П о р т у г а л о в. Я, тормышлар ничегрәк, Олечка? Бөтен ирләр гимназиясе Олечка Ульянова өчен ут йота диләр. Дөресме шул, юкмы?

О л ь г а. Әй, китегез лә!

П о р т у г а л о в. Хатын-кызлар белән һич кенә дә сөйләшә алмыйм. Ни өчендер мине бөтенесе, сүз куешкандай, ачуланалар, кыйныйлар, сугалар... *(Ольга чәй китерә, Ульяновка.)* Сездә кунсам, сүз әйтмәссезме икән?

У л ь я н о в. Куныгыз, әлбәттә. Яңалыклар юкмы?

П о р т у г а л о в. Хәзер, хәзер. Балакайны йокларга гына озатыйк та.

О л ь г а. Мин барында берни дә әйтергә теләми, ә! Ай, эчкерле дә инде син, Португалов!

П о р т у г а л о в *(ул суга дип башын яшерә).* Әйтәм бит: нишләптер кызлар яратмый мине.

О л ь г а. Мин сезгә үч итеп йокламыйм. Күрше бүлмәгә кереп утырам да үч итеп йокламыйм! Мескен чыш-пышлар! Бик кирәге бар иде миңа сезнең серләрегезнең! Үзләрен әллә кемгә куйган булалар! Кыланчыклар! *(Ишекне каты ябып чыгып китә.)*

П о р т у г а л о в. Ай, кызу канлы да соң!

У л ь я н о в. Я, сузма!

П о р т у г а л о в *(телеграмма чыгарып бирә).* Үзәктән. Менә. Смелянкскийга килгәненә ике генә сәгать.

У л ь я н о в *(укый).* «Никахлашу декабрь башында булачак. Түземсезлек белән көтәбез...» *(Тора, бүлмә буйлап йөренә.)* Димәк, әзерләнә башларга кирәк.

Португалов. Иртәгә сәгать алтыда җыелабыз. Барысын да йөреп чыгарга кирәк. Чын кыямәт булырга тиеш ул!

Ульянов *(телеграмманы яңадан алып).* «Никахлашу... декабрь башында...»

2

Төн. Күз ияләшер-ияләшмәс караңгылана. Өстәлдә — керосин лампасы. Студент Никонов, ротмистр Мангушевский, гади киемле кеше, жандарм, понятойлар. Тентү бара. Ялыктыргыч, әмма өстән-өстәнрәк кенә тентү. Кулдан өскә таба тәмәке төтене сузыла. Штатский киемендәге кеше өстәл янында утыра, кәгазьләр, китаплар актара.

Мангушевский. Тынычсызладыкмы? Борчыласызмы?

Никонов. Һич көтмәгәндә.

Гади киемле кеше. Бик үк көтелмәгәндә булдымы икән?

Жандарм. Полковник әфәнде, менә!..

Гади киемле кеше. Рәхмәт, кадерлем. *(Китапларны игътибарсыз гына актарып.)* Беркетмә языгыз, ротмистр. Кызыклы берни дә юк. Никонов әфәнде революция уены уйнамый. *(Көлемсерәп.)* Юкка борчылырга мәҗбүр иттек без аны.

Мангушевский беркетмә яза. Никонов аркасы белән стенага сөялеп басып тора, әле аңа, әле гади киемле кешегә карый.

Мангушевский. Понятойлар, бире килегез! *(Аларга.)* Кул куегыз. *(Никоновка.)* Законга каршы килердәй берни дә юк. Сезнең белән танышуыма бик шатмын... Хәлегез начармы?

Никонов. Юк, юк.

Гади киемле кеше. Барыгыз, ротмистр. Никонов әфәнде чынлап та үзен начаррак хис итә. Тынычландырырга тырышырмын мин аны.

Барысы да чыгалар.

*(Үзе белән таныштырып.)* Губерна жандарм идарәсе начальнигы полковник Гангардт. Законга каршы килерлек берни дә тапмадык. Никонов әфәнде. *(Тартманы күтәреп һәм капкачын ачып.)* Хәер, менә бу... бик тә... типография буявына охшаган. *(Никонов дәшми.)* Мин инде бүген үк сезгә куну урынын төрмә бинасыннан тәкъдим итә алган булыр идем. Аңлыйсызмы сез моны? *(Бармаклары белән өстәлне шакый.)* Без тапмаган материаллар җитәрлек монда.

Никонов. Ни өчен соң?..

Гангардт. Мин дә шулай уйлыйм. Нигә? Гуманлы кеше булып кыланасым килми. Юк, кызганудан түгел. Хәер, күпмедер еллар элек үзем дә шушындый ук минутларны кичердем. Сезнең кебек үк яшьлегем белән... Лыгырдарга яраталар Россиядә. Әмма лыгырдауларга җитди карый торган ил түгел ул Россия. Мондый тартма кебек нәрсәләр, яки сез артык саксызлык аркасында үз өстәлегездәге саклый торган кәгазьләр өчен төрмә белән түләргә мөмкин. Дилетант күнекмәләр өчен, бик кыйммәт түләү булмыймы соң бу? Сездә бераз салкынчарак димме?

Никонов. Әйе, салкынрак.

Гангардт. Чыраегыз киткән, Никонов. Мин сезнең үз-үзегезне бик тә иркен тотуыгызны теләр идем. Без хәзер сезнең белән элеккеге якын танышлар кебек сөйләшәбез.

Никонов. Миннән ни кирәк сезгә?

Гангардт. Күп нәрсә.

Никонов. Кулга алынуга мин әзер. Күптән әзер.

Гангардт. Нигә, Павел Николаевич? Сездән тагын бер корбан ясаргамы? Аллам сакласын! Аңлагыз мине, моны эшләү җиңел түгел. Әчәргә бирәр нәрсәгез юкмы?

Н и к о н о в. Белмим. Әйе, бар.

Аракы, стаканнар, кабым китерә. Аракы сала.

Г а н г а р д т. Шулай да сез бик үк кунакчыл хуҗа түгел.

Никонов икенче стаканны тотыра.

Сезнең исәнлеккә!.. Политика күзгә ташлану мөмкинлеге бирә. Рухың ярлы булганда бу кызыктыра. Әмма, кабатлап әйтәм, куркыныч кызыгу ул. *(Кинәт.)* Кем ул Шелонов?

Н и к о н о в *(бик үк ашыкмый гына)*. Алай искитәрлек нәрсәсе юк.

Г а н г а р д т. Ә Ульянов? Аның абыйсын җәзаладылар. Бу фактка мөнәсәбәтегез ничегрәк?

Тынлык.

Берничә генә соравым бар минем. Рәсми булмаган сөйләшү бу, дустым. Минем кабинетымда бармый торган сөйләшү. Сезнең сүзләрегезне берәү дә ишетми... Ә, ни, Лидия Звонарская мәсьәләсендә... Мин чибәр хатын-кызларның революция эшенә кереп китүләрен һәрвакыт бик авыр аңлыйм. Чибәрлек — сирәк күренеш. Шуңа күрә ул бикләнмәскә, ә дөньяны бизәргә тиеш... Беләм, сез аны яратасыз. Ул да битараф түгел. Тыегыз аны...

Н и к о н о в. Үзегезне мондый мөнәсәбәтләргә дә кагылырга хаклы дип исәплисезме?

Г а н г а р д т. Бу сезне рәнҗеттеме? *(Көлә.)* Русь үзенең каршылыклары белән әйбәт! Крепостное праводан чыгарга да өлгермәдек, ә инде горурлыгыбыз борынгы республикачыларныкыдаймы? Бу яктан алганда, немец эч пошыргыч. Җирдә йөри ул. Шул ук революцияне ясаганчы, ул аны линейка белән үлчәп караячак. Үлчәп караячак та баш тартачак! Чөнки аңа пфеннинг пирогка кирәк. Ә рус кешесе, тирәнме-юкмы икәнен дә үлчәп тормыйча, суга сикерә! Ә Смелянский нәрсә? Ул немец җидлыгын таратмыймыни?

Н и к о н о в. Нәрсәне күздә тотуыгызны аңламыйм.

Г а н г а р д т. Мин университет курсларын тәмамлаган елларда студентларда Россия производствосы нигилизмы артты. Чабата киеп, мужик янына бару, револьвер белән эш итү, бомба ыргыту — болар барысы да һич югында рус формасы! Ә хәзер нинди дер яңа мода... Шул ук мужикның нинди дер идея белән кайнавы... Мин боларны патриот буларак сөйлим!.. Сез дә патриотмы, әллә яңа модалылар яклымы?

Н и к о н о в *(каны кызып)*. Сәбәбе бар икән — мин әзер! Әмма рәсми яктан караганда... Чакырыгыз понятойларны! Ә бу кәмитне туктатыгыз!.. *(Өстәлне ача һәм тартмаларны алып ыргыта.)* Әйе, нелегальщина! Әйе! Менә, менә!

Г а н г а р д т *(көлемсерәп)*. Каһарман ролен дә уйнамакчы буласызмы? Ышаныгыз миңа: Россия чынбарлыгында бу һич тә кызыгырдай роль түгел. Кызыгырлык түгел. Һич тә кызыгырлык түгел! *(Пышылдап.)* Ә иң мөһиме, кешенең бу рольне ничек үтәвен беркем дә беркайчан да белмәячәк... Җандарм күзәтүе астына сез икенче тапкыр алынасыз инде. Сезнең әнкәгез бар. Карт анагыз! Үзе дә очын-очка гына ялгап яшәгәндә, сезне гимназия курсларын тәмамлаттыру җиңел булмагандыр. Ә университетка күпме өметләр баглыйсыз! Өстәвенә апагыз, энегез бар... Алар өчен җаваплылыкны санга сукмаска уйлыйсызмы?

Никонов. Сез миннән шпион ясый алмассыз.

Гангардт. Юкка борчыласыз, Павел Николаевич. Безнең очрашулар үтә дә сер булып калыр. Полициянең әлегәчә үз кешеләренең берсен дә сатканы юк. Революционерлар сатты, ә без — юк.

Никонов. Файдалы түгелмени?

Гангардт. Нәрсә?

Никонов. Файдасызмыни, дим? Шуннан соң провокаторлыкка берәү дә бармаячакмы?

Гангардт. Сез мине дә, үзегезне дә мәсхәрәлисез. Ышаныгыз, кайчан да булса бу көннәрне рәхмәт хисләре белән искә алырсыз әле.

Никонов. Рәхмәте ни өчен тагы?

Гангардт. Сезне мәгънәсез иллюзияләрдән коткарганым өчен. Мин сезне реаль тормыш туфрагына кайтарам.

Никонов. Арыдым мин.

Гангардт. Без — аучылар, сез — корбаннар. Шулай да булсын ди! Әмма сез, аучыларга, ә без сез атачак киеккә әверелгән очракта дөньяда берәр нәрсә үзгәрер микән соң? Тарих сәхнәсенә яңа уенчылар чыгармы? Әйе! Тик вакыйгаларның төп мәгънәсе үзгәрерме соң? Сез дөнья тәртипләренә каршы көрәшәсез. Төп фаҗигагыз да менә шунда инде! Социаль мохитны үзгәртергә була. Әлеге политик, юридик һәм экономик учреждениеләрне дә була! Ләкин идеяләрне, гадәтләрне, кешеләрнең хисен ничек үзгәртмәк кирәк? Сезнең яңа дип аталган җәмгыятегезне төзү өчен башта кеше үтерергә кирәк. Аны нindидер башка берәү белән алыштырырга кирәк!

Никонов. Иске җыр бу!

Гангардт. Шулаймыни? (*Көлемсерәп.*) Ә сез аны җырлыйсызмыни?

Никонов. Иң элек кеше табигатен үзгәртергә, кеше хисләрен, инануларын, кеше төшенчәсен үзгәртергә, тик шуннан соң гына иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үзгәртергә тотынырга була. Шулаймы?

Гангардт. Ә сезнеңчә алай түгелмени?

Никонов. Сез безгә ахырдан башларга кушасыз, ә без башыннан башларбыз. Ышануларны һәм хисләрне яңадан үзгәртүдән элек бу инану һәм хисләрне гариплəгән нигезне җимерүдән башлаячакбыз! Революция фәнни нигездә, кешеләрне үз колачына алып, аларны үз хосусыйлыкларыннан, аның властеннан тартып алучы тулы бер система булдырыр. Һәм ул кеше күңелен яңартачак. Өстәвенә тамырдан һәм бик тиз яңартачак.

Гангардт. Бүгенге социал-демократлар үз идеяләрен фәнни итеп күрсәтергә тырыша. Сез хаклы. Әмма фәннең, кадерлекәем минем, әлегә барлык таркау нәрсәләрне фәлсәфи гомумиләштерердәй синтезны таба алганы юк. Дин синтезын алыштырырлык нәрсә юк әлегә. Шулай булгач, сезнең әхлакый яңарышка өметләнүегез дә... Бик томанлы фәлсәфи бәхәс бу. Сүз сезнең тормышыгыз турында бара. Сезнең якыннарыгызның тормышы турында.

Никонов. Минем тормышым күптән хәл ителгән инде.

Гангардт. Бөтенесен сызып ташларгамы? Нәрсә хакына? Ниндидер өрәк хакынамы? Дөньяны үзгәртеп кору турындагы буш, бөтенләй хыялый идея хакынамы?

Тынлык.

Соңгы мәгълүматларга караганда, чуалышлар Россиянең күпләгән университетын чолгап алган. Россиядә студентлар чуалышы турында кайчан һәм кайда сөйләшенде? Аның вәкилләре кайсы шәһәрдә җыелды? Киңәшмәнең составы нинди иде?

Тынлык

Шушы көннәрдә бер доктор килде. Сахалинда эшләгән. Кичә бергә эбәт ашадык. Аның сүзләре белән әйтсәк, каторгадагы хатын-кыз һәртөрле женси эксплуатация объектына әверелә. Ул аннан уйнашчы булып чыга. Чыга алса, әлбәттә... Сез үзегез яраткан хатын-кызга шундый язмыш телисезмени?

Никонов (*йөзен каплап*). Бу дөньяны, мөгаен, алла түгел, шайтан яраткандыр.

Гангардт. Ихтимал. Мин үзем сезнең ул шайтаныгыз акрын эволюция нәтиҗәсендә кайчан да булса алла кебек үк фәрештәгә әверелер дип исәплим. Тик аңа бу эштә ярдәм итәргә генә кирәк...

Никонов. Сезгә мине җаным кирәкме?

Урыныннан тора. Бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә.

Гәүдәм кирәкмиме, ә? Бөтенесе шыгрым тулганмы инде? Гәүдәләр өчен урын юкмы? Җан аулау башландымы?

Стакандагыны кинәт кенә алып эчә. Урындыкка утыра.

Гангардт (*озак паузадан соң*). Сезгә беркем дә гап-гади хәбәрче ролен уйнарга тәкъдим итми. Безнең андый кешеләребез бар. Без сездән күбрәк нәрсә өмет итәбез.

Никонов. Нәрсә?

Гангардт. Студентлар түгәрәкләрендә сез икенче рольләрне уйныйсыз. Нигә дип беренче рольне алмаска ди әле? Моңа бар сыйфатларыгыз туры килә. Акыллы, укымышлы. Төрле караштагы кешеләр белән эшлекле, яхшы бәйләнешләр булдыра аласыз. Башлык булырга бөтен мөмкинлекләрегез бар. Аларны үстерергә генә кирәк. Сез — яшь — монысы да зур әһәмияткә ия. Ниһаять, сез дворян баласы түгел. Киресенчә, кара сөяк. Революцион хәрәкәт тенденциясен исәпкә алганда, бу деталь бер дә артык түгел. (*Көлемсерәп.*) Яшьләрне революция үзенең романтикасы белән дә тарта, шулай түгелме?! Андый романтика сездә кирәгеннән артык булачак.

Никонов (*Гангардтка карамыйча*). Мин сезне нишләптер аңламыйм.

Гангардт (*тынлыктан соң*). Мин сезгә хезмәттәшлек итүнең иң квалифакацияле, иң тәвәккәл һәм иң романтик төрен тәкъдим итәм. Безнең белән эшләүне һәм безнең мәнфәгатьләргә игътибарны яшерен оешмаларда иң актив төстә катнашып та алып барырга була. Иң зур сәнгать — ул нииндидер дәрәҗәдә җинаять дип танылган эшләрне ачу яки аларны үзең генә эшләү түгел, ә аларның инициаторы булуда да.

Никонов. Шундый уенда мин катнашырга тиешме?

Гангардт. Әйе-әйе, Никонов әфәнде! Әйе! (*Пышылдап.*) Без сезгә гомумроссия подпольеларында дәрәҗә яуларга, иң абруйлы члennар алдында шөһрәт казанырга ярдәм итәрбез...

Никонов (*көлә*). Акылдан шашкан сез, полковник! Артыграк бәяләдегез сез мине! Миннән талантлыраклар бар.

Гангардт. Без бу мәсьәләне ныклап уйлаштык. Талантлыраклар бар дисезме? Аларның юкка чыгуы мөмкин, Никонов әфәнде. (*Тынлык.*) Хәзер Россиядә политик фикер чуалышы хөкем сөрә. Таркау төркемчекләр. Һәр партиядә хыялый партияләр. Анархистлар, эсдек түгәрәкләре, террорчы малай-шалайлар, иске киемдәге пропагандистлар, тарала башлаган марксистик коткы. Һәм, үзегез белгәнчә, һәркайда үзара мөнәсәбәтләр буталчыклыгы. Лидерлар юк. Ә бу соңгысы дөрес агентура көчләрен оештыру өчен бик тә уңайлы. Иртәмесоңмы, мондый тайпылыш нык таралыр һәм менә шул чакта иярдә кем утырачагы бик мөһим! Тулаем революцион хәрәкәтнең нинди гомуми характер алачагын белү дә мөһим безгә.

Н и к о н о в. Иртәгәге көнгә әзерләнәсезмени инде? Ачыктан-ачык сөйләшәсез сез, полковник.

Г а н г а р д т. Гадәтем шундый. Башкаларның да шундый булуына исәп баглыйм.

Никонов тора.

*(Кискен.)* Утырыгыз!

Н и к о н о в. Кешене мәсхәрәли торган тәкъдимнәрегезне бик җиңел ясыйсыз. Сезгә андый хокукны кем бирде? Мәсхәрәләүгә хокукны дим!

Г а н г а р д т. Безнең башка чарабыз юк, Никонов. *(Өстәлгә бармаклары белән шакылдатып.)* Легаль булмаган нәрсәләр генә дә түгел. Типография — үзе генә дә бик житди нәрсә. Сезне Петербург университетыннан куганнар, җиңел котылгансыз. Әмма кайбер нәрсәләр хәзер генә ачыкланды. Патшаны үтерүгә юнәлтелгән эш белән бәйле нәрсәләр. Элеккеге иптәшләрегез кайда? Осипов, Ульянов дим? Асылдылармы? *(Тынлык.)* Ә кече Ульянов хакында берни дә әйтергә теләмисез... *(Елмаеп.)* Мин — уенчы, һәм сезнең белән бик зур уен уйнарга җыенам. Бүгенге беренче ставка — сезнең тормышыгыз. Һәм сезгә кадерле булган хатын-кыз тормышы. Кызганычка каршы, һөҗүм белән бәйле эшкә аның да катнашы бар.

Н и к о н о в. Минем җаным бәрабәренә үзегезгә карьера ясамакчы буласызмы?

Әкрен генә кузгала.

Г а н г а р д т *(револьвер чыгара)*. Монысы инде артык, Никонов. Анда, ишекнең теге ягында, кешеләр бар. Ә бу *(револьвер көпшәсе белән өстәлгә сугып.)* ...уенчык түгел.

Н и к о н о в *(чигенә)*. Нигә дип сез боларны нәкъ менә миңа тәкъдим итәсез?

Г а н г а р д т *(тынлыктан соң)*. Без сезнең хактагы барлык мәгълүматларны җентекләп өйрәндек.

Никонов бүлмәдә әрле-бирле йөренә, эчмәкче була. Кабалана-кабалана стаканга сала. Стакан ава, түгелә. Ул янадан сала, эчә.

Сез үзегезне кияүгә чыгучы карт кыз кебек тотасыз.

Н и к о н о в. Нәрсә?

Инбашы салынып төшә. Урындыкка капчык кебек ава.

Г а н г а р д т. Детальләрен соңыннан сөйләшербез. Инде яктырып килә.

Арыган кыяфәттә кульяулык белән битен сөртә. Ишеккә таба бара. Бусага төбендә туктап кала.

Попов тавы. Овсянникова йорты. Якындагы сишәмбедә кичке алтыда. Шуны истегездә тотыгыз, ставка сезнең тормышыгыз гына түгел.

Китә. Никонов урындыкта тирбәлеп утыра. Шешәне ала һәм ниндидер бер усаллык белән аны идәнгә атып бәрә. Кыйпылчыклар оча. Идәнгә тагын нидер ыргытыла.

Керосин лампасы сүнә. Һәм кинәт иртәнге әңгер-меңгердә, караңгыда диярлек, үкерү тавышы ишетелә. Бу үзенең җанын саткан дисез кеше үкерүе. Яктыра. Никонов идәндә ята. Йоклый. Лидия Звонарская керә.

З в о н а р с к а я. Паша! Паша!

Никонов. Нәрсә-ә?

Звонарская. Паша! Исерекме әллә син?

Никонов. Алдыйм мин! Төп башына утыртам мин ул кабахәтләрне! Ярык тагаракка утыртам!.. Бары тик синең хакка, аңладыңмы? Синең хакка!

Звонарская. Нәрсә лыгырдыйсың син? *(Чүмечтән аның битенә су агыза, сөлге белән сөртә.)* Уян дим!

Никонов. Син!..

Звонарская. Бөтен җирдә тентү, кулга алу бара. Зворыкинны, Перельштейнны, Сапроновны кулга алганнар. Фатирда, флигельдә икс туташ яши. Екатеринбург гимназиясе укучылары. Аларны да алдылар. Куркып синең янга йөгердем. Күңелем нидер сизенә.

Никонов. Эчәсем килә.

Звонарская. Я хода, бер дә болай исергәнең юк иде ләбаса синең! *(Аны торгыза.)* Әйдә, әйдә, урынга ят.

Ул иелә, револьверы төшә.

Никонов. Һаман шул тимерең белән йөрисеңме? Син берәр кешене... яки үзеңне үтерә алыр идеңме? Үтерә алыр идеңме?

Звонарская *(револьверын яшерә)*. Мин бары ирекле хәлдә генә яши алам.

Никонов. Ирекле... Ирек ул һәрвакыт упкын кырыенда.

Звонарская. Иң мөһиме, үз язмышыма кемдер түгел, ә үзем хуҗа буласым килә. Үзем! Ни булды сиңа?

Никонов. Әйе, исерек мин. *(Тора да кроватька таба бара.)* Исерек. Җаным да яна. Янып бетәчәк һәм тю-тю! Күккә очачак!

Звонарская. Ни сөйлисең?

Никонов *(карана)*. Стеналар... Мин бу стеналардан янымда син булганда гына курыкмыйм.

Звонарская. Ник алай дисең, кадерлем? Сиңа ни булды? Шәһәрдә тентүләр бара, ә мин синең янына йөгердем. Исеңдәме, без гел бергә булырга ант иттек ич.

Никонов. Россиядә һәрвакыт тентү бара!.. Ә минә җанымны тентесәләр, җанымны!.. Ярат әле мине. Үп мине. Үп!

3

Шау-шу, халык төркеме. Ачык калган ишектән зал, өстәл почмагы, кешеләр күренә. Кемдер фисгармониядә уйный. Кемдер самовар күтәреп бара. Көлеш, кычкырган тавышлар.

Мундирлы студент. Питерда прогресс диләр. Почта ведомствосында хатлар ачып укучы хезмәткәрләр күбәйгән икән.

Кыз. Ә мин Иванга хат яздым. Сагындым.

Гади киемле озын студент. Кем бу?

Кечкенә студент. Тегесеме, әллә монысымы?

Озын. Монысы.

Кечкенә. Людка Бааль. Акушерлар бүлегеннән. Генерал кызы.

Озын. Генерал кызы булса да, ярыйсы. Ә үзе ничегрәк соң, генерал түгелме?

Кечкенә. Аннан да хәтәррәк. Үтә дә холыксыз һәм үлеп гашыйк.

Озын. Кемгә?

Кечкенә. Үз-үзенә. Тагын революциягә гашыйк диләр.

Озын. Шундый ботлар беләнме?

Кечкенә. Булса соң? Бары тик чехоткалылар гына ясыймы әллә ул революцияне?

Залдан кемнендер тенор тавышы ишетелә:

О Казань, ты Казань многогранная,
За грехи наказал тебя бог!

Кемнендер меццосы:

Кибетка легкая летит
Родными, снежными полями,
Морозно, тьма кругом, все спит,
А снег грустит под тормозами.

Кемнендер тавышы: «Әфәнделәр! Әфәнделәр!» Никонов белән Звонарская керә. Алар каршысына Шелонов килә.

Шелонов. Нәстәгә бик сыраең сыттың, Паса? Махмырмыни? Нинди уйлар уйлысың... касык сөяге?
Никонов. Бәйләнмә әле.
Звонарская. Син һәрвакыт балкып кына йөрисеңме?
Шелонов. О-һо-һо!
Кайсыдыр бер елдамы. Ишеттегезме, Дида, Паша, ишеттегезме? Петербургта Менделеев ректорны лабораториядән куып чыгарган. Мәскәүдә унжиде кеше яраланган.
Шелонов. Шуңа синең гражданлык йөрәгең сыкрыймы?
Кайсыдыр бер елдамы. Синең белән сөйләшсәң!.. Син!..

Шелонов кул селти, борыла. Португалов күренә.

Португалов. Шелонов, тукта әле!

Читкә алып китә.

Син университет ачылу хөрмәтенә оештырылган тантаналы актка килеп зур хөрмәт күрсәттең. Кызык, беләсе иде, ни өчен?
Шелонов. Кит әле моннан!..
Португалов *(кулын аның иңбашына куеп)*. Тагын бер тапкыр сорыйм синнән. Студентлар советы бүгенге көн тәртипләренә протест йөзеннән байкот турында карар кабул итте. Аңлатып бирүегезне үтенәм, ни өчен син...
Шелонов. Тагын бер тапкыр кабатлап әйтәм, кит моннан! Шайтанына олак... үзеңнең судың белән! Инспектор белән, аның шымчылары гына җитмәгән, тагын икенче бер эчке инспекция тапканнар!
Португалов. Студентлар суды белән шаярмыйлар.
Шелонов. Мин үземә-үзем закон һәм бернинди дә өстән күзәтүче кирәкми миңа.
Португалов. Кем чакырды монда сине?
Шелонов *(тынлыктан соң)*. Никонов әфәндегездә авыр махмыр. Дәвалауга мохтаҗ. Рөхсәт итәсезме, бөек инквизитор әфәнде? Ха-ха-ха!

Кызып, бәхәсләшеп, залдан Бронский, Ульянов, Фадеев, Людмила Бааль, Звонарская чыгалар.

Бронский. Германиядә революцион көчеш өчен бөтен шартлар бар. Өстәвенә, катастрофасыз юл белән күчәргә. Эволюция белән! Эсдекларда — алтмыш газета. Үзгәрешләрне тою һәм аңлау бар халыкка да хас булырга тиеш. Алар шул халык белән эшли дә инде менә. Шул ук сәүдәгәрләр белән эшли.

Ульянов. Димәк, революцияне көчләп переворот мәгънәсендә ясыйлар булып чыга? Сәүдәгәр революционер булып өлгергәнне көтеп ятырга кирәк, димәк?

Бронский. Сез яшь әле, Ульянов. Артык яшь...

Ульянов. Әлбәттә, күпчелек үз интересын аңлагач, шулай ук аны канәгатьләндерү юлларын һәм чараларын төшенгәч, ана инде көчләп переворот ясап торырга да кирәкми.

Фадеев. Бир кирәген, Ульянов!

Ульянов *(кычкыруларга игътибар итмәстән)*. Әмма барлык ихтыяжларны тану һәм аңлау кинәт кенә килеп чыкмый. Моны көтеп тормаска да була!

Звонарская. Тел төбегезне аңламыйм.

Ульянов. Кызганыч прогрессчы сез, Бронский. Һәм сезнең революциягез дә революция түгел, ә шулерлык, буталыш кына.

Бронский. Минем революция — шулерлык, ә сезнеке нәрсә?

Ульянов. Белмим. Һич югында әкрен генә үсүен көтеп яту түгел. Әмма ләкин мажара тулы роман да түгел!

Португалов. Нәрсә соң? Күпләгән гади халыкның кырмыскаларча эшеме?

Ульянов. Үз юлымны белмим әле. Сайлыйм гына әле мин юлны.

Баал ь. Элек халыкка йөрү әйбәт тон булып атала иде, хәзер — марксизм.

Ульянов *(көлемсерәп)*. Әйбәт тон булып? Эш модадамыни?!.

Португалов. Эшләргә кирәк! Буш сафсата кормаска, ә эшләргә! Кешене буган чакта бердәнбер уй — буучыдан котылу.

Шелонов. Аннары нәрсә?

Португалов. Аннары... анысы соңыннан.

Шелонов. Әгәр кул күнегеп китсә? Һәм кемнендер муены ошамаса ничек?

Португалов. Син үз муеныңны гомуми муеннан өстенрәк куярга теләр идеңме әллә?

Шелонов. Димәк, шәхси муенлы кеше кисәге... Ха-ха!

Португалов *(ярсып)*. Безнең эш — юк итү! Тар-мар итү. Без — динамитка тоташкан бикфорд шнуры.

Ульянов. Сезнеңчә ничек: кешеләр революциядә үз алларына бернинди дә төгәл идеал куймаска тиешмени? Үзен шундый эшчәнлеккә багышларга карар кылган берәр идиотны табу мөмкин булыр микән соң?..

Шелонов. Сарыклар һәрвакыт җитәрлек.

Ульянов. Әгәр дә без шул сарыкларга охшасак һәм үз эшчәнлегебезнең максаты турында да, аны гамәлгә ашыру турында да уйланмасак... *(Португаловка.)* Андый эшчәнлек уйланмаган, инстинктив эшчәнлек ул. Минемчә, без барыбыз да кайдадыр шул дәрәҗәдә... Инстинкт дәрәҗәсендә җимерү, нәрсәгәдер каршы көрәшү турында бәхәсләшеп туймыйбыз, ә менә җимерелгәнне нәрсә белән алыштырырга соң? Бу бит тавык кетәклеге төзү генә түгел, әфәнделәр!

Фадеев. Хода кушып, башта җимерергә насыйп булсын иде әле. Аннары ни дә булса уйлап табар идек.

Шелонов. Ни дә булса, дисезме? Менә кайда икән чикләвек! Менә нәрсәне түземсезлек белән көтә икән кешелек дөньясы! Ни дә булса! Ә мин төкерәм синең «ни дә булса»ңа, кадерле туганкаем!

Ульянов. Күпләгән революцион программаларыбызның уңай өлешләре буталчыклыктан, томанлы булудан җәфа чигә. Безнең йомшак ягыбыз шунда.

Шелонов. Әгәр андый уңай өлеше булмаса, Ульянов? Андый нәрсәнең бөтенләй булмавы сәбәпле булмаса? Җәза эшләнгән — төрмә,

сөрген, каторгалар бар. Ә бүләк? Күкрәккә тагарга калай, чүпрәк тасмамы? Шул гынамы? Данте тәмугның тугыз катын җентекләп язган, ә оҗмах шагыйре кая? Фантазия җитмиме? Әгәр дә ул бөтенләй булмаса?

Б а а л ь. Ничек — булмаса...

Ш е л о н о в. Бу зур дөнья, бөтен җир шары тотташ минустан гына торса? Бөтен әкәмәте шул булса, ә? Ә плюс кайдадыр галәмдә булса?.. Кайдадыр, ниндидер этләр йолдызлыгында югалып калса? Кирәкмәс сөяк кебек, алла аны шунда ыргыткан булса? Анда аны кемдер башка берәү, бәлкем, шул ук этләр кимерсә, ә? Ә без — монда. Бөтен фаҗига да менә шунда. Хо-хо! Кәмите дә менә шунда. Кешелек яшәешенең трагикомедиясе!

У л ь я н о в. Әйе, фаҗига! Әмма төп мәгънәсе дә шунда: безнең бурыч — аннан чыгу юлын табу. Фаҗигале хәлдән чыгу юлын табу!

Никонов, Смелянский күренә.

С м е л я н с к и й. Әфәнделәр, игътибар сорыйм! Игътибар, әфәнделәр!

Шау-шу әкренләп басыла.

Б а а л ь *(кычкырып)*. Һәрвакыт бер үк базар!

С м е л я н с к и й. Базар да — эш. Бөтен Россия базарда кайнаша һәм юл сайлый. Эш турында сөйләшик, әфәнделәр! Бүген бирегә землячество вәкилләре килде. *(Никоновка.)* Бәлкем син әйтерсең?

Н и к о н о в *(кул селтәп)*. Юк, әйдә үзең...

С м е л я н с к и й. Билгеле булганча, Мәскәү университетында өченче курс студенты Синявский шушы көннәрдә инспектор Брызгаловның яңагына суккан. Чуалыш башланган. Итчеләрне һәм казакларны җибәргәннәр. Атлар белән таптатканнар. Унҗиде кеше гарипләнгән. Өчәү үтерелгән. Университет ябылган. Кулга алулар башланган. Петербургта да хәлләр шулай тәмамланган. Чуалышлар дулкыны хәзер, берсен дә калдырмыйча, барлык университетлардан узачак. Россия студентлары протестны үз тормышларының формасы итеп сайларга тиешләр. Без — студентларның ирегең тулысынча юкка чыгарган университет тәртипләренә каршы протестны! Һәм тулаем бөтен полиция режимына каршы протестны! Бу режим һавасын хәтта сабый да сулый! Ишлибез, әфәнделәр? *(Тынлык.)* Безгә, иптәшләр, шуны белдерергә кушылды; кичә студентлар судында... Казан университетында сходка турында карар чыгарылды. Безнең һәрберебез нинди генә караштa тормасын, теоретик яктан ничек кенә аерылмасын, бу — гомуми эш. Без мәскәүлеләрне һәм петербурглыларны якларга тиешбез. Ә бу яклау сизелерлек булсын өчен, аларның хатасын истә тотарга, алар эшли алмаганны эшләргә кирәк.

У л ь я н о в. Без бөтен университетны, барлык Казан студентларын күтәрергә тиеш. *(Көчлерәк тавыш белән.)* Әгәр бөтенесе дә күтәрелсә... Университетта тугыз йөз тугыз кеше. Һәрберсе үзенең билетын ташласа!..

Ш е л о н о в. Әгәр ташламаса?

У л ь я н о в. Нигә дип җыелдык соң без монда? Шундый фокуслар өчен генәме?

С м е л я н с к и й. Миңа калса, безнең һәркайсыбыз үз-үзенә революция тантанасы өчен тотыла торган капитал итеп карарга тиеш. *(Озаклап Шелоновка карап тора.)* Әллә сез риза түгелме?

Ш е л о н о в. Капитал итеп тотылыргамы?..

С м е л я н с к и й. Әйе, кирәк икән, тотылырга да. Ахыргача. *(Карашын башкаларга күчереп.)* Шуның белән тәмам, әфәнделәр. Иртәгә үк бу мәсьәләне землячестволар җыелышларында тикшерүгезне үтенәм. Ә бүген *(яңадан Шелоновка карый)* язмышны артык ярсытмыйк. Таралышыйк.

У л ь я н о в. Аерым детальләре, гомуми характеры, көне һәм сәгате соңрак әйтелер.

Барысы да таралыша.

Б а а л ь. Озатып куясыңмы мине, Ульянов?

Ш е л о н о в. Төркемгә бүленәләр, группага... Чиркәүләр, партияләр... Ә теләсә кайсы төркем — кеше дошманы ул.

Ф а д е е в *(Никоновка)*. Син кая барасың? Ашыкмый тор.

З в о н а р с к а я *(Никоновка)*. Мин сине урамда көтәрмен.

Б а а л ь. Ульянов!

У л ь я н о в. Миңа монда калырга кирәк әле.

Фадеев, Смелянский, Ульянов, Никонов һәм Португаловтан башкалар китәләр.

У л ь я н о в. Чынлап та... кем чакырды ул Шелоновны бирегә?

Ф а д е е в. Берәү дә чакырмады.

С м е л я н с к и й. Кызык.

П о р т у г а л о в. Сашка Бронский күптән провокатор дип атый инде аны.

Н и к о н о в *(караңгы чырай белән)*. Провокаторлар үз-үзләрен алай тотмый.

С м е л я н с к и й. Ярый, йөз илле кеше үз билетларын ташладылар да ди... Ә калганнары? Башкаларын ничек мәҗбүр итәргә соң?

П о р т у г а л о в. Провокатормы-түгелме — Шелонов ишеләргә бирелә урын булмаска тиеш!

Ф а д е е в. Бер тинтәк кенә бит соң ул! Үз акылы белән!

П о р т у г а л о в. Бигрәк кече күңелле кеше инде син. Тик шунысыннан куркам, синең ул кече күңеллелегең аркасында... Без еш кына, җитмешенче еллар революционерларының аяк астында җир йомшак булган, алар болытларда йөзгәннәр, сабын куыгыдай шартлаган бала-чага конспирациясе белән шөгыльләнгәннәр, дип уйлыйбыз. Ә без, әбез — бөтенләй башкалар янәсе... Үзебез исә шул ук хаталарны кабатлыйбыз. Әзерләнә торган сходка турында инде жандарм идарәсендә белмиләрдер дип кем гарантия бирә ала?

С м е л я н с к и й *(Фадеевка)*. Овсянниковага ни булган?

Ф а д е е в. Кәефе юк. Әмма аның авызыннан сүз чыкмаячак. Гангардт турында бер сүз дә әйтми. Миңа калса, аның өен...

С м е л я н с к и й. Алар арасында үз кешеләребезне булдырмасак, әлбәттә, без үзебезне хыянәтчеләрдән саклый алмабыз.

П о р т у г а л о в. Шелонов инспекторга Сембер землячествосы турында ычкындырган.

С м е л я н с к и й. Кит әле!..

Тынлык.

У л ь я н о в. Һәркем һәр кеше турында барысын да белә. Һәркем барысы белән дә турыдан-туры мөнәсәбәттә тора. Квартиралар уртак... Еш очрашабыз. Аларда очраклы кешеләр була. Хатлар саклана, һәм аларның шифры күпләргә билгеле... *(Никоновка.)* Син ник дәшмисең?

Н и к о н о в. Болай гына. Баш авырта.

Ульянов. Шелоновтан курыкмаска кирәк. Читләшкән ул. Бөтен кешедән читләшкән. Андыйлар була. Әмма очраклы кеше ул.

Португалов. Ә мин Шелоновны читләштерергә, аның белән танышуны гаепләргә тәкъдим итәм! Сходка университет белән чынлыкта кем идарә итүен күрсәтергә тиеш. Безме, әллә инспекцияме? Үз властебызны безгә инде хәзер үк күрсәтергә кирәк. Студентлар судын санга сукмаган очракта ни буласын һәркем белеп торсын. Ә Шелонов... Бөтенесенә дә төкерә ул! Шул исәптән, судка да!

Никонов. Белмим. Бик тә рәхимсез бу. Белмим.

Ульянов. Килешми. Әлбәттә, аның кебекләргә монда, мондый җыелышларда урын булмаска тиеш, тик тикшереп-нитеп тормастан, кинәт кенә...

Португалов. Әйе, кинәт кенә. Әйе, рәхимсез! Югыйсә без яши башламас борын ук үләчәкбез! Ә башка нинди сиздертерлек факт белән белгертәчәкбез без үзебез хакында!? Юкса без университетны күтәрә алмаячакбыз!

Никонов. Барлык студентларны күтәрү мөмкин эшме соң?

Ульянов. Барысын да күтәрергә кирәк. Тик менә нәрсә белән, ничек?

Португалов. Ничекме? Азрак булса да кеше табигатен белергә кирәк.

Никонов. Уртача кешеләр — күпчелек.

Португалов. Әйе. Аларда ялкын да уртача. Шулай да һәр төрле уртача кешене ирексездән протестка чакырырга була. Я аны пароксизмга төшәр дәрәҗәгә житкәнче ярсытырга, я анда уңышка ирешүгә ышаныч уятырга кирәк. Бер яктан, җәзасыз калу хисе, икенче яктан, тыңламаган өчен курку! Курку!

Никонов. Курку...

Португалов *(иптәшен кочаклап)*. Без бит аз, Паша! Һәм безне үтерәләр! Башкача эшли алмыйбыз без! Бронский дөрес әйтә. Шелонов — провакатор. Андыйларны гомумән юк итәләр.

Ульянов. Хыянәтче булуына инанган очракта. Тик шул очракмы соң бу?

Португалов. Без... күпмедер дәрәҗәдә дучар ителгән кешеләр, Ульянов. Абыегызны гына алыгыз, мәсәлән. Ул үзенең буынтык-аяклыларын өйрәнүдән баш тартты... Безнең үз мәнфәгатьләребез дә, эшләребез дә, хисләребез дә, чын күңелдән бирелгәнлегебез дә, мөлкәтебез дә, хәтта үз тормышыбыз да юк һәм булырга тиеш тә түгел. Без бу черек дөнья белән һәртөрле бәйләнешебезне өздек, һәм без анда яшәвебезне дәвам иттерәбез икән, бары тик аны ничек итеп дөресрәк җимерү өчен генә яшибез!

Ульянов. Җимерү генә аз.

Португалов. Җимерү — бу инде бик күп дигән сүз. Һәм моның өчен минем тормышым кирәк була икән — бирәм мин аны. Шундук бирәм. Тагын кемнеңдер — Шелоновныкымы, аныкымы, я мәсәлән, синекеме кирәк була икән — алам. Һич икеләнмичә алам.

Смелянский. Ул хаклы. Үз-үзебезгә катгый икән, без башкаларга да катгый булырга тиеш.

Никонов. Белмим.

Фадеев. Мин дә... белмим...

Ульянов. Яшерен түгәрәкләр өчен генә яраклы гадәттән тыш нәрсәләр телисеңме?.. Бирегә үзең дә сизмәстән принципларны чаралар белән алыштырып куюың ихтимал.

Португалов. Тикшереп торырга вакыт юк. Вакыт юк!

Смелянский *(дусларын кочаклап)*. Әйе, үзәкләштерелгән катгый оешма булдырырга кирәк безгә. Иң югары гаделлек хакына кайчак корбаннар бирергә дә туры килә, Ульянов!

Ульянов. Аны корбан итәргәме?

Смелянский. Хәтта бик күп. Күпләрне! Бәлкем, юлыбызның фаҗигасе дә нәкъ менә шундадыр, әмма туры килә! Башка чара юк!.. Лабиринт бу, ә чыгу юлы... Анысы, бәлкем, кайдадыр борылыш артындадыр!.. Кайдадыр шундадыр!

Ульянов. Борылыш артында дисезме? Без аның кайдалыгын фараз кылмаска, ә табарга тиеш! *(Португаловка.)* Мин Шелоновка бойкот белдерергә каршы. Үз-үзебезгә аяк чалу бу...

4

Жандарм идарәсенең яшерен очрашу квартиры. Бернича ишекле залда — штатский киемдәге Гангардт һәм Бронский.

Гангардт *(кәгазьләрне актарып)*. Молодец сез, Александр Евгеньевич. Алтыным сез! Чынлап та, революция һәм танцы эшләре остасы.

Бронский *(конверттан хезмәт хакы алып саный)*. Тик осталарга начар түлиләр сездә, Николай Иванович.

Гангардт. Дөрес, начар. Начар.

Бронский. Яз көне мин егерме тугыз кешегә исемлек бирдем. Ә хәзер? *(Кәгазьләр актарып һәм яңадан өстәлгә ыргытып.)* Йөздән артык биредә. Һәм шунысын әйтим, бу инде — эш. Өстәвенә җиңел эш тә түгел!

Гангардт. Анда, анда!.. *(Бармагы белән түшәмгә төртеп күрсәтә.)* Гафу итегез мин бүкәнне. Революциягә принципиаль рәвештә ышанмаган тинтәк маразматикларның оптимизмы Россиягә бик кыйммәткә төшәчәк. Бу революциянең инде җәмгыятьнең тотрыксыз өлешендә тирән тамырлар җибәрергә өлгерүен һәм ул тамырларны өстән генә тигезләп кисәргә түгел, ә чокып, казып алырга кирәклеген алар башларына да китермиләр. Я хода, тирән итеп сөрү өчен күп акча кирәклеген ул патриотларга аңлатуы ничек читен!

Бронский. Кызганычка каршы, миңа аннан гына бер җиңеллек тә килми.

Гангардт. Эшне шуңа кадәр җиткергәннәр ки, тикшерү мәгънәсендә Россия бөтенләй нуль! Петербургта, Мәскәүдә аз-маз бар да — шуның белән вәссәлам! *(Кул селти.)* Биредәге эшләрне кабул итәргә килдем... Күзәтү бүлеге тикшерү эшләренең элементарь таләпләренә дә җавап бирмәслек хәлдә. Яшерен агентура бөтенләй юк. Ә эшне орденнар таккан карт утын пүләне генерал-майор Житков тапшыра. Пенсиягә китмәкче... Идиотизмның иң югары ноктасы түгел диген инде — үзенә ышанып тапшырылган идарәдә барысы дә әйбәт дип уйлый. Менә ни өчен түли алмыйм мин сезгә хезмәтегез таләп иткән кадәр. Әмма түләячәкмен мин, түләячәкмен! Бөтенесе үзгәреп тора. Хезмәт хакыгызның әлегә бик кечкенә икәнен аңлыйм.

Бронский. Әгәр дә бөтен эш җимерелсә? Суы сыгылган лимонга күпме түлиләр?

Гангардт. Нинди чебен тешләде соң сезне бүген?

Бронский. Һәрвакыт, кулга алырлар, сөрерләр, судка бирерләр дип куркып яшисен... һәм ни хакына бит!?

Гангардт. Йөрәгегез сызлаганын аңлыйм, Александр Евгеньевич. Ышаныгыз, минеке дә сезнекеннән ким сызламый.

Бронский. Аз түләвеннән бигрәк мине шул фактның үзе ныграк мәсхәрәли! Хезмәтең шулай бик аз түләнгәч, үзеңне хөрмәт итү бик читен.

Гангардт. Уйлармын. Нәрсә эшләргә мөмкин икәнлеген уйлармын. Чәй эчмисезме?

Бронский. Рәхмәт.

Г а н г а р д т *(кәгазьләрне карап).* Бик яхшы! Бик тә асыл сыйфатлар күрсәтәсез сез. Үтә дә сак һәм нигезле шәхси фаразларыгызны фотография төгәллеге белән тапшырасыз. Хатын-кыз женесе дә шактый активлык күрсәтәме?

Б р о н с к и й. Әйе.

Г а н г а р д т. Нинди гүзәл кешеләр... Бааль Людмила Львовна. Әтисен белә идем мин аның. Үзе Кронштадт гимназиясен алтын медальгә тәмамлады, Петербургта югары хатын-кызлар курсында укыды... Сөйкемле кыз, шулай бит?

Б р о н с к и й. Минем искитәрдәйләрдән түгел.

Г а н г а р д т. Аңлыйм, теге ниерәк, пикантлы, җиңелчәрәкне яратасыз. Сез мине кайчак үз хисләрегезнең рыцарьлыгы белән шаккатырасыз.

Б р о н с к и й. Нәрсәне күздә тотасыз?

Г а н г а р д т. Звонарскаяның Никонов сөяркәсе булуына карамастан...

Б р о н с к и й. Ул мөнәсәбәтләрдә сезнең эшегез юк.

Г а н г а р д т. Нишләп? Никонов белән шөгыльләнү фикерен миңа сез бирдегез... Аның белән тигезләшергә, дөресрәге, аны үз дәрәҗәгезгә төшерергә теләвегездән түгел идеме икән бу?

Б р о н с к и й. Мин сезгә, полковник, кайбер темаларга кагылмаска киңәш итәр идем.

Г а н г а р д т *(тынлыктан соң).* Гафу итегез. Димәк, Никонов җыелышта активлык күрсәтмәде?

Б р о н с к и й. Соңгы атнада эчә ул.

Г а н г а р д т. Шәп түгел. Алай... Ә Ульянов ничегрәк? Мәгълүматлар азмы? Бөтен яклап характерлау өчен кайчак сезгә юмартлык житенкерәми.

Б р о н с к и й. Аның артында җәзаланган абыйсы күләгәсе тора. Өстәмә дан. Шул дан аны бик тиз үзеннән тәҗрибәлерәкләр белән тигезләп куйды. Әмма үзе дә каты чикләвек. Яшенә күрә генә түгел. Хәзер инде үзен дә шәхес итеп таныйлар.

Г а н г а р д т. Мине студентлар судының исемлеге кызыксындыра. Ачыкларга тырышыгыз. Португалов Шелоновны суд исеменнән кысты, дисезме?

Б р о н с к и й. Бу әле берни сөйләми. Мин үзем дә кемнедер суд исеменнән дер селкеттем. Бөтенесе шуның белән авыз чайкый. Ә менә аңа кемнәр кирә, анысы караңгы.

Г а н г а р д т. Кешенең костюмы гына түгел, эчке киеме дә бар. Ә ул киемдә төрле таплар була. Таплар да кирәк, Александр Евгеньевич. Хәтта чүп кирәк! Әйтик, ниндидер чәч кисәге. Кем кем белән? Кем кемне ярата, кемне яратмый? Кем саран, ә кем ялагайлануга эреп китә?

Б р о н с к и й. Аңлыйм.

Г а н г а р д т. Капшагыз. Барысын да капшагыз. Ульяновны да. Смелянскийны да. Никоновны да. Ул күгәрченкәйләр минем алда утырганда, мин алар турында үзләре белмәгәнне дә белергә тиеш.

Б р о н с к и й. Ә үзегез турында мәгълүматлар җыймыйсызмы сез, Николай Иванович?

Г а н г а р д т. Үзем турында? *(Шаркылдап көлә.)* Гафу итегез, шельма сез! *(Тынлык.)* Хәер, бер тапкыр мин төш күрдем. Үтә дә төгәллекне сакласак, күптән түгел күрдем. Тиргә батып уяндым. Төшемдә мин, имеш, икегә ярылдым, һәм шул ике ярты бер-берсен әзәрлекли башлады. Бер ярты икенчесеннән сорау ала башлагач, уянып киттем. Җитмәсә, иң ерткычларча ала сорауны. *(Онытылып, Бронскийга шаккан күзләре белән үтәли карап тора.)* Еш кына миңа... мин үземне башка берәүдән эзлимдер кебек тоела... Тик һич кенә дә тота алмыйм. Ә үзем тотарга да куркам. Куркам! Киек җәнлек белән аучы арасын-

дагы ниндидер мәңгелек ау... Әйе, тотарга да куркыныч... Әгәр тотканым мин булмаса? Ниндидер өрәк тотсам?..

Тынлык. Кинәт урыныннан тора, кулын суза.

Бүгенгә җитте, Бронский.

Бронский китә. Икенче ишектән хуҗа хатын Овсянникова чыга. Үкчәләренә кадәр төшкән халат, үзе чибәр, елмая.

Овсянникова. Ниһаять, бушадың. *(Гангардтның чәчләреннән сыйпый.)* Дәү үскән бала кебек син. Һаман шул... үзеңнең уенчыкларың белән уйнарга кирәк сиңа. Әйдә.

Гангардт. Арыйм мин, алтыным. Арыйм.

Овсянникова. Я, хода, бер генә тапкыр булса да минем янга гына килсәң икән син! Атап минем янга!

Гангардт. Атнаның бер көнен тулысынча диярлек идарәдә түгел, монда эшлим.

Овсянникова. Миңа бик аз, аз!

Гангардт. Хәзер миңа тагын бераү килә. Аннары синең белән уйнарбыз, шаярырбыз. Эш, Катенька. Без инде гөнаһсызлыгыбызны күптән югалттык, аны югалтырга тырышып йөрүчеләр дә бар бит. Әмма бер үк вакытта, үзең белгәнчә, азрак боргаланган да булалар. *(Сәгатенә карап.)* Алты тула икән инде.

Овсянникова. Син мине көнләмисең дә хәтта. Фадеев турында берни дә сорашмыйсың.

Гангардт. Ә нәрсә? Гыйшык-мыйшык өлгереп киләмени?

Овсянникова. Ошый ул миңа.

Гангардт *(аның яңагын чәбәкләп)*. Революционер әфәнде белән миңа хыянәт итмәгәндерсең дип уйлыйм, балакай.

Овсянникова. Аның белән минем арада тормышка ашмастай мөнәсәбәтләр генә.

Гангардт. Ышанам.

Овсянникова. Минем синең сөяркәң икәнемне ул белә. Без аның белән халык турында, киләчәк турында сөйләшәбез. Кичә ул миңа турыдан-туры үзләренә эшләргә тәкъдим ясады. Искитмәле минутлар булды.

Гангардт. Кызык! Барысы да агентура челтәре кора. Синең ул яңа дустыңны ниләр кызыксындыра соң?

Овсянникова. Шелонов синең белән турыдан-туры бәйләнештәме? Әллә югыйсә университет инспекторы белән элемтәдәме? Иң мөһиме — хәбәр ташып торучылар кем? Мин ачыкларга вәгъдә иттем.

Гангардт. Шәп!

Овсянникова. Минем уемча...

Гангардт. Бик шәп! Синең кебек матур маңгайлылар да уйларга тиеш. *(Аны үбә.)* Без синең белән тагын берәр гүзәлрәк нәрсә уйлап табарбыз әле.

Ишектә — ротмистр Мангушевский.

Мангушевский. Гафу итегез, полковник әфәнде. Ишек ачык иде.

Гангардт. Зарар юк, ротмистр. Катенька белән эш турында гына сөйләшә идек без. Тартынмагыз. Узыгыз.

Мангушевский. Түзмәдем, Николай Иванович. Кызыклы мәгълүматлар бар.

Гангардт. Мин — уенчы, Мангушевский. Һәм кайчак минем йөрәгем азарттан сикерә башлый. Катенька, ач мин. Үз ягыңда өстәл

әзерлә, зинһар. Ә без әлегә ротмистр белән эш турында сөйләшеп алырбыз.

Овсянникова чыга.

Мангушевский *(портфеленнән кәгазьләр чыгарып)*. Гектографта басылган листовка. Студентлар судының Шелоновка хөкем карары.

Гангардт *(листовканы алып укып)*. Кызык! Бик тә кызык! *(Ишек ача.)* Катенька!.. Әйт үзеннең яңа дустыңа, Шелонов мәсьәләсендә ялгышмагансың, ул — Гангардт агенты, диген. *(Мангушевскийга.)* Бронский ул малайны кыйнату өчен махсус әмәлләде. Өрәк итеп... Ярый соң, курка бирсеннәр куләгәдән. Хыялый куләгә үзенең кыяфәте белән һәрвакыт мәҗаралырак.

Мангушевский. Куләме белән дә зуррак.

Гангардт. Куләме белән дә! *(Яңадан текстны укый.)* Кызык. Зур вакыйгалар чоры якынлаша, ротмистр. Һәм ау вакыты да. Профессиональ ау вакыты!..



## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Казан уку округы попечителе Масленников кабинеты. Ике кеше — Масленников һәм университет инспекторы Потапов.

Масленников. Землячестволарда — студентларның өчтән ике өлеше! Устав белән тыелган землячестволарда!

Потапов. Юк, юк, Викентий Сидорович. Минемчә, полковник арттыра. Өчтән бер өлеше булуы мөмкин, әмма өчтән икесе...

Масленников. Гангардт...

Потапов. Минем үз күзәтүчеләрем дә бар, Викентий Сидорович. Күп кенә студентлар өчен землячество шартлы бер нәрсә генә ул. Көчләп кертү булмаса!.. Күпләр куркудан керә...

Масленников. Күгәрченкәем минем, бөтенесе дә сез уйлаганча гына җиңел түгел шул. Мин полковник карашын яклыйм. Землячестволар бу очракта яшерен оешмалар өчен ярымлегаль пәрдә булып хезмәт итәләр. Тикшерүләр күрсәткәнчә, бер землячествоның гади членнары, мәсәлән, башка группаларның составын белми. Ни дигән сүз бу? Кул бар, оештыру бар монда! Әмма иң мөһиме шунда, бу яшерен түгәрәкләр эчендә тагын да яшеренрәк ядро бар. Нәрсә ул мифик студентлар суды дигән сорау туа. Шелоновка чыгарылган хөкем карары — бу бит чакыру, каршы чыгу. Турыдан-туры һәм оятсызларча каршы чыгу! Көчне күрсәтү! Ә сез мине тынычландырмакчы буласыз. Без... куып чыгарылган студентлар буенча бөтен Россиядә беренче урында. Беренче урында! Ә сез мине тынычландырасыз. Ни өчен тынычландырасыз сез мине?

Потапов. Тынычландырмыйм мин сезне, Галиҗанәб. Мин һәрвакыт сезгә белдерә килдем...

Масленников. Әйе-е! Гафу итегез, нервлар какшаган.

Потапов. Сез нәрсә? Сез нәрсә?

Масленников. Гаепләмим мин сезне. Әмма кызганыч миңа, бик тә кызганыч!.. *(Йөрәк сыкравы белән.)* Россиянең иң өлкән университетларыннан берсе, һәм шунда ук тәрбияләнүче ике кеше — патшаны үтерүчеләр арасында! Оят! Ә хәзер?.. Университет файдалы

гражданнар тәрбияләү өчен оештырылган, ә без нәрсә күзәтәбез?.. Тәртипсезлек һәм чуалыш. Шуларны көчсез рәвештә күзәтеп торабыз... Һич кенә дә башыма сыймый.

Потапов. Тынычланыгыз, Викентий Сидорович.

Масленников. Россияне хәзерге уллары ни эшләтәләр, ә? Ни дә булса аңлыйсызмы сез? Ничек мәсхәрәлиләр бит аны, ә? Үз прокламацияләрендәниләр язалар бит, ә? Бу бит, гафу итегез, бөтенләй мәгънәсезлек!

Потапов. Соң, Викентий Сидорович, кайчак мәгънәсезрәк эш эшләвенә карап кына рус кешесе турында шулай уйларга ярамый инде. Безнең тормышта сүзнең бер әһәмияте дә юк. Кайбер минутларда, ул сүздән файдаланган вакытларда, гомергә дә башыбызга килмәгән нәрсәләр әйтеп ташлыйбыз икән, моның ни гаҗәбе бар? Сөйләгән юкбар сүзләребезне беркайчан тормышка ашырмаслыгыбызны һәм ашырырга уйламавыбызны да белә торып, ник сөйләмәскә ди андый сүзләрне? Ә безнең мәкальләребез? Тел йомшак ул, сөяксез. Телең белән тегермән тарт, әмма кулларыңа ирек бирмә!.. Бу акыллы мәкальләрдә, минемчә, үтә дә колачлы һәм нигезле тәҗрибәбез чагыла. Бездә буш сүздән чын эшкә кадәр, тел белән тегермән тартудан кул белән эшләүгә кадәр аерма гаять тә зур. Россия котырынып, сафсата сатар һәм тынычланыр.

Масленников. Белмим, белмим!

Потапов. Җиңел акыллылык — безнең милли сыйфатыбыз диләр, Викентий Сидорович. Безнең халык чынлап та хыялыйрак ул. Көнбатышта сай акыллылар безне, имеш, бөтенесен уйлап-нитеп тормыйча гына эшлиләр, бөтенесен шундук колачламакчылар дип лыгырдыйлар.

Масленников. Белмим, белмим... Мин үзем рус җирлеген яклаучылар ягында. Тик җиребез генә каты түгел хәзер... Танымыйм мин аны...

Потапов. Викентий Сидорович...

Масленников *(урыныннан тора)*. Ни әйтсәгез дә, авыру безнең Россия — анакаебыз! Авыру! Һәм Достоевский Федор Михайлович бик хаклы. Яңа кешеләрнең бу хыяллары һәм фантазияләре — алар барысы да шайтаннан артык берни дә түгел. Нәкъ менә авыру Россиянең эченнән чыккан һәм, евангелие шайтаннары кебек, дуңгызга әверелгән шайтаннар! Дуңгызга әверелгән ул хыялый үсмерләргә кыя башыннан ташланып, диңгезгә батып үлүдән башка чара юк. Һич арттырмыйча, юридик тел белән әйтсәк, моны без эшләргә тиеш!.. Без... үз кулларыбыз белән... үз балаларыбызны... төртеп төшерергә тиеш! Ә кайчак, беләсезме, нәрсә уйлыйм мин, ә бәлкем ул шайтаннар — без үзебездер, ә?!

Потапов. Сез ни сөйлисез, Викентий Сидорович?

Масленников. Әйе-әйе, үзебез! Без, инде берни турында да уйламаучы картлар — шайтаннар, ә?! Бик мөмкин... Бәлкем, алар да, без дә шайтаннардыр, ә! Шайтаннар бары тик шайтаннан гына туа ала бит... Димәк, без дә...

Ишектән түрә күренә.

Түрә. Студент Шелонов килде, галиҗанәбләре. Дөресрәге, китердек. Көчкә эзләп таптык.

Масленников *(йөзен чытып)*. Исе... килмиме?

Түрә. Юк. Аек.

Масленников. Монда кертегез. Гангардт күренмиме әле?

Түрә. Юк.

Масленников. Килү белән үк керсен.. Һәрвакыт соңгара ул адәмкәй.

Тура кабинетка Шелоновны алып керә. Тегесе кырынмаган, бөрешеп калган, ачулы.

Ш е л о н о в. Император университетының юридик факультетыннан дүртенче курс студенты Шелонов. Сезнең чакыруга килдем.

М а с л е н н и к о в *(ачык йөз белән)*. Узыгыз, Шелонов. Ялгышмасам, Константин Константинович бит әле? Утырыгыз. Инспектор әфәнде белән сез таныш инде, ә безнең беренче күрешүебез. Утырыгыз.

Ш е л о н о в. Рәхмәт.

М а с л е н н и к о в. Мин сезне берничә сорау бирер өчен чакырдым.

Гангардт керә.

Менә, полковник әфәнде дә килде.

Кул бирешү, баш ию, елмаюлар.

*(Гангардтка)*. Студент Шелонов. *(Шелоновка.)* Мин шуны белүегезне теләр идем: биредә — сезне һич кыерсытырга ирек куймаячак өлкән дусларыгыз.

Ш е л о н о в. Дусларым? Минем беркайчан дусларым булмады.

М а с л е н н и к о в. Әмма ләкин бу шулай. Һәм мин, Константин Константинович, эшгәмәбезнең эчкерсез булуын теләр идем... студентлар суды дип аталган нәрсәнең хөкеме билгелеме сезгә?

Ш е л о н о в. Әйе.

М а с л е н н и к о в. Сезгә ул хөкем карарын кем, кайчан һәм нинди формада белдерде? Карардагы жинаять итеп тагылган фактлар турында сез студентларның берәрсеннән сораштыгызмы?

Ш е л о н о в. Моны бүген миннән инспектор әфәнде төпченде инде. Өстәп әйтердәй нәрсәм юк.

М а с л е н н и к о в. Анысын беләм. Потапов әфәнде сезнең белән очрашу турында җентекләп сөйләде миңа. Кызганычка каршы, сез ышаныч күрсәтмәгәнсез. Берни дә сөйләмәгәнсез... Бәлкем кемнән дә булса куркасыздыр?

Ш е л о н о в. Кемнән?

Г а н г а р д т. Хөкем турында каян белдегез соң?

Ш е л о н о в. Шәһәрдә гектографта басылган листовкалар таралган. Укый беләм.

П о т а п о в. Мине менә нәрсә кызыксындыра, Шелонов: землячестволар турында беркайчан да әйткәнегез булмады. Миңа билгеле булганча, ярлы семберлеләр өчен җибәрелә торган суммадан пособие гомумән алганыгыз юк. Ә хөкем карарында исә, сез бу пособиене студентлар теләгенә каршы килеп алдыгыз, диелә. Иптәшләрегез күзлегеннән караганда, сезне гаепләрлек башка эшләрегезне дә хәтеремә төшерә алмыйм. Гектографта басылган листовкалардагы һәм иптәшләрегез ташлаган бердәнбер дөрес гаеп — ул да булса 5 ноябрьдә университетның ел саен үткәрелә торган тантаналы актында катнашуыгыз. *(Масленников белән Гангардтка караштыргалап.)* Житмәсә, сез ул тантанага бик каты әчеп килгән идегез. Шуның өчен миннән шелтә әләкте.

Ш е л о н о в. Шелтә, хөкем — бар җирдә бер үк нәрсәләр.

П о т а п о в. Хөкем ителүегезнең төп сәбәбе нидә дип уйлыйсыз соң?

М а с л е н н и к о в. Чынлап та, ник хөкем иткәннәр сезне?

Ш е л о н о в. Белмим.

М а с л е н н и к о в. Ничек инде белмисең, Шелонов?

Г а н г а р д т. Сезнең мөгаен, студентлар арасында берәр дошманыгыз бардыр?

Тынлык.

Бәлкем, сезне куарга хөкем иткән судның составы хакында берәр нәрсә әйтә алырсыз?

Шелонов. Мин берни дә белмим.

Гангардт. Чын күңелдән сөйләшергә теләмисез. Сез бит элегрәк үзегез үк землячествога кергәнсез.

Шелонов. Үзләрен судьялар дип атаган студентларның фамилияләрен дә, землячествоның составын да белмим. Белергә теләмим дә! *(Кызып китеп.)* Төкерәм мин барысына! Һәм бөтенесенә!

Гангардт *(Тынлыктан соң.)* Бездә, мәсәлән, Сембер-Самара землячествосының иң даһи члены — Португалов дигән мәгълүматлар бар. Хөкем карары чыгаручыларның берсе шул дип шикләнергә мөмкин түгелме?

Шелонов. Төкерәм мин ул кәгазьләрнең барысына да!

Гангардт. Ә Смелянский турында ни әйтә аласыз?

Шелонов. Бик күпләр кебек үк кеше.

Урыныннан тора, ишеккә табарак китә.

Кешеләрнең эреп юкка чыгучылары була. Бер ишләре бөтен жирдә дә эриләр. Икенче берәүләр аерым бер сыеклыкта гына эри. Эремәүчеләр дә була. Менә мин — беркайда да эреми торган кеше!

Масленников. Туктагыз! *(Аптырап).* Сез кая, Шелонов?

Потапов *(Шелонов янына килеп һәм аның кулыннан тотып).* Ярый, ярый, Шелонов. Барысы да җайланыр. Тыныч кына укуыгызны дәвам иттерегез.

Шелонов. Дәвам иттерергә? Мин — хөкем ителгән кеше. Миннән хәзер барысы да кача! Аңламыйсызмыни сез шуны?

Потапов. Рәнжеттермәбез.

Шелонов *(көлә.)* Су тәкъдим итәсезме? Үз суыгызны?.. Сезнең су да кирәкми миңа! Ул минем күңелне болгата... *(Бусага төбендә туктап.)* Мин, мөгаен, иртәрәк туганмындыр? Ә сез — кабәхәтләр! Барыгыз да кабәхәтләр сез!

Китә.

Масленников *(озакка сузылган тынлыктан соң, котырынып).* Дда! Мерзавец! Үзем үк хөкем итәр идем мин аны. *(Потаповка.)* Һич кичекмәстән куып чыгарыгыз!

Авыр тынлык.

Гангардт *(Эшлекле төстә).* Әфәнделәр, студентларның гомумшәһәр сходкасы иртәгә булачак. Сәгать уникедә. Тәртипсезлекләр дулкыны барлык югары уку йортларын колачлап алган. Безне дә читтә калдырмады ул.

Масленников. Шуның өчен чакырдым да инде мин сезне, Николай Иванович. Университетта кайбер чаралар күрделәр. Хәзер инспектор безгә әйтәчәк. Әмма безнең барлык тырышлыкларыбызны һәм көчләребезне берләштерергә кирәк. Гомуми эшләребезне билгеләргә кирәк.

Гангардт. Мәгълүматлар әлегә бик үк төгәл түгел. Әмма менә нindирәк картина төсмерләнә. Университетны гына түгел, рухани академия семинаристларын да, ветеринария институты студентларын да күтәрергә телиләр. Шелонов вакыйгасының моңа турыдан-туры бәйләнеше бар. Бу — тыңларга теләмәүчеләргә янау. Иртәгә бөтен илгә ишетелерлек зур вакыйга куптарырга җыеналар. Һәм вакыйгасы да ачыктан-ачык хөкүмәткә каршы юнәлдереләчәк!

Масленников *(тәрәзә янына килеп)*. Мәгънәсез идеяләр белән агуланган авыру кешеләр! Алланы оныткан авыру дөнья!.. Я хода, ярлыка безне! Коткар бу җирне!

2

Шәһәр бакчасы рәшәткәсе. Людмила Бааль белән Бронский.

Бааль *(читкә карап)*. Ульянов! Володя!.. Ишетми. Сез кычкырыгыз әле, Саша.
Бронский. Ульянов!
Бааль. Ишетте.
Бронский. Тамагым карлыга лабаса, Людочка.

Ульянов керә.

Бааль. Нишләп ялгызыгыз гына каңгырып йөрисез?
Ульянов. Болай гына.
Бааль. Кыз белән очрашырга сөйләштегезме әллә? Берәр гимназистканы көтәсезме? Комачауладыкмы сезгә?
Ульянов. Юк-юк.
Бронский. Без сезгә дип бара идек, Ульянов. Людмила Львовнаның сезне күрәсе килде, ә мин — чибәр туташлар теләгенең колы.
Бааль. Саф һава сулап йөрисезме?
Ульянов. Әйе. Болай яхшырак уйлана. Һәрвакыт кем белән булса да бәхәсләшәсең. Йөренгәндә яхшырак әйткәләшәсең.
Бронский. Нәрсә турында бәхәсләшәсез инде, Ульянов?
Ульянов. Күп нәрсәләр турында.
Бааль. Кем белән?
Ульянов *(бераздан)*. Абыем белән.
Бааль *(тавышы үзгәрә)*. Абыегыз белән?! Гаҗәп... Нәрсә турында? *(Кинәт елый башлый.)*
Ульянов. Ни булды сезгә?
Бааль. Мин сезгә соңыннан аңлатырмын.. Инде җир йөзендә юк абыегыз белән ни турында бәхәсләшәсез сез? Аның белән бәхәсләшергә мөмкинме соң? Аның хаклыгы, аның чын-чынлап хаклыгы — аның үлемендә.
Ульянов *(озак тынлыктан соң)*. Ярый, калдырыйк бу хакта. Әйдәгез соң, киттекме? Өйдә кайнар чәй көтә.
Бронский. Бик рәхәтләнеп.
Бааль. Кирәкми. Монда гына йөрик. *(Елмаеп.)* Теләсә кайсы минутта тормышың стеналар белән чикләнергә мөмкин. Ә аннары мондый гүзәллекне еллар буе күрә алмавың бар.
Бронский *(көлемсерәп)*. Тик юморыгыз тупасрак, Людмила Львовна! Ә минем сезнең белән бәхәсне дәвам иттерәсем килә, Ульянов. Шуның өчен бара да идем. Хәтеремдә, сез уңай идеалга чыгу турында нидер сөйләдегез. Ул идеалны үзегез күз алдына китерәсезме?
Бааль. Саша!
Бронский. Лидочка, томаламагыз минем авызымны.
Бааль. Син үтә дә кызыксынучан кеше, андый вакытларда еш кына сөйкемсез дә буласың. Аннары мин...
Ульянов. Юк ла. Гадәти генә сөйләшү, Людмила Львовна. *(Бронскийга.)* Минем карашым шундый: кеше хәзер алып бара торган көрәш — кешелекнең иске язмышына каршы көрәш ул. Яңа язмыш өчен көрәш. Әмма без җавап табарга тиешле төп сорау — иске язмыштан чыгу юлы бармы? Аның лабиринтында кеше инде күптән чәбәләнә. Һәм икенче сорау — кайда ул чыгу юлы? Хәзер Россиядә булган револю-

цион программаларда, анархизм агымымы ул, әллә халыкка төрлечә йөрүләрме, мин яңа дөньяга чыгу юлын күрмим. Димәк, аны каяндыр башка җирдән эзләргә кирәк.

Б а а л ь. Сез нигилист, Ульянов. Элеккеләрнең барысын да кире кагаргамы!.. Абыегыз белән дә шул хакта бәхәсләшәсезме әллә? Үз карашлары өчен ул каны белән түләде.

Ульянов дәшми.

Яшьлегегез белән генә шулай сөйлисез сез. Яшь вакытта бар кеше дә тәвәккәл.

Б р о н с к и й. Төкерәбез без карт буынга! Кемдер безгә төкерәчәк. Тормыш шундый.

У л ь я н о в. Чыгу юлы тапсак, бераү дә төкермәс!

Б р о н с к и й. Сез хаклы, Людмила Львовна. Әгәр дә, кечкенә провокатор Шелонов әйткәнчә, ул бөтенләй булмаса? Чыгу юлы, дим?

У л ь я н о в. Сезнең өчен бу көлке мәсьәләме?

Б р о н с к и й. Кырыс кеше сез, Ульянов... Нәрсәгә ишарәләвегезне аңлыйм мин. Ярый, димәк, Россиянең үзенә генә хас юлын инкарь итәсез? Бөтенесен дә бер тарак белән тарыйсыз? Ә минем карашымча, Европа эшчеләр партиясенең төп социалистик принциплары белән килешкән хәлдә дә, аның тактикасы белән килешмәскә мөмкин. Европа хәзер марксләша. Ә Россия һичкайчан марксләшмаячак. Безнең илнең хәле бөтенләй башка. Аның Көнбатыш Европадагы нинди дә булса ил белән бернинди уртаклыгы юк.

У л ь я н о в. Нәрсәдә соң аның хәленең башкалыгы?

Б р о н с к и й. Нәрсәдәме? Безнең Россиядә Көнбатышта гомумән, һәм аерым алганда Германиядә булган көрәш чараларының берсе дә юк. Пролетариат юк бездә. Матбугат иреге юк. Вәкаләтле җыелышлар юк. Капитал власте бездә яңа туып кына килә әле. Томана халык массасын барлык эшчеләрнең дисциплиналы союзында берләштерергә өмет итәргә хокук бирүче берни дә юк. Шуның өчен дә безгә бөтенләй башка революцион программа таләп итела. Өстәвенә ул Германия программасыннан Германиядәге социаль-политик шартлар Россиядәге шартлардан аерылган кебек үк аерылырга тиеш. Терроризм, мәсәлән, русларга гына хас күренеш. Көнбатыш җирендә мөмкин түгел ул. Безнең илебезнең бүгенгесе һәм киләчәге турында Германия күзлегеннән карау, Германия программасын рус күзлегеннән караган кебек үк мәгънәсезлек һәм мөмкин булмаган эш. Сезнең абыегыз юкка гына терроризм идеологы булмаган ләбаса!

У л ь я н о в. Гаҗәеп тиз үзгәрәсез сез, Бронский. Теге вакытта сез тыныч прогресс тактикасы яклы идегез, хәзер инде террорчыларга табынасыз. Өстәвенә... хәтерегез бик тә шәп! *(Коры гына.)* Логикагыз да ышандырырлык!

Б а а л ь. Һәрвакыт шулай төрле якка ташлана ул. Сөйләнергә генә булсын аңа.

У л ь я н о в *(кисәк кенә, сөйләшүнең кызыгын тапмыйча)*. Сөйләнергә икән, нәрсә хакында сөйләнәбез соң? Иң яхшысы һава торышы турындадыр инде?

Тынлык.

Б а а л ь. Нигә тынып калдың, Бронский? Революцион онанизм белән шөгыльләнергә өйрәндеңме? Медицина термины өчен гафу ит мине, Володя.

Бронский *(бераз каушап калгандай, таркаурак)*. Сөйләшеп тә булмый!.. Бер-берегнен карашын... ачыкларга кирәктер бит инде? *(Ульяновка.)* Нигә дип миңа алай карап торасыз?

Ульянов. Күзләрегез бигрәк чиста, Бронский.

Бронский. Алар ник чиста булмаска тиеш ди?

Баль. Чиста күз — чиста күңел билгесеме?

Бронский. Ярый, минем хакта сөйләшүне туктатыйк.

Бааль. Ай нинди тыйнак! Володя, аның бик тә шәп биегәнен беләсеңме? *(Бронскийга.)* Кил, үбим дә, юлыңда бул.

Бронский. Людмила Львовна сезгә гашыйк булды ахрысы, Ульянов.

Бааль. Мин аның өчен картрак инде. Саша. Чынлап та, бар юлыңда бул. Сүзем бар минем.

Бронский. Сез мине бик тә кызыксындырасыз, Ульянов. Башка вакытта бәхәсләшербез әле.

Ульянов *(ашыкмый гына)*. Бәлкем.

Бронский китә.

Бааль *(аның артыннан карап калып)*. Нигә аның белән сөйләшмәс булдыгыз?

Ульянов. Белмим.

Бааль. Кешеләргә тумыштан ук ышанып бетмисезме?.. Чынлап та кызыксындырасыз сез аны. Сезнең турыда сорашты. *(Тынлык.)* Беләсезме, мин сезне, Ульянов, кулыгызны кысар өчен һәм саубуллашырга дип эзләдем. Бәлкем гомерлеккәдер дә.

Ульянов. Саубуллашырга?

Бааль. Мине ераккарак, Себергә җибәрәләр. Профилактика максатындадыр, мөгаен. Өч сәгатьтән китәргә тиеш мин... Сез бәхәсләшкән абыегызны яраттым мин, Ульянов. Ул минем яратканымны белми дә калды... Ичмасам, бу хакта сез белегез. Нишләптер мин шулай телим.

Ульянов. Рәхмәт... Людмила Львовна, ышанычыгыз өчен рәхмәт.

Бааль. Алай ук тантаналы итеп эндәшмәсәгез дә ярый. Людмила гына диегез. Люда. Володя, сезнең берәр кешене яратканыгыз булмадымы? Янсә хәзер.

Ульянов. Юк. Юк әле.

Бааль. Абыегыз белән мин дә еш кына сөйләшә башлыйм. Сигезенче ноябрьдә аны үтергәннәренә ярты ел тулды. Төне буена елап чыктым, үземнең мәхәббәтемне аңлаттым, имеш. Саубуллашырга дип сезне эзләп йөрдем, сырганактай булып Бронский ябышты.

Ульянов. Әйе.

Бааль. Мин еш кына: нигә мине дә алмадылар икән дип уйлыйм. Саша белән... аның соңгы минутын бүлешер идем... Аның авыртуларын алыр идем, газапларын! Уйлап та тормыйча барыр идем!.. Яратырга ярамый безгә. Тормышыгызны революция белән бәйләргә уйлыйсыз икән, качыгыз сез ул әлмәктән. Ачык яра белән йөрергәме? Төшләремдә үземне асканнарын күргәлим. Аның белән бергә асканнарын!.. Уянып китәм дә — юк! Ярты ел мәет кебек йөрим инде! *(Елый.)*

Ульянов. Аны җәзалап үтергәннән соң... күп уйладым мин.

Бааль. Уйлый торган егет сез, Ульянов. Охшашмагансыз сез... Әмма нидер бар, бар. Әнә шуның өчен дә шундук сезгә тартылдым да инде мин. Бу дөньяда үзе исән чакта абыегызны һәрвакыт истә тотачак хатын-кыз барлыгын истән чыгармагыз. Хушыгыз, Володя! Иртәгә сходка. Бөтенесе чәлпәрәмә киләчәк. Тормыш бөтенләй үзгәрәчәк. Бөтенесенең асты өскә киләчәк. Барысы да башкача хәл ителәчәк. Абые-

гыз язмышын кабатлавыгызны теләмим мин. Башка язмыш телим мин сезгә! Дөресрәге, шундый ук язмыш, башка үлем телим. Башка үлем!

Түзә алмыйча, кинәт кенә борыла, ашыгып чыгып китә. Ульянов аның артыннан озаклап карап кала. Күзләрен сөртә. Кесәсеннән кулъяулык эзли, таба алмый, яңадан сөртә.

Ульянов. Чыгу юлы кирәк... Чыгу юлы!..

Акрын гына икенче якка китеп бара.

3

Эңгер-меңгер. Шәм.

Никонов кушеткада ята. Уң кулы белән Звонарскаяны кочаклаган. Йомшак кына итеп аның чәчләреннән сыйпый. Лидия Звонарская янәшәдәге урындыкта утыра. Никоновның өстендә таушалып беткән ак күлмәк. Лидия — кара күлмәктән.

Звонарская. Шул елны... Күңелдә шул кадәр уелып калган ул. Кышкы иртә иде. Институт яныннан Арча кыры буйлап хурлык арбасында бер политик тоткынны алып баралар. Аны атарга хөкем иткәннәр. Тыңлыйсыңмы?

Никонов. Әйе.

Звонарская. Кулларың йомшак синең!

Никонов (*тигез, тоныкс тавыш белән*). Әйе.

Звонарская аңа таба борыла. Иелеп үбә. Янадан турая.

Звонарская. Ә иренең салкын... Нишләп миңа соңгы вакытта гел балачагым искә төшә икән? Ә? Һәм нигәдер эчем поша. Нидер сизенәмдер кебек!

Никонов. Берни дә юк ла. Тормыш шундый.

Звонарская. Әмма иң тетрәндергече авылда, каникул вакытында, табигать фәннәре өйрәнүче бер студент белән очрашкач булды. Миңа ул вакытта унбиш яшь иде инде. (*Көлә.*) Ул минем барлык институт тәрбияләремне эттән алып этка салып тәнкыйтьләде, ә үзенең җирнең төзелеше, кояш, йолдызлар турындагы сөйләүләре, ботаника өлкәсендәге, минерология өлкәсендәге белемнәре белән шаккатырып бетерде! Беренче мәхәббәтем булды ул минем!.. Менә шулай! (*Елмаеп.*) Ишетәсеңме син?

Никонов. Әйе.

Звонарская. Син иртәгеге көн дип борчыласыңмы соң? Сходка өченме?

Никонов. Юк. Белмим.

Звонарская. Соңгы көннәрдә сәерләнеп калдың. Яратмый башладыңмы әллә?

Никонов. Тагын да кадерлерәк син миңа... Чәчләрең йомшак. Сөйкемле син.

Звонарская. Беләсеңме, һич үкенмим... Беркайчан берни турында да үкенмәдем! Аның каравы эшкә бөтен җаннары-тәннәре белән бирелгән дусларны таптым! Сине таптым. Монысы да мәңгегә. Сез дә, туганнарыгызның эгоизмына да, үзегезнең мин-минлегегезгә дә карамастан, шул ук хисләрдән, шул ук уңайлыклардан баш тарттыгыз. Бу туганлык хәтта иң мөкатдәс мәхәббәттән дә югарырак!.. Шул чак мин үземнең кирәкле кеше, нәкъ менә бирегә, Россиядә кирәкле кеше икәнлегемне, үземне шуңа әзерләгән, бөтен күңелем белән тартылган

эшкә файдалы кеше булуымны аңладым... *(Кинәт нидер ишеткәндәй туктап кала, кисәк кенә Никоновка борыла, аңа иелә.)* Елыйсыңмы әллә?

Н и к о н о в. Тукта. Тукта!

Кисәк кенә урыныннан сикереп тора. Булмә буйлап әрле-бирле йөренә.

Шайтаныма олаксын! Барысы да шайтаныма олаксын! Булдыра алмыйм!

З в о н а р с к а я. Ни булды сиңа?

Н и к о н о в. Син боларны ни дип сөйлисең? Ә?

З в о н а р с к а я. Белмим.

Н и к о н о в. Юри сөйлисеңме?! Ышанмыйсың син миңа, шуңа сөйлисең!.. Дөрес эшлисең! Мин хәзер син сөйләгәннәрдән бик ерак торам.

З в о н а р с к а я. Ни булды сиңа, ә?

Н и к о н о в. Эшчәнлегем бетте, Лида. Мин.. беттем!.. Дүрт көн элек мин Гангардка сатылдым. *(Көлемсерәп.)* Миңа берни дә сөйләргә кирәкми инде. Куркыныч!

З в о н а р с к а я. Сафсата корасың дисәм...

Н и к о н о в. Чынлап булса нишләрсең?

З в о н а р с к а я. Үтерәчәкмен!.. Сине дә, үземне дә...

Н и к о н о в. Алайса хәзер үк үтерә аласың.

З в о н а р с к а я. Дөрес түгел!.. Дөрес түгел!..

Н и к о н о в. Дөрес. Ничек килеп чыкканын үзем дә белмим. Баштарак, аны ничек тә булса алдармын, төп башына утыртырмын дип уйлаган идем!.. Файда китерермен, ни дә булса белермен дип! *(Тынлык.)* Курыкма. Берегезне дә күңелсез эш белән шөгыльләнергә мәҗбүр итмәм. Исәп-хисапны үзем белән үзем өзәрмен.

З в о н а р с к а я. Утыр да сөйлә.

Н и к о н о в. Нәрсәсен сөйлисең инде аның? Сөйләр нәрсә юк. Син алар кулында, дип куркытты... Мин каршы килсәм ул сине... Аның кулында безнең патшаны үтерү турындагы беренче март эше белән бәйле мәгълүматлар бар. Шунлыктан шүрләп калдым... Кул куйдым. Икенче тапкыр бардым да кул куйдым!.. Акланмыйм. Күрәсең, җаным боламыграктыр.

З в о н а р с к а я. Ярый. Кем турында сорашты?

Н и к о н о в. Аны, барыннан да элек, студентлар суды составына кемнәр керүе кызыксындыра. Берни әйтмәдем.

З в о н а р с к а я. Тагын кем турында сорашты?

Н и к о н о в. Ульянов, Фадеев, тагын бик күпләр турында... Барлык университетларда бара торган хәзерге чуалышлар кайда, кайчан һәм кем тарафыннан хәл ителүе турында. Синең хакта сорашты. Валлаһи!

З в о н а р с к а я. Нәрсәләр сорады соң?

Н и к о н о в. Шайтаным белсенме аны? Бөтенесен дә киная белән генә сораша, туп-туры түгел. Мин берни дә әйтмәдем.

З в о н а р с к а я. Шулай да нәрсә турында сорашты соң ул?

Н и к о н о в. Син ышанмыйсыңмы әллә? Мин инде үз-үземә дә ышанмыйм.

З в о н а р с к а я. Нәрсә турында сорашты?

Н и к о н о в. Мин өч тапкыр очраштым, берни дә әйтмәдем. Ялгыш кына ычкындырсам инде. Юк, минемчә. Бүген пычак алдым. Аның яшерен квартиры бар. Попов тавында, Овсянникова йортында. Пычак тыгып бардым!.. Булдыра алмадым. Кеше бит. Аңлыйсыңмы, дошманын дошман, әмма кеше. Пычак белән кадый алмадым! Җаным боламык! Револьверым булса, бәлки... Пычак белән кадауга караганда ату җиңелрәк!.. Хәшәрәт ул. Лыгырдый да лыгырдый, янәсе минем гади генә провокатор булуымны теләми. Имеш, уен зуррак: берничә елга исәп-

ләнгән. Мине иң югарыга күтәрмәкче. Һөнәре — провокаторлар ясау! Хәтта ялагайлыкны да эшкә җигә. Үзе сораша да сораша!

Звонарская. Тагын нәрсә турында сорады?

Никонов. Сходка, безнең үзара мөнәсәбәтебез турында. Башка шәһәрләр белән элемтәләр, чит илләр белән бәйләнешләр. Португалов, Смелянский турында. Киңрәк карарга, курыкмаска кирәк, имеш. Минем кебек шәхескә нәрсәне дә булса белмәү — башка сыя торган эш түгел.

Звонарская. Я, син нәрсә дидең?

Никонов. Минме... Болай гына. Юньле берни дә әйтмәдем. Әмма очрашкан саен ул ныграк кыса бара. Кемдер сатылган аңа. Мөгаен, Шелоновтыр. Бик күпне белә. Кыса да кыса.

Звонарская. Ә син?

Никонов. Юк. Юк беркемне дә сатмадым. Мин берни дә әйтмәдем. Ник шулай текәлдең? Күземә кара әле!

Звонарская. Атна буе йөрәгем сыкраган иде.

Никонов борыла, йөренә, туктый.

Никонов. Ник шулай карыйсың?

Звонарская. Ничек карыйм соң мин сиңа?

Никонов. Бу хакта без икәү генә беләбез. Башка берәү дә белми. Берәү дә, аңладыңмы?

Яңадан түгәрәк ясап йөрени башлый.

Мин сатлык түгел. Кармакка эләктерде ул мине. Тентү вакытында эләктерде! Ә мин, хәсис, биреләдем! Тик мин сатлык җан түгел! Ышанасыңмы?

Звонарская *(озак дәшми торганнан соң)*. Ышанам. *(Бармаклары белән аның битен, күзен тотып карый.)* Ышанам... Күпме якыннарым төрмәдә утыра инде! Акылдан шаштылар, үз-үзләрен үтерделәр!.. Үтерелделәр!.. Я хода!..

Никонов. Әйтмәсәм дә була иде. Әмма хушлашмый булмый. Хушлашырга кирәк. Дөньяда бер генә кеше булса да белсен һәм гафу итсен. Бер генә җан булса да... гафу итсен!

Звонарская. Берәүне дә сатмадыңмы?

Никонов. Юк.

Звонарская. Яхшы. Сөйләвең әйбәт булды әле. Намусыбызның чиста булуы әйбәт.

Тынлык.

Никонов. Гафу ит мине.

Звонарская. Ни өчен?

Никонов. Синдә начар тәэсир калдырганмын икән, гафу ит. Мине гаепләвең ихтималын уйлавы да авыр иде. Хәзер, каберем янында торганда, миңа бар нәрсә бер ноктада — минем җанымда җыйналгандыр кебек тоела. Бу көннәрдә мин җирдәге барлык исәп-хисапларымны өзәчәкмен. Һәм шуны бел: яраттым мин сине, синең белән газапландым һәм синең хакка дога укыдым. Минем намусымның яклаучысы бул.

Звонарская револьверын чыгарып өстәлгә куя. Озаклап күзгә-күз карашып тору.

Юк!

Звонарская. Безнең беренче төнебезне хәтерлисеңме?

Никонов. Әйе.

Звонарская. Икебезнең тормышыбызны ни хакына бәйләдек соң без?.. Нәрсә дип ант эчтек без ул чакта?

Никонов *(тынлыктан соң)*. Язмышыбыз бер булыр дип... Дөнья бездән беркайчан да көчлерәк була алмас дип...

Звонарская. Безгә бер-беребезне яратырга да ярамыймы соң? Дөнья безне бер-беребездән тартып ала. Төрле төрмәләргә, сөргеннәргә ташлый. Берсен үле итеп калдыра, икенчесен — тере итеп. Без ул чакта шул хакта сөйләштек!.. Син минем ирем, абыем, улым. Биредә, жирдә, никахлашмаган да булыйк ди. Бәлкем без анда — күктә никахлашканбыздыр! Кайда икәнен генә белмим!

Никонов. Юк, юк, Лида!

Звонарская. Дәшмә.

Никонов. Хәзер иркенләп китәм мин. Бу көннәрдә мин үземне кешеләр исемлегеннән сызып ташлангандай хис иттем, ә хәзер тагын алар белән. Синең белән. Егетләр иртәгә сходкага барачаклар. Капкын иртәрәк ябылды. Кызганыч.

Звонарская. Ничек кенә нык яшеренмәсен, һәр подпольщикның уртача гомере кыска.

Никонов *(тынлыктан соң)*. Ни эшләргә тиеш булсам, шуны эшләдем. Булдыра алганны. Көчемнән килгәнне. Күп эшли алмадым алуын да... Нишләмәк кирәк...

Звонарская. Шәмнәрең тагын бармы синең?

Никонов. Берәү бар.

Звонарская. Яндыр. Булса, шәраб та ал. Бу төннең бәйрәм булуын телим.

Никонов. Хәзер син кайтып китәрсең... Үзем генә калам.

Звонарская. Минем дә башка чарам юк. Бу хакта билгеле булуга мине иртәгә үк кулга алачаклар... Патшага кул күтәрү уен эш түгел. Ә төрмә минем өчен түгел ул. Юкка гына мин револьверымны йөрәгем янына куеп йоклыйммыни? Минем азатлыгым — шунда. Һәм синдә.

Никонов. Син акылдан шашкансың!

Звонарская. Барыбыз да шашканнар без! Бөтен дөнья шашкан!

Никонов. Минем җаныма тагын бер гөнаһ өстисең.

Звонарская *(аны кочаклый)*. Безнең хакта төрле кабахәтлекләр сөйлиләр. Пычрак аталар. Алар революционерларның ничек яратышуларын, ничек үлүләрен белсеннәр.. Яндыр шәмнәреңне.

Никонов тагын бер шәм ала, яндыра. Өстәлгә бер шешә шәраб, ике рюмка куя. Шунда ук револьвер ята.

Кызык натюрморт... Христка, православиегә ышанмыйм. Әмма атеистка түгел мин. Ниндидер югары, серле һәм буй җитмәс нәрсә. Миңа әле тагын без үлемсезләрдер кебек тоела. Бу жиргә бик күп тапкырлар киләбездер кебек. Мөгаен, шулай булырдыр, без икенче тапкыр әйләнеп кайтканда бәлкем инде сугышларны, әшәкелекне, кан коешны күрмәбездер! Кеше, ниһаять, кеше булырдыр? Бу шәмнәр янып беткәч, күп нәрсәләр беләчәкбез без, бәләкәчем минем...

Никонов. Яратам мин сине. Яратам дип бик сирәк әйттем мин сиңа. Саранрак идем. Тик йөрәгем саран булганга түгел. Шуны белеп тор.

Звонарская. Кадерлем!.. Сөеклем!..

Шашкан бәхетле көлү белән хатын-кыз көлә, ир-егет көлә.

Никонов. Яратам мин сине! Яратам!

Звонарская. Кадерлем! Мәңгелек каным минем!

Эреп аккан шәмнәр сүнә. Кемдер керә, шырпы сыза. Моның Бронский икәнлеге күренә. Звонарская белән Никоновны күреп, аларга ташлана. Исе-акылы китеп күтәрелә. Алар, кочаклашкан хәлдә диярлек, янәшә яталар. Звонарскаяның читкә ташланган кулында — револьвер.

Бронский *(чигенеп)*. Лида! Лида!

Өстәлдә кечкенә генә кәгазь. Яңадан шырпы сызыла.

*(Укый.)*

«Безне бергә күмегез!..»

*(Кәгазь кулыннан төшеп китә.)*

Мин гаепле түгел! Гаепле түгел!

Шырпы сүнә. Караңгылыктан кешенең ачы итеп кычкырганы ишетелә.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Ишек шакыйлар.

Бик үк бай булмаган өй җиһазы. Икенче бүлмәгә чыга торган ишек. Шелонов бер яктан икенче якка тирбәлеп утыра, җырлый:

Син, Казан, әй, мескен Казан,
Гөнаһларың өчен алла каргаган,
Дөм сукыр да, шыр томана син,
Игелек тә, иман да калмаган,
Ахмак губернаторларыңнан
Чыкты бик күп сенатор.

Яңадан ишек шакыйлар.

Шелонов. Кемгә кирәк булды анда корчаңгы белән авыручы? Керегез.

Хуҗа хатын керә. Бу — сөйкемле йөзле, өлкән яшьләрдәге хатын.

Хуҗа хатын. Гафу итегез, Константин Константинович.
Шелонов. Ә-ә, сезмени? Нәрсә?
Хуҗа хатын. Гафу үтенәм...
Шелонов. Ярый инде, ни бар? Нәрсә кирәк?
Хуҗа хатын. Миңа бу атнада сеңелем килә, Константин Константинович. Ул һәрвакыт бирелә, флигельдә туктала.
Шелонов. Соң?
Хуҗа хатын. Башка квартир эзли алмассызмы икән?
Шелонов. Мин сезгә бер айга алдан түләп куйдым, ич.
Хуҗа хатын. Әлбәттә, әлбәттә! Мин... акчагызны кире кайтарырмын, Константин Константинович, һичшиксез, кайтарырмын.
Шелонов. Сеңелегез каян кайта соң?
Хуҗа хатын. Каян дисезме? *(Тынлык.)* Таганрогтан.
Шелонов. Еракта икән.
Хуҗа хатын. Әйе, еракта.
Шелонов. Димәк, квартирдан чыгып китәргә кирәк.... Танышлар, димәк, күз ата? Хөкем карарын үтәү сораламы?
Хуҗа хатын. Сез гафу итегез, Константин Константинович. Тик, беләсезме, бик тә уңайсыз. Шәһәрдә сөйлиләр бит. Ә минем әле квартирда торучы башка студентларым да бар. Кайтып төшүләре ихтимал.
Шелонов. Чыгып китәрмен. Тик китегез генә! Шайтаныма олагыгыз!

Хужа хатын. Гафу утенэм...

Китэ

Шелонов.

О дурак, ты дурак многогрешный,
За грехи наказал тебя бог!

Көзгегә килә, үз-үзенә карый.

Менә шулай, Шелонов энекәш, эреми торган элемент! Үзеңнең кеше икәнлегеңне син аларның берсенә бер исбат итә алмассың. Шулай ук чистарына да алмассың!.. Ярый, зарар юк! Югары белемсез дә яшәргә була. Университет тамугыннан башка да. *(Көлә.)* Һәркайда көтүләр, көтүләр... Дөньяда бары тик көтүләр генә!

Ишек ачыла. Смелянский, Фадеев, Португалов. Күпмедер вакыт бер сүзсез генә берберсенә карашып — өчәүләп бер кешегә, бер кеше өчәүгә карап басып торалар.

Шелонов *(башта кыюсызрак кына)*. Егетләр! Сезме? *(Шатланып.)* Сез! Ә мин... Белдем бит мин. Белдем!

Смелянский *(Португаловка)*. Ишекне яп. Өйалдын бикла.

Португалов чыга, янадан керә.

Шелонов. Белдем бит мин! *(Бүлмәдә әрле-бирле йөренә, урындыклар әзерли.)* Алай ярамый лабаса инде! Тикшерергә кирәк. Утырыгыз, утыр... Хәзер чәй әзерлим! Зубровкам да бар.

Португалов. Мәшәкатьләнмә.

Шелонов. Нәрсә? Аңламадым.

Смелянский. Мәшәкатьләнмә. Чәй эчәргә килмәдек. Зубровка да эчеп ятмабыз.

Шелонов. Зубровка эчмисез? *(Озак тынлыктан соң.)* Ах, әнә ничек икән... Өч палач, димәк? Азрак тоелдымыни? *(Фадеевка.)* Син дә, Алексей, алар беләнме?

Фадеев. Мин барысы белән. Ә син кем белән?

Шелонов. Я-я...

Португалов. Утыр!

Шелонов. Басып та торырмын.

Португалов *(кискен)*. Утыр, диләр сиңа!

Шелонов. Сез нәрсә?

Португалов. Нәрсәме? С...сатлык эт! Сорап торган була бит әле. Юк, син кабахәттән без үзебез сораячакбыз! Ә син җавап бирерсең!

Шелонов. Сезгә җавап биреп яттым ди, төкерәм! Хөкем карары гына азмыни? Ни өчен?

Смелянский. Дәлилләр һәм сәбәпләр булмый торып, оешма беркемне дә бернинди җинаятьтә дә гаепләмәячәк.

Шелонов. Кая соң сезнең дәлилләрегез?

Смелянский. Безнең Гангардтка якын даирәләрдә үз кешебез бар. Шулай булгач, кайбер нәрсәләр безгә тәгәл билгеле.

Португалов. Исерек баштан Бронскийга инспекторга йөрүең турында ычкындыруыңны оныттыңмы?

Шелонов. Мин сезнең ул Бронскиегызны! Ул бетне!.. Үтерәм хәшәрәтне!

Фадеев. Тыпырчынма!

Шелонов. Нәрсә?

Ф а д е е в. Тыпырчынма дим. Син беркемне дә үтермәссең.

С м е л я н с к и й. Инспектордан тыш тагын кемнәр янына бардың?

П о р т у г а л о в. Кемне саттың? Җавап бир! Аларга нәрсәләр билгеле — шуны әйт!

С м е л я н с к и й. Без барысын да белергә тиеш, җавап бир.

Ш е л о н о в. Шайтаныма олагыгыз барыгыз да!

С м е л я н с к и й. Попечительдә нәрсә турында сөйләштегез?

Ш е л о н о в. Оһо! Күзәтү оештырдыгызмы?

С м е л я н с к и й. Зур эш алдыннан максимум сизгерлек һәм саклык чаралары күрмәсәк, без шыр тинтәкләр булыр идек. Бигрәк тә инде үзен ничектер күрсәткән кешеләр мәсьәләсендә.

Ш е л о н о в. Кызык бу.

Ф а д е е в. Тыпырчынма, Костя. Үз башыңа кыланасың!

С м е л я н с к и й *(ачуын тыеп)*. Сиңа мөмкинлек тудырдылар, Шелонов. Шәһәрдән китә ала идең. Университеттан кудылар, әмма сиңа исән калу мөмкинлеге бирделәр. Курсташларың сине тагын бер кат кисәттеләр... Шулай да акылга утырмадыңмы? Һаман эшеңне дәвам иттердеңме? Шундук попечительгә йөгердеңме? Ә ул вакытта анда Гангардт, инспектор бар идеме?..

Ш е л о н о в. Беркая да йөгермәдем, көчләп алып бардылар мине.

П о р т у г а л о в. Син аларга тагын кем турында әләкләдең?

Ш е л о н о в. Мин аларга бер нәрсә дә әйтмәдем.

Португалов кизәнеп йодрыгы белән аның йөзенә суга. Аннары тагын берничә тапкыр каты итеп сугалар.

П о р т у г а л о в. Тагын кемне саттың? Әйт, әйт!

Ш е л о н о в. Ни эшлисез сез, егетләр? Акылдан шаштыгызмы әллә? Ни эшлисез?

Ф а д е е в. Егетләр түгел без сиңа, Костя.

С м е л я н с к и й. Шәһәрдә тентүләр, кулга алулар бара. Синең эшме? Бик күпләрне университеттан кудылар. Шулар исәбендә аны да *(Португаловка ишарәләп күрсәтә.)* Баальне Себергә җибәрәләр, ә башкаларны... Иртәгә булачак сходканы таркатмакчы буласыңмы?

Ф а д е е в. Сходка турында Гангардт нәрсә белә, Костя?

Киеренке тынлык. Бераү — өч кешегә, өчесе бер кешегә карый.

П о р т у г а л о в. Ярый, нишлибез әле без аның белән?..

Ф а д е е в *(күлмәк якасын ычкындырып)*. Без кайчандыр синең белән дуслар идек. Бер гимназиядә укыдык. Балалык елларыбыз бер урамда узды. Шуңа күрә миңа кыен... *(Тынлык.)* Киләчәк исеменнән, Костя... Киләчәк исеменнән революция суды сине җәзага хөкем итте! Кызганычка каршы, син үзеңне аклардай берни дә әйтә алмадың... Шпионлыгың өчен, Костя. Үз иптәшләреңне сатканың өчен. Провокаторлыгың өчен.

Ш е л о н о в *(гаҗәпкә калып, әле барысын да аңлап бетермичә)*. Сез нәрсә? Ахмаклык эшләргә ялландыгызмы?

С м е л я н с к и й. Ташласана, Шелонов! Уен бетте. Җитәр.

Ш е л о н о в. Уен? Сиңа уен, ә миңа?

П о р т у г а л о в. Ярты сәгать вакыт бирәбез. Үзеңә-үзең кул сал. Шулай яхшырак булыр. Әнә теге бүлмәдә элмәк бар, ә без монда көтеп торырбыз. Фокус күрсәтергә маташма.

Ф а д е е в. Үлемеңне, ичмасам, кирәгенчә каршыла, Костя. Ирләр кебек... Язу язып калдыр. Менә мондыйрак эчтәлектә... Мин, диген, бу кешелексез җәмгыятьтә яши алмыйм, диген. Ичмасам, үлемең киләчәккә хезмәт итсен.

Ш е л о н о в. Киләчәккә? *(Көлә.)* Кем хокук бирде сезгә минем тормышымны... тормышымны... Кем?

С м е л я н с к и й. Кем хокук биргәнне белмисеңмени әле? Ә безне ерткычларча җәзаларга кем хокук бирде соң? Меңләгән шпионнар һәм провокаторлар белән миллионлаган штыкларга шундый зур илне таптарга һәм изәргә кем хокук бирде. Байлыкларыбыз юк. Властебыз, полициябез, жандармнарыбыз да юк. Әмма бездә кеше шәхесенә һәм кеше хокукына карата чиксез хөрмәт бар! Син аларны үзеңнең әләкләрең белән пычраткан әнә шул хөрмәт, кеше хокуклары хакына хөкем итәбез без сине!

Ш е л о н о в. Хакыйкать сукыр була алмый! Сез бит сукырлар, сукырлар!

С м е л я н с к и й. Хакыйкать сукыр түгел. Үзенең дошманнары кайда икәнен ул белә. Одессадагы, Петербург, Харьков, Киев, Ростовтагы шпионнар нәкъ әнә шунын өчен җәзага хөкем ителде. Мондагы суд та шуның хакына эшләнә.

П о р т у г а л о в. Провокатор! Хәсис!

Ш е л о н о в. Мин провокатор түгел! Кабахәтләр! Я, бетерегез! Үтерегез!

С м е л я н с к и й. Мондый җәзаны синең кебек хәсисләр генә үтерү дип атый ала, Шелонов...

Ш е л о н о в. Намусыгызда... намусыгызда эреячәкмен мин сезнең.

С м е л я н с к и й. Сатлыкларның намусы юк. Без... Без ул иң югары халык намусының һәм хакыйкатенең башкаручылары!.. Иң югары, иң югары!..

Ш е л о н о в *(чыгырыннан чыгып)*. Үзем! Үзем! Тик үзем генә!

Икенче бүлмә ишеге бусагасында кинәт туктый, борыла, коелып төшкән, акылдан шашкан кыяфәттә бармак селки. Югала. Яңадан яный.

Кайчандыр Христны да шулай ук... Сине дә, мине дә! Барысын да!

Шашынып көлеп, икенче бүлмәгә кереп югала.

Ф а д е е в. Хуш, Костя... Гафу ит...

П о р т у г а л о в *(кулын аның җилкәсенә куеп)*. Этка эт үлеме. Ә иң югары суд? Иң югары суд безне аклаячак. Ә бәлкем аны да...

2

Император университетының тәмәке тарту бүлмәсе. Диван, берничә урындык, өстәл. Кешеләр үтеп-сүтеп йөри торган бүлмә. Халык күп. Коридор ишеге гел ачылып-ябылып тора. Тегендә дә, монда да — кешеләр төркеме. Үз сүзләре, үз бәхәсләре, үз инанулары. Әле кызып бәхәсләшкән, әле тынып калган, төрле хәбәрләр, киеренке көтү белән яшәүче, теләсә нинди корбаннарга әзер торган бу төркемнәр арасында — Ульянов. Ул да нык дулкынланган, киеренке, һәр нәрсәгә игътибар белән карый. Шаушу. Бәхәс, кычкырыш.

К е м д е р *(исерек, кечкенә)*. Кая алып килделәр мине ул кабахәтләр?

Т а в ы ш л а р. — Йокла, шадра. Уятырбыз!
— Вакыт бик акрын уза, җирәбә кайчан була соң?
— Ә теге... Бронский килмәде! Өендә качып ята, авыру булып кылана.

У л ь я н о в. Хәзер кризис. Иске формалар юкка чыга. Яңалары туа. Формалар яңарышы, идеяләр яңарышы. Иң мөһиме — эш ничек барыр? Түгәрәкләр ничек тупланыр? Нинди җирлектә?

С т у д е н т *(озын, гади киемдә)*. Мужик турында онытма, Ульянов! Рус мужигы турында. Әнә шуңа карарга кирәк. Чит ил кешесен коллык

инстинкты тәрбияләде. Кыләчәк матурлыкны аларның инстинктларыннан, аларның омтылышларыннан эзләргәме әллә? Сыя алмаячакбыз без анда. Тончыгачакбыз.

Мундирлы студент. Инстиктларны берәү дә күчерергә җыенмый.

Озын. Ә тамыры белән йолкып алырга теләмисеңме соң? Әнә — исерек хәшәрәт! *(Диванда селкенеп утырган кечкенә студентка бармагы белән төртеп күрсәтеп.)* Чырае — котсыз. Ә котсыз чырайда мәңгелек идеал яшеренгән. Мең еллык тарих. Кая куймакчы буласың син аны?

Мундирлы студент. Шул котсызнымы?

Озын. Әйе! Чистартырга кирәк аны. Пычрактан чистартырга кирәк. Һәм чистартачакбыз да!

Ульянов. Сез, анархистлар, халык идеалларының кагылгысызлыгын да сакларга һәм бер үк вакытта барысын үзгәртергә дә телисез. Безнең мескен рус халкын тумыштан ук ахмакка исәплисез сез. *(Көлә.)* Ул акылга таманрак, сезне бу каршылыкларыгызда тотмас дип уйлыйсызмы әллә?

Озын. Ә-ә!.. Шома дөнья кайда соң?

Кемдер *(диванда тирбәлеп)*. Кеше, сыра китер! Сыра бир, кеше!

Тавышлар: — Тондыр борынына, Ефим!

— Тик ахырын чамала, карачкы!

Шау-шу, бәхәсләр. Яңа бер төркем, аның белән Смелянский, Фадеев, Португалов килеп керәләр.

Озын *(Португаловны күреп)*. Кудылар үзеңне, ә син берни булмагандай йөрисең.

Португалов. Кичә кудылар, иртәгә чыгарырлар. Синең белән бергә, ә?

Мундирлы студент *(Ульяновка)*. Сугышны кешеләргә каршы түгел, ә принципларга каршы ачарга кирәк! Сугыш — талау, үтерү ул. Аңа башка сыйфатны без бирми кем бирсен? Ни өчен соң без үзебезнең дошманнарыбызда да ихтимал дусларыбызны күрмибез? Шундый һәр дусның тормышы кадерле бит безгә.

Ульянов. Бүгенге дошманнарыбызның тормышы да кадерлеме? Сезне үк үтерүчеләрнекеме? Гафу итегез, сезнең бу акыл гимнастикагыз Иуда шөгыле.

Смелянский *(урындыкка басып)*. Әфәнделәр, игътибар! Җирәбә, әфәнделәр!

Урындыктан төшә, үзен урап алган төркемдә югалып кала. Барысының да кулы аңа сузыла. Һәм инде шуннан, куллар астыннан, аның тавышы ишетелә.

Бәхетле билет кемгә? Билетлар бүректә, әфәнделәр. Кем бушны ала, инспекторга шул суга.

Җирәбә салу бара. Ишек ачыла. Анда — педель, университет инспекциясе хезмәткәре.

Педель. Таралыгыз, әфәнделәр! Таралуыгызны сорыйм!

Исерек студент *(диванда тирбәлеп)*. Кая алып килдегез? Бу бит... сыраханә түгел!

Озын *(педель янына килеп)*. Вон, хәсис шпион! Вон! Тагын бер генә сүз әйтсәң дә изамәңне изәм. *(Авыр ишекне көч белән каты итеп яба.)* Җимерегез-ватыгыз бөтенесен дә, егетләр! Бүген — безнең көн!

Мундирлы студент. Ә пуля аласың килмиме?

Озын. Пуля? Минем дә револьвер кисәгем бар!

Мундирлы студент. Ишегалдында бер батальон солдат

Икенче батальон попечитель йорты янында. Бар, шунда уйна үзеңнең пушка кисәгең белән!

Ф а д е е в. Карыйм әле!

Пәрдә чыгып китә. Төркем тарала, уртада — бераз аптыраштарак калган, елмайган студент Алексеев. Аның кулында — буш кәгазь.

А л е к с е е в. Яхшы, егетләр. Яхшы! Тондырырмын!

О з ы н. Оятка калдырма, якташ!

П о р т у г а л о в. Бүген Потапов йөзендә университет начальствосын никадәр ныграк туендырсаң, ватаныбызга шул кадәр файда китерерсең.

Көлеш. Янадан ишек ачыла. Бусагада — Потапов. Аның артында педель башы күренә.

П о т а п о в. Кичекмәстән дәресләрегезгә таралыгыз! Кисәтеп куям: аз гына тәртипсезлек булган очракта да, барлык катнашучылар...

О з ы н *(аны бүлдереп)*. Үзе үк телиме? *(Шатланып.)* Вакытыннан алда тели ул. Хәзер мин сине үзем үк, җирәбәсез дә...

П о т а п о в *(тавышны көчкә басып)*. Барлык катнашучылар куып чыгарылачак! Нинди генә чинда булуына да карамастан!

Португалов ыргыткан «буш шешә инспектор белән янәшә генә стенага бәрелеп ватыла, инспектор артка чигенә, ишек ябыла.

У л ь я н о в. Нервларыңны сакла, Португалов! Сходка өчен сакла! *(Смелянскийга.)* Никонов кая соң? Нишләп юк ул? Бронский да юк...

М у н д и р л ы  с т у д е н т. Мәгънәсез провокаторлык кына бит болар! *(Португаловка.)* Уголовный җинаять!

П о р т у г а л о в. Буш бугаз киерүче әфәнделәрнең тез буыннары калтырыймы? Сөйләнергә бик осталар, ә эшкә килгәндә — юкмы?

М у н д и р л ы  с т у д е н т. Телең кычытуын ике батальон бик тиз басар.

О з ы н. Баррикадалар оештырып, бөтен Ивановскаяны дер селкетергә иде бит, ә! Әйбәт погром булыр иде...

С т у д е н т *(диванда айнып китеп)*. Сыра! Бирегез әле кайсыгыз да булса... Сыра!

К а й с ы д ы р  б е р  е л д а м ы *(мундирлы студентка)*. Килешәм мин сезнең белән. Гаскәр чакыртылган, әфәнделәр. Аларга барысы да билгеле. Студентларның төп өлеше якламаячак. Семинаристлар баш тартты. Катгый төстә баш тарттылар! Ветеринарлар икеләнә. Мәгънәсезлек бу. Үз-үзеңә пычак салу!

О з ы н. Ялландыңмы, сатылдыңмы, кабахәт?

С м е л я н с к и й *(Озынны бәреп җибәреп)*. Әфәнделәр, әфәнделәр! Без теоретик яктан теләсә ничек аерыла алабыз, әмма практик эшчәнлек җирлегендә...

О з ы н *(Мундирлы студент белән Елдамга)*. Мескен әкрен кыймылдаучылар! Сез табынган революцион программаны төзүчеләр пешеп җитмәгән кешеләр булган алар!

М у н д и р л ы  с т у д е н т. Безнең программа...

У л ь я н о в *(Озынны туктатып, катгый)*. Бәхәсләшер чак түгел хәзер...

С м е л я н с к и й *(ике студентка)*. Сезнең группа сходкада катнаша икән, бетте дигән сүз. Юк, шайтаныма олагыгыз! Суны болгатырга ирек куймабыз. Юк!

М у н д и р л ы  с т у д е н т. Катнашырбыз катнашуын. Әмма мин үз белдерүемне ясаячакмын.

У л ь я н о в *(урындыкка баса)*. Сходка билгеләнгән тәртиптә барыр-

га тиеш, әфәнделәр! Землячество җыелышларында сөйләшенгәнчә! Инспекторның яңагына сукканнан соң...

Алексеев. Эшлим, егетләр! Эшлим!

Ульянов *(кычкырганга игътибар итмичә)*. Инспекторның яңагына сукканнан соң — гомумән рус тормышының, аерым алганда, студентлар тормышының чыдап булмаслыгы турында петицияләр. Монысы иң мөһиме. Политик таләпләр — иң мөһиме! Һәм нәтиҗә рәвешендә — студент билетларын өстәлгә! Университеттан чыгаруларын сораган гаризалар! Бу чын-чынлап политик чыгыш булырга тиеш! Шунысы мөһим: аңа беркем дә, беркем дә җинаять ярлыгы ташлый алмаслык булсын! Тик без бер организм булып эш итсәк кенә. Тик шул очракта гына...

Смелянский. Теләсә нинди башбаштаклыкны студентлар суды провокация дип бәяләячәк!

Ишекне ачып, Фадеев йөгереп керә.

Фадеев. География кабинетында... берничә кеше. Ишекне бикләгәннәр. Шунда уздырмакчылар. Кайсыгыз көчлерәк, әйдәгез!

Берничә студент Фадеев белән китә.

Смелянский *(алар артыннан)*. Беркемне дә чыгармагыз. Университеттан беркемне дә чыгармагыз!

Ульянов *(сәгатен чыгарып карый)*. Тагын берничә минут.

Төркемнәр, кызып-кызып сөйләшүләр. Киеренкелекнең иң соң дәрәҗәсе, алга ыргылыш алдыннан соңгы әзерлек.

Португалов. Нишләптер Никонов юк. Бәлкем кулга алганнардыр? Кичә бар иде. Лида белән калды. Аудиторияләргә барырга кирәк. Барысын да залга җыйнарга! Һәр кайсын!

Смелянский. Ветеринарлар килсен иде! Әгәр алар да якласа... Нервлар какшый башладымы? Калтырый ук башладым инде мин!

Кемдер ишеккә бара. Кинәт әче итеп кычкыру: «Безне бикләгәннәр!» Каушап калу. Буталыш. Катгый карарга килү. Ачу чыгу.

Тавышлар: — Ват! Бергәләп ат!
— Тагын! Ник чукынып китми шунда!

Ульянов. Тәрәзәдән! Әйдәгез, тәрәзәдән!

Бергә укмашкан, күп куллы, ачуы кабарган массаның ишеккә берьюлы сугуы. Ишек ярыла, ачыла, һәм төркем коридорга ташлана. «Сходкага! Сходкага!» Кычкырыш, шау-шу. Йөзләрчә кешенең аяк тавышы. Аудиторияләрдән коридорлардан, кабинетлардан ишетелә. Тавыш тоташ гөрләүгә кушылып, әле экренәя, әле тагын яңа дулкын булып килә. Анда — яшьлек көче, куәт...

3

Губерна жандарм идарәсе. Аяк тавышлары, сөйләшкән тавышлар ишетелә. Гангардт кашыгы белән стаканга бәргәли. Чәйле стакан Смелянский алдында да тора. Ул аңа кагылмый.

Гангардт. Компаниягезнең барлык дулкынланулары бетте, Сергей Вениаминович. Ә мине эш көтә, эш. Сезнеңчә ничек, безнең җилкәгә артык йөк, мәшәкать өйгән кешеләр белән нишләргә?

Мангушевский керә.

Мангушевский. Полковник әфәнде...

*Кәгазь суза.*

Гангардт. Яратам шундый исемлекләрне, ротмистр... Алып килделәрме инде?

Мангушевский. Анда билгеләнгән, кем...

Гангардт. Ә Бронский кая? Кая соң ул?

Мангушевский. Булдык. Өйдә туры килмәде.

Гангардт. Тагын җибәрегез. Бүген үк кулга алырга! Ульяновны күрмим, Португаловны...

Мангушевский. Кулга алырга киттеләр. Кешеләр житми, Николай Иванович.

Гангардт. Нәзәкатьләнеп тормасыннар. Зур ау төне. Мыштырдамаска! Менә күрәсезме, Смелянский әфәнде, кешеләр житми, үз проблемаларыбыз бар. Бөтенесе дә сез уйлаганча барып чыкса, нәрсә булыр иде, безне нинди хәлгә куйган булыр идегез, ә?

Смелянский. Булдыра алганны эшләдек. Юкка шатланасыз.

*Мангушевский чыга.*

Гангардт *(аның артыннан)*. Барысын да кулга алыгыз, ротмистр! Барысын да! Һәм кичекмәстән! *(Смелянскийга.)* Нидер әйттегез бугай сез?

Смелянский. Кешеләрнең телен Петербургта, Мәскәүдә, Киевта кисеп алдыгыз, инде хәзер Казанда кисәсезме? Әгәр дә алар Одессада, Женевада, Владимирда телгә килсә?

Гангардт. Инануларны хөрмәт итәм мин, Смелянский әфәнде. *(Көлә.)* Инанган кешеләр белән эшләве кызыграк. Әмма безнең эштә иң кызыктырган нәрсәнең ни икәнен беләсезме? Инануларны җимерү. Кешенең... аларга ихтыяҗын үтерү.

Смелянский. Тарих һәр кешегә нинди дә булса эш бирә. Барысын да җимерә алмассыз.

Гангардт. Эзләү техникасы һәм кешенең үз-үзен тотышына контрольлек итү техникасы үсә, кадерле Сергей Вениаминович.

Смелянский *(көлемсерәп)*. Революция кайчак мең башлы аждаһа булып күренмиме сезгә, полковник? Сез аның бер башын кисәсез, ә аның урынына икенчесе үсә. Шундук үсеп чыга! Аны үтерер өчен мохитның социаль шартларын үзгәртергә кирәк. Иҗтимагый тормышның барлык биналарын яңадан үзгәртеп корырга... Ягъни деспотизм дәүләте иң әлек үз-үзен үтерергә тиеш. Әлеге шартларда да эшебезнең үлмәслегенә инанганбыз икән, димәк, аны тиз генә юкка чыгарып булмаячак! Шулай булгач, эзләү һәм башка төрле техника... Кызганыч чаралар гына алар.

Гангардт. Фәлсәфи бәхәс, ә? *(Рәхәтләнеп көлә.)* Яратам. Мөкиббән китәм хәтта.

*Бусагада — Мангушевский.*

Мангушевский. Николай Иванович?

Гангардт. Нәрсә бар?

*Мангушевский Гангардт янына килә, колагына нидер пышылдый.*

Утырып торсын. Көтәр.

*Мангушевский китә.*

*(Смелянскийга.)* Яхшы! Мине ышандырдыгыз да дип фараз кылыйк. Мең башлы аждаhа... жиңә. Зур энергияле мең революционер Россиянең дүрт-биш төп пунктында барлык иң югары дәрәҗәдәге кешеләрне hәм төп начальникларны шушы минутта кулга төшерде ди. Гаскәрләр, политик инициативага күнекмәгән җәмгыять каршылык күрсәтә алмый ди... *(Көлемсерәп).* Әйтик, революция ясалды ди. Бер төркем кеше вакытлы властька менә. Декретлар игълан итеалә. Бәхет бик якын hәм мөмкин эш! *(Көлә.)* Ышаныгыз, кадерлем, әгәр дә мин шул төп революционерлар арасында булсам, андый переворот ясау минем өчен чиста профессиональ эш булыр иде. Әмма эш анда гынамы соң? *(Урыныннан тора, бүлмә буйлап йөренә.)* Яхшы, сез барлык хосусый hәм дәүләт милкен гомуми милеккә әвереелдерүче декрет та чыгардыгыз ди! Аларда сез халыкны гомуми файда өчен гомуми хезмәт куярга өндәдегез. Декрет чыгару алай бик якын эш түгел ул. Әмма аларны хәрәкәткә китерү! Император Иван Антоновичны империатрица Елизавета Петровна белән алыштыру турындагы указ гына түгел ул, атакаем. Мөлкәтне яклап мөлкәтлеләр генә күтәрелмәячәк. Кулаклар гына түгел! Крестьяннар социаль революциягә гомумән әзер булмаган хәлдә хосусый, хәрәкәттәге мөлкәтне иң ярлы хуҗалыклар да аяк терәп яклаячак. Диктаторлар төркеме hәм аларны яклаучылар барлык бу дошманнар алдында көчсез булып калачаклар. Тарих сезне мәсхәрә хәленә куярга мәҗбүр була. hәм... сытачаклар сезне! *(Ләззәтләнеп, кәефләнеп.)* Әмма моның алдыннан, трагифарсның соңгы пәрдәсе алдыннан сез бер-берегезне үзегез үк сытып бетерәчәксез. Чөнки өстенлеккә ирешү өчен котылгысыз рәвештә көрәш башланачак. hәм комизмның иң югары ноктасы да әнә шунда!

Смелянский. Моңа гомуми мәнфәгать ирек куймас.

Гангардт. Юк, әйтеп бетерергә рөхсәт итегез, рөхсәт итегез! Мин сулга кирәк дип ышанырмын, ә сез, уңга диярсез... Менә сиңа сугыш! Гомуми мәнфәгать хакына. Өстәвенә фарс рәвешендә. Фарс. Трагедия фонында! *(Смелянскийга сүз әйтергә ирек куймыйча, пышылдап, гайрәт белән, кызып.)* Сез хаклы — мең башлы аждаhа! Бер башын киссәң — икенчесе! Тагын киссәң — тагын. Ничек онытыгыз соң, сезнең алда да бит... Сезнең дошман да аждаhа! Башлары да hич тә ким түгел! Мөгаен, дөнья тарихының мәгънәсе дә шул бер-берсенә чорналган аждаhадыр! Аждаhалар никахы, аларның бергә берләшүедер! Яшәгән саен, алар куркынычрак, дәhшәтлерәк була баралар, ә? Ә киләчәктә тагын да хәтәррәк, ә? *(Көлә.)* Дөньяның яхшылык аждаhасы белән усаллык аждаhасы. Сезнеңчә, ха-ха... сезнеңчә, сезнең баш яхшылык аждаhасы башларына керәме? Мин дә бит үз аждаhам турында шулай уйлыйм. Нишләргә соң инде безгә? Ә? Нишләргә?

Смелянский. Акылдан шашкан сез!

Гангардт *(аны бүлдереп).* Сез дә шашкан! Сез дә! Ә бәлкем ике аждаhа түгелдер, ә берәү генәдер? Бәлкем без бер аждаhага хезмәт итәбездер? Күп башлы аждаhага? Күп куллы аждаhага? Ха-ха... Кемнең башы кайда икәнен дә белмәссең. Иң яхшысы берсенә генә хезмәт итүдер! Шулай әйбәтрәктер! Ә? Килешәсезме?

Смелянский. Нәрсә? Нәрсәгә?

Гангардт. Нәрсәгә? Ха-ха-ха... Шелонов асылынды, ә аждаhага башкасы кирәк. Бүтән бер баш кирәк! Шулай түгелме әллә? Ә бәлкем, күгәрченкәем, алмашка үз башыгызны тәкъдим итү нияте белән сез аскандырсыз аның башын? Ә?

Смелянский. Кабәхәт!

Гангардт. Дорфа сез, Смелянский. Селедка гына ашатырга, су бирмәскә кушам мин сезгә.

Смелянский *(тынлыктан соң, мыскыллы көлемсерәп, ачык итеп).* Берьюлы hәм бер мизгелдә... алла башыннан... бары тик Минев-

ра гына атылып чыга. Һәм без аңлыйбыз... социаль переворот ул... экономик, юридик, безнең барлык иҗтимагый... хосусый, гаилә мөнәсәбәтләребезне... барлык карашларыбызны һәм төшенчәләребезне... *(тавышын күтәреп)* барлык идеалларыбызны һәм әхлакыбызны үзгәртеп кору! Мин моны сез жандарм этенә әйтәм! *(Һәм инде үз-үзен тыя алмыйча.)* Юк, син генә юкка чыгара алмыйсың минем инануларымны, кабахәт! Син түгел!

Кулына кара савыты алып, урыныннан сикереп тора. Күнегелгән гадәт белән ниндидер бер секундта револьверын алып, Гангардт та сикереп тора. Өстәл белән генә аерылган ике кеше күпмедер вакыт бер-берсенә каршы басып торалар. Утыралар. Гангардтның стаканында кашык челтери.

Г а н г а р д т. Чәй эчмисезме, Сергей Вениаминович?

С м е л я н с к и й. Рәхмәт. *(Бераздан.)* Менә шул, мин әйтеп бетермәдем бугай. Гафу итегез...

Г а н г а р д т. Әйе-әйе.

С м е л я н с к и й. Сүзебезне дәвам иттереп, нәрсә әйтергә тиеш идем әле мин?.. Андый переворот бер көндә генә дә, ике елда гына да ясала алмый. Һәм без, социалист-революционерлар, бу мәсьәләдә беркайчан да үз-үзебезне алдамадык. Властьны кулга алабыз да, иртәгә үк җәмгыятьне бәхетле итәбез, дип беркайчан да буш хыял кормадык. Без, полковник, сез күрсәтергә тырышканча, доктринерлар да, утопистлар да түгел. Үз көчебезне бик яхшы аңлыйбыз. Ни булдыра алабыз да, ни эшләргә тиеш икәнлегебезне дә бик яхшы аңлыйбыз. Һәм хәтта сез безнең кайберләребезгә тозлы балык кына ашатып, эчәргә бирмәсәгез дә, без барысын да эшләрбез!

Г а н г а р д т *(ишек янына килеп)*. Алып китегез арестантны!

Ике жандарм, аннары Мангушевский керәләр.

Ж а н д а р м. Минем арттан барыгыз.

Г а н г а р д т. Карагыз әле, Смелянский. Шелонов мәсьәләсендә... бик нык хаталандыгыз бит.

С м е л я н с к и й. Нигә дип һаман саен шул Шелоновыгыз белән авыз чайкыйсыз әле?!

Г а н г а р д т. Бер хөрмәтле әдәбиятчы зур мәсьәлә белән шөгыльләнгән, Сергей Вениаминович... Оҗмахны гөнаһсыз күз яше белән юарга кирәклеге турындагы мәсьәлә белән. Корбаннар китерү кирәкме, әллә юкмы? *(Пышылдап, ләззәт белән.)* Гөнаһсыз күз яше белән... сугардыгыз...

С м е л я н с к и й *(агарынып һәм күлмәк якасын ычкындырып)*. Вөҗдан газабы... кайчак шпионнарны да тормыш белән исәп-хисапны өзәргә мәҗбүр итә. Әмма моның өчен бөтен җаваплылык... бөтен җаваплылык сезнең өстә! *(Түзә алмыйча.)* Кем аларның чын үтерүчеләре? Сез! Сез куып кертәсез кешене кире чыгалмаслык караңгы почмакка! Җәза белән куркытып, сез үтерәсез аларның җанын. Сез!

Г а н г а р д т. Ха-ха! *(Көлә.)* Шелонов... Шелонов. Сезгә серне ачарга рөхсәт итегез, ул... университет инспекциясенең дә, минә ышанып тапшырылган идарәнең дә шымчысы булмады!

С м е л я н с к и й *(авырлыктан сыгылып төшкәндәй)*. Алып китегез мине. *(Үз-үзен тыя алмыйча.)* Алдыйсың, кабахәт! Эт җан син!

Г а н г а р д т. Дорфа сез, Смелянский. Дорфа. Сездән сорау алган чакта мин дә дорфа булсам, гаеп итмәссез. Фәлсәфи әңгәмәләрдән тыш чаралар да бар! Селедка гына ашатып калмабыз. *(Инде үз-үзен тыя алмыйча, котырынып.)* Без әле үргә дә сикертәбез! Җелекләрегезне суырабыз!

Смелянский. Исбатлый алмассын!
Гангардт. Ә мин исбатлап та тормаячакмын. Алып китегез!

Смелянскийны алып китәләр. Гангардт, хәле бетеп, креслога ава.

Уф, арыдым!.. Барысы белән дә шулай газаплансаң...
Мангушевский. Бронский кертә, Николай Иванович.
Гангардт. Бронский?.. Эт баласы! Кулга алулар ничек бара?
Мангушевский. Тәртиптә.
Гангардт. Керт теге хәсисне.

Мангушевский чыга, яңадан Бронский белән әйләнеп керә.

*(Урыныннан торып һәм Бронскийга кулын сузып.)* Сез нәрсә, Александр Евгеньевич? Иң хәлиткеч момент, ә сез юк! Нишләп сходкада булмадыгыз?
Бронский. Белмим. Яшеренеп яттым.
Гангардт. Кичекмәстән кулга алырга һәм башка кулга алынганнар янына урнаштырырга дип полиция белән без бөтен шәһәрне бетереп эзлибез, ә сез качып ятасыз! Моны ничек аңларга? Ничек?
Бронский. Сез мине кулга аласыз дигән килешү юк ла безнең.
Гангардт. Никонов кая?
Бронский. ... Никонов белән Звонарская кичә үз-үзләрен үтергәннәр.
Гангардт. Нәрсә? *(Тынлык.)* Уенны бозды, ахмак.

Тынлык.

Шулай кирәк, Александр Евгеньевич. Камераларда ни турында сөйләшүләрен белергә кирәк безгә.
Бронский. Мине кулга алырлык берни дә сәбәп юк. Өемдә барысы да тәртиптә. Бернинди нелегальщина юк. Миңа димәгәе ун тентү булсын. Сходкада булмадым. Кулга алыр өчен сәбәп юк. Юридик сәбәп юк.
Гангардт. Бала-чага сүзе! Без сездән потлаган нелегальщина табачакбыз. Һәм понятойлар аны раслап кул куячак.
Бронский *(Гангардтка карамыйча гына).* Минем университетны тәмамлыйсым килә. Анда барырга теләмим мин!
Мангушевский. Сез, Александр Евгеньевич, үзегезне шактый файдалы һәм тулы ышаныч күрсәтелергә лаеклы хезмәткәр итеп таныттыгыз! Канәгать без сездән.
Бронский *(шашар дәрәҗәдә).* Ә рәхмәт урынына нәрсә? Төрмәме? Сөргенме?
Гангардт. Сез үз урыныгызга Шелоновны куйдыгыз. Без сезгә бу уенда ярдәм иттек... Я-я, Александр Евгеньевич! Уенны бозмагыз... Үз белемегезне күтәрү белән шөгыльләнегез, революционерлар арасында ышаныч казаныгыз. Сез инде турыдан-туры контрольсез, үзегез генә дә эшләргә сәләтле... Эзләү мәсьәләләрен үзләштердегез, теләсә нинди хәлләрдә тиз һәм һәрвакыт чыгу юлы табу тәҗрибәгез бар. *(Мангушевскийга.)* Пенсия турында әйттегезме сез аңа?
Мангушевский. Юк.
Гангардт. Соң шулай ярыймыни инде? Безнең үтенеч белән, Александр Евгеньевич, Полиция Департаменты Эчке эшләр министры әфәндегә сезгә үтенеч белән мөрәҗәгать итү хокукы бирү турында...
Бронский. Үтенеч... Үтенеч!..
Гангардт. Тәртибе шундый. Гомерлек пенсия. Елына мең дә ике йөз сум. *(Тынлык.)* Башка юлыгыз юк сезнең, Бронский. Уен дәвам итә. Һәм бик озак дәвам итәчәк.

Бронский. Куркам мин. Аңлыйсызмы, куркам. Бернинди дә акча кирәкми. *(Йөзен каплый.)* Каннан, үлемнән... куркам мин!

Гангардт. Я-я, житәр.

Бронский. Миннән, мөгаен, шикләнәләрдер инде. Ульянов, нишләп синең күзләрең шундый... чиста, дип сорады. Барасым килми минем алар янына! Килми. Куркам.

Гангардт. Алып китегез үзен. Беркетмә язсыннар. Һәм шундук крепостька, камерага япсыннар.

Бронский. Куркам мин.

Мангушевский Бронский белән бергә чыга, кире керә. Гангардт арыган, нервлары какшаган, йөренә.

Гангардт. Кырык кеше билетын ташлаган һәм университеттан чыгаруларын сорап язган. Әле — бөтенесе дә кулга алынмады. Ә күпме вакыт үтте инде! Әгәр дә без ике йөз илле кешене кулга алырга уйласак? Сходкада катнашкан бар кешене дә? Әгәр алар биш йөз булса? Башта уйланылганча? Иртәгә инде алар тугыз йөз булачак, ротмистр! *(Урындыкка үрелеп һәм аны читкә алып ыргытып.)* Шундый кечкенә штат... Бүкәннәр! Акылдан язганнар!.. Соң бит шундый серләр, политик эзәрлекләүнең профессиональ серләре бар лабаса! Полиция эшенең техникасы бар!.. Шул хәтле аз кеше белән ни эшли алам мин? Революцияне иң элек Полиция Департаментында ясарга кирәк! Шул чакта Россиядә революция булмас та. Хаклы ул теге Смелянский. Кырып бетерә алмаслык кабилә бу! *(Кинәт шашынып Мангушевскийның кулыннан тота.)* Губернада кайда нинди чебен очканына хәтле белергә тиеш мин, ротмистр. Чебен очканын! Бөтенесен җәтмә белән уратып алырга кирәк. Һәр кешене агент итәргә! Һәр кешене! *(Нindидер акылдан язган көлү белән көлеп.)* Кешеләрне авыр чирдән коткарырга кирәк, ротмистр! Вөҗдан, әхлак дип атала торган, пычрак һәм шәхесне кимсетә торган, үз-үзеңне агулаучы химералардан коткарырга кирәк!.. Ә? *(Көлемсерәп.)* Хөррият һәм шәхси бәйсезлек таләп итүдән... Дөньялыкта безнең эш бу, ротмистр! Ышаныгыз, хөррият белән бик азлар гына файдалана ала. Бик азлар гына! Сайлап алырга! Иң мөһиме сайлап алу! *(Һаман саен шашканрак кыяфәттә.)* Сайлап алу тәртипсезлеккә каршы көрәш чарасы ул. *(Пышылдап.)* Энтропиянең үсүенә каршы! Кеше молекулаларын күзәтүче һәм үзе теләгәнчә сайлап алучы, сортларга аеручы демон ул! Сайлап алу! Юкса дөнья харап булачак! Шуңа күрә һәр кешене агент итәргә кирәк, ротмистр!..

Мангушевский. Ни булды сезгә, Николай Иванович? Ни булды?

Озак тынлык

Гангардт. Мин дә... нидәндер куркам, ротмистр... Куркам!

Мангушевский. Арыгансыз сез.

Гангардт. *(Шашкан күзләре белән бушлыкка карап.)* Куркам... Куркам!..

## 4

Төн. Ярымкараңгылык, керосин лампасы. Ульянов — аның барлык нервлары, фикерләре, хисләре киеренке — тәрәзә янында басып тора. Сеңлесе әйберләрен җыя.

Ольга. Я хода! Аня сөргендә, Сашаны үтерделәр, хәзер инде син... Боларга әни ничек түзәр икән соң? *(Тынлык.)* Аңа ни диярргә?

Ульянов. Караңгы. Нindидер утлар, кырлар... Аларның җаны бар микән?

О л ь г а. Менә! Бөтенесен җыйдым.

У л ь я н о в. Рәхмәт.

О л ь г а. Кара. Бәлкем берәр нәрсәне оныткандырмын?

У л ь я н о в *(кул селти)*. Бу дөньяда кешенең, мөгаен, хәзер бер генә һөнәре булу мөмкиндер. Профессиональ революционер һөнәре... Тик бу һөнәргә өйрәнү җиңелдән түгел.

О л ь г а *(энке киемнәрне тикшереп)*. Шулай итеп, син инде юрист булмассың микәнни? Ай, сәдәф тагарга кирәк икән. Хәзер һаман да шаяртуны гына беләсең син.

У л ь я н о в. Шаярту түгел бу.

О л ь г а. Әнигә ни дияргә соң инде?

У л ь я н о в. Белмим. Мин һөнәр турында әйтер идем. Белмим. Хәзер һәрвакыт уйлыйм мин. Һәрвакыт!

О л ь г а. Ни турында?

У л ь я н о в. Ничек ни турында?

О л ь г а. Нәрсә турында соң?

Тынлык.

У л ь я н о в. Үлем, хаталар турында... Болар бөтенесе дә түләүдер, мөгаен. Рәхимсез, әйеме? Кешелек үзенең барасы юлы өчен алдан ук рәхимсез исәп белән түли. Әле алда, мөгаен, түлиселәр бик күптер... Аңлавы да кыен. Һәркем ни дә булса үзе яратканны таба. Шуңа канәгать тә. Бер бөтен итеп, тулаем ала торган дөнья юк. Үткәне һәм киләчәк үсеше белән ала торганы.

О л ь г а. Ни сөйлисең син?

У л ь я н о в. Һаман уйлыйм мин. Айлар, көннәр буе уйлыйм. Яраклыны яраксыздан аерырга кирәк... Карап торуга күренгәнчә генә җиңел түгел. Практика революцион эшчәнлекнең берничә төрен эшләгән. Заговор юлы, политик заговор, пропаганда, турыдан-туры халык агитациясе — болар барысы да төрле юллар. Үз эчләрендә үз җыерчыклары... Бер яктан, череп таркалучы народниклык, ә икенче яктан?.. Икенче яктан, туып килүче марксизм. Яңа форма эшләнә. Нинди дә булса бердәнбер юл бардыр бит инде? Булырга тиеш ул! Һәм бар ул! Без үз кулыбызда рус тарихының, ә бәлкем әле бөтен дөнья тарихының да язмышын тотабыз. Таңре бер генә — хөррият, яктылык. Ә стена кайда юкарак соң? Аны нәрсә белән тишү җиңелрәк! Бөтенләй башка юл кирәк!

О л ь г а. Я хода! Хәзер шуның турында уйларга тиешмени соң син?

У л ь я н о в. Нәрсә турында соң? Мин тагын ни турында уйларга тиеш соң?

О л ь г а. Хәзер килеп житәчәкләр ләбаса! Сине кулга алырга тиешләр бит!

Ульянов эндәшми. Яңадан тәрәзә янына килә.

Карап керим әле!

Чыга.

У л ь я н о в *(ялгызы)*. Нинди караңгы!.. Бөтен кешелек өчен чыгу юлын бәлкем нәкъ менә без, без табарбыз әле?.. Лабиринттан чыгу юлын! *(Стенага йодрыклары белән суга.)* Чыгу юлы!

Русчадан **МИРГАЛИМ ХАРИСОВ** тәрҗемәсе.

# Нури Арсланов

## ДУЛКЫННАРГА КАРАП

### Арыныр микән

Канатлары арыды микән әллә —
Акчарлаклар суда тирбәлә:
Яшәү өчен көрәш тик бер бәла...
Тынычлык юк сезнең илдә дә.

Тыныч яшәмиләр балыклар да:
Эреләре йота вакларын.
Балык аулап сезнең халыклар да
Кимен куймый, акчарлакларым.

Бер карасаң сездә ни язык бар?! —
Табигатьтән килә җанварлык.
Тырнак җәйгән, теш ырҗайткан җанвар —
Корбан гына булсын ялмарлык...

Азык асылы сезгә балык инде!
Тере килеш йоткан чакларда
(Тиңләү мөмкинме соң андый җимне!)
Рәхәт була акчарлакларга.

Кешеләр дә шулай бит «көн күрә»:
Бер ил җыңә, берсе җиңелә...
Шуңа дөнья сакта — аяк үрә!
Сугыш килмәсен ди җиренә.

Канатлары тәмам талыр икән —
Акчарлаклар суда тирбәлә.
Җанварлыктан кеше арыныр микән
Дөнья дигән зәңгәр тирмәдә?!

### Йөрәгемә

Йөрәк, җилкен, җилләнеп кал,
Агармагае чәчләр! —
Картларга карап гыйбрәт ал,
Яшьләргә карап яшәр!

Җылыт син җылың барында,
Ал канат асларыңа!
Эрет бозын да, карын да
Һәм күңел ташларын да.

Мин хәятта кунак диеп
Утырма түрдә генә.
Язмыш алдында баш иеп
Сөмәя күрмә генә.

Читлектәге арысландай
Атылсаң-бәрелсәң дә,
Дошман белән алышканда
Калсаң да авыр хәлдә.

Сынмаган, сыгылмагансың
Көрәшләр, яулар кичеп!
Инде нигә моңланасың
Болай сагышка төшеп?

Ташла, йөрәк, җилкенеп кал,
Эрет күңел карларын!..
Узган гомереңнән гыйбрәт ал,
Үксез итмә калганын.

## Бүре аулаганда

Дәстәрхандай ята җәйрап
Тип-тигез дала.
Шул далада бүре аулап
Атлылар чаба.

Аучы үз хәйләсен кора:
Куып җитмичә,
Артка да калмыйча гына
Бер яктан төшә.

Ә ерткычның гел бер якка
Карап барышка
Муен тамырларыката —
Ягы карыша.

Кинәт шунда берсе чыга
Кире ягына:
Чукмар белән селтәп суга —
Бүре абына...

Ягы карышкан язмышны
Сук кире яктан:
Ирештеңме — ал табышны,
Төшмә дә аттан.

Далалар киң, атың чая,
Үзең ир-егет!
Өмет аты һаман чаба,
Савыры ак күбек.

## Чытык Иделдә

Каш-кабаклары төелгән,
Йөзләрен чыткан һава...
Тукайда ничек диелгән:
«...Җил дә вакытында исеп,
Яңгыр да вакытында ява»?

Кайда ул вактында! Монда
Көн дә җил, яңгыр... харап!
Дәрдмәнд тереле аңымда:
«...Җилкәнен киргән кораб!
...Юл бара ят ил карап...»—

Ул кояш эзли ят илдән,
Ә кояш өстә генә,—
Тик болытларга күмелгән...
Ачмый калмас күк йөзен бер,—
Ит өмет, эстә генә!

## Заһид Хәбибуллинга

Скрипка ни дип әйтә,—
«Кәләү Гайшә» дип әйтә.
Шул «Кәләү Гайшә» көйләре
Тар сулышны киңәйтә.

Уенчының иягенә
Сазының сыенганы,
Кылларның һәр тиягеннән
Моңнарның коелганы!..

Очкыннар сибелә тылсымлы
Бармаклар арасыннан:
Смычекта йөрәк чыңы
Яктыра, яна сыман.

Уйный ла уйный шул чаклы!
Тула да күңелләрең,
Сизми дә каласың татлы
Яшьләрең түгелгәнен...

Дулкынлы Идел кебек син,
Моңлысың Илем кебек:
Татар көйләрен уйнауда
Юк, Заһид, синең кебек!

Уйна бер мәңгелек көйгә,
Буыннар баш исеннәр:
— Скрипка тавышы килә,
Заһид уйный!— дисеннәр.

## Арфачы

Аккош муены — ак беләкләр сарыла
Арфа кылларына,
Тылсымланган җаннар концерт залында
Алмый тыннарын да.

Күм-күк пәрдә. Прожектор нур төшерә,—
Айлы төндәй серле.
Уйный арфа... ләззәт биреп кешегә
Мең еллардан бирле.

Иске арфа уен саен яңара,
Отыры үзгәләнә,
Кылларында гаҗәп чыңнар ярала,
Ярсый-өзгәләнә.

Ак канатын җәйгән аккош — арфачы,
Йөзә зәңгәр моңда.
Изге рух һәм якты хисләр алласы
Тик ул гына монда!

## Корабта

Акчарлаклар, үзгәреш юк сездә,—
Моннан ничә гасыр элек тә
Бүгенгедәй, дулкын сөзә-сөзә,
Уйнагансыз шулай иректә.

Сезне күргәч никтер узган чаклар
Уяндылар кинәт: җәйләүләр,
Ак тирмәләр, бабам торган яклар,
Киң далада елкы әйдәүләр...

Мавык, күңелем, әйдә атка менеп
Томырылып чап син, яр ягала:
Иске заман сыкрый җанга кереп,
Иске заман аңда яңара.

Ул заман да ирек көрәшләре
Кичергәндер, ирләр аугандыр,
Изге аналарның күз яшьләре
Шулай Идел булып калгандыр...

Әй сез, акчарлаклар, шул Иделдә
Элеккедәй гамьсез очыгыз.
Сезнең халык үзгәрми ул бер дә,
Язмышта юк сезнең эшегез.

Сезге яшәү — шатлык, әмма безгә
Өстәмәгә — яшәү кайгысы:
Туган көннән алып төшә эзгә
Кырыс язмыш... түзми кай кеше.

Үзенә үзе кеше канун ясап,
Үзенә үзе куя киртәләр...
Акчарлаклар, сез мәңгегә азат,
Кояш сезне мәңге иркәләр!

## Элегия

Үзем телим, үзем каушыйм, качам,
Үзем кыю, үзем тарсынам:
Сине күрсәм бер тынам, бер шашам,
Гүя миңа дигән, буй җитмәслек,
Бәхет тажы синдә бар сыман...

Очрашсак та бер дә көтмәгәндә,
Кинәт кенә, гади шартларда,—
Әйләнә көн гаҗәп бер бәйрәмгә!—
Нидән икән җанда бу тантана
Синең белән булган чакларда?!.

Сарыласың йөзне йөзгә куеп,
Мин сак кына кочам, назларың
Күңелнең бер читен ала уеп...
Өмет куна кайткан кошлар булып,—
Кабатлана күкрәп язларым!

Янам, янам күзләреңнән көйрәп,
Үзем телим, үзем тартынам...
Мәхәббәтне була мыни сөйләп!
Йолдызларга ашам өермәндә,
Күтәреләм хисләр артыннан!..

Нишләтергә инде бу өметне!—
Атылган кош сыман талпынам...

## Имәнем

Бакчамның күрке, матурым —
Имәнем корыган минем,
Имәнем — яшел чатырым
Дигәнем корыган минем...

Күләгәсендә утырдык,
Торды җәм ташып кына.
Инде имән калган корып,
Ялангач басып тора.

Ни кәтмәк язмыштан — шуктан,
Күр, ниләр кылган кирең!—
Ник, нинди салкыннар суккан
Бакчалар-гөлләр илен?!.

Җансыз һәйкәл булып калган,
Имәнем корыган минем,
Гомерлеккә аерылалмам
Дигәнем корыган минем...

— Шул гынамы бар бәласе?
Я,— диләр,— тавышланма,
Яшь имән утырт,— янәсе,—
Юк-барга сагышланма!

Яшь имән күләгәсендә
Тик мин утырмам инде,
Юатып ни сөйләсәң дә
Имәнем корыган инде,
Теләсәм, теләмәсәм дә
Торганча тормам инде...

## Дулкыннарга карап

Кургашындай салкын дулкыннарның
Чал яллары ята суларга.
Араларын иңләп ике ярның
Акчарлаклар чыккан сунарга.

Аралары ерак ике ярның —
Өмет белән максат шикелле...
Гомер буе максатыма бардым,—
Ирешүе булды икеле.

Өмет һаман маяк булып басты,
Өметләнгән саен яшәрдем.
Барган саен максат ераклашты,
Шуңа ахры озак яшәвем.

Сабый чакта күктән йолдызларны
Тоту ансат булып тоелган.
Теләкләрем йолдыз булып янды,—
Биек шул ул кеше буеннан...

Барып җитәр әле бәлки моңым
Дулкыннарда ерак ярларга.
Тик пошынам, барыр юллар озын,
Ә гомер бик кыска калганга.

Кургашындай салкын дулкыннарның
Чал яллары ята суларга.
Миндәй түгел, акчарлакның аның
Бар кайгысы фәкать сунарда.

## Уем яхшы

АКЫННАРЧА ИМПРОВИЗАЦИЯ

Йөзек күрке — кашында,
Сыйлаганның — ашында,
Абруйның — ил түрендә,
Данның — халык телендә,
Иминлекнең — илеңдә,
Илнең йөге — иңеңдә,
Һәр кемнең — үз эшендә:
Кешелекнең — кечедә,
Кечелекнең — олыда,
Юлаучының — юлында,
Дилбегәсе — кулында,
Ә кылычның — кынында
Булуы яхшы.

Ирләр комар ияргә,
Хатын-кызлар — сөяргә.
Ялкау йокса кирегә —
Елмаерга иренә.
Ялагайлык — куштанда,
Баш ия ни кушсаң да.
Һәр ямaнлык — исеректә.
Үпкә бетми кичереп тә.
Тасма телләр беленә
Салынганга теленә.
Берәү күккә үрелә,
Берәү янмый сүрелә,
Берәү хәтер калдыра,
Булмаса да аңгыра,
Берәү юкка кайгыра —
Бәхет эзләп каңгыра:
Ихлас күңел биргәндә —
Бәхет ул үз тирәңдә.
Кабаланмак-кабынмак,
Артык күзгә чалынмак,
Белдеклегә салынмак,
Түрәләргә табынмак —
Бигрәк яман.

Бер дә юкка үчеккән
Яман булыр көчектән.
Мактаганга итенгән —
Йөзгә оят китергән.
Нигә гаеп эзләргә?—
Бар ул үзебездә дә.
Җилгә каршы төкергән,
Белми бәхәскә кергән —
Ак-караны аермас,
Җаһиллектән арынмас!
Егет калҗасыз калмас,
Ләкин ятныкын алмас:

Тарса ачык авызга —
Калҗа төшәр явызга.
Балык җимли суларда,
Ә акчарлак сунарда:
Уйласаң шул да хәтта
Гыйбрәтле табигатьтә.

Бар әйткәннәрең төсле
Вәзеннәрең дә иске,
Дип йөзең читкә борма,—
Иске булса да тыңла:
Ис китәрлек искегә!
Һәр искегә хисле дә
Өрьяңа бер төс керә;
Һәр яңа да искерә,
Модага да таралып
Иске кайта яңарып.
Иске булса да алмаз
Өлгесен кисми калмас!—
Балкыр күңел тәрәзәң.
Сүзләрем булсын Зәм-зәм,
Уем яхшы.

*1979—1980*

*Илгә 2 миллиард тонна кара алтын бирүче Татарстан нефтьчеләренә дан!*

## Шамил Бикчурин

# ТИРӘН КАТЛАМ

РОМАН

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

I



Кузгә төртсәң күренмәс караңгыда килеп төште Курамшин пристаньга. Сандык кадәр чемоданнар, зур-зур капчыклар, эреле-ваклы төеннәр күтәргән пассажирларга ияреп, ашыга-ашыга тар басмадан чыкты, алар белән, мышный-мышный, бормалы сукмактан яр өстенә күтәрелде. Ничек тә бу кешеләрдән калмаска, әрсезләнеп булса да ияреп һәм алар белән бергә Вах дигән поселокка барырга иде исәбе.

Ләкин теплоходтан бергә чыккан кешеләрнең үз хәлләре хәл иде — борылып та карамыйча, шунда торган йөк машиналарына, җигүле атларга, мотоциклларга утырып китеп тә бардылар. Күрәсең, аларны биредә көтеп торганнар, каршы алганнар.

Биштәрле капчыклары белән шушы тирәдә генә басып торган ике хатын да, кай арададыр, юк булды. Курамшин аларның караңгыда аяк тавышларын гына ишетеп калды. Әллә шул якта микән Вах поселогы?

— Вах, Вах! — дип, эт өргән сымаграк аваз чыгарып алды Кәрам Ризванович.— Кызык, нәрсә дигән сүз икән ул Вах?

Чекерәеп, караңгылык пәрдәсе аша әнә шул, хатыннар киткән якта дип уйлаган поселокны, һич югы, нинди дә булса ут яктысын күрергә азапланды. Юк, дөмнең дә дөме!

Ул арада теплоход сигнал бирде, дебаркадер борты шыгырдаганы, дулкыннарның ярга бәрелеп шапылдавы ишетелде. «Метеор», гөрелдәп, әкрен генә кузгалып китте.

Менә шунда тәнен чымырдатып, куырып алган ялгызлык тойды Курамшин. Таныш булмаган чит җирдә, караңгы яр өстендә япа-ялгыз басып калу шомландыра иде. Ул, моңаеп, ярдан һаман саен ераклаша баручы «Метеор»ның якты тәрәзәләренә карап торды.

— Менә сиңа Вах!

Әле Курамшин бөтенләй үк ялгыз түгел икән. Әнә аста, дебаркадерда кемдер чаж-чож килеп, нәрсәдер эшләп йөри. Җан кереп киткәндәй булды Кәрам Ризвановичка. Чемоданын алып ул шунда юнәлде.

Өстенә ялтыравык төймәле бушлат, башына тузган чәче өстеннән «кәбестәле» елгачылар фуражкасы кигән шактый олы яшьтәге юан гына хатын саплы себерке белән, печән чапкандай кизәнеп, дебаркадер идәнен себерә иде. Кәрам Ризванович аны теплоходтан чыкканда ук шәйләп калган иде. Ул басма янында пассажирлардан билет күрсәтүләрен таләп итеп кычкыра, ә кешеләр аны санга да сукмый, өерелеп ярга агылалар иде.

— Әйтегез әле, зинһар, Вахка ничек барырга?— дип Курамшин хатынны эшеннән туктатты.

— Ах, менә сиңа Вах!— дип әйтте ди берәү. Ничек барырга дисең инде?— Фуражкалы хатын тагын да ныграк кизәнеп, яңадан идән себерергә кереште.— Күрсәтермен, миленькай, күрсәтермен... Каян буласың соң үзең?

— Татарстаннан.

— Ә-ә, Олы җирдән икән, миленькай...

Бу хатынның «миленькаеннан» бигрәк, «Олы җир» дип сөйләве кызык тоелды Кәрамга. Әйтерсең, болар җир читендә, бөтен дөньядан аерылып кечкенә бер утрауда яшиләр!

— Хәзер монда, миленькай, Олы җирдән килүчеләр күбәйде! Ишеткәнсең, Черек күлдән нефть таптылар бит. Җир астыннан елга булып агып чыга, ди. Хәзер пристаньга көн саен йөзләгән кеше төшә. Хәер, кире китүчеләре дә шуның кадәр... Акча күрергә дип киләләр дә, ошатмыйлар безнең якларны, табан ялтыраталар. Акча шул ул бик тирәндә ята, миленькай, казып алырга кирәк...

Хатын, идән себерүеннән туктап, Курамшинга текәлде.

— Син дә акча эзләп килдеңме? Кая, капчыгың зурмы соң?

Турысын әйткәндә, Курамшинның һич тә шаярып, сүз озайтып торасы килми иде. Аңа тизрәк юлга чыгарга, атлый башларга кирәк.

— Мин акча куып килмәдем, командировкага!— диде ул кистереп кенә.

— Ә-ә, командировкага! Алайса сиңа начальство кирәк. О-о, миленькай, алар поселокта түгел, шәһәрдә яши. Иске Вахтан өч чакрымнар ары. Бу төндә син шунда китмәкче буласыңмы?

— Әйе.

— Лучше син иртән барыр идең.

— Миңа гостиницага урнашырга кирәк.

— Тутырган ди сиңа гостиница! Әнә, пассажирлар залына кер дә ят!— Ул дебаркадерның сул ягындагы ишекне күрсәтте.— Синең кебекләр әллә кайчан йоклыйлар инде...

Ләкин Курамшин бу хатынның киңәшен тотмады, чемоданын алды да, рәхмәт әйтеп, өйрәткән юл белән китеп барды. Поселок моннан өч чакрым, шәһәр дип аталган өлешенә тагын өч чакрым икән— күп мени ул аягы сау кешегә? Аз узды мени Кәрам Курамшин андый араларны?

Кәрамның бәхетe җәяү йөрүдә булгандыр инде. Алар авылында урта мәктәп юк иде — җиде классны тәмамлау белән көн саен алты километр ераклыктагы район үзәгенә йөреп укыды. Аннан армия, алтмыш-җитмеш километрлы походлар, маршлар. «Эх, пехота, прошел сто, еще охота!» дип торганнар иде солдатлар.

Армиядән кайткач — нефть институты. Анда укыганда да байтак тәпиләргә туры килде. Өлкән курсларда практикага нефть промыселларына я оператор, я ярдәмче оператор итеп җибәрделәр. Анда аралары бишәр-алтышар йөз метр булган унлап скважинага хезмәт күрсәтте. Шуларның берсеннән икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә йөри торгач, узылган километрлар исәбе кайсы көнне егермегә, кайбер көннәрне утызга җитә иде...

Яшьрәк чакта җәяү чаба-чаба аякларын ярыйсы гына ныгыткан иде ул, ә менә институтны бетереп инженер булып алгач... машинага ияләшеп китте бугай. Инде ун еллап җәяү йөргәне дә юк. Вакыт җитми. Хезмәте шундый. Ашыгырга, бар җиргә дә өлгерергә кирәк.

Караңгыга күз ияләшә төшкәч, ул барасы юлның ярыйсы гына такыр икәнен күреп сөенде. Нәрсәдер сөйрәп трактор үткән һәм юл шомарып-ялтырап калган. Әнә шул ялтыравыкны югалтмаска, шул эздән генә атларга тырышты Кәрам. Тик, таныш булмаган җирдә, дөм караңгы төндә җәяү йөрү ифрат кыен икән. Сукыр кеше кебек, һәр адымыңны чамалап атларга кирәк. Алай да әле я сөрлегеп китәсең, я чокырга төшеп абына язасың.

Иң кыены ялгызлык. Ул, җанлы бер нәрсә төсле, артыңнан калмый ияреп бара, төрле уйлар уйларга мәҗбүр итә...

Бу мизгелдә Кәрам, караңгыга да, юлның кыенлыгына да игътибар бирми, үзенең еракта, Татарстан җирендә, Әлмәт кырларында калган скважиналар, автоматлары һәм алар белән мәж килеп йөргән эшчеләре турында борчылып бара иде. Бик тә уңайсыз вакытта җибәрделәр бит аны командировкага, ифрат та авыр чакта. Скважиналар белән читтән торып идарә итү системасын көйләп, җайга салып эшләтә генә башлаганнар иде — мә сиңа. Түбән өлкәсенә командировкага кит! Җитмәсә, күз күрмәгән, колак ишетмәгән Вах поселогын эзләп тап, ниндидер Черек күл буендагы скважиналарга бар...

Ә бит Курамшинның үз промыселында да эш, аллага шөкер, муеннан иде. Яңа системаның әле бер, әле икенче җире кәҗәләнә калды. Автоматларның кайсысын төзәтергә, кайсысын үзгәртеп көйләргә, кайсысын бөтенләй алыштырырга кирәк. «ПАТ» системасы да, «Спутник» дигәннәре дә нефтьчеләр өчен яңа нәрсә, егетләрнең бу өлкәдә тәҗрибәсе юк, хәзер нишләрләр инде анда калганнар?..

Китәр алдыннан хатыны белән әрләшеп алуы да күңел түреннән төшми әле Курамшинның. Ямьсезрәк килеп чыкты аерылышу. Гаеп Хәтимәдә. Яше утызга җитте, өч бала анасы булды, ә акылы, ташка үлчим, һаман сабыйларча. Кәрам үзенең командировкага китәсен әйтүгә, балалар кебек урыныннан сикереп торды да: «Мин дә барам!» — дип, киенә үк башлады. Әйтерсең, аның ире әбиенә кунакка бара! Әйтерсең, аларның йорт-җире дә, бала-чагалары да юк.

Тагын, киткәндә Кәрамның иң ачуы килгәне «Шәфрун кайткан», — дигән хәбәр булды. Ул күз көеге, Хәтимәнең «җан кисмәге» тагын нигә дип кайткан? Килеп, шулай яңадан да борчып йөрерме ул Хәтимәне?..

Ярты сәгатьләр узгач уңда да, сулда да нарат, чыршы агачлары очрый башлады. Алар ешайганнан-ешая барды һәм Курамшинның алдына куе кара стена булып басты. Димәк, теге хатын өйрәткән буенча, шушы урманны гына чыгасың да поселок башлана, поселокны үтеп тагын өч чакрымнар барасың да шәһәрнең үзенә керәсең.

Юлның иң яманы алда булган икән. Урманга килеп керү белән исәпсез-хисапсыз бормалар, чокырлар, салулар башланды, әйтерсең, монда кайчандыр диңгез булган да, аның дулкыннары чайкалып торган көенә катып калганнар.

— Аю-мазар юк микән? Булмас, шәһәр тирәсендә йөрмәс ул чатан аяк...

Аюдан куркудан да түгел, эчпошыргыч ялгызлыктан аптырап әйтте ул моны. Киткәндә Себер диделәр, тайга диделәр, урманнарында кош-корт, җәнлек тулып ята диделәр, аюлар, бүреләр белән өркеттеләр — кая соң әлегә хет берәрсе? Ичмаса күңел өчен генә булса да бер җан иясе күренсен, берәр агач шытырдасын, яфрак кыштырдасын иде. Ә бит туган як урманнарында сирәк кенә булса да куян,

төлке кебек җәнлекләр очрап куя. Шунда пырылдап агач башыннан ябалак очып китә, куак артыннан чаштырдап «кылый» чыгып йөгерә, яфрак астында керпе кыштырдап йөри...

— Монда җәнлекләргә ни калган? Алар да бит ахмак түгел, җан иясенә якын җирдә яши,— дип үзенчә нәтиҗә чыгарды Курамшин. Эчкәрәк кергән саен урман куера, юл караңгылана барды. Инде хәзер чокырларны, борылмаларны да шәйләп булмый — агачларга бәрелүдән кулны алга сузып сакланырга, аяклар белән капшанып кына атларга туры килә.

— Пристаньда гына кунасы калган, бер кая да кузгалмаска! Эх, юләр, акыллы хатынның киңәшен тотмадым бит!— дип уйлана-уйлана барды ул. Шунда үзенең ахирәт дусты, сабакташы, Вах шәһәрендә яшәүче Кузьма Пичуговны исенә төшерде.

— Кузьмага телеграмма сугасы калган. Бәлки каршы алган булыр иде...

Кузьма Пичугов турында ул күптән түгел генә Төмән якларыннан командировкага килгән бер инженердан ишетеп белде. Бу кешене Пичугов очраклы рәвештә идарәдә очраткан һәм, аның Татарстан нефтьчеләре янына барасын белгәч, кечкенә бер язу җибәргән. «Барын да соңыннан аңлашырбыз, миңа хат яз», дигән, өй адресын биргән. Пичугов яңа төзелгән Вах нефть идарәсендә начальник урынбасары икән, сөйләшеп-аңлатып торырга бер минут та вакыты булмаган. Төмәннән килгән инженердан бары тик менә шуларны гына белә иде Кәрам.

Биш ел бергә укып, бер торакта, бер бүлмәдә бергә яшәгән, бер кашыктан дигәндәй ашаган дуслар иде Кәрам белән Кузьма. Институтны бетергәч Кузьманы эшкә Себер промыселларына җибәрделәр. Дөресрәге, Татарстанга билгеләнсә дә, күп гозерләр белән йөреп, үзенә Себерне даулап алды, күк гөмбәзе кебек кабарынкы, зур зәңгәр күзле Татьяна Семашкинага иярде. «Танясыз яши алмыйм, ул кая китсә — мин шунда» — диде.

Кузьманың бу кыз белән китү ниятен Кәрам бер дә хуп күрмәде. Геология факультетында укучы Таня Семашкина үзенең җилбәзәклеге белән генә түгел, усаллыгы белән дә башка кызлардан кискен аерылып тора иде. Үткәндә-сүткәндә студентларга теләсә нинди төртмәле сүзләр әйтеп калу дисеңме, егетләрнең фуражкаларын очырып төшерү, аларны аяк чалып егу дисеңме... Кыз юньләп бер егет белән дә йөрмәде, әмма аларны үз тирәсендә тотарга, танцыларга теләсә кайсын өстерәп чыгарып үз кубызында биетергә ярата иде. Юашрак студентлар Танядан уттан курыккан кебек куркалар, яныннан качалар иде.

Кәрамны иң шикләндерә калганы профессия төрлелеге булды. Таня геолог, ә Кузьма автоматчы. Чынлап яши-нитә калсалар нинди-рәк уртак фикер, уртак эш табарлар икән болар?..

Студентлар, дипломнар алып, төрлесе-төрле җирләргә китте. Таралыштылар. Баштагы елларда, бигрәк тә беренче айларда Кәрам үзе белән бергә укыганнардан бик күп хатлар ала иде. Егетләр дә язды, озын-озын итеп, чуклап-чәчәкләп кызлар да язды. Яңалыклар илнең бөтен почмагыннан диярлек килде: бүген Бакудан булса, иртәгә Сахалиннан, берсекөнгә Кавказдан, Башкортстаннан, Куйбышев промыселларыннан...

Бераздан кызлар кияүгә чыгып беттеләр, егетләр өйләнде — хатлар сирәгәйде: тора-бара Кәрамга бәйрәмнәр алдыннан уч төбе кадәр открыткаларда саран котлаулар гына килә башлады. Соңыннан алары да тукталы. Оныттылар...

Ә менә Кузьма Пичугов белән элемтә озак елларга сакланды. Институтта студентларның фәнни түгәрәгенә бергә йөргән, төннәр буе

китапханәләрдә утырган, шырпы тартмасы кадәр генә радиоалгычлар ясарга хыялланган һәм егетләр бүлмәсеннән кызлар бүлмәсенә радиотелефоннар үткәреп сөйләшүче дуслар курста икәү генә иде бит алар!

Диплом алып аерылышканда болай дип сүз бирешкәннәр иде: «Күкләр җимерелсен, яңгыр урынына ташлар яусын, безне усал җилләр җир читләренә илтеп ыргытсын, ләкин кайда гына булсак та, нинди генә хәлләргә юлыксак та элемтәне өзмәскә, хатлар язып торырга! Һич яшермичә, дөп-дөресен, туп-турысын язарга!»

Кош теле кадәр генә соңгы записка кисәген исәпләмәгәндә, инде хәзер Пичугов белән хәбәрләшмәгәнгә дә биш-алты еллап...

Кәрам шуларны уйлый-уйлый һаман караңгы урман эченнән атлады. Бәхеткә каршы, урман алай калын булып чыкмады — йөз еллык чыршы, нарат агачлары сирәкләнә башлады һәм алда, шул агачлар артында гына, тычкан утыдай сүрән, тонык берничә ут ноктасы күренде. Ниһаять поселок!



## II

Поселоктан шәһәргә тип-тигез бетон юл китә икән — бүтән азапланырга туры килмәде, төнге сәгать икедә Курамшин Вахның шәһәр дип аталган өлешенә килеп керде.

Бу башыннан бараклар, фин тибындагы өйләр белән башланган шәһәр эчкәрәк кергән саен киңәя, ике катлы кирпеч йортларга, тимер-бетон панельдән салган дүрт-биш катлы корпусларга әверелә барды. Кайдадыр, шәһәрнең теге башында әллә тугыз, әллә унике этажлы итеп салына башлаган йортның кысасы да күренә. Үсәргә, зураерга йөз тота икән шәһәр.

Урам уртасындагы бетон юлдан барды да барды Кәрам. Бу караңгы төндә инде ул ни кунак йорты, ни үзенә кирәк нефть идарәсен, ни Пичуговларны таба алмаячак. Теге елгачы хатынның киңәшен тыңламаганга, үҗәтләнеп пристаньнан китеп баруына, шушы сукыр төндә җәфаланып килүенә яңадан үкенде.

Ул чын-чыннан арган иде. «Метеор»да утыргыч аркасына баш терәп, тәүлеккә күп булса ике-өч сәгать черем итеп алгандыр. Юл азабы — гүр газабы дигәндәй, аңа кадәр дә бит әле ул Әлмәттән Казанга биш сәгать автобуста, Казаннан Төмәнгә дүрт сәгать самолетта килеп ялыккан. Җир читенә барган кебек булды бу командировка. Хәзер менә шушында бер утырыр җир тапса, эһ тә итми капчык кебек авып төшәр иде, салкын диме, каты диме, бала урынына йоклар иде дә йоклар иде...

Күз аллары томаланып бер мәлгә туктады, чемоданын аяк очына куйды. Шулай да я Пичуговлар квартирасын, я кунак йортын табасы иде бит. Тик ул урамнарны, ул йортларны җиде төн уртасында кемнән сорарга? Ахры, иртәне, яктырганны, кешеләр уянганны көтәргә кала...

— Тукта, ниндидер тавыш килә түгелме?

Арырак, әнә теге яңа салына торган биек йорт ягында җыр сыман нәрсә ишетелә. Колак шаулыймы, әллә җырмы?

— Әйе, әйе, җыр! Һәм, житмәсә, татарча җыр, чын авыл җыры, егетләр җыры!

Курамшинның миражлар турында укыганы, очсыз-кырыйсыз чүлләрдә, дала уртасында, кызу кояш астында кешеләр бер тамчы суга тилмереп йөргән чакларда кинәт алларында җәйрәп яткан диңгез, ургып аккан елга, яшеллеккә чумган бакчалар күреп ымсынулары ту-

рында ишеткәне бар. Бәлки бу да табигатьнең шундый бер шаяруыдыр?

Юк, җыр бу якка якынлаша, торган саен ачыграк ишетелә бара һәм Кәрамның колагында бик күптәнге таныш моң булып яңгырый:

Караурманның уртасында
Каерылып ла кар калган.
Кояш баешы ягында
Аерылып ла яр калган.

Җырлаучылар бик үк айнык түгел ахрысы. Тегендә, туган якларда булса урамдагы җырга, аеруча исерекләр җырына һич кенә дә игътибар итмәс иде. Ә биредә шушы карлыккан тавышлар белән салулы-сикәлтәле җырланган җыр да Курамшинга әйтеп бетергесез ягымлы, якын тоелды.

Ул түзмәде, җиргә куйган чемоданын алды да, җыр ишетелгән якка китте. Бар икән әле тормыш, Кәрам уйлаганча Себер дә йоклап ятмый, төн уртасында, таң алдында булса да кешеләре җырлары белән, җитмәсә, үз милли моңнары белән дә моңланып яши икән.

Җырлап килүчеләр өч ир-ат иде. Алар, нәкъ авылдагыча, берберсенең җилкәсенә кулларын салып, билләреннән алышып, тап урам уртасыннан атлыйлар һәм озын итеп «шахта» көен сузалар.

Курамшин тротуардан канау аша сикереп юлга, тегеләрнең каршыларына чакты. Тынына капланды, гүя күтелмәгән очрашу аның муеныннан буа сыман иде.

— Сәлам егетләргә!— диде ул үтә каушап.

Егетләр шып туктадылар. Берсе, зур гәүдәлесе, куллары белән бөерләренә таянып алга калыкты, усал, карлыккан тавыш белән әйтте:

— Сәлам дә булсын. Сез кем, ягъни?

— Әйтегез әле, зинһар, монда кунак йорты кайда?— Курамшинның тавышы шул кадәр дә мескен, шул кадәр дә юаш булып чыкты — ул менә-менә елап җибәрер төсле иде.

— һе, кунак йорты! Димәк, кунак?

— Әбисенә кабартма ашарга килгән!

— Түгел, утырмага диген!

Егетләр кыргый тавышлар белән акырып көлделәр. Арада иң тәбәнәк буйлысы:

— Каян буласыз?— дип сорады.

— Татарстаннан.

Егетләр минут эчендә Курамшинны урап алдылар.

— Без дә Татарстаннан бит! Сез кайсы районнан, абый?

— Әлмәттән мин. Командировкага килдем.

— Әлмәттән? Без дә Әлмәтнекеләр бит, абый! Кайсы авылдан?

— Бигәштә яшәдем мин... Хәзер шәһәрнең үзендә торам.

— Бигәшнеке? Мин дә Бигәшнеке бит!— дип кычкырды әлеге кечкенә буйлы егет, чәчрәп алга чыкты. — Тукта, тукта. Сез мастер Курамшин түгелме соң?

Курамшин караңгыда аның йөзенә иелде.

— Кем малае буласың син?— дип сорады картлар кебек.

— Барый малае мин. Беләсез сез аны. Икенче промыселда оператор булып эшли.

— Ажгый буыны түгелме?

— Менә, эзенә бастыгыз!— дип кулын бирде егет.— Ажгый нәселеннән мин. Барый абзыйның төпчек улы булам, Рафат...

Боларга карап хәйран калып янда торучы теге таза егет янә телгә килде:

— Соң, болай булгач нәрсә терәлеп каттың, Ажгый тәре, алып киттең авылдашыңны! Тот кулыннан, Рафат! Ал чемоданын, Гриша!

— Туктагыз әле, егетләр, ни бит... Миңа гостиница кирәк иде.
Кызмача егетләр, Курамшинны ай-ваена карамыйча култыклап, чемоданын күтәреп үзләренең торакларына алып киттеләр. Имеш, гостиница шәһәрнең әллә кай читендә, ерак, имеш, анда урын әле бармы-юкмы, анысы да мәгълүм түгел, булган суәттә дә ерак юлдан килгән якташны төн уртасында җибәрү килешә торган эш түгел.
Сырланып-назландырып торыр чак мыни — арылган, ачыгылган, йокы килә, кайда, ничек булса да баш төртергә кирәк — ул карышмады, егетләргә ияреде.
Егетләрнең: «Менә шушында гына, якында, әнә теге гаражлар артында гына»,— дигән торaклары да ярыйсы ук ерак булып чыкты. Ниндидер караңгы урамнарны, пычрак тыкрыкларны үтеп, биек койма белән әйләндереп алган гаражларны урап, аннан соң да күперчекләр, тар басмалар салынган тирән-тирән канауларны кичеп, багана башларына прожекторлар куелган якты, зур бер мәйданга килеп чыктылар. Мәйдан тирәли дуга ясап бер төсле, бер рәвешле игезәк вагоннар тезелгән, алар көмеш сыман ялтырап, ут яктысында әкияттәге сихри бер шәһәрне хәтерләтәләр иде.
— Менә шушында инде безнең оя,— диде Рафат, барган җиреннән туктап, уртадагы вагоннарга таба кулын сузып күрсәтте.— «Буйдаклар поселогы» дип атыйлар.
— «Дураклар поселогы» дип тә йөртелә,— дип өстәде таша гәүдәле егет.— Ни өчен дисезме? Акыллы кеше менә дигән йорт-җирен ташлап шушы караңгы сазлыкка киләме?
— Я, я, ыңгырашма!— дип туктатты аны Рафат.— Монда яшәргә сиңа чуртым да кушмаган. Торасың килмәсә — дүрт ягың кыйбла!
— Һәм тормаячакмын да!
Йөзләгән игезәк вагоннар арасыннан үтеп, берсенә килеп туктадылар. Аның стенасына аршын буе итеп ниндидер дегет төсле буяу белән 132 саны язылган иде. Күрәсең, йорт номеры була.
Агач баскычтан менеп, Рафат ишектәге йозакны борды.
Тышкы яктан соры, шыксыз күренсә дә вагонның эче шактый иркен, ярыйсы гына иркен икән. Үзенә күрә идәне, түшәме дә бар, кечкенә генә ике тәрәзәле. Такта белән икегә бүлгән бу куышның алгы ягын кухня итеп көйләгәннәр. Анда газ плитәсе дә, табак-савыт өчен шкаф та, утырып ашарга өстәл дә куелган. Бүлмәләргә пар үткәрелгән, су кертелгән. Иң кызыгы — өстән аркылы-торкылы җеп сузып, аңа балык киптерергә элгәннәр. Шәп балыклар! Өзелеп кулыңа төшәргә теләп, ашыйсыны китереп торалар.
— О-о, сез шәп яшисез икән!
— Түрдән узыгыз, Кәрам абый, түрне тапсагыз...
Егетләр Курамшинны, плащын салдырып, ачык ишектән түр бүлмәгә әйдәделәр.
Биредә күренеп торган байлык — өч тимер карават та алар янына куелган тумбочкалар белән берәр урындык иде. Карават турында стеналарга журналлардан кисеп алынган төрле кыяфәттәге хатынкыз рәсемнәре, спортсменнарның һәм киноартистларның карточкалары ябыштырылган.
Күзгә бәрелеп торганы — уртадагы зур өстәл һәм аның өстендә буш аракы шешәсе, капкачы ачып ташланган консервалар, колбаса, балык кисәкләре...
Курамшин тузган табынга сәерсенеп карап торды, әченнән генә көрсенеп монда, шушы исерек егетләргә ияреп килгәненә үкенә башлады.
Аның җимерелгән йөзен күреп, Рафат дигәне юатырга ашыкты:
— Беләсезме, Кәрам абый, без монда азрак кына озату кичәсе

ясап алган идек... Мин иртәгә туган якларга, сабан туена кайтып китәм...

— Шулай мени!

— Иртәгә түгел, ә бүген!— дип, сәгатен Рафатның борынына китереп терәде юан егет.— Кара, сәгать ничә булган!

— Әйе, чыннан да сәгать өченче киткән икән бит!

Егетләр дәррәү кузгалып, плитәгә бәрәңге кыздырырга куйдылар, ашыга-ашыга өстәл өстен, урын җирләрен тәртипкә китерергә керештеләр. Тузылган бүлмәгә бераз гына булса да ямь, кот кергәндәй булды. Курамшин да, үз кешедәй, пинжәген салып урындыкка элде, аягыннан туфлиләрен төшерде. Ни генә булса да хәзер моннан чыгып китмәячәк иде инде ул.

Алга кыздырылган бәрәңге, ысланган һәм тозланган балыклар, алар янына бер шешә аракы да килеп утыргач, тар вагон эченә тагын да ямь кереп китте кебек. Һич көтмәгәндә ерак Себердә, житмәсә бик ачыккан һәм арган вакытта шушы бер карауга ярлы гына табында утыруы барысыннан да өстен, күркәм иде.

— Чыннан да матур яшисез!

— Әйтәсе дә түгел, оҗмах!— диде әлегә кадәр бер сүз дә дәшми утырган сары кашлы, сипкелле егет. «Оҗмах» сүзенә ул басым ясап, иреннәрен кыйшайтып әйтте. Күренеп тора, нәрсәдәндер риза түгел.

— Керәшеннәрнең оҗмахы була мени!— дип көлде юаны.— Сез бит ни теге, ни бу дингә ябышмаган!

— Беләсегез килсә, теге дөньяда оҗмахка бер керәшеннәр генә керә алачак! Аларга нәрсә, дине белән христиан, милләте татар, гөнаһларын шәйтан санап торамы?

Егетләр утырыштылар. Рафат кырлы стаканнарны тутырып аракы салды. Барысы да сүзсез генә чәкештеләр.

Курамшин эшче халыкның гадәтен яхшы белә: әгәр инде үзеңне зурга куеп, кәнфитләнеп утырасың икән — алардан җылы караш көтмә, алар шунда ук арт белән борылып утырачаклар.

Хәмердән авыз итеп, кайнар бәрәңге белән кыздырылган балык кабып куйгач табын җанланып китте.

— Сез, Кәрам абый, һаман да әле болар кемнәр икән, ничек бу җирләргә килеп тап булганнар,— дип аптырап утырасыз бугай,— дип башлап җибәрде сүзен Рафат.— Бу якларда безнең халык күп, әйтерсең, ярты Татарстан монда күчеп килгән. Менә бу егетебез,— ул, янындагы сипкелле, сары кашлы егетнең җилкәсенә кулын салды,— безнең арада иң грамотные. Хәтта ун класс бетергән! Коридорын да санасаң — унбер дияргә була. Исеме Гриша, Григорий ягъни. Без аны Гергери дип йөртәбез...

— Ак эшләр буенча минем урынбасарым була,— дип килеп кушылды зур гәүдәле егет.

Егетләрнең шаярып сөйләшкәннәрен белсә дә, Курамшин төшенмәде:

— Ничек «Ак эш»?

— Ак эш эзләп килгән ул Төмән якларына. Биргәннәр андый эшне, бирми була мени шундый гыйлем иясенә! Баржадан акбур бушатырга кушканнар. Ошатмыйча китеп барган бу юньсез! Икенче эшкә кергән. Анда кулына ак буяу тоттырып нефть резервуарларын буярга мәҗбүр иткәннәр. Я, ак эш түгел диген инде? Аннан да качкан, керәшен тәре! Менә хәзер бездә, электрик мин дигән булып йөри, багана төпләре казый... Ә бу бүлмәдә, минем заместителем буларак, сөткә йөгерә, яки ипи алып кайта, кай чакларда, кушсаң, бер шешә ак башны да кыстырып кайткалый...

— Я, юк белән мактанып утырма әле,— дип туктатты юан егетне Рафат. Стаканнарны эчемлек белән тутырып куйды.— Синең үзеңне кем дип таныштырырга инде? Касыйм дияргәме, ашыйм дияргәме? Икесен әйтсәң дә туры килә. Күрәсең инде, Кәрам абый, бу егетнең теш тегермәне ничек тартканын... Мөмкин булса бөтен Себереңне тотып кимерер иде!

— Бозаулар боз ялаганда сыерлар су эчә,— диде Касыйм, алдындагы зур гына колбаса кисәген кабып куйгач.

Кәрам Ризванович бу таза гәүдәле, әвен кебек егетнең кергәннән бирле гел ашау белән генә булышып утырганын күргән иде инде. Касыйм, ничектер, сөйләшкәндә дә ашаудан туктамый, гүя азыкны да ул сүзе белән бергә чәйни, бергә йота.

Стаканнан тагын берәр йотым аракы кабып куйгач, Курамшин кызышып, үз-үзенә гаҗәпләнеп утыра башлады: булса да була икән кешедә чыдамлык! Авызга хәмер түгел, бер кисәк ипи дә каба алмый авып китәр төсле иде, хәзер тәненә яңадан көч, гайрәт йөгерде, ул үзен элеккедән дә ныграк, уяурак сизә башлады. Бу кеше дигәнеңнең мөмкинлекләре чиксез икән...

Моңа кадәр көләргә, шаярырга тырышып та ачылып бетә алмый интегеп утырган егетләр дә яхшы гына телгә килделәр. Алар Курамшиннан туган як турында, нефтьнең чыгу-чыкмавыннан башлап игеннәрнең торышына, хәтта явым-төшемнәргә кадәр сораштыра башладылар. Һәр җавапны авызга керердәй булып тыңлауларыннан Кәрам бу егетләрнең туган якларын бик тә сагынуларын, кайтасы, күрәсе килүләрен тоеп утырды.

— Я, Кәрам абый, сезне бирегә нинди җилләр ташлады? Озаккамы?

— Ике айга гына... Уйламаганда-көтмәгәндә тоттылар да җибәрделәр. Скважиналарга автоматлар куярга кирәк икән, имеш... Әйтерсең, Себернең үзендә кеше беткән!— Курамшин, зур хәсрәткә калган кешедәй, башын иеп утыра иде, тураеп егетләргә карады.— Нинди җир соң ул «Черек күл» дигәннәре? Еракмы?

— Черек күлгә җибәрделәрмени?!— дип, ничектер, дәррәү кузгалып куйдылар егетләр.— Без дә шунда эшлибез бит, абый! Электриклар без. Черек күлне яктыртырга маташып ятабыз!

— Әле электры да юк мыни?

Рафат, янынннан чебен куган кебек, кулын гына селтәде.

— Электр дисез сез, Кәрам абый. Багана утыртырга җире бармы дип сорагыз! Тапканнар да соң инде җирен, кайда борауларга урын! Саз боткасы бит ул, промысел түгел!

— Аяк кирәкми анда безгә, очып йөрергә канат кирәк!— дип өстәде Гергери.

— Канатлы фәрештәләр затыннан булганнар гына эшли биредә. Фәрештәме соң син, әллә кеше генәме?

Шулай тупас итеп, «син» дип дәшеп арада Касыйм гына сөйләшә. Курамшин аңлап бетерми әле бу егетне: әллә ул үзен бик эрегә куя, әллә көченә масая, әллә инде тәрбиясе шундый. Һәрхәлдә Курамшин Касыйм дигәнен ошатмый. Аның соравын да ишетмәскә булды.

Хәмердән тагын бераз кыза төшкәч, әлеге егет торып ук басты да учлары белән күкрәк йоннарын йолка-йолка:

— Син арада иң бәхетлебез, Рафат!— дип өзгәләнергә керешә.— Сабан туена кайтасың бит син, сабан туена! Их, билләргә сөлге салып бер генә көрәшәсе иде хәзер!..

— Күпсенмә, мин дә бер генә атнага! Анысын да үз исәбемә, тезләнеп ялынгач кына бирделәр.

Янәшә утырган Гергери, тәрҗемәче кебек, Курамшинның колагына хәлне аңлатып бара:

— Касыймның бишенче ел инде авылында булганы юк. Кыйнашкан өчен бер елга утырткannar аны. Срогын тутыргач, авылдашларыннан оялып, өенә кайтмаган, туры шушында килгән.

— Ни өчен сугышкан?

— Хатыны моны ташлап кияүгә чыккан да... көндәшен бу тотып кыйнаган!..

Гергеринең аңлатмаларын Касыйм ишетеп тора һәм тагын да үрсәләнеп китә:

— Кайтсам түзә алмам, чыдый алмам дип куркам! Я ирен, я үзен юк итәрмен!..

— Ә син нигә кайтмыйсың?— дип сорады Курамшин Гергеридән. Рафат белән Касыйм шырык-шырык көләргә тотындылар.

— Себердә ак эш тапкач кайтамыни!

— Инженер булгач, «Волга»ларга гына утырып кайтырга исәбе!

Кәрам Ризванович Гришаның битендәге, борын очындагы вак кына булып сибелгән шактый сөйкемле сипкелләренә карап торды да:

— Ник көләсез, — диде елмаеп. — Ният иткән — ерак киткән дигәннәр. Тырышса, инженер гына түгел, әллә кемең дә булыр иде.

Касыйм әйтмешли, арада иң бәхетлесе Рафат бугай. Аның бүген күңеле күктә йөзә, хыяллары диңгез булып чайкала. Рафатның авылда Садә исемле сөйгән кызы бар икән, шундый да чибәр, шундый да сөйкемле, имеш, андыйны бер җирдән дә таба алмыйсың...

Кызга карата мәдхияләрен үзе белән яшәгән егетләр Рафаттан унынчы, йөзенче тапкыр ишеткәннәрдер, ә һаман да әле беренче мәртәбә хәбәрдар булгандай, тәм белән тыңлыйлар.

— Сез ул кызны беләсез, Кәрам абый,— дип кабатларга маташа Рафат, өстәл аша кулларын суза-суза.— Укытучы Гариф кызы ич ул, безнең күрше. Менә шушындый кечкенә генә, түгәрәк кенә кыз!

— Бер дә хәтерләмим шул. Яшьләр белән аралашкан юк.

«Белмәмешкә салыша» дип, эченнән генә зарланып алды Рафат.

Чыннан да Курамшин үзе «Кияү булып төшкән» Бигәш авылыныкыларны начар белә, бигрәк тә яшьләрне танымый иде. Аның каравы, авылның читтән килеп йортка кергән бердәнбер кияven Бигәшләр бетереп беләләр. Хәтта, кирәгеннән артыгын да. Тиешле-тиешсезен дә. Мәсәлән, Кәрам Рафатны төсмерләми дә, ә Рафат исә инженер Курамшинның авылга килеп кайчан өйләнүен дә, хатынының исеме Хәтимә икәнен дә, шул Хәтимәне яратам, онытa алмыйм дип әйлешәйле Шәфрунның болар капка төбенә килеп, төннәрен гармун уйнап утыруларын да — барысын да белә.

Кәрам Ризванович болай дип уйлап утыра: инде кыз да чибәр, егет тә күркәм, өстәвенә бер-берсен бик яратышалар икән, алайса ник кавышмыйлар, кем тота?

Үзенә күрә моның да сәбәбе бар икән. Юлларына кителмәгән бәхетсезлек аркылы төшкән, кавышу насыйп булмаган...

— Караңгы яңгырлы төн,— дип, тавышына да бертөрле шом салып сөйли башлады Рафат.— Хезмәтне тутырып армиядән кайтам. Машинадан авыл читендә төшеп калдым да дәртләнеп-очынып караңгы, күзгә пычрак урамнан өйгә атлыйм. Өйдә әни, күршедә өч ел буе хат алышкан, вәгъдәләр куешкан кызым көтә. Мин үзем кайда гына барсам да кайту турында алдан хәбәр биреп куярга яратмыйм. Әле хәзер дә телеграмма сукмадым. Шулай кызык. Шап иттереп кинәт кайтып өйдәгеләрне дә, Садәне дә, авылдашларны да шаккатырырга исәп. Менә шулай. Үзем солдат итеге белән урамнан пыч-

рак ярып алга атлыйм, үзем өйләрне санyйм. Безнең йорт авыл башыннан унҗиденче. Сагындырылган. Сигезне санадым, тугызны, унны санадым, унберенчесендә йортлар бетте дә китте! Менә шулай, ышансаң ышан, ышанмасаң юк! Тукта, мәйтәм, бу нинди хикмәт әле, ялгышып башка урамга кердемме әллә? Өч ел эчендә авылны, өемне оныттыммы?

Шулай да аяк үзебезнең тирәне сизә, өйгә таба тартыла. Турыбызга барып җитсәм, ни күрәм: безнең өй урынында убылып торган чокыр! Анда янып күмергә әйләнгән бүрәнә башлары, кап-кара ишек, тәрәзә яңаклары, уалып беткән кирпечләр... Каршымда, җилдә ыңгырашып, янган-көйгән шәрә каен агачы чайкала... Шуңа сөялдем дә, йөземне каплап елап җибәрдем...

Рафат, җилкәләрен күтәреп авыр итеп сулап куйды, өстәлдән папирос алып кабызды.— Менә шулай...— дип, башын иеп тәтенен өреп торды да дәвам итте.— Урам аша Садәләр ягына чыктым. Аларның өйләре дә юк. Хәтерлисездер, Кәрам абый, заманында челтәрле карнизләре, бизәкле тәрәзә капкачлары белән урамга ямь биреп, бөтен авылны кызыктырып тора иде бит ул... Үзебезнекеләрнең кайда икәннәрен дә кешеләрдән сорашып кына белдем: югары очта, чыбык очы тиешле абзыйлар мунчасында торалар икән.

Моннан берничә ел элек Бигәш авылында булган көчле янгын Курамшинның да нык хәтерендә. Октябрь урталарында, коры, җилле көнне булды бу фаҗига. Өч малайның шуклыгыннан башланган дип сөйләделәр. Галәмгә ракета җибәрәбез дип, үзләре ясаган аппаратларын мунча башына төшергәннәр дә, түбәгә ут капкач качканнар. Әйе, коточкыч янгын булды авылда, балалар уены халык өстенә зур каза булып төште.

— Ә кызың белән ничек очраштың?— дип, малайларча кызыксынып куйды Курамшин.

— Садәне мин һич тә ул хәлендә күрермен дип уйламаган идем... Ул бик матур, пөхтә киенергә ярата иде. Ни әйтсәң дә авылда бер дигән укытучы кызы. Шуңа күрә өстендә ефәк тә затлы йон күлмәк, аягында ялтырап торган лаклы туфлиләр генә булыр. Янгач, мәктәпнең бер классында торалар икән. Чакырып чыгарсам, ни күрим: өстенә иске генә киемнәр кигән бер кыз. Танымыйм. «Садә, бу синме, син булсаң бар, киенеп чык, клубка киттек» мин әйтәм. «Нәрсә киим соң, бөтен байлыгым, бар булган бирнәм шушында инде минем»,— ди, үксеп-үксеп елый, юләр!

— Син инде күлмәгеннән курыктың да Себергә качтың! — дип куйды Касыйм, кызарган күзләрен иптәшенә төбәп.

Аның соравы Рафатны котыртып җибәрде:

— Мин түгел шул, ул курыкты! Уйлап кара, суз куешылган, армиядән кайту белән туй ясау турында килешенгән, ә ул бирнәләрем янды дип утыра!

— Барыбер өйләнергә иде!

— Кая алып кайтырга?

— Мунчага!— дип үрти аны Касыйм һаман.— Яшь кәләш белән мунча керү борынгыдан калган гадәт!

Арада олы кеше буларак, кызып барган бу мәҗлесне Курамшин сүрелдерергә ашыкты.

— Чыннан да, көлке түгел, егетләр. Үз күзләрем белән күрдем ул янгынны. Скважиналардан, ерак буровойлардан нефтьчеләр кайтты, тревога белән тирә-як шәһәрләрдән янгын машиналары килде. Авылны айкап, актарып янган утны тиз генә баса алмадылар — бер-ике сәгать эчендә кырыктан артык йорт кара күмергә калды, ихаталар, мунчалар юк булды, абзарларда маллар, кош-кортлар һәлак булды.

Минем бригада. ул көнне, сулы чиләкләр белән түбәдә торып, янәшәдә, ялкын астында мәктәпне саклап калган иде. Яңа мәктәпне...

Кәрам Ризвановичның күптәнге янгын турында сөйләп утыруы Касыймны да, Гришаны да уйга сала алмады. Аларның фикерләре башкада иде.

Бу юлы инде Рафатка тыныч кына утырган керәшен егете бәйләнә башлады:

— Шулай да, Рафат, мондый чакта авылыңны, әниеңне, сөйгән ярыңны ташлап китү егетлек түгел!

— Минем урында нишләр идең, хәсрәт? Я, нишләр идең?!

— Шунда эшкә керер идем, акча эшләр идем дә өй салып бирер идем!

— Ул вакытта колхоздамы акча?

— Ә ник нефть эшенә кермәдең?— дип сорады Курамшин тыныч кына.— Әнә, сездә нефтьчеләр йортларын бик тиз өлгертеп керделәр. Нефть идарәсе агачын да, шиферын да бирде, машина белән дә булышты.

Рафат, тирән сулап, тәмәкесен өстәлгә ыргытты.

— Барган идем мин нефтьчеләр янына, алмадылар. Һөнәрең юк диделәр.

— Минем бригадага киләсең калган, туп-туры үземә.

— Әх, Кәрам Ризванович!— дип, кинәт урыныннан сикереп торды егет.— Килдем бит, килдем! Хәтерлисезме, скважина янында очраштык? Безгә тәҗрибәле кеше кирәк, энем, дидегез. Җитмәсә, «тараканның мыеклары нәрсәгә хезмәт итә?»— дип көлке сорау бирдегез...

Курамшин уңайсызланып кулъяулыгын чыгарды, борын өстендә ялтыраган тир бөртекләрен сөртеп алды. Менә бит ничек килеп чыккан... Шундый яхшы, яшь егет мөрәҗәгать иткән булган эш сорап, ә ул, мастер Курамшин, шул авылның кияве, сорашып-танышып та тормыйча аны кире борып җибәргән... «Тау белән тау гына очрашмый» дип бик белеп әйткәннәр шул. Менә кайда китереп кавыштырды язмыш.

Әле генә шау-гөж килеп торган вагон эче бер мизгелгә тынып калды. Кәрам янындагы Гриша торып китте дә урынына барып мыштым гына ятты, боларга арты белән борылды.

Урындыгын каты шыгырдатып Касыйм да кузгалды. Ул кухняга чыгып нәрсәләрдер шалтыратып йөрде, краннан су агызып аны чутылдатып эчте. Аның:

— Интеллигент атала, үзе инженер, анасының кабер тактасы!— дип мыгырданып сүгенгәне ишетелә иде.

Рафат исә, башын алдындагы стаканга иеп, сүзсез утыра, табынның ямен җибәргәнгә, кунакның хәтерен калдырганга үкенә иде.

— Хәзер кирәкми инде, бары да үтте, онытылды,— диде егет, ниһаять бераздан.— Сабан туена кайтам бит, егетләр, туган илгә!

Курамшин тәрәзәгә күз салды. Тышта яктыра башлаган, тезелеп киткән вагон түбәләре өстендә соргылт наратларның очлары калкып тора иде.

Курамшинның арган, борчылган йөзенә карап алгач:

— Ятыгыз, Кәрам абый, ял итегез,— диде Рафат.— Ә мин ятмыйм. Күзгә йокы керми барыбер... Кайту дәрте... — Үзенең урынын туздырып ташлады, мендәрен күпертеп куйды.

— Рәхмәт, хәзер мин дә китәм. Хәерле юл сиңа.

Курамшин урыныннан кузгалды.

— Хәтимә апага нәрсә дияргә соң, Кәрам Ризванович? Сәлам әйтергәме?

Курамшин уйлап-уйлап торды да кул селтәде.
— Үзем хат язармын әле. Очратсаң, күрмәдем диген, шул гына.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Менә нинди икәнсең, Себер! Гасырлар буе кеше аягы басмаган урманнар иле, кеше күзе күрмәгән күлләр, баткак сазлыклар, мәңгелек туң җирләр иле, шушы мыни инде син? Ерак Себер дип, салкын Себер, куркыныч Себер дип, тарих тарафыннан бөтен ләгънәтләре белән каргалган, яшәү-тору өчен яраксызга чыгарылган хикмәтле, серле җир син буласың мыни? Канлы патша әмере белән сөрелгән кыю декабристларга сыенып урын биргән, ирек даулап баш күтәргән юксылларны залим изүчеләрдән, түрәләрдән яшергән, император тәхетләрен дер селкеткән революционерларны үз кочагына алган иркен, киң күңелле Себер, кырыс һәм мәһабәт Себер, син мени бу?

Курамшин, машинаны туктатып кабинадан төште дә, каршысында куе яшел стена, алай гына да түгел, зәңгәрсу-көрән тау булып баскан чыршы урманына текәлде. Онытылып, хәйранга калып, шомланып басып торды. Шушы калын, тыгыз урман-стена аша инә-буе белән бөтен Себерне — Уралдан алып Иртыш, Обь елгаларына кадәр сузылган, аннан ары Енисей һәм Лена буйларына җәелгән, ахыры Ерак Көнчыгышка барып тоташкан тулы бер Себерне күз алдына китермәкче булды.

Китапларда Себерне яшел океан дип тә, урманнар материгы дип тә язалар, дөньяның җиденче континенты дип тә атыйлар. Уйласаң хәйранга калмый чара юк: шушы Көнбатыш Себер тигезлегенең Төмән өлкәсенә кергән яртысы гына да миллион ярым квадрат километр икән. Аңа Англия, Франция, Италия, Германия Федератив республикасы, Голландия, Дания һәм Люксембург кебек эреле-ваклы җиде ил сыя.

Курамшин үзен Себер урманнарына кереп адашкан бер кечкенә, мәхлүк бөҗәк итеп тойды һәм, шушы иксез-чиксез тайгада юл тапмыйча курыккандай, кырт борылып машинага кереп утырды.

Шофердан башка, кабинада мастер Аввакумов та бар иде. Төртмә телле, бик бәйләнчек кеше. Ул Черек күл мәйданында эшли, бораулаучылардан скважиналарны кабул итеп, аларны җиһазлау, көйләү, ходка җибәрү белән мәшгуль икән.

Командировкага килгән яңа танышының турист шикелле гел тукталып, муенын суза-суза каранып баруына ачуы килә башлады аның.

— Шул инде ул командировкага килгән кешеләрнең! Белмим, нинди кызык таба торганнардыр...

— Мин бит Себердә беренче тапкыр...

Аввакумов шоферга машинаны ашыктырырга кушты.

Чыннан да, барасы җир ерак — кырык километрдан артык. Төнлә яңгыр явып, болай да йомшак, баткак юлны тагын да изрәткән — тәгәрмәчләр әле уң, әле сул эзгә кереп чума, машина әвеш-тәвеш килә, Кәрамны як-якка бәрә, башын чайкарга мәҗбүр итә иде.

— Тотыныбрак утырыгыз,— ди Аввакумов, үзенә черем итәргә комачаулаган Курамшинга таба борылып.— Ныграк тотыныгыз!

Кәрам, моторның көчәнеп, елак тавыш чыгарып баруын пошынып тыңлы-тыңлый һаман Себер турында уйлана. Ләкин уйларының очыочка ялганмый, фикерләре тарала, үткәннәре, бүгенгесе, киләчәге бергә бутала.

Кичә кунак йортына урнашкач газеталар караштырып утырган иде Курамшин. Төмән газетасы өлкәнең төньягында тагын бер зур нефть

һәм газ ятмасы табылу турында хәбәр итеп, язучы Радищев хатыннан бер кызыклы өзек китергән: «Нинди бай як бу, Себер дигәнең, нинди куәтле як! Гасырлар үтәр, һәм ул үзләштерелгәч, аңа дөнья елъязмасында зур роль уйнау насыйп булыр».— дип язган Илим төрмәсеннән Радищев. Нинди гаҗәп күрәзәлек!

Әйе, бу яклардан — Себер юллары, Тубыл тракты буйлап беренче рус революционерлары — декабристлар узганнар.

Тубыл зиратында декабристлардан Фердинанд Вольфның, Муравьевның, Кюхельбекерның, Краснокуцкийның һәм украин шагыйре Гребовскийның каберләре калган. Бу якларда — ирек җырчылары Радищев, Чернышевский, Достоевский, Короленко, Фонвизинның аяк эзләре. Алар ерак сөргеннәрдә дә, зинданнарда да Россиянең матур киләчәге турында хыялланганнар, кайчан да булса Себернең үсәчәгенә, чәчәк атачагына ышанып яшәгәннәр.

Ә шул ук вакытта патша чиновниклары Тубыл губернасы турында мондый мәгълүматлар биргән: «...Губерня гаҗәеп ярлы... хәтта Урал сыртының губерняга кергән өлеше дә... киләчәктә файдалы казылмалар чыгарырлык өмет билгеләре күрсәткәне юк».

Бирегә шәһәрләр төзү өчен гади таш белән известьны да Пермь һәм Семипалат губерналарыннан китерткәннәр. Юк, теше үтмәгән, көче җитмәгән патша властенең Себер байлыкларын ачарга!

Күзеннән бер нәрсәне дә ычкындырмыйча әле бер, әле икенче тәрәзәгә карап бара Курамшин. Юл буйларында су тулып торган зурзур чокырлар һәм шунда йөзгән агачлар, сазга батып тәгәрмәчләре я морҗалары гына күренеп торган тракторлар һәм краннар, давылда ауган нарат урманнары, ниндидер күл уртасында багана кагып, электр, телефон линияләре үткәрергә азапланучы эшчеләр, озын траншея буйлап сузылган нефть торбалары һәм торба өстендә якты чаткылар сибеп ятучы сварщиклар... Кәрам кабинада селкенә, кымырҗый, янында утырып баручы Аввакумовка да комачаулый иде бугай. Үзе: «Ничек әле: «Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәннең качасы килә»,— диләрме? Туярсың әле, гарык булырсың, дустым! Командировкаң гына чыдасын!»— дип мыгырдана.

Себер нефтьчесе, мастер Виталий Иванович Аввакумов белән Курамшин кичә идарәдә, баш инженер Бабиков бүлмәсендә танышкан иде. Дөресрәге, баш инженер аны кайдандыр үзе чакыртып китерде.

Сәер холыклы, үзсүзле кеше икән Аввакумов дигәннәре, командировкага килгәннәрне җене сөйми ахры. Курамшинны күрү-танышу белән:

— Миңа толкач кирәкми, миңа эшчеләр, нефтьчеләр кирәк!— дип бәргәләнә башлады. Кыен булды Курамшинга, шул чак чыгып йөгерәсе, үпкәләп кайтып китәсе килде аның. Әмма бик тиз тынычландырды Аввакумовны баш инженер — өстәл тартмасыннан бер кәгазь алып укуы җитә калды. Бу — Төмәннән шушы көннәрдә килгән приказ иде. Бу — мөһим дәүләт заданиесе, диелгән.

Бүген Аввакумов басылган, хәтта бераз яхшыра да төшкән кебек. Иң беренче эше итеп, әлегә Черек күл мәйданы, андагы эшләр, кешеләр белән таныштырырга булды, машинасын китертте, кабина кысырык булса да, янына урын бирде. Шулай да әле ул Курамшинга килмешәк итеп карый, җае туры килгәндә чәнечкеле сүзләр дә ычкындыра.

— Ардым,— ди ул, көрсенеп.— Көн-төн эш, скважина да нефть, үземә дә бераз командировкага чыгып кирми булмас, ахры. Командировочный кешенең эше рәхәт бит аның: ашау патшадан, йөрү тактадан. Бер нәрсә өчен дә кайгырмыйсың, һич нәрсә өчен җавап бирмисең. Аңа нәрсә: үгез үлсә ит, арба ватылса утын...

— Шулай йөргәнең булдымы?

— Туры килде. Өченче ел Бакуга автоматлар буенча киңәшмәгә

җибәргәннәр иде. Тәҗрибә уртаклашу кебек тә нәрсә иде инде ул үзе. Барсам, анда нефть чыгаручылар түгел, ә бораулаучылар җыелган икән. Мин нинди бораулаучы инде, я? Алар бораулар, турбобурлар, гидромониторлар һәм ачкычлар турында, ә мин үземнең нефть үлчәгечләрне, скважиналарны, автомат япкычларын сөйлим. Кыскасы, кем урман, кем утын турында. Шыксыз үрдәк урынына, ни эшләргә белми, бер көн иреп йөрдем боларга, ике көн, ахырда тәкатем калмады, әйттем шундагы җитәкчегә: рәхмәт чакыруыгызга, мин әйтәм, бораулаучы булмасым килми, коткарыгыз ул һөнәрдән, кайтам, дим. Авызны да ачырмый. Что син, ди бу, Себер кадәр Себердән килгәнсең, ул яктан вәкил булдымы, дип сорасалар нәрсә дип җавап бирермен, зинһар кал. Күңелсез булса әнә дингез, әнә пляж, кызын да ят!— ди бу. Җитәкченең киңәшен тыңларга туры килде. Күптән шулай рәхәт ял иткән юк, курортка барырга вакыт тими иде — командировкадан тазарып, кояшта чүл гарәбе кебек каралып, чыныгып кайтып кердем.

— Миңа монда әлегә кызыныр урын күренми,— дип Аввакумовның лыгырдап баруына ачуы килеп әйтеп куйды Курамшин.

— Анысы шулай инде... Шартлар җитешеп бетми шул бездә,— дип, тагын үчекләп алды Аввакумов, янә командировка хәлләрен сөйли башлады:

— Хәер, теләгән кеше монда да җаен таба инде ул командировканың. Быел яз бер айга эшкә дип сварщик килгән иде. Безнең идарәнең үтенече буенча Куйбышевтан авралга дип җибәргәннәр боларны. Ягъни безнең үз вакытында ялганып бетмәгән торбаларны ялгарга. Килделәр — эшләмиләр, каһәрләр! Берсе торба өстенә менеп утыра да, көн-төн өенә хат язуда, икенчесе, «маскасын» киеп, электродын тотып, торба астына кереп ята да йокы симертә.

Кәрам, дөресме-юкмы дигәндәй, Аввакумовның авызына карап ала. Себер мастерының зур авызы, кабартма кебек калын иреннәре кешедән көлү, кеше ирештерү өчен махсус ясап куйган кебек тоела аңа. Әнә аның шоферы да, юлны онытып диярлек, түрәсенең авызына күбрәк карый. Кызыкмы, кызык түгелме, күркә гөлдерәвен хәтерләтеп көлеп бара.

Әллә булганны, әллә юкны сөйли Аввакумов, шулай да Курамшинга төрттергәне ачык. «Улым сиңа әйтәм, киленем син тыңла!»— димәкче була картлач. Акыл өйрәтеп маташа.

Аввакумов Курамшинга табарак борылып утырды да, күзен елтыратып, хәйләкәр генә сорап куйды.

— Синең соң, семьяң бардыр бит?

— Бу яшьтә семьясы булмаган кешенең, минемчә, камиллеген тикшереп карарга кирәк.

— Анысы шулай инде...— дип килешә Аввакумов, су капкандай кинәт тынып кала.

Шул чак Курамшин үзе дә, яңа өйләнгән егет кебек, тәкать тота алмый хатынын сагынганын тойды, балаларын юксынып куйды. Килгәч тә хәт язарга, я телефоннан шалтыратырга иде. Ничектер, вакыт тар булды. Аннары урнашып-көйләнеп беткәч хәбәр итәрмен диде. Әйе, мондагы хәлләрнең барысын да Хәтимәсенә түкми-чәчми соңыннан, бүген булмаса иртәгә язар әле. Аңынчы Черек күлнең үзен күрергә, эше, кешеләре белән танышырга, барыннан да бигрәк якын дусты, сабакташы Пичуговны табарга, аның белән очрашырга кирәк.

Килгәндә һәм килгәч шушы бер-ике көн эчендә генә дә онытылмаслык, әсәрләнерлек тәэсирләр алды Курамшин. Ләкин әле бу күз өстеннән шуып үткән беренче тәэсирләр генә, әле алда тагын да кызыклырак, матуррак нәрсәләр көтәдер. Язар әле бу турыда хатка. Янсә кайткач, Хәтимәсенә кич утырып сөйләр, төн ката сөйләр. Юк, язып, сөйләп кенә аңлата торган нәрсә түгел — үзенчә бер дөнья икән бу Себер!

Машина уң якка салулап тәгәрмәч чокырына кереп батмаса, гел дә матур буласы иде беренче сәяхәт.

Әйе, нык утырды машина. Тизлек рычагын бер алга этеп, бер артка тартып, рульне тегеләй дә, болай да әйләндерүгә карамастан, шофер ның ун көпчәкле «Урал»ы селкенергә дә теләмәде.

— Ачык авыз, нәрсә карадың!— диде шоферына Аввакумов, усал гына.

Курамшин белән Аввакумов юл кырыена сикерделәр дә икесе берь юлы машинаның бортына ябыштылар.

— Раз, два, взяли! Еще раз, взяли! Раз, два...

Көпчәкләр артка пычрак атып бертуктаусыз әйләнә, әйләнгән саен астан казып тирәнрәк чума бара иде.

— Стоп!— дип кулын селекте Аввакумов шоферга.— Маташма! Кая, төшер агачларны.

Кирәк очракларда тәгәрмәчләр астына салу өчен машина әрҗәсендә һәрвакыт бүрәнәләр, такталар йөртәләр икән болар. Шуларны алга күпер итеп җәйгәч бик тиз күтәрелде машина.

Киттеләр. Өч-дүрт чакрым да үтәргә өлгермәделәр, тагын кереп батты машина. Начар юлның мең гөнаһларын шофер өстенә аударып, хуҗа тагын тиргәргә кереште:

— Күзеңә кыярак үстеме аллә, җебегән! Кулыңа руль түгел, шакшы себерке тоттырырга синең!

Бу юлы әрҗәдә иң соңгы чиккә дип калдырылган берничә бүрәнә һәм такта кисәкләре дә, ниндидер иске капчыклар да, хәтта запас баллон да коткара алмады машинаны сазлыктан. Ул башта тәгәрмәчләреннән, аннан әрҗәсеннән үк кереп батты. Шуны этә-этә Аввакумов белән Курамшин хәлдән тайдылар, бот төбеннән лайга чумдылар, өс башлары дегет кебек кара сыекча белән капланды.

Өздереп, камчылап яңгыр ява башлады.

— Ходай тәгаләдән трактор көтәргә кала,— диде хуҗа, битен, маңгаен чуарлаган балчык тапларын ак кульяулыгы белән сөртә-сөртә.

— Ходайда бармы андый трактор?

— Ялварып сорасаң, бәлки җибәрер...

Икесе дә кабинага кереп утырдылар. Аввакумов, яны белән борылып үзенә урын җайлагач, зарлана башлады.

— Менә шулай инде, иптәш командировочный, монда. Шушы шофер төсле бәбәгеңне ачыбрак йөрмәсәң утырасың да каласың. Аннан сапа сәгатьләреңне, көт кем дә булса килеп чыкканны. Грузовик кына тартып чыгара алмый, трактор я бульдозер кирәк. Авария командасы таләп ителәә. Дежурда йөриләр алар. Бу участокта гадәттә Фая була. Көтик, бераздан килеп чыгар...

Куе җирән сакалы белән мыегы арасына папирос кыстырып куйгач, сүзен дәвам итте:

— Между прочим, еезнең яклардан. Татар хатыны. Әйт әле, сездә хатын-кызлар бар да шундыймы?

— Нинди?

— Белмим, курыкмыйча нинди ана тудыргандыр аны — ут инде менә! Чын иблис токымыннан! Между прочим, молодец үзе. Ун иргә дә алмашмас идем аны.

Әйтеп тә бетермәде, барасы яктан гөрелдәп трактор тавышы да ишетелә башлады.

— Әнә, әйттем бит килә. Фая үзе, шәйтан алгыры!

Калын корыч бауны өчәүләп тоткан хәлдә, бульдозерны көтеп алдылар.

— Әйдә, каптыр!— дип кычкырды кабина ишегеннән башын чыгарып Фая дигәннәре. Ничектер, бульдозерны оста, кырт арты белән борып, җиргә сикерде.

— Ә-ә, син мени эле?— дип күптәнге танышыдай килеп Аввакумовка кул бирде бульдозерчы хатын.— Шулай дип уйлаган идем аны. Ничә карасаң син батып ятасың!

Кәрамга таба борылды Фая. Аның белән күзгә-күз карашып, шул мәлдә катып калды.— Курамшин?!

Кырт борылды да, ирләр кебек эре-эре атлап, бульдозеры янына китте, бер талпынуда тәгәрмәч чылбырына сикереп кунды, йомран житезлеге белән ишеге ачык кабинага чумды.

Бу хатын Кәрамнең якташы Фәнүзә иде.

Аның очравы Курамшинның кәефен кырды да төшерде. Исән-сау килеп житү, авылдашы Рафат, якташ егетләр белән очрашу, кунак йортына урнашу шатлыклары, Себер турындагы матур тәэсирләре — барысы эреп юкка чыккандай булды.

— Менә сиңа Фая! Каян килеп чыккан әле бу Фәнүзә бирегә? Киткәндә генә коммутаторда телефоннан «Утыз өч» дип җавап биреп утыра иде түгелме? Бик тә охшаган иде бит тавышы. Алайса, кемнән гафу үтенде Кәрам?

Бульдозер бер талпынуда өч кучәрле «Урал»ны ныклы юлга өстерәп чыгарды. Фәнүзә машинадан бауны ычкындыргач та китмәде, тагын батарлар дипме, әкрен генә арттан озата барды.

— Кара син аны ничек килеп чыкты: заманында мин аны батырдым, хәзер ул мине тартып чыгарды...

Моны үзалдына елмаеп та, тирән көрсенеп тә әйтте Курамшин.



## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Кайсы кайда урын табып, кешеләр йоклап беткәч тә әле Ишәй абзый калай мичкәдән ясалган буржуй корсаклы мич каршында утыра бирде. Арган булса да йокламады. Хәер, өй эчендә ятарлык урын да юк иде. Өстәвенә, юлда яңгырда чыланып килгән кешеләрнең өс-башларын, киемнәрен дә киптерергә кирәк.

Ул мич авызына шылтырап торган нарат утыннарын өсти торды, кесәләрен капшап, әледән-әле тәмәке төреп тартты, менә сүнәм, менә сүнәм дип утырган куыклы лампаның филтәсен үрелеп күтәргәләде һәм аркылы-торкылы ятып йоклаган кешеләргә шул арада каш астыннан гына карап алды.

Дөньяда бәхетле кешеләр генә шулай ваемсыз йоклый торгандыр,— дип уйлап куйды Ишәй. Ә болар бәхетле микән соң? Ай-һай! Гамьсезләр. Туган якларын ташлап киткән кешеләр бәхетле булмый. Була да алмый.

Ишәй абзый төрле рәвештә йоклап яткан халыкка хәйран калып, сирпеп янган лампа яктысында озак кына карап торды. Кешеләрнең күбесе хырлый, борын сызгырта, ямьсез итеп иреннәрен пырылдата иде.

Ишәй, янчыгын чыгарып, кәгазьгә тагын бер чеметем тәмәке салды, ике бармагы белән тәрә-тәрә үз эченнән тагын сөйләнә китте:

— Ярый, яшьрәкләр килсен дә инде. Аларның шундый чагы: булмаган бәхетне эзлиләр, чыкмаган кояшка кызыналар, тумаган тайның билен сындыралар. Аларга мондый хыял килешә дә. Ә соң әнә теге,— Ишәй сул почмакта гырлап яткан җирән мыеклы кешегә таба иягең күтәрде,— теге алашасына ни җитмәгән? Ә бит әле аның хатыны, өй тулы балалары калгандыр...

Иң түрдә, өеп куйган такталар өстендәге кызга игътибар итте Ишәй.— Тагын килеп, менә бу бичара кызга Себер тайгасында нәмә кирәк булды икән?

Сабый балаларча бөкләнеп, тезләрен иягенә терәп йоклый иде кыз.

Аның күлмәк итәге сыдырылып менгән дә, шалкан төсле ак, шәрә ботлары күренеп ята. Ишәй торды, кешеләр арасыннан сак кына үтеп, кыз янына килде һәм итәген каплады.

— Әй, дөнья, кеше дигән бәндәләрне кайларга гына илтеп ыргытмыйсың да, нинди генә нужаларга тартмыйсың син!— дип көрсенә-көрсенә, янә мич каршына килеп утырды.

Шул чакта тышта трактор гөрләгән тавыш ишетелде.

— Бу вакытта тагын нинди кешеләр йөри икән?— дип, мыгырдана-мыгырдана, Ишәй карт вагон ишеген ачты, иплəп кенә лычкылдык җиргә төште.

Юлдан яңгырлы кара төнне утлары белән айкый-айкый бульдозер килә, ул корыч бау белән артына йөк машинасы таккан иде. Менә ул, тирә-якны нурга күмеп, нәкъ вагон алдына килеп туктады. Кабина эченә үрелеп карады да, Фәнүзәне танып алды Ишәй.

— Ә-ә, син мени әле, кызым? Ник болай соңлап?

— Кунаклар китердем,— диде Фәнүзә, кабина ишегеннән башын чыгарып.— Батып яталар иде. Шофер белән безнең Аввакумов. Өченчесе минем якташ, Курамшин, бик зур начальник...

— Шулай мыни!— дип гаҗәпләнде Ишәй. Үзе: «Кая гына куярмын икән соң бу зур начальникны?» — дип борчылып алды.

Кечкенә бер вагонга кешеләрне китерәләр дә тутыралар, китерәләр дә тутыралар. Нинди кыямәт кузгалды соң әле Черек күлдә?

Фәнүзәгә рәхмәтләр укый-укый, Аввакумов, аның шоферы һәм Курамшин өчәүләп машинадан корыч бауны ычкындырдылар. Бульдозер китәргә бөрылгач, аны туктатып, Курамшин Фәнүзә янына сикереп менде:

— Сине каян табарга, Фәнүзә? Ял көне өйдә буласыңмы?

— Тырышырмын. Онытма, кызлар барагы уналты да биш. Фәнүзә дип сорасаң әйтерләр!

Бульдозер китеп тә барды. Дүрт ир караңгыда машина янында калдылар.

— Гүрничәндә йокларлык урын бармы, Ишәй абзый?— дип сорады Аввакумов.

— Энә төртер урын да юк, Виталий Иванович,— диде карт, гаепле кешедәй, кулларын җәеп.— Яңгыр көчәю белән вышкачылар да кайтып тулды, торба салучылар да. Аннары Кузьма Николаевич тагын бер төркем кеше китерде. Самара ягыннан диме шунда.

«Кузьма Николаевич» сүзен ишетү белән Курамшин сагаеп калды: «Кузя Пичугов бит бу. Димәк, шушында эшли... Кешеләр ташып йөри микәнни?»

Сорашып торыр урын түгел, вакыты да юк иде — вагонга керделәр.

— У-һу — дип куйды Аввакумов төрлесе төрле җирдә ауган кешеләрне күреп.— Лутчы мин машинада гына кунам. Утырган килеш. Сиңа хәерле төн, Кәрам Ризванович.

— Хәерле.

Аввакумов белән шофер чыгып киткәч тә, нишләргә белми аптырап, кешеләр өстенә озак кына карап торды Курамшин. Нәкъ чегән таборы!

— Урын табыгыз да ятыгыз инде,— диде аңа Ишәй, кисәү агачы белән мичтәге утыннарны этәләп.

— Ә үзең нигә йокламыйсың?

— Кешеләр йокласын дип...

Кәрам арган иде, ятарга урын эзләп янә вагон эчен айкап чыкты. Әнә тегендә, түрдәрәк баш төртерлек урын бар төсле. Ярый, аз булса да черем итеп алырга кирәк...

Ике таза гына ир уртасына кереп плащын җәйде. Пинжәген баш очына салды. Теге кешеләрнең сул яктагысы кысылып урын бирде, уң яктагысы торып утырды да:

— Аналарын дыңгыр-дыңгыр, монда да тынычлык бирмиләр!— дип сүгенеп, өстенә ябынган фуфайкасын Курамшинның баш очына этәрде. — Ал һәм бүтән тынының чыгарма!

Ишәй, ерак елларга китеп, үзенең туган якларында калган, хәзер утыз биш-утыз алты яшь булырга тиешле ике баласын исенә төшереп алды — туң йөрәге, таш булып каткан бәгыре йомшап киткәндәй булды. Гомер дигәнең ике килсә, хәзер һич тә ятим итмәс иде кебек.

Гөнаһлы тормыш әкияттәге җен кебек җилкәсенә менеп атлана, кусаң да төшми торган авыр йөккә, вөҗдан газабына әверелә икән. Моны Ишәй элегрәк яшьлек тилелеге, җилбәзәклеге аркасында белмәгән, гомерен җиңел генә үткәреп җибәргән. Көн узган, картайган саен аның фани дөньяда кылган эшләре, күрсәткән әкәмәтләре күңел түренәрәк үрмәли барды, ниһаять, бугазыннан буып, тынын кыса башлады...

Башкалар кебек тыныч кына, ипле генә яшәргә иде аңа — нигә шулай кылгандыр, хәзер үзе дә аптырый. Тынгысыз холкы, тиктормас табигате кушкандыр аңа. Шулдыр. «Мөгез чыгарырга» ярата торган гадәтләре чамадан артык иде бит Ишәйнең.

Юк, ул башкалар кебек куркып, пыскып, хода язмышына бирелеп яшәүне өнәмәде. Егерме беренче елны ул ун алты яшьлек Ишмөхәммәт, авылдашлары сыман, ачлык бугаздан алганны, селкеп салганны көтеп ятмады. Ата-анасыннан качып, станциядә беренче очраган поездга ябышты да, күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга китеп барды. Казах далаларында, Иртыш буйларында көтү көтеп йөрде, Омскига килеп такта яру заводына эшкә ялланды. Зыңгылдап әйләнгән пычкы тавышы ул көннәрдә моңлы көй булып ишетелә иде аңа.

Кесәсенә аз гына акча керү белән үк, егет, һичнәрсәгә карамыйча, кучәрләре-ниләре белән түгәрәк пычкы сатып алды, шыр тиледәй, шуны күтәреп туган авылына кайтып егылды. «Ишәй кайткан икән, юләрләнгән, кием-салым урынына бер сандык тимер-томыр төяп кайткан»,— дип гөж килеп сөйләделәр авылда. Әйдә, сөйләсеннәр, көлсеннәр, Ишәй күрсәтер әле кемлеген.

Хәер, авылда теге гайбәтчеләр кебек барысы да томана надан түгел икән, түгәрәк пычкының серен аңлый торган, бәһасен белә торган кешеләр дә бар икән әле.

Тегермәнче Мәүлет кергән иде Ишәй янына — күзе шар булды пычкыны күреп. «Нигә әрәм итеп яткырасың моны? Бу бит хәзинә! Бу бит минут эчендә бүрәнәңне телеп ыргыта!»— дип аһ итте.

НЭП заманы, кулакларның баерга тырышып котырган вакытлары иде. Мәүлет Ишәйгә шундый бер кызыктыргыч тәкъдим ясады: «Пычкы — синнән, ясау — миннән, эшләү — синнән, ашау — миннән. Әйдә, бүгеннән үк тегермән буасында такта яру заводы ачабыз!»

Әти-әниләре, туганнары ачлык елны үлгән, йорт-җирсез, мал-туарсыз ялгыз егет кая барсын? Риза булды. Аннан, Мәүлет әйтмешли, иген игеп кем баеган? Ә пычкыдан әйләнгән саен такта чыга, тактадан пычкы чүбедәй акча чыга... Килешенде, куллар кулга шапылдап сугылды.

Акчадан да бигрәк завод дигән шөһрәтле исем кызыктырды бугай Ишәйне. Завод! Омскидагы кебек озын-озын цехлары, биек морҗалары, өем-өем такталары һәм йөзләгән эшчеләре белән күз алдына китерде ул тегермән буасындагы заводны.

Үзенә дигәндә Мәүлет җир тычканы кебек— әллә кайлардан юл сала, әллә нәрсәләр юнәтә. Килешкән атнаны ук тегермәннең өч ат тарта алмаслык ташын кубарып алды, биш-алты көн дигәндә куласа кучәренә каеш тарттырып станок ясады, пычкы көйләп куйды һәм бүрәнәләрне ярдыра башлады.

Халыкның сугыштан, ачлыктан-хәерчелектән яңа мантып килә торган чагы, йорт җирен, каралты-курасын тергезә башлаган чоры — агач-

ка мохтаҗлык күп, хәтта тирә-як авыллардан да килеп тегермән буасы янында чират торып такта ярдыралар. «Егәр егермедә килер» дигәннәр бит. Ишәйнең беләгендә көче, йөрәгендә дәрте ташып торган чак. Мәүлет заказлар кабул итә, Ишәй көне-төне бүрәнәләр телә...

Бары бер ел дигәндә, Ишмөхәммәт, бөтен авылның исен китәреп, шыңгырдап торган нарат бүрнәләрдән алты почмаклы менә дигән йорт салып керде, җитмәсә аның түбәсен калай белән дә яптырды. Ул гына да түгел, өй артындагы чирек гектар бәрәңге бакчасын казып алма агачлары утыртты. Монысы инде хәтта төрле планнар корырга, шухыр-мухыр ясарга һәвәс булган Мәүлетне дә таң калдырды.

Егетнең кулга осталыгын, эшкә булганлыгын һәм малга хирслеген күреп-тоеп торган Мәүлет үзенең утырып калган кылый кызын — Мәгъмүрәсен димләтү өчен егеткә яшерен яучылар җибәрә башлады. Имеш, ялгыз йорт — ямьсез йорт, дөнья көтү өчен башлы-күзле булырга кирәк, ә зур хуҗалыкны алып бару мал-туар күреп үскән бай кызының гына кулыннан килә. Андый кыз авылда бер генә, бары Мәгъмүрә генә...

Эш арасында булмасын, табында утырганда булмасын, Мәүлетнең телендә бары тик зур хуҗалык, уңган хатын булырга лаеклы берданбер Мәгъмүрә генә иде.

Ишәй Мәүлеткә гаҗәпләнеп бетә алмый: үз итеп, тиңе итеп сөйләшкән була бит бу бай азгыны. Ә Ишәй бит аны ялантәпиле малай чагыннан, әтисе белән тегермәнгә килгән вакытлардан бирле белә. Болай иш итеп, чәй янында, ачылып сөйләшү кая — өйләренә су эчәргә дә кертми иде бит ул. Бервакыт, ашыйсы килеп елагач, Мәүлет шушы кызын чакырып, Ишәйгә бер телем ипи чыгарып бирергә кушты. Анда да Мәгъмүрә ипине малайга үз кулы белән китереп тоттырырга гарьләнде — эткә ыргыткан шикелле, баскыч идәненә ташлап китте.

Менә бит дөньялар кая таба борылды: кулы белән Ишәйгә ипи бирергә дә җирәнгән кыз бүген аңа хатын булырга ике куллап риза, ә бай абзый Мәгъмүрәсен этеп-төртеп кияүгә бирергә әзер...

Тегермәнченең бу кылый кызына Ишәйнең өйләнәсе килмәде. Ниләктер, ул кыз елмайганда да кешеләргә акаеп, усаллык белән карый төсле иде. Егет аңа өйләнмәскә җаны-тәне белән тартышты, ләкин язмыштан узмыш юк, күрәсең... Аның эшләре Мәүлеттән бәйле иде, аны акчалы да, йорт-җирле дә иткән Мәүлет иде. Ә бер көнне бу мәкерле зат, Ишәйне кунакка дәшкән булып, сыйлап, исертеп, шунда мулладан никах укытып, тәки үз кызын тагып җибәргән бит...

Каян башланды соң әле тормышның кителә башлавы?— дип беравык уйга калып утырды Ишәй карт, мичтә күмерләнә барган утыннарга карап. Утыннар түгел, гүя аның гомере шулай янып күмерләнә, сүнә бара, көлгә әверелә иде.

— Каян башланды соң әле тормышның түбәнгә тәгәрәве? Йортка сөйкемсез Мәгъмүрә килгән көннәнме, әллә алданракмы — теге зәһәр тешле түгәрәк пычкыны алып кайткан вакыттанмы? Юк, явыз Мәүлет белән берләшеп тегермән буасында такта яра башлаган яздан булса кирәк. Күпме гомерләрдән соң да пычкының елан кебек чыжгыруы, зыңлавы колакта, үткер тешләре белән каты агачны кимерүе, өзгәләве күз алдында. Агачны түгел, пычкы гүя йөрәкне телгәли.

Тормышның ватылуына, ахры, тегеләре дә, болары да сәбәпче түгел, Ишәйнең хатын өстенә яшь хатын алып кайтуы гаепледер. «Урыс баеса чиркәү сала, татар баеса хатын ала» шул буладыр инде.

...Гөлбануны Ишәй көз көне, корбан бәйрәмнәре узгач, Мәүлет кушуы буенча такта яру өчен авылларга заказлар җыярга баргач күрде. Тегермәнченең кияве булганнан бирле ул эшләми, кем йорт сала, кемгә такталар кирәк шуларны гына белешеп йөри иде. Ишәй инде аксөякләр рәтендә исәпләнә, алыш-биреш белән генә шөгыльләнә.

Куып чыгарга дип фатир сорап кергән иде ул аларга.

Иске генә йорт, фәкыйрь генә гаилә. Ишәй белән хуҗа дөнья хәлләре турында гәпләшеп утыралар, ә җиткән кызлары, чулпыларын чылтыратып, самавар куеп, табын әзерләп йөри. Типтәрләрдә астыртын эшләнә торган шундый гадәт бәр: өйгә егет, яшь кеше керде исә, табын әзерләргә җиткән кызларны чыгаралар. Күр, янәсе, аң бул, бездә бүген тотып кияүгә бирерлек кыз бар, егет икәнсең — йоклап утырма!

Хуҗага сиздерминчә күз кырые белән генә кызга карап ала Ишәй: ул чибәрлеге, мин сиңа әйтим, ул буй-сыннары! Борынгы китапларда язылган Йосыфның Зөләйхасыннан бер дә ким түгел! Йөргәндә, толымнары тирбәлеп, чулпылары чылтырый, гүя ул тәңкәләр дә: «Чылтыр, чылтыр, чибәр кыздыр, чибәр кыздыр», — дип хәбәр салалар, күңелне ирексездән җәлеп итәләр. Менә кайда яшеренеп яткан икән Ишәйгә буласы хатын! Менә кайда адашып йөри икән аның бәхете!

Ә хуҗа, Ишәйгә игътибарсыз, күзләрен әле идәнгә, әле түшәмгә төбәп тормышыннан, өенең искелегеннән зарлана: «Менә өй ишелергә тора, идән сайгаклары тузган, кешеләр кебек такта ярдырып йорт-кураны яңартып алганда да ниһәйт итмәс иде, рәт юк, гаилә ишле, замана авыр...»

Чәй янында да сүз һаман зарланудан узмады, шул иске өй, черек идәннәр, бүрәнәләр, такталар тирәсендә йөрде. Хуҗаның сүзләреннән шуны төшенде Ишәй: «Син, егет, миңа өйлек бүрәнәләр, такталар бир, мин шуның бәрабәренә сиңа кызымны бирәм», — дигән киная ясый карт.

Ишәй, чәй эчкән арада, сүз җаен эләктереп, иплән кенә әйтеп салды:

— Килештек! Кызыңны алып китәм. Иртәгәдән үк йортлы да, маллы да булырсың!

Бу сүзләрдән соң хуҗаның ничек каравы, ни әйтергә белми авызын чәпелдәтеп, аптырап торуы, чәен дә эчми чынаягын каплап куюы һәм:

— Өйләнмәгәнме син? — дип шөбһәләнеп соравы әле дә булса Ишәйнең хәтеренә кирт булып киртләнгән.

— Егет кеше, — дип алдады Ишәй хуҗаны. Башкалары да Ишәйчә тиз, җитезлек белән эшләнде. Кызның ата-анасы белән килешү, Гөлбануны күреп сөйләшү, тәнышу, вәгъдәсен алып кайту. Ике-өч көннән, «авылга такталар, бүрәнәләр сатарга барам» дигән булып, Мәүлетне алдап, Гөлбануның атасына өйлек материаллар китереп бушату. Тиешле калым бирелеп беткәч, яхшы атларда гына, хәер-фатиха белән Гөлбануны алып киту...

Ишәйнең көтелмәгән «мал» белән кайтып керүе йортта зур тавышгауга кузгатты. Үзенең чибәр, яшь көндәшен күреп, өйгә сыймады Мәгъмүрә, бөтенләй дулап, котырынып, ишегалдына чыкты, бер гаепсез малларны кыйнарга тотынды, хәтта буаз сыерны сәнәк белән чәнечте.

Ишәй Мәгъмүрәне сөйрәп алып өйгә бикләп куйган иде, тегесе ярсынып ишекләргә типте, чыгарга омтылып, тышкы яктан капкачлары ябылган тәрәзәләрне ватып бетерде...

Көндәше өстенә яшь хатынлыкка килгәнен белгәч, гарьләнеп, ачынып Гөлбану да яшь түкте. «Өйләнмәгән дип әйттең... Мин бит сиңа ышандым, болай явыз икәнеңне белмәдем... Инде ничек кеше күзләренә күреним, ходаем!» дия-дия ак кулъяулыгын идәнендә илереп аунады, чыгарга сораган мәэмай кебек шыңшып, ишекләрне тырнады...

Ике хатынны юату, тынычландыру өчен өч-дүрт көн вакыт китте. Арт белән киртә җимереп булмый икәненә, ахры, төшенделәр, тындылар.

Аның караваты янындагы ак усалы башка яклап ябырылды. Киявенең яшь хатын алып кайтканын ишеткәч, Мәүлет дөньяга сыймады. «Мин ул ач хәерчене кеше иттем... мин ул мәлгуньне дөньядан да юк

итәм!»— дип исереп, өйгә мылтык тотып килде, «гөрс-гөрс» ата-ата, кияве мунчалардан, бакчалардан эзләп йөрде. Хәвефне алдан сизенеп, Ишәй яшь хатыны белән кырга печәнгә куна киткән иде — бу төнне аны үлемнән бәлки шул гына коткаргандыр да.

Ата-баба, хатын-кыз ягы тынгач, барысы да басылды, тормыш үз урынына утырды кебек иде. Юк икән, алай ансат кынга котылып булмый икән бу бәладән. Инде көн саен авыл советына чакырып тинтерәтә башладылар. «Ике хатын белән торырга бу сиңа патша влачы түгел, аерып җибәр яшь хатыныңны!»— дип өстәл төеп кычкыра, яный башладылар. «Картын аерам, яшен юк!»— дип кырт кисте Ишәй, Гөлбануны яклап тау булып басты. Ул да бит Мәгъмүрә кебек үк мулла никахы белән теркәлгән!

Авыл советына чакыртып азапладылар. Нәкъ төнге сәгать уникедә китерәләр дә сорыйлар: «Яшь хатыныңны җибәрдеңме әле? Киттеме инде?»

Ишәй бер көнне, түземлеген җуеп, авыл советына юрган-мендәрен күтәреп барды, шунда йокларга ятты. «Мин кирәк булсам кеше интектереп чакыртып йөрмәгез, уятыгыз да сорагыз, уятыгыз да сорагыз!— диде.— Ә минем җавабым бер: Гөлбануны ташламыйм! Ташламыйм булгач ташламыйм!»

Шул елларны искә алып вакыт-вакыт елмаеп та куя Ишәй.

Ике хатын белән торуның мәшәкатьләре, җәһәннәм газаплары булган кебек, үзенә күрә кызыгы, рәхәте дә бар икән аның. Бигрәк тә бикәчләрнең бер-береннән көнләшүләреннән, иргә ярарга тырышып бишкә ярылырга җитеп йөрүләреннән ләззәт таба иде Ишәй. Менә арыпталып я утыннан, я печәннән кайтып төшә хуҗа. Тр-р дип кычкырып ат белән капка төбенә килеп туктый. Ягъни хәбәр сала: ирегезне каршы алыгыз, йоклап ятмагыз! Капка ачарга этешә-төртешә Мәгъмүрә белән Гөлбану йөгерешеп чыгалар. Тамакны кырып арбадан төшми генә карап тора Ишәй. Гөлбану яшьрәк, житезрәк — алданрак элдертә, ә тегесе, явыз, уздырмаска тырышып моның итәгенә асылына, җиңеннән тотмакчы була. Усал гына итеп чеметешеп алалар. Ә Ишәй: «җитте ме сезгә, юкмы!»— дип камчысын шартлатып кычкырып җибәрә — тегеләр шунда ук шым булалар. Аларга ирек бирсәң бер-берсенең чәчләреннән алырга да күп сорамыйлар. Ишәй белә: хатыннарны аны катырак тотсаң да таманга туры килә!

Атны туарып, арган кыяфәт белән баскыч төбенә тәмәке тартырга утыра, ә хатыннар, көянтә-чиләкләрен асып, ат эчерергә суга йөгерәләр. Монда да үзенә күрә ярыш, уңганлыкны-булганлыкны күрсәтү. Кая инде Гөлбануга җитәргә! Мәгъмүрә бер юллаганчы икене китерә, бер басканчы өчне баса! Ишәйгә сиздерми генә тагын акаеп ала Мәгъмүрә, яшь бикәне кыерсытмакчы, әмма баскыч янында ире бар. Ә ирдән шүрлиләр инде алар, күз карашыннан котлары алынып тора!

Ишегалдында әле бар да әйбәт, тышта әле хатыннар, ни әйтсәң дә, үз-үзләрен авызлыклап тоталар. Көндез бит, кеше-кара ишетмәсен, авыл халкы күрмәсен дип тә тыелып торалар. Ә менә кич җитсә — акәмәт! Хатыннар өчен фаҗиганең иң зурысы кич җитә башлагач икән аның!

Менә кояш Ала тау артына кереп поса, авыл өстенә эңгер-меңгер тарала. Кояш югалу белән хатыннар да, тавыклар кунакчага юнәлгәндәй, мыштым гына өйгә кереп сызалар. Ишәй төшенә: алар анда бүген ир кем янында ятарга тиеш, кемнең чираты икәнлеген бүлешәләр, тәрәзәдән чыккан тавышлары ук әйтеп тора. Әле өйгә керми Ишәй, тегене-моны каккалаган, аны-моны суккалаган булып ишек алдында йөри, хатыннарның аңлашуларын, тынычлануларын көтә. Белә, нәүбәт буенча бүген Мәгъмүрә янына керергә тиеш ул, тик күңел һаман яшенә, Гөлбануга тарта чукынган!

Бераздан Ишәй тамак кырып өйгә керә, аякны сузып сәкегә утыра. Ике хатын ике яктан килеп итекләрен салдыралар. Таз, комган куеп берсе бер, икенчесе икенче аякны юа. Үзеннән хуҗа икәнлегенне сизү, кадерене тою бик тә рәхәт нәрсә бит ул. Хикмәт анда гына да түгел: хикмәт бай кызыннан үч алуда. «Ә-ә,— ди эченнән генә Ишәй,— кешеләр сиңа, синең әтиеңә бик күп хезмәт итте, әйдә көчән! Миңа ипине дә эткә ташлаган кебек бирә идең, языгын күр!» Шунда, аякны юган арада, баш бармакны әкрен генә селкетеп, Гөлбануга хәбәр биреп куя үзе: тыныч бул, бүген синең янга керәм, янәсе.

Юынып-сөртенеп алганнан соң өстәл янына барып утыра хуҗа. Монда да хатыннар арасында эш бүленгән. Мәгъмүрәсе аш китереп куйса, Гөлбануы табак-савытлар тезә. Берсе кашыклар чыгарса, икенчесе аларны табынга өләшә.

Бисмилланы әйтеп тыныч кына ашый башлыйлар. Бу тынычлыкта да үзенә күрә бер шом бар, эчке көрәш бар. Мәгъмүрә, үзенә ире карамасмы, елмаймасмы дип өметләнеп, астан гына күз төшереп ала, ә Ишәй — таш сын мыни: ашаганда ашны игътибарсыз гына чөмерә бирә. Бераз кызганыч та төсле Мәгъмүрә. Ул бит, бичара, Мәүлетнең бердәнбер иркә кызы, моңа кадәр бернинди эш күрми үскән, ни теләсә шуны ашаган, ни дисә шуны кигән, йокысы туйганчы йоклаган, ә бүген башы тоташ кайгы хәсрәттә. Менә хәзер ул ярарга тырышып бишкә ярылырдай булып чаба. Көтмәгәндә уңганланып, уйламаганда ягымлыланып китте. Тәмам акылга утыртты, иманга китерде аны көндәш дигән нәрсә! Әйдә, бай кызы булып, борынын чөеп ярлы егетләрен, ярлы кызларын санга сукмый үскән идең, күр инде хәзер шуның киялеген! Ә Гөлбану исә табында үз бәясен белеп, эчтән генә көндәшен үчекләп, астан гына көлеп утыра бирә. «Әйдә, көчән, карт сыер, ничаклы ярарга тырышсаң да кукиш Ишәй сиңа!»— ди бугай.

Шушы ызгышлар, шушы гаугалар җәй буена, көзгә, кышка кадәр дәвам итте. «Көмәнем бар»— дип кугач та китмәде Мәгъмүрә, ә Гөлбануны Ишәй үзе җибәрмәде.

Нинди генә зыяннар, усал янаулар, куркытулар күреп бетермәде шушы хатыннар аркасында Ишәй. Аны Мәүлет туган-тумачаларын яллап кыйнатты. Куштаннарыннан киявенең тешләрен койдырып, күсәк белән сугып башын ярдыртты, алай да булмагач, тегермән бусагасындагы уртак милкеннән мәхрүм итте.

Барысын да кичерде Ишмөхәммәт, барысына да түзде, әмма җанны кыйнаганы Ишәйгә карата чыгарылган усал такмаклар иде. Яшьләр, комсомоллар капка төбенә килеләр дә:

Ишми, Ишми, Ишмөхәммәт,
Сатып җибәр тактасын.
Карт хатынныны бәйләп куй,
Яшь хатының качмасын!

— дип биешә-биешә җырлыйлар. Моннан да хурлыклысы, үзәккә үткәне юк иде! Кырык мирнең авызын томалап кара син, бар!

Тиздән авылда кулакларны сөрү башланды һәм хатын ыгы-зыгылары онытылып, Ишәйне яңа хәсрәт биләп алды. Кулаклар исемлегендә Мәүлет белән беррәттән Ишмөхәммәт Ишбулдин да кертелгән иде. Имеш, ул чын кулак, сыер тота, ике хатын белән тора, калай түбәле йорты, чирек дисәтинә алма бакчасы бар... Дөрес, аны яклаучылар да булмады түгел: «Нинди кулак инде Ишәй? Авызын ачса үпкәсе күренеп торган ярлы баласы ич! Әгәренки, инде калай түбәле йорт салдырган икән — ул бары тик кулак коткысына гына бирелгән. Ул кем? Ул фәкать Мәүлетнең ялчысы, батрагы! Әгәр дә мәгәр кулак кызын аерып җибәрсә, һәм дә йорт түбәсендәге калайны кубарып ташлап, башкалар

кебек салам белән яптырса, һәм дә ки үзенең алма бакчасыннан ваз кичсә, калдырырга кирәк аны»,— диделәр җыелышта.

Тыңламады аларны Ишәй. Ишетергә дә теләмәде халык киңәшен. Инде авылдашлары бик кыса башлагач, түзмәде, «Сезгә дә булмасын, үземә дә калмасын»— дип бакчадагы алмагачларны балта белән кисептурап, ботарлап, калай башлы йортына ут төртте дә, авылдан чыгып качты. Шул китүеннән ул Кыңгыраулыга бүтән әйләнеп кайтмады.

Кылган явызлыкларын исенә төшереп, хәзер үзе дә аптырый Ишәй Үкенә. Түзәргә, сабыр итәргә кирәк булган. Туачак балалары хакына, яраткан Гөлбануы хакына чыдарга, күнәргә, баш иярга кирәк булган. Уйламаган. Яшьлек. Кайнарлык.

Туган җиренә кайтырга куркып, авылдашларына, семьясына күренергә оялып газаплы, күңел әрнеткеч еллар кичерде тайгада Ишмөхәммәт. Күзгә күренеп урман картайды, бу гомер эчендә агач кәүсәләре утыз җиде балдак сызарга өлгерделәр...

Тайгада Ишмөхәммәт кырык елга якын сунарчы булып йөрде, япаялгызы кардонда, үзе әйтмешли, урман эчендә шүрәле кебек яшәде. Дүрт елын сугышта, фронтларда уздырды, аннан кайткач — тагын тайгада...

Куанып бетә алмый: ходайның биргәненә шөкер ди, хәзер ул менә монда, Черек күл төбәгендә нефтьчеләр янында эшли. Кем булып, үзе дә белми. Штатта каравылчы санала, ләкин ул утынын да кисә, мичен дә яга, идәнен дә юа, кем нәрсә кушса, шуны үти.

Теге елларны җир мае эзләүчеләргә юл күрсәтүдән башлады бу яңа кәсебен. Көннәрдән бер көнне сакаллы-мыеклы таныш булмаган кешеләр тракторларда, машиналарда урманны ерып керделәр дә кардонга килеп туктадылар. «Черек күл еракмы, абзый, ничек барырга?»— дип сораштыра башладылар. Аңлатып-аңлатып та төшенмәгәч, юл күрсәтүен үтенә башладылар. Гозер белән килгәч, тыңламый булмый — Ишәй, геолог дигәннәрен баткак-сазлыклар аша Черек күлгә илтте. Тагын бер төркемен ияртеп поселогына алып кайтты, икенчеләрен — нефть эзләүчеләрне китерде. Шулай итеп, аның өчен көтмәгәндә яңа эш табылды, яңа тормыш башланды.

Ни әйтсәң дә ялгыз башың түгел, кешеләр белән. Алар белән күңелле, алар белән рәхәт. Юкса, карурманда бер үзең яшәп көнеңне генә түгел, телеңне дә онытып бетерүең бар иде. Ишәй абзый, көрсенгән тавыш ишетеп, Курамшин яткан якка карады, яңа кешенең һаман да булса йоклап китә алмавына борчылды. «Хәсрәте бардыр бу бәндәнең. Күңелен корт кимермәсә, кеше болай офтанып ятмый» — дигән нәтиҗәгә килде.

— Өшисеңме әллә?— дип сорады ахырдан, янына барып.

— Эссе. Якма, зинһар, шул мичеңне!

— Сүндерәм, сүндерәм.

Кәрам кысылып ятуны сөйми, гадәтенчә җәелеп, баш очына куллары салып, чалкан китеп, кирәк чакта як-ягына әйләнгәләп йокларга ярата иде. Әйе, аның кадерле башы хәзер менә шушылай идәндә аунарга калгандыр инде...

Күптән, бик күптән мондый кысан яшәгәне юк иде бит. Студент вакытларда, институтның торагы булмыйча Мәскәүдәге бер әбинең чоланында йоклаган чаклардан бирле. «Ат бер баскан җиренә җиде кат баса» ди торган иде аның әтисе. Күрәсең булса, сугыштан соңгы заманнарга да әйләнеп кайтасың икән.— «Ярый, ике айга куян тиресе дә чыдый, түзәрбез»,— дип юатты үзен Кәрам.

Ул хәзер, янындагы кешеләрне уятудан куркып, борылып ятарга да базмый, каты, салкын идәндә үз өстендәге матур тормышын сагынып уйланырга гына мәҗбүр. Җитмәсә, аска идән ярыгы туры килгән, чак кына селкенгән саен ул Кәрамның сыртын аяусыз рәвештә каезлый иде.

«Мине менә шушы хәлдә Хәтимә күрсә нәрсә дияр иде икән?»— дип, ул хатынын искә төшереп алды. Икенче якка борылмакчы булган иде, янындагы бәндә, күрәсең бик үк мәрткә китеп йоклаучылардан түгел, тагын уянып:— «Син, анаңның кабер тактасы.... тик кенә ята беләсеңме, юкмы?»— дип сүгенде.

Курамшин, тынын да тартырга читенсенеп тагын бик озак селкенмичә ятты, әмма йоклап китә алмады. Шушы атна эчендә юлда килгәндә, инде биредә йөргәндә күргәннәре, җыелган тәэсирләре — исәпләп тә очына чыгышлы түгел иде.

Иртәнге якта сай гына төш күреп алды Кәрам. Төш дисә, төш инде: аның башы монда йоклап ята икән дә, гәүдәсе тегендә — туган якларында. Табанай тау итәгендә йөри икән. Шул чакта аның Хәтимәсе очрый. «И-и, Курамшин, башыңны югалтып кайткансың бит!» — дип кайгыра. Ул да булмый, кайдандыр, сабакташы Кузьма Пичугов килеп чыга. «Менә Себердә башыңны онытып калдыргансың»,— дип капчыктан алып Кәрамның башын моңа тоттыра. Уянып киткәч, әле үзе кайда икәнен дә белештермәстән, кеткелдәп көлеп алды Курамшин. Төш димәсәң хәтере калыр, билләһи!

— Нәрсә, әллә пәриләр кытыклыймы?— дип сорады теге төнлә сүгенеп ятучы кеше. Курамшин башын күтәрүгә исә шунда ук кычкырып җибәрде: — О-о, кемне күрәм! Сәлам, начальник!

Бу егет Вахка килеп төшкән көнне урамда очраган өч егетнең берсе, Рафат белән вагонда яшәүче Касыйм иде. Ул, күзләрен уа-уа, торып утырды да сөйләнә башлады:

— Болай булгач, минем авторитет бер метрга күтәрелде! Кем уйлаган рабочий башым белән кайчан да булса инженерның үзе белән рәттән йоклармын дип. Менә бит син, ә? Шул буладыр инде ул тигез хокук!..

Касыйм, әзмәвердәй зур гәүдәсен көчкә күтәреп, торып басты, кулларын як-якка сузгалап, ботларын күтәреп гимнастика ясаган булып кыланды. Монысы да Курамшинны үртәү өчен икән:

— Физзарядка ясап алырга кирәк, иптәш инженер. Иртәнге зарядка ул бик тә файдалы нәрсә. Бигрәк тә сезнең кебек интеллигент кешегә... Аннары бик җитди итеп сорады:— Сез йокысызлык чире белән интекмисездер бит?

— Ничектер яңа урынга күнегеп булмый әле,— дигән булды Курамшин.

— Башта гына шулай ул, башта гына! Мин үзем дә биш-алты ай һич күнә алмый интектем шушы каты идәнгә. Хәзер — оҗмах, бир түшәк-ястыгыңны — алмыйм, кирәкми! Йомшак урын кеше дигән бәндәне иркәли, боза гына ул!

Бер-ике минут үтүгә бөтен вагон эче аякка басты, халык эшкә әзерләнеп, юынырга эзләп, ашау ягын кайгыртып гөж килә башлады.

Вагонга Аввакумов килеп керде.

— Ну, ничек, йоклап булдымы?— дип Курамшинга игътибарсыз гына кул сузды да: — Кичә килгәннәр, әйдәгез минем арттан! — дип команда биреп, бер төркем кешене үзе белән алып чыгып китте.

Аларга Курамшин да иярде. Уе һаман төш тәэсирендә, күңеле белән Әлмәттә, Хәтимәсе янында башсыз килеш йөри иде әле. «Бу кызыклы төш турында бүген кайткач ук Хәтимәгә хат язарга кирәк булыр...»

Ләкин ул өенә бүген дә, иртәгә дә, аннан соң да тиз генә хат яза алмады. Аңлык кына вакыты да бар, тик биредә эше хәл ителмәгән, мактанып язарлык, кемне дә булса куандырырлык нәрсәсе юк иде.

Хатыны белән сөйләшергә дип, телефон станциясенә барды, анда да кинәт кенә уйлап, промыселын алды, үз урынына калган Мәснәвине чакыртты.

Курамшин Себер белән түгел, Әлмәт белән яши иде әле.

## I

Кунак йортыннан чыккач, Курамшин ишек төбендә тәмәке кабызып, бер-ике минутлар шәһәрне күзәтте.

Бүген яңгыр туктаган, җил басыла төшкән, көн аяза башлаган иде. Шуңамы, ничә көн караңгы торган шәһәр матурланып, зураеп киткән төсле. Урамнар, йортлар да алай ук ямьсездән түгел. Әле күбесе агач өйләр: ике катлы итеп тигез, шома борыслардан салынган. Кайберәүләре тышкы яктан штукатурка белән каплатылган, яшел, сары, алсу төскә буялган. Нефть чыкканның беренче елларында Әлмәт тә нәкъ шундый иде. Яңа шәһәрләрнең туу тарихы, күрәсең, һәркайда шулайдыр.

Урам уртасында шактый киң асфальт юл. Ике якта тар гына итеп салынган такта тротуарлар. Монысы инде Әлмәттә юк. Анда тротуарларны, ком һәм вак таш сибеп, асфальт белән түшиләр.

Такта тротуарларны дыңгырдатып арлы-бирле узучы кешеләр эшкә ашыга. Барысы да диярлек куртка, плащ, комбинезон кигән ир-ат затыннан. Арада яшел солдат киеменнән булганнары да байтак. Алары, билгеле, армиядән кайткан яшьләр.

Шунысы гыйбрәтле: иртән урамнарны, тротуарларны монда Әлмәттәге кебек иңләп, бәреләсугыла эшкә баручы хатын-кызларны, йокысыннан да уянып бетмәгән балаларын күтәреп, җитәкләп, яки арбаларда тартып яслеләргә, бакчаларга ашыгучы аналарны бөтенләй диярлек күрмисең. Рафатлар торагында яшәүче теге егетләр әйтмешли, чыннан да дыңгычлап тутырган ир-ат шәһәре икән бу Вах. Кыз-кыркын, бала-чага чуарлыгы булмаса бер дә яме юк икән шәһәрнең.

Әһә, әнә хатын-кызлар да бар. Икәү бу якка таба киләләр. Берсенең кулында чемодан, икенчесе җилкәсенә шактый ук күперенке биштәр салган.

Кунак йорты турысына җиткәч тукталдылар, әйберләрен тротуарга куйдылар. Як-ягына каранып алгач, өлкәнрәк яшьтәгесе Курамшинны күрде.

— Әйтегезче, нефтьчеләр торагын ничек табарга?— тузып маңгаена төшкән чәчләрен яулык астына яшереп куйды.

Икенчесе, ни дип җавап бирергә аптырап калган Курамшинга якынрак килеп, аңлатырга ашыкты:

— Егерменче барак дип йөртәләр аны. Ир-атлар торагы... Күпме кешедән сорашып киләбез — белүче юк. Бездә андый ир-ат торагы уйма, диләр...

— Мин шул үзем дә яңа кеше,— дип көрсенгәндәй итеп кулларын җәйде Кәрам.— Урамы ничек дип атала соң?

— Урамы юк аның. Нефтьчеләр торган егерменче барак. Хат шуның белән бара иде.

— Телисез икән — нефтьчеләр идарәсенә алып барам. Бәлки шуннан сорарсыз,— диде Курамшин. Үзенең ашыкканын белдереп, сәгатенә карап алды. Бүген ул сәгать сигездә идарәгә барырга, анда баш инженер янына керергә тиеш иде. Бу ике хатын да шәһәрне үзе дә юньләп белмәгән Курамшинга иярделәр дә киттеләр.

Кәрам өлкәнрәк яшьтәге хатынның чемоданын алды.

— Сез еракtанмы?

— Ерактан. Оренбург ягынныкылар.

— Әле бәхетегез, иртән төшкәнсез. Мин төнлә килгән идем.

— Без дә төнлә. Пристаньда кундык. Ярый әле, рәхмәт төшкере, шунда эшләүче бер мәрхәмәтле хатын урын бирде...

«Миленькай» дип сөйләшә торган «кәбестә» фуражкалы хатынны — дебаркадер идәнен себереп йөрүчене исенә төшерде Курамшин.

Сумкалы хатын, юл йөгән әле бер, әле икенче җилкәсенә күчерә-күчерә, ирennән зарланып барды:

— Барсаң барып, кайтсаң кайтып җитәрлек түгел — китте дә олакты бит шушы җен оясына! Белмим, нәрсәсен ошаткандыр бу сөргеннең!

Аңа ияреп өлкән яшьтәгесе сукрана, йодрыкларын селки-селки, ирен тирги башлады:

— Кайт дидем үзенә, ничә мәртәбәләр хат яздым. Мине уйламаса, анә өч баласын исенә төшерер иде, мөртәт! Я, уйлап карагыз: яше илленең өстендә — акыл кермәде. Юк, зимагор тек зимагор! Гомер буе читтә йөреп тилмертте безне, мәлгун.

Хатын җәһәт кенә алга чыгып басты, бөтен зәһәрен Курамшинга карап чәчә башлады, әйтерсең, иренең кайтмый йөрүенә ул гаепле иде.

— Менә, яхшы иттегез әле конторасына алып барып. Күрим әле мин аның начальнигын! — дип кызганнан-кыза, янындагы яшь хатынны да үзеннән үрнәк алырга өнди иде.

— Син дә, Маланья, җебеп торма! Мунчалап алып кайт иреңне! Юкса, минем кебек ялгыз башың яшәрсең!

«Ай-яй, явыз хатын! — дип бәя биреп алды Курамшин. — Бәлки ире моңардан ераккарак качып дөрес эшли торгандыр?»

Шушы урамдагы бердәнбер биек йортка, кара пыялага алтын хәрефләр белән «Черек күл нефть идарәсе» дип язылган ике катлы агач бина янына килеп туктадылар. Курамшин, әлеге хатыннарны аста калдырып, тар агач баскычтан югары катка менеп китте.

Әйе, бүген аңа баш инженерны да, идарә начальнигын да күрергә кирәк. Кичә, Черек күл төбәгендәге эшләр, кешеләр белән танышып кайтканнан соң, шактый гына каршылыклы мәсьәләләргә килеп төртелде Курамшин. Идарә җитәкчеләре белән аңлашмыйча булмый.

Башта шунысын ачыкларга кирәк: кем ул командировкадагы кеше? Нинди дә булса вазыйфасы яки статусы диикме, бармы аның? Әллә ул кем нәрсә кушса, нәрсә боерса шуны гына үтәп йөрергә тиешме? Бирегә кемгә буйсынырга, кемне тыңларга тиеш? Үзенең эше буенча мондагы эшчеләргә заданиеләр, күрсәтмәләр бирә аламы? Шулар турында сорарга кирәк. Юкса, бер казанда ике тәкә башы дигәндәй, Аввакумов белән бәхәсләшү, сүз көрәштерүдән ары китеп булмавы мөмкин...

Курамшинны, скважиналарны җиһазлау, автоматлаштыру буенча белгеч буларак, бирегә Төмән нефтьчеләрен өйрәтергә, ягъни консультация бирергә дип җибәрделәр бит. Каршы килмәде ул, Черек күл нефть идарәсенә булдыра алган кадәр ярдәм итәргә дип килде. Ә монда хуҗа — Аввакумов. Аның сүзе генә сүз, аныкы гына закон икән! Кире кагып булмый торган киң хокуклардан файдалана. Аңа, кем тарафыннандыр, кадими заманындагы сызымнар бирелгән һәм ул шуларны гына таный. Имеш, эш планы да, сызымнар да расланган, үзгәртү мөмкин түгел, скважиналарны яңача җиһазлап, яңа төр автоматлар кертеп баш катырырга соң. Ул: «Обь елгасында яңа навигациягә кадәр Черек күл мәйданындагы скважиналарны эксплуатациягә бирергә, торба үткәргечләр буйлап нефть җибәрүне тәэмин итәргә» дигән приказ белән генә яшый. Гомумән, Курамшин фикерләре белән килешергә теләми, аны санга сукмый, «вакытлы кеше» дип кенә карый.

Аңлашырга кирәк идарә җитәкчеләре белән. Булмый икән — моннан тәртәне кире борырга! Өйгә, туган якларга!..

Курамшин кабул итү бүлмәсенә ярсып, каударланып керде, идарә начальнигының ишеген тартты. Бикле иде. Шунда гына үзенә томырылып карап торган секретарь хатынны күрде.

— Начальник Төмәндә киңәшмәдә,— диде бу мөлаем ханым. Ма-

шинкада баса башлады да туктап: — Баш инженер үзендә,— дип сулдагы ишеккә таба баш изәде

Бибиков белән килгәннең икенче көнендә бер очрашкан иде инде Курамшин. Болай ярыйсы күренә. Ипле сөйләшә, игътибар белән тыңлый белә. Тик менә аңа эндәшү өчен үзенең һәм атасының исемен әйтермен димә инде. Буталчык, озын, нинди дер эт эчәгесе... Ничек кенә онытмый әйтергә?— дип ишек төбендә пошаманга төшеп калды Кәрам. Кесәсеннән блокнотын алып, теге көнне язган язуын карады: «Бибиков Пасарби Пшимахович».— Тапканнар исем! Нинди милләттән икән? Ярый, мин аңа иптәш баш инженер яки иптәш Бибиков дип кенә дәшәрмен. Иң шәбе шул булыр.

Баш инженер ишегенә тәртип өчен бер-ике мәртәбә чиртте дә эчкә узды Курамшин.

Бүлмәдә өч-дүрт кеше бар, алар барысы да өстәлдәге зур табаклы кәгазь өстенә иелгәннәр иде. Баш инженер Курамшинны таныды, елмайгандай итте һәм, башы белән ымлап, утырып торырга кушты. Аларның сүзе нинди дер җылыту системасы, пар казаннары тирәсендә бара иде.

Курамшин, беренче көндәге кебек үк, гел Бибиковка карап утырды, аны гына күзәтте. Йөзе, мыегы, кашлары һәм борыны белән ул Кавказ кешесен хәтерләтсә, үз-үзен тотышы, хәрәкәтләре белән рәссамнарга охшый төсле иде. Әнә, кәгазь өстеннән күтәрелә дә бер адым артка чигенә, башын кырын салып сызымга карап тора. Шул урыннан бер дә кузгалмыйча төз итеп кулын суза һәм карандаш белән ялт итеп нинди дер билге ясап куя.

— Булдымы? Килештекме?— дип сорый аннан.

Тегеләре дәшми.

Бибиков бераздан тагын артка чигенә, бөркет кебек төбәлеп зур табаклы кәгазьгә карап тора. Туры итеп кулын алга суза һәм яшен тизлеге белән янә бер сызык төшереп ала.

— Килештекме?

Тегеләре дәшми, мыш-мыш килеп утыра бирәләр. Төзәтмәләр белән килешмиләр, күрәсең.

Болар белән озак юанмады Бибиков.— «Ярый, әлегә кайтыгыз, уйланыгыз, аннан тагын миңа керерсез»,— дип чыгарып җибәрде. Шуннан соң килеп Курамшинга кул бирде. «Ну, ничек, иптәш командированный, ошадымы Черек күл?»

Баш инженерның «командированный» дип дәшүе тагын ачуын кабартты Курамшинның. Әйтерсең, аның чын исеме юк!

— Димәк, Черек күл сезгә ошап бетмәде?

— Ошарга, кызлар түгел лә ул!..

— Күр син аны: «Кызлар»!— имеш....

Курамшинны сынап, тыйнак кына көлеп алганнан соң Бибиков, игътибар белән тыңларга нияте барын белдереп, тамак кырды да бөркет күзе белән Курамшинга текәлде.

— Я, Кәрам Ризванович.

— Иң әлек, иптәш Пшим... иптәш баш инженер, шуны әйтегез әле: мин монда кем?

Бибиков бераз аптырап калды, аннан шаярган булып:

— Ничек инде кем? Кеше!— диде.

Курамшин әле һаман җитди иде:

— Дөрес, анысы бөтән түгел. Шулай да мин кем соң? Эшче дисәң — беркем дә эшләргә кушмый, инженер дисәм — кул астымда эшчеләрем юк! Хәтта бернинди хокукым да юк минем монда!

Кәрам Ризвановичның көйсезләнүдән, гадәттәгечә, ияк чокыры тартышып куйды. Курамшинның хәләтен бик тиз төшенде Бибиков: «Әйе, болар Аввакумов белән уртак тел таба алмаганнар икән. Бар шул

андый гадәтләре Виталий Ивановичның. Кешегә каты бәреләә торган холкы бар...»

— Аңлыйм, Кәрам Ризванович. Сезнең Аввакумов белән боткагыз пешмәгән, дөресме?

— Гөрбиян ул сезнең Аввакумовыгыз! Элементарь культура житеп бетми аңарда!

Курамшинның ияк очындагы чокыры инде унга-сулга тайпылып ук бии башлады.

— Нәрсә ул ике сүзнең берендә «командированный» да «командированный» дип битәрли. Мин командировкага акча куып килмәгән ич.

— Ярый, ярый,— дип тынычландырды Курамшинны Бибиков. Янына килеп утырды, портсигарын ялт кына ачып, папирос тәкъдим итте. Тартмавын белдереп, Кәрам Ризванович баш какты.

— Без Аввакумовка әйтербез. Ул гел шундый инде — командировкага килгән кешеләрне күрдеме — котыра. Договор белән вакытлыча килгән кешеләрне дә өнәми ул. Төп башына утыртып киткәләделәр аны — шуңа да шулай кылана... Ә үзе болай начар кеше түгел ул. Ачу сакламый. Кесәсендә таш йөртми. Эш кешесе. Башы-аягы белән шуңа чумган бәндә. Тик менә бер үзе ул. Кул арасына керердәй ышанычлы ярдәмчесе юк. Кадрлар житешми...

— Бәлки аның үзен өйрәтердәй кеше юктыр?— дип усал итеп төрттереп куйды Курамшин.

— Бәлки шулайдыр да... Ә Черек күлдә эшләр — чамасыз! Уйма! Яз көне навигация ачылуга без аның нефтен баржаларга агыза башларга тиешбез. Бу — Төмән приказы. Без инде Кәрам Ризванович, сезгә ышанып, дөресен әйткәндә, персонально соратып алдык. Исемегезне ишетеп тә, укып та беләбез: сезне «автоматларның атасы» дип әйтәләр. Тик без яңа навигациягә кадәр зур эшләр кубара алмабыз төсле. Татарстандагы кебек комплексы автоматлаштыру эшләре әле безнең перспективада гына.

Бибиков, өстәл тартмасын җәһәт кенә ачып, бу җәйнең эш планын чыгарды, аны өстәлгә куеп, карандашы белән төртә-төртә биредәге хәлләрне кыскача аңлата башлады.

Вакыт, чыннан да, бик кыска, ә эш бихисап икән.

Черек күл мәйданында утрау-утрау итеп ясалган һәм һәр утрауда бер урыннан унар-унбишәр итеп бораулаган скважиналарны бораулаучылардан кабул итеп аласы бар икән. Монысы бер, икенчедән, ул скважиналарны чистартып, буяп тәртипкә китерәсе, тирә-юньдәге мәйданны рәткә саласы. Өченчедән, шушы утраулардагы, ягъни төбәкләрдәге скважиналарны барысын бергә тоташтырасы, нефтьчеләр теле белән әйткәндә, обвязка ясыйсы. Дүртенче зур һәм мәшәкатьле эш булып нефть һәм газны аеру җиһазларын урнаштыру кала. Аннан, нефтьне жыю һәм үлчәү резервуарларын куярга кирәк. Моннан да авыррагы һәм күп көч таләп итә торганы — алтмыш чакрым ераклыктагы Обь елгасына урманнар, күлләр, елгалар һәм сазлыклар аша нефть үткәргеч сузу.

«Боларда әле Татарстандагы илленче еллар проблемалары икән»,— дип куйды эченнән Курамшин. Аның уйларын сизгәндәй, баш инженер:

— Билгеле, болары сез автоматчыларга кагылмый,— диде.— Сезнең өлешкә тигәне менә нинди операцияләр:

скважиналарны читтән торып ходка җибәрү һәм туктату;

нефть һәм газ чыгару процессларына контроль приборларын урнаштыру;

скважиналарда тиешле нефть чыгару режимын саклау. Монысы да кешеләрдән башка;

насослар белән нефть кудыруны тәэмин итү;

нефть юлын автомат рәвештә ачу һәм ябу;
жиһазлар һәм приборлар сафтан чыкканда операторларга хәбәр итү сигналларын кую;
һәм шуның кебек бүтән күп кенә эш процессларына автоматлар һәм приборлар көйләү...
Баш инженер, укуыннан туктап, беравык уйга калып утырды. Шушы эшләрне башкарып чыгасына ул үзе дә ышанмый кебек иде.
Әйе, авыр икән боларга, бик кыен икән. Бигрәк тә эшче көчләр, кадрлар житмәү теңкәләренә тия икән. Кеше юк, ә син — хет шартла, хет ярыл, югарыдан бирелгән заданиене срогында үтә!
Курамшин инде бу бүлмәгә ник кергәненә дә үкенә, күңеле инде аны бүлмәдән куа башлаган иде: «Их син, кеше! Шушындый зур эшләр арасында нинди вак, пүчтәк дәгъваләрең белән буталып йөрисең! Хурлык, валлаһи! Утырма эч пошырып, чыгып кит син моннан тизрәк, анә тегендә еракта, тайга аръягында кешеләр олы эшләр башкара торган жиргә, үзеңнең билгеләнгән урыныңа — Чергән күлгә кит!»
Курамшин, борчуы өчен гафу үтенә-үтенә, Бибиков белән хушлаша да башлаган иде инде — бүлмәгә Аввакумов килеп керде. Монда барысы да үз кешеләр, эш белән йөриләр, тәртип шундый — шакып, рөхсәт сорап торыш юк икән.
— Исәнлек-саулыкмы, Пасарби Пшимахович,— дип, туп-туры килеп, дусларча инженерның кулын кыскач, Курамшинга борылды Аввакумов.
— Кунакка сәлам булсын!
— Исәнмесез.— Моны Курамшин аеруча басым ясап, кистереп әйтте. Әшнәсенә эндәшкән кебек кыланмасын әле Аввакумов. Курамшин аның өчен кунак та, урам малае да түгел ниһаять.
Баш инженер үз урынына барып утырды, ике кулы белән битен сыпырып алды, бөркет күзе белән Аввакумовка текәлде.
— Әле үзеңне чакыртырга дип тора идем, Виталий Иванович. Ну, ничек анда сезнең эшләр?
Аввакумов, сакал-мыек арасыннан кызыл авызын ачып, зарланырга тотынды:
— Турысын әйткәндә, эшләр алама! Скважиналарны тоташтыру, ялгау эшләре ташбака адымы белән бара. Резервуарлар бүгенгә кадәр әзер түгел, булитлар юк. Бигрәк тә сварщиклар, монтажчылар тота кулны. Автоматларны куя алмыйбыз — эш фронты әзер түгел. Житмәсә тагын менә...— Аввакумов күз кырые белән генә Курамшинга карап алды.— Житмәсә, башка бәла итеп, күп белмеш инженерны жибәрдегез!
Баш инженер, урындыгын шыгырдатып, Курамшинга борылды.
— Аңлатып сөйлә, Виталий Иванович!
— Нәрсәсен аңлатып торырга? Шулай инде командировкага килгән кешеләр: әллә ниләр майтарырдай булып каударланып йөриләр дә китеп баралар — привет, сәлам, гуд бай! Бер бүген генә күрмәгән аларны...
Баш инженер тагын битен сыпырып алды. Бу — күрәсең, аның борчылу галәмәте.
— Аңлатып сөйлә, Виталий Иванович!
— Нәрсә аңлатып торырга? Курамшинның нияте — скважиналарны эшләтә башлау түгел — ә хикмәт чыгару! Аңа тегесе ярамый, бусы ошамый! Имеш, без узган гасыр техникасы белән яшибез!
Аввакумовның сүзләренә моңарчы түзеп утырган Курамшинның да чыдамы калмады, нервланып, ияк очындагы чокыры уйный башлады, сүз сорап кул күтәрде дә, торып басты.
— Чыннан да, Пшимах... Иптәш Бибиков, сез хәзер скважиналарга куярга жыенган автоматлар — инде үтелгән этап, чәйнәп төкергән

нәрсә. Без аларны, арттырып әйткәндә, илленче елларда куллана идек... Мине бит монда командировкага телемеханика системасын, электрон-хисаплау җайланмаларын корырга дип җибәрделәр. Ишеткәнегез бардыр, электроникага, транзисторга, интеграл системаларга нигезләнгән аппаратларны. Алайса, иптәш Бибиков, мин ялгыш килгәнмен, алданган булып чыгам...

Курамшин утыруга, кулын алга суза-суза, урынынНан Аввакумов сикереп торды.

— Беләбез, иптәш! Сез безгә әлифба өйрәтмәгез! Ләкин бит шунысы да мәгълүм: син ул эшне башлыйсың да ташлап китеп барасың, ә авыз пешерергә безгә кала! Бүген генә күрмәгән командировка кешеләрен...

Ике арада җәнҗалга күтәрелеп бара торган тавышны баш инженер туктатты.

— Сабыр, сабыр иптәшләр. Минемчә, дөреслек — икегездә дә. Бу хакта без әле уйлашырбыз. Бүген мин анда — Черек күлдә булырмын, күрешербез, сөйләшербез...

II

Кәрам чыккач тәмәке кабызды, уйлана-уйлана коридор буенча атлап китте. Түбәннән Кузьма Пичугов кайткан диделәр. Черек күлгә киткәнче үзен күреп чыгарга иде.

Баш инженер бүлмәсеннән бик тә борчылып, ватылып чыккан иде Курамшин — Пичугов янына керергә дә читенсенде. Син нәрсә, күгәреп кайткансың, дияр, ябыккансың, борчылгансың; картайгансың дияр...

Сулдагы өченче бүлмәнең ишегенә килеп, теге көндәге кебек үк, «Зам. начальника по общим вопросам Пичугов К. Н.» дип язылган пыялага карап торды. Соклануы һәм гаҗәпләнүе бүген дә тышка бәреп чыкты. Менә бит син ә, Пичугов начальник урынбасары! Бөтен бер нефть мәйданының зур житәкчесе! Начальник булырга каян килгән диген бу кодрәт? Укыганда Кузьма алай зур гайрәт күрсәтә алмады — биш ел буена башы өчле билгеләреннән чыкмады. Диплом яклар вакыт житкәч тә Пичугов тема таба алмый озак тинтерәде. Алдына куйган максаты, төпле фикере юк кебек иде аның.

Дөрес, бер уңай сыйфаты бар иде — ул һич тә аптырап, югалып калмас. Акча юнәтү өчен теләсә каян теләсә нинди эш таба белә иде үзенә. Шуңа күрә, бер килере юк ятим малай булып та, акчага мохтаҗлык күрмәде. Бер карыйсың — Кузьма шәһәрдә урам себерүче, икенче күрәсең — Кузьма театрда я кием элеп торучы, я кибет алдында, кычкырып-кычкырып, мактый-мактый, морожный сатучы. Ун ган, булдыклы малай иде Кузьма.

Әнә, эчтә, аның тавышы булса кирәк, кемдер кычкырып телефоннан сөйләшә.

Кәрам ишекне тартмакчы булды, туктап калды. «Рөхсәт сорарга мы, юкмы?» Ни өчендер, Пичугов, бик эреләнеп, танымаска салышыр төсле тоелды аңа. Үскән бит Пичугов, Кәрам дустының буе житмәс дәрәҗәгә менгән!.. Шулай кинәт кенә Курамшин үзен тормыштан артта калган кеше итеп күрде. Пичугов кына түгел, ишетүенчә, үзе белән институтта бергә укыган иптәшләре дә нык кына күтәрелгәннәр: кайсы идарә житәкчесе, кайсы баш инженер, кайсы бүлек мөдире. Хәтта производство берләшмәләрендә бүлек начальниклары булып эшләүчеләр дә бар. Ә Кәрам Курамшин үзләрендә рационализация һәм уйлап табу бүлегенә начальник булып торырга да курыкты. Производство-техника бүлегенә өлкән инженер итеп чакырдылар — аннан

да баш тартты. Янәсе, тынчу бүлмәдә тәмәке төтене иснәп утырасы килми. Янәсе, ул кырда, нефть бәреп чыккан урыннарда, ачык һавада күнегелгән егетләре белән эшләүне хуп күрә. Ул гына мыни аның югалтулары! Шулай төрле сәбәпләр табып ничәмә-ничә яхшы урыннарны читкә какты бит Кәрам — кире баш! Шуннан соң инде аны кайда да булса башка эшкә кыстаучы булмады. Бик тә аз сүзле, тискәре, дигән ярлык тактылар аңа.

Ә бит төп сәбәп югары урынга менәсе килмәүдән дә, тискәрелектән дә түгел, бөтенләй башка нәрсәләргә бәйле иде...

Ишек төбендә тәмәке суырып, уйланып, кыймыйчарак торган арада урынбасар бүлмәсенә унлап кеше кереп китте. Инде бер клиент та калмагач, ачкыч шалтырата-шалтырата, Пичугов үзе дә китәргә җыена башлады бугай.

Шул чак Курамшин ишектән башын тыкты.

— Керергә мөмкинме?

— Рәхим итегез.

Күптән күрешмәгән ике дус күзгә-күз карашырга да өлгермәделәр — телефон шалтырады. Пичугов өстәл янына барып телефон трубкасын алды, урынына утырды, кем беләндер, кызып-кызып сөйләшә башлады. Төсеннән, ябык йөзеннән, арт чүмеченә таба озаеп киткән башыннан бигрәк, Курамшин аның бер кимчелегеннән тиз таныды: дулкынланган, ашыккан вакытларда ул «Т» авазында бераз тотлыгып кала иде.

Хәзер дә әнә:

— Т-т... транспорт юк, җибәреп бетердем. Бу мәсьәләдә автоколонна начальнигы Т-т... Ткачевка мөрәҗәгать итегез,— дип сөйләшә.

«Таня» дип әйтергә өйрәнә алды микән?»— дип, кызыксынып елмайды Кәрам. Таня бит аны нәкъ әнә «т» авазын әйтә алмаганга яратмый иде. «Кайчан да кайчан шул «Таня» дип абынмый-сөртенми әйтергә өйрәнәсең — минем янга шул чакта килерсең!» — дип борып җибәрә иде Кузьманы.

Пичуговның төсе-бите әллә ни үзгәрмәгән кебек. Юка иреннәре һәм озынча ияге өстенә җирән сакал-мыек үстереп җибәргән дә, бераз күз төпләренә, маңгайларына җыерчыклар чыккан. Аннан беркадәр юанайган, карап торырга ярыйсы ир булып киткән.

Сөйләшеп бетереп трубкасын куюга, өстәлдәге икенче телефон шалтырады. Пичугов, гафу үтенгәндәй, Курамшинга баш иде дә трубканы алып тагын сөйләшергә кереште. Үзе вакыт-вакыт Кәрамга карап ала, үзе телефонга кычкыра:

— Безнең тарафтан отношение җибәрелде бит инде, нигә шухыр мухыр ятасыз? Обязательно квартираны Ишбулдинга бирергә кирәк. Әйе, Ишмөхәммәт Ишбулдин. Бөек Ватан сугышы ветераны, ике орден кавалеры. Сугышның башыннан алып азагына кадәр фронтта булган кеше. Хәзер Черек күлдә эшли, каравылда тора. Мич ягып тора, әйе. Квартира алуга ул беренче кандидат!

Телефон трубкасын ташлап бер-ике генә секунд уйланып торды да Курамшинга карады.

— Тыңлыйм сезне.

— Мине чынлап танымыйсыңмы, әллә танымаганга салышасыңмы?— диде Кәрам, ачы елмаеп.

— Кайдадыр күргән дә төсле...

Кәефне бозып, янә телефон шалтырады.

— Шулай инде бездә,— диде Пичугов, трубканы ала-ала.— Кергән кешеләр белән һич иркенләп сөйләшергә юк. Бюрократка әйләнеп бетәбез инде...

Ул тагын кем беләндер, юллар, агачлар, машиналар турында сөйләште, нинди дер комнар, ташлар хакында бәхәс алып барды һәм шул

арада, тутырып-тутырып, Курамшинга карап алды. «Бу нинди бәндә, «син» дип эндәшергә минем белән нинди уртаклыгы бар икән моның?» дип уйлый иде бугай.

Сүзен өзеп, Пичугов трубканы куйды, кинәт урыныннан сикереп торды.

— Курамшин түгелме соң син? О, Кәрам, син бит бу явыз!— дип гөрелдәтеп кычкырып җибәрде.— Да, да! Әнә, ияк чокырың әйтеп тора.

— Кузьма!

Кәрам кулларын җәеп түргә узды да Пичуговны кочагына алды. Кузьма да Кәрамның башын учлап үзенең сары сакал баскан яңагына кысты.

Идән уртасында, парлап вальс биегәндәй, берничә мәртәбә бөтерелеп алдылар. Туктап бер мәл карашып тордылар да, аркаларыннан кагышырга, җилкәләренә суккалашырга тотындылар. Күтәрешеп карадылар, аяк чалыштылар. Ул да булмады, көч сынашкан батырлар кебек, билләреннән алышып көрәшә башладылар.

Берәү читтән карап торса, бу әкәмәткә гаҗәпләнеп бетә алмас иде: зур бер учреждение эчендә, җитмәсә начальник урынбасары кабинетында ике сакаллы сабый, бөтенләй малайларча, нәкъ мәктәп балаларыча кыланышалар.

— Күпме ел үтте бит, боже мой, күпме сулар акты!— Пичугов әле һаман исенә килә алмый, Кәрамны кочаклап, аның аркасын кагып тора иде.— Я, сөйлә, ничек син болай?

— Үзең сөйлә, сабакташ! Бу кадәр еракка сине кем китереп чыгарды? Себергә «сөрәләрме», әллә үзең мәҗбүр булдыңмы? — дип уены-чыны белән шелтәләде аны Кәрам.

Кәрамның бу сүзләре Пичуговны айнытып җибәргәндәй булды. Кузьма, әкрен генә чигенеп, урынына барып утырды.

— Имеш, бәндәләрне яраткан чакта аллаһе тәгаләдән кешеләр сораганнар: «Син без адәмнәрне дөньяга китерәсең китерүен, ә барыбызга да урын табылырмы соң?»— дигәннәр икән. «Сезнең һәммәгезгә дә тиешле урын бүлеп бирелгән, ә аның кайсы кайда икәнен эзләп табу сезнең эш»,— дип җавап биргән ди ходай тәгалә. Күрәсең, миңа тиешле урын шушы булгандыр инде, дустым.

— Сине бер дә рәнҗетмәгән ходай. Җирдә әнә нинди зур тәхет әзерләп куйган!

Пичугов әле һаман да башын артка ташлап хахылдап көлә торган гадәтен куа икән. Түшәмдәге мөгезле люстраларга карап бер көлгәннән соң, үзенең «тәхетен» һәм дәрәҗәсен искә төшереп бугай, тынып калды һәм җитди итеп сорады:

— Я, сөйлә, ничек килеп чыгасы иттең? Командировкага билгеле. Монда бит ул модада.

— Себерне буксирга алырга килдек. Ягъни, үзебезгә юк акылны сезгә бирергә...

Пичугов урыныннан торып ишекле-түрле йөреп китте.

— Ишеткән идем шул. Татарстаннан Хөзер галиәссәламгә торышлы бер инженер килә, әфсен укып, бер ай эчендә бөтен скважиналарны хутка җибәрә икән, дип әйткәннәр иде, син булгансың икән, дустым Кәрам.

— Димәк, авызлары дөрес шапылдаган!— дип көлде Курамшин, бик сер бирергә теләмичә.

Пичугов һаман саен җитдиләнә, эреләнә барды:

— Мин үзем, мәсәләнә, командировка белән генә мондагы йөкне тарта алуга ышанмыйм. Япа-ялгыз инженер Курамшинны җибәрәләр дә Себернең убылган төшен томалыйлар, имеш! Нәрсә ул бер кешенең бер-ике айлык командировкасы?! Диңгезгә бер тәкерек! Монда,

дустым, меңнәр, миллионнар кирәк! Һәм синең кебек вакытлыча түгел, бөтенләйгә торырга!..

Пичугов тагын нәрсәләр сайрарга теләгәндер — бүлмәгә шакымыйнитми генә ике кеше килеп керде, сүз өзелде.

Керүчеләрнең берсе күк костюм өстеннән ак якаларын чыгарып салган, портфель тоткан. Икенчесе, майлы куртка кигәне, аның шоферы иде булса кирәк.

Ыспай киенгәне пошаманга төшеп сөйли башлады:

— Мәктәпне шушы арада тапшырырга уйлыйлар, ә җитешсезлекләре — хәттин ашкан! Акылга утыртырга кирәк ул төзүчеләрне, Кузьма Николаевич, кабул итмәскә мәктәпне, төзәттерергә кирәк!

Сөйләшүләрдән мәгълүм булды: бу ыспай кеше булачак урта мәктәпнең директоры икән. Төзүчеләр бинаны тәмамлаганнар, ләкин проектта каралган тышкы планировканы, спорт мәйданын, ихата-мазарларын соңыннан, бинаны тапшыргач эшләргә вәгъдә итәләр.

— Бер китсәләр, ул төзүчеләрнең коерыкларын тот аннары!— дип директор шуңа борчыла, комиссия члены буларак, Пичуговны алар белән сөйләштермәкче була икән.

— Төзүчеләргә бернинди ташлама ясау юк! Мәктәп тулы комплексы белән тапшырылырга тиеш!— дип кырт кисте Пичугов.

«Кара син бу Кузьманы! Чын начальникларча сөйләшергә өйрәнгән!»— дип аңа карап сокланып утырды Кәрам.

Телефон шалтырап, тагын кем беләндер пионер лагерьлары, анда торба белән су китерү мәсьәләләрен сөйләшеп алгач, Кузьма Николаевич көрсенеп Курамшинга карады.

— Менә сабакташ, белсәң килсә шундый инде минем эш... Кергәндә ишектәге язуга игътибар иткәнсеңдер: «Зам. по общим вопросам». Төшенәсеңме: гомуми мәсьәләләр буенча!

— Ә мин тагын, конкрет мәсьәлә белән кергән булам!— диде Кәрам сүзенә мөмкин кадәр җитди тон биреп.

— Алайса ялгышкансың, дустым. Конкрет мәсьәләләр белән безнең начальник үзе шөгыльләнә!— Пичугов башын артка ташлап көлде дә сәгатенә карады.

— Кич җитеп берәр караңгы почмакка кереп качмыйча, синең белән конкрет мәсьәлә турында сөйләшеп булмас, ахры, сабакташ. Хәзер пристаньга төшеп китәм. Командировкага барып Черек күл өчен менә дигән йортлар кайтарттым. Тузмый-күгәрми торган металл вагоннар! Яшибез, дустым!

— Үземнең дә Черек күлгә китешем. Мине анда «шеф» көтәдер, Аввакумов хәзрәтләре... Аввакумов дигәннән, нинди бәндә ул, әйт әле, Кузьма?

— О, Аввакумов! Виталий Иванович ул, дустым, монда патша! Тайга бүресе! Юк, Себер аюы! Сөйләрмен әле тагын очрашкач.

Пичугов, өч көннән иркенләп утырырга сүз биреп, аерылышты. Эше белән китте, тик монысы Кәрамны тагын төрле уйларга салды. Ни өчен өч көннән, ник бүген яки иртәгә түгел? Сагынуы шул хәтле генәме Кузьманың, әллә эреләнүе, бәясен күтәрергә тырышуымы?

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

«Административ бина» дип аталган Черек күлдәге ике катлы йортның аскы катында, ачкычларын шалтырата-шалтырата, әле бер, әле икенче ишекне ачып каранып йөргәннән соң, Курамшин яңадан диспетчер бүлмәсенә әйләнеп керде.

Бүлмә зур һәм иркен, аяк атласаң да, тамак кырсаң да гөрелдәп, яңгырап тора. Аның дүрт почмагында да, түшәмгә кадәр диярлек төрле әрҗәләр, тартмалар, капчыклар өеп куелган. Һәрберсендә: «Не контовать!» «Не бросать!», «Осторожно!» дигән кап-кара язулар.

Бүлмәнең уртасы да буш түгел: анда төрле зурлыктагы электр моторлары, чыбыклар һәм кабельләр уралган кеше биеклеге кәтүкләр аунап ята. Борынны әчеттереп машина мае, сумала, буяу исе аңкый. Бу бүлмә бөтен ягыннан да складны хәтерләтә, ә Курамшин үзенең кара сатин халаты һәм кулында шалтырап торган бер бәйләм ачкычлары белән склад мөдиренә охшый иде.

Ул, әрҗәләр, тартмалар һәм капчыклар арасыннан атлый-сикерә йөреп, аларны ачып карап, тикшереп, бирегә китерелгән автоматика җиһазларын барлагандай итте дә, кәефе кырылып, бер почмактагы зур гына әрҗә өстенә менеп утырды. Аны һаман да әле «тотыныргамы?» дигән уй борчый, шул куркыта иде. Җитмәсә, читтән торып идарә итү системасына кергән «ПАТ — Нефтяник» аппаратларының яртысы да, турыдан-туры скважиналарга куела торган «Спутник» автоматларының чиреге дә кайтарылмаган. Эшләп караган кеше үзе генә белә: ай авыр, ай катлаулы һәм чуалчык бит ул система! Аларны урнаштыру, көйләү-җайлау өчен Курамшин участогында бер көтү автоматчылар белән дә ике еллап вакыт кирәк булды! Бу турыда аз гына булса да белә микән баш инженер, моның мәшәкатьләрен ичмаса чак кына күз алдына китерә микән?

Менә бүген Бибиков автомат мәсьәләләрен урында хәл итү өчен үзе киләчәк. Һәм, чыннан да, озак тормады — җиңел машинасына утырып килеп тә җитте.

— Я, эш нәрсәдә терәлеп калды, хезмәт иярләре,— диде ул ишектән керә-керешкә үк, аптырап утырган Курамшинны күреп.

— Эшнең әле урыныннан кузгалганы юк, иптәш Бибиков.— Әнә карагыз,— дип бүлмәдәге өем-өем әрҗәләрне күрсәтте Кәрам.

Пасарби Пшимахович та, Курамшин кебек үк, төрлесе-төрле җирдә аунап яткан җиһазлар һәм материаллар арасында сикерә-атлый йөреп чыкты да, моның янына килеп утырды.

— Иң мөһиме — җенне шешәдән чыгару кыйммәт безгә, Кәрам Ризванович,— диде, папиросын кабыза-кабыза.— Җенне шешәдән чыгарсак, үзе хәрәкәткә килә ул...

— Ящикларны каерып ачарга кирәк дисез инде.

— Әйе. Аларны алып, сөртеп-юып, детален детальгә туры китереп комплектлап куярга кирәк.

— Шуннан үзләре эшли башлар дисезме?

— Кайсысы печән, кайсысы салам — син безгә шушыны әерып бир. Ягъни мәсәлән, без белик: «ПАТ — Нефтяник» системасының нинди җиһазлар кайтып бетмәгән дә, «Спутник»та ниләр җитми.

— Күренеп тора: «Нефтяник» аппаратларының яртысы, «Спутник»ның чиреге дә кайтмаган...

— Алар төрлесе төрле заводтан. Тулы комплект җыелганны көтеп ятасы юк — булганны куя, көйли башларга кирәк. Я, әйт, хәзергә сиңа ярдәмгә ничә кеше бирим? Кемнәрне аласың?

— Аппаратларны җыйнап кую өчен гыйлем кирәкми. Кемне телисез — шуны җибәрегез. Миңа, мәсәлән, монда мич ягып торучы Ишәй абзый да бара.

Курамшинның эшләргә бернинди дәрте-теләге юк дип уйлапмыдыр, Пасарби Пшимахович холыксызланып алды:

— Сез галәмәт тә кызык кеше, Кәрам Ризванович!— дип, урыныннан кискен генә кузгалып торып китте.— Сез нинди дә булса предприятие оешкан чакта аның тулы составта булганын күргәнегез бармы? Мин мәсәлән, нефтьтә утыз ел эшләп андый бәхеткә тәтемәдем.

Кая килсәм дә, кая җибәрсәләр дә эшне нольдән башлап җибәрергә туры килде. Сугыштан кайткач, Төньяк Кавказга, Молгобек промыселларына мастер итеп җибәрделәр. Барсам, я алла, бомба-снарядлар белән актарылып ташланган җир, бөтен төшендә я::эн-көйгән, кәкрәеп-бөкерәеп беткән торбалар, әллә ничәгә ярылган чаннар һәм шартлатылган скважина җиһазлары гына аунап ята! Сугышка кадәр мин анда берничә ай гына оператор булып эшләп кит-кән идем — шушы варварлыкны күрдем дә утырып еладым... Әллә кы..я эш чыкмый, икенче көнне үк диярлек миннән нефть таләп итә башладылар. Кемнәр белән, нәрсә белән чыгарырга икәнен тикшермиләр, ә нефть сорыйлар! Менә шулай, хөрмәтле Курамшин!.. Ә бирегә, Черек күлдә ничек иде дисең? Моннан бер ел элек, мин килгәндә, булачак бу идарәдә, бер Аввакумов утырып тора иде. Әлеге дә баягы Виталий Иванович! Шулай, хөрмәтле хезмәт иясе, берәү дә безнең өчен алдан коймак пешереп куймый!..

«Ә бит Пасарби Пшимахович хаклы»,— дип дөресләп куйды аны Курамшин эчтән генә. Ә үзе автоматлар белән җенләнеп йөргәндә аны белгән, ярдәм итәм дип канатландырып торган кешеләр күп идеме соң?

Курамшин урыныннан торды.

— Миңа эшне башлап җибәрү өчен әлегә әйбәт кенә өч егет кирәк булыр,— диде, өстен кага-кага.— Электр, радио тирәсен белсәләр тагын да яхшы...

— Баштан ук шулай диләр аны, хезмәт иясе! Радио белгечләрем юк, электрикларым бар. Теләсә кайсын сайлап ал!

Курамшин шунда ук Рафатны, ул бүлмәдәге тагын ике татар егетен исенә төшереп алды. «Без электриклар»,— дип әйткәннәр иде бит

— Мин монда кемне дә белмим. Каршы килмәсәгез, бирегез үз якташларымны...

— Пожалуйста. Кемнәр алар?— дип, кесәсеннән блокнотын чыгарды баш инженер.

— Фамилияләп әйтә алмыйм, тик әйбәт егетләр икәнен генә беләм. Алар Аввакумов янында эшлиләр.

— Киттек алайса Виталий Иванович янына!

Алар күл буена җәяү төштеләр. Пасарби Пшимахович, күңел өченме, юлда Курамшинның кәефе, семьясы, бала-чагалары белән кызыксынып барды. Шунда кинәт кенә:

— Синең анда гостиницада шартлар ничек соң?— дип сорап куйды.— Бик тыгын бүлмәдә яшисез икән, дип ишеттем.

— Чрыйсы. Ике айга куян тиресе дә түзә.

— ..лай димәгез, Кәрам Ризванович. Зур хата булыр. Кешегә бер көн яшәү өчен дә шартлар кирәк... Анысын көйләрбез. Ә буфетта ашау-эчү яклары ничек? Җылы аш юк бугай анда?

— Иртә-кич тамак ялгап алырга булгач җитә.

— Дөрес түгел. Эш кешесенә иртә-кичләрен җылы аш обязательно кирәк! Минем мәрхүм әти революциягә кадәр Брэдли исемле инглиз нефть промыселларында тартальщик булып эшләдем, ди торган иде. Мистер Брэдли кешене эшкә аласы булса, иң беренче чиратта өенә алып керә дә аның алдына зур бер табак аш чыгарып куя һәм ничек ашаганын карап тора икән. Әлбәттә, яхшы ашаса алган, начарларын куып чыгарган.

— Алай аппетиттан зарланган юк. Сез миңа аш бирмәгез, эш бирегез, эш!..

— Эш булыр ул.

Аввакумов эшли торган төбәк Черек күлдә «Робинзон утравы» дип йөртелә иде. Кайчандыр ул бирегә разведчиклар килеп бораулый башлаган бердәнбер утрау булган. Шунда салынып беткән скважиналарны

акт белән кабул итеп алучы, нефть промыселы оештыра башлаучы бердәнбер кеше иде Аввакумов дип сөйлиләр. Шуңамы, Черек күл нефть идарәсендә Аввакумовны аеруча хөрмәт итәләр. Виталий Ивановичның эче телен дә, шактый тупаслыгын да кичерәләр иде. Шулаймы-юкмы, һәрхәлдә аңа кисәтү ясаучы, каршы сүз әйтүче булмый. Алны-ялны белмәс эшчәнлеге, турылыгы коткара иде ахры. Эчендәге тышында: маңгайга бәреп сөйләшә бит ул.

Әле хәзер дә янына баш инженер белән Курамшин килеп туктагач:

— Нәрсә урларга килдегез? — дип сорады күзен зурайтып.

— Кешеләреңне, Виталий Иванович. Курамшинга эш башлап җибәрү өчен өч кенә бөртек кеше кирәк булып чыкты.

— Грамм да кешем юк! Минем промысел җир асларыннан кеше чыгармый!

— Я, чәпчемә, Виталий Иванович, барыбыз да бер максатка эшлибез ич.

— Курамшинның максаты әле суга сәнәк белән язылган, ә минеке барып чыгачак! Нефтьне язга җибәрәчәкмен, алла боерган булса...

— Син куллакларча эш йөртәсең, Виталий Иванович! — диде Кәрам ахырда тотырыгын җуеп.— Монда сүз синең утравың турында гына бармый...

Шуннан икесе кычкырышып киттеләр. Бибиков аларның араларына керде.

— Ну, хезмәт нияләре, җитәр!

Баш инженер аларның холкын күргәләде инде. Шырпы белән шырпы тартмасы кебек: бер-берсенә чак кына орындылармы — кабынып китәргә генә торалар.

— Нәрсә, сезгә эшне бүлеп бирергә кирәкме әллә? — диде Бибиков каты итеп.— Берегезгә салам, икенчегезгә печәнме? Алайса әйтим: «ПАТ — Нефтяник» системасы өчен тулысынча Курамшин, ә «Спутник» өчен син җавап бирәсең, Виталий Иванович. Бүгеннән керешергә кирәк!

Ашханә янында төшке ашка чакырып чаң суктылар.

— Әйдәгез, ач тамактан сөйләшеп булмас бу турыда — диде Бибиков, кулы белән ашханәгә бара торган сукмакны күрсәтте.

Курамшин елмайды:

— Кем күпме ашаганын мистер Брэдли кебек карап тормакчы буласызмы?

— Юк, ач кеше талашучан була. Сугышып китәрсез дип куркам.

— Менә сез, Курамшинның якташы Касыймның ничек ашаганын күрсәгез иде! Тегермән урынына тарта, билләһи!— дип кушылды аңа Аввакумов.

Касыйм ашарга ярата да төп сәбәп анда түгел икәнен Курамшин сизеп алган иде инде. Егетнең күңелендә Фәкыйһә...

Фәкыйһә дигәннәре яше кырык тирәләрендәге бер шадра, тәбәнәк, ләкин бик сөйкемле пешекче хатын. Ә Касыйм су эчәргә дигән булып эштән алданрак китә дә, туп-туры Фәкыйһәнең аш пешертән җиренә керә. Бик әдәпле генә баш иеп исәнләшә, кәефен белешә, туган илен сагыну-сагынмау мәсьәләләре белән кызыксынган була. Аннан, сүз җаен китереп кенә, бер стакан су сорый. Бүген эш галәмәт күп булган иясе, арыткан, тирләткән, сусаган.

Ялгыз, киң күңелле Фәкыйһә, зур казанда аш болгаткан җиреннән туктап, симез кулларын, юан беләкләрен алъяпкычына сөртә-сөртә, Касыйм янына килә, мөлаем генә итеп сорый:

— Әллә кайнаган сөт биримме?

— Кайнаган сөт? Анысы тагын да яхшы!— ди егет, кулларын уа-уа.

Касыйм бер күтәрүдә литрлы кружкадагы сөтне чөмерә дә җиңнәре белән авызын сөртеп куя.

— Әх, сөтең тәмле икән. Рәхмәт, күбәләгем,— ди, иреннәрен ялый-ялый. Китәргә җыенгандай, фуражкасын кия; кесәсеннән бияләйләрен ала.

— Төш тә житеп килә, әллә берәр тәлинкә генә аш ашап чыгасыңмы?— ди Факиһә егетнең мактавыннан күңеле булып.

— Әйе шул, зарар итмәс иде. Аш-ашка, урыны башка. Бераз ачыгылды да бугай. Ахшам вакыты — ашау вакыты, дигәннәр бабайлар,— дип, сәгатенә карап сөйләнә-сөйләнә, Касыйм өстәл янына килеп утыра, бияләйләрен яңадан арыш капчыгы кебек зур кесәләренә тыга.

Касыймның ашарга яратуын белгән Факиһә аңа шулпаның куесын, итнең зуррак кисәген сала, тәлинкәне дә мөлдерәмә итеп, күзеннән түтыра. Касыйм ашап, иелә-бөгелә рәхмәтләр әйтеп чыгып киткәннән соң, күп тә үтми төш җитә. Черек күл төбәгендәгеләр шаулашып-гөрләшеп ашханәгә килә башлыйлар. Инде Касыйм яңа гына ашап тамак туйдырып чыкты, биредә юктыр дисәң — төркемнең иң алдыннан килеп кергән, түр башына ук барып утырган ул булыр. Кашыгы белән тәкатьсезләнеп өстәл кага:

— Факиһә, тизрәк бул, ачтан үләм!

Тегесе дә бит Касыймны күптән күрмәгәндәй:

— Хәзер, Касыйм, сабыр ит,— дип елмая-елмая мөлдерәмә тулы савыты белән егет янына ашыга. Икенчесенә ботка китерә. Анысы да тәлинкәдә түбәләмә тулган. Ләкин пәһлеван егеткә бу — бер генә йотарлык.

— Ии, Факиһә җаным, син мине болай булса ачтан үтереп кабергә тыгасың!— дип ризасызлык белән генә кабул итә Касыйм тәлинкәне.

Касыймның ашавына сокланып бөтенесе көлешә, ах итә.

— Шауламагыз, җәмәгать, аппитетны качырасыз,— ди Касыйм, ашый бирә.

— Нигә көләсез,— ди Факиһә бер дә исе китмичә,— ашасын! Ашаган малда өмет бар дигәннәр... Яратам мин ашның кадерен белгән кешене...

— Дөрес әйттең, Факиһә күбәләгем! Ашына күрә табагы, эшенә күрә тамагы!

Күптән ашказаны белән интегүче, ашау ягына үтә нәзберек мастер Аввакумов Касыймның авызына карап тора да:

— Әйе, әйе, аз эшли, аз эшләсә дә күп тешли,— дип баш чайкый.

Факиһә егетне тагын да яклый:

— Нигә алай дисез, Виталий Иванович? Себер коэффициенты белән ашый ич ул. Түләве икеләтә-өчләтә булгач, ашавы да шулайдыр инде...

Факиһә әйткәннәр ашханәдәгеләрне тагын гөр китерә.

Курамшинны да гаҗәпкә калдыра Касыймның ашавы. Булса да була икән аппитет кешедә. Кашыгы белән авызы тәлинкә арасында экспресс поезды урынына йөри диярсең.

— Син, Касыйм, өендә дә шулай идеңме?— дип сорый аннан чынлап торып.

— Ашау мени бу!— дип зарлана егет.— Һаман шул кәбестә шулпасы да карабодай боткасы! Күпме әйттем Факиһәгә коймак пешер, дип. Коймак пешерә белмиләр ахры болар, Кәрам Ризванович, аның нәрсә икәнен дә ишеткәннәре юктыр.

— Өеңдә коймак ярата идеңме?

Касыймның авызлары җәелеп китә, ирен читләре юешләнә.

— Әх, ул кайнар коймак!.. Әле дә булса төшләремә кереп азаплый. Әни пешереп өлгертә алмый иде, табадан төшкән берен йотып кына барам... Әни минем үги иде — күпсенде. Көннәрдән бер көнне әйтә бу миңа: син, улым, ди, берәр җиргә эшкә китсәң иде. Безгә ак-

чаң кирәкми, үз тамагыңны үзең туйдыра алсаң, шул җитә, ди. Шуннан чыгып киткән кеше мин, Кәрам Ризванович. Аллага шөкер, үлмәдем...

Касыйм бүген дә «Табаның тапылдамаса авызың шапылдамас» дип иптәшләре Рафатны, Гришаны артта калдырып, ашханәгә беренчеләрдән керде.

Факиһә инде, Касыймга дигән зур савытны әзерләп, аны көтә иде. «Билгеле, Касыйм ашардан йөрми — дип уйлый ул эченнән сөенеп.— Бу заманда кеше ач түгел. Нинди дә булса җылы сүз әйтер, әйтми калмас. Теге көнне дә ашап туйгач, савытын китергән булып, кухня янына елышты. Ниндидер сер чишмәкче булып авызын ачкан иде дә, кешеләр кереп комачаулады. Бичара, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча «рәхмәт» дип чыгып китәргә мәҗбүр булды. Рәхмәт белән тун тышлап булмый шул...»

Факиһә исә, Касыйм үзенең гыйшкы турында бер әйтмәсә бер әйтер әле, дип шулай көн саен көтә, «яратам, сөям, сине хатынлыкка алам» дигәнне карт егет һаман ычкындырырга ашыкмый.

Бүген Кәрам таныш егетләрнең өчесен дә бер өстәл артында күреп сөенде: Рафат кайткан икән! Ишек төбендә шып туктап калды. Әнә, «Өч мушкетер», авызга-авыз куеп, ниндидер бик кызыклы нәрсә турында сөйләшеп, көлешеп утыралар. Егетләрнең шундый кәефле чагы кирәк тә инде Курамшинга: ничек булса да үзенә эшкә кодаларга, күндерергә кирәк!

Ул, Бибиков белән Аввакумовны юынгычлар янында калдырып, туп-туры шушы күңелле өстәл янына килде.

— Син түгелме соң бу, Рафат?— дигән булды.— Кайтып та җиттең мени әле? — Үзенең иң якын дустын күргәндәй шатланып, аңа кул бирде. Башкалар белән исәнләште.

— Гомерле булырсыз, Кәрам абый, сезне ничек табыйм, дип утыра идем әле!— Рафат, шалтыр-болтыр китереп, өстәл янындагы урындыкларны кузгатып куйды, Кәрам Ризвановичка янәшәннән урын күрсәтте.— Туган илләрдән күчтәнәч бар сезгә... Сабан туе күчтәнәче...

— Хәтимә апаңны күрдеңмени?

— Теләсә нәрсә диегез, Кәрам абый, сезне күрүемне әйттем. Сабан туенда очрадылар. Бер улыгызны җитәкләгән, берсен иярткән, берсен күтәргән, каз бәбкәләре кебек тезелешеп йөриләр, мин сиңа әйтим...

Курамшинның тез буыннары йомшап китте, утырды.

— Тезелешеп йөриләр дисең инде... Үзләре генәме?

Эчендәге ниндидер җене, вәсвәсәләнеп: «Шәфрун да янында түгел идеме?» дип сорый язды. Шул каһәр суккан малай гел эчен тырный да тора инде аның.

— Я, нәрсә ди Хәтимә апаң?

— Рәхмәт, ди. Сәлам әйтергә кушты. Киткәндә өйгә кечкенә генә төргәк китерде. Ул монда, эшләгән җиремдә...

— А-л-ай,— дип сузды Кәрам картларча.— Бик яхшы, рәхмәт! Минем участок кешеләрен күрмәдең инде?

— Аларны белмим бит мин.

— Әйе, әйе... — Кешенеке кештәктә, дигәндәй генә, Рафатның сөйгән кызы турында да сорашмый булдыра алмады: — Ә Садән, Садән соң ни хәлдә? Сагынганмы?

— Сагынган. Яннан да китми дә...

Рафат бу хакта башка сүз озайтасы килмәде, очының-очының сабан туйларын тасвирлап китте:

— Их, егетләр, күрсәгез иде быелгы сабан туйларын! Ул көрәш, ул ат чабышлары, ул йөгерешләр!.. Әйтимме, иң кызыгы нәрсә булды? Биек колга башындагы әтәч! Бер малай инде менеп алдым дигәндә

генә читлегеннән очты да китте! Шуны тотам дип, бичара, чак егылып төшмәде, гарьлегеннән елап җибәрде...

Касыйм көрсенеп әйтте:

— Бәхет һәрвакыт шулай инде ул: тоттым дигәндә генә оча да китә, каһәр...

— Без, егетләр, ул сабан туйлары турында бер иркенләп сөйләшербез әле,— дип бүлдерде бу әңгәмәне Кәрам. Йомышын иплəп кенә, бик ерактан, читләтеп кенә әйтергә булды.

Башта ул егетләрнең торагына ничә мәртәбәләр барырга җыенып та һаман бара алмавы өчен гафу үтенде, вакыт тапмаудан зарланды. Аннан егетләрнең хәл-әхвәлләрен, көнкүрешләре белән кызыксынган булды, шуннан соң гына төп мәсьәләгә күчте:

— Ну, Гөргери туган, синең хәлләрең ничек соң әле, ак эш тапмадыңмы? Әгәр дәртең-теләгең булса, кулың бер дә каралмый торган эш бар миндә.

— Тагын җир чокыргамы?— дип, авызын кыйшайтып көлеп куйды Гриша.

— Чынлап әйтәм. Ак эш. Ап-ак чыбыкларны аккургаш белән генә ялгыйсың...— Ул, әлеге тәкъдим белән кызыксынып киткән Рафат белән Касыймны да күз алдыннан җибәрми иде.— Әгәр үземә ярдәмгә алсам, килер идегезме?

— Киләбез, ник килмәскә!

— Чакыр гына, барабыз!

— Өйрәтеп торсаң эшлибез!

Аларның шулай җиңел генә ризалашуына Кәрам Ризванович башта сөенгән иде, соңыннан уйлап карагач, кәефсезләнде. Әлеге егетләрдән өмет өзүе — ни дип әйтешле дә түгел. «Болардан гомергә дә автоматчы чыгасы юк», дип нәтиҗә ясады эченнән. Аларның автоматны, телемеханиканы аңламауларыннан түгел, үзләренең һөнәрен, эшен тиз генә алыштырырга, ташларга әзер торуларына гаҗәпләнде. Үз һөнәренә шундый карашлы кешеләрне элек-электән җене сөйми иде аның. Промыселда эшләгәндә эшчеләр белән ике арада бөтен конфликт та әнә шуннан килеп чыкты. «Яратмаган эш эшләү — яратмаган хатын белән тору кебек»,— ди торган иде Курамшин. Бригадада Җәмил исемле кеше бар иде. Эшен яратмады — ул аны куды. Ә менә Мәснәви, хатынын яратмаса да, үз эшен, бигрәк тә автоматларны үлеп ярата иде — ул аны җыелышның карары булуга карамастан, кумады, калдырды, бөтен гаепләре белән үз өстенә алды...

Юк, үз һөнәреңә, үз профессияңә бирелгән булсаң, син инде эшеңнән китә алмыйсың. Бигрәк тә автоматлар өлкәсендә. Үзенә гашыйк итә дә куя бит ул автомат дигән нәрсә, каһәр! Ә бу егетләр әле, күрәсең, үз эшләренә сеңә алмаганнар, автоматларның гына түгел, чынчыннан электрның да нәрсә икәнен белмиләр. Алар өчен барыбер — кем нинди эшкә чакырса — шунда китәргә торалар. Вакыты белән, җаен туры китереп, аларга иплəп кенә әйтер әле бу турыда, әйтми калмас.

Ярый, Кәрам үзе дә монда вакытлы гына, шулай булгач, вакытлыча кемне дә алырга була... Әйдә, «Ит юкта үпкә дә тансык»...

— Алайса килештек,— диде Курамшин егетләргә бертөрле битарафлык белән.— Иртәгә башлыкларыгыз белән сөйләшербез. Минем штаб әнә тегендә, яңа йортта.— Ул, уң яктагы ике катлы бинаны күрсәтте, китәргә җыенды.

— Күчтәнәч турында оныттыгыз мыни, Кәрам абый,— дип туктатты аны Рафат.

— Әйе бит, күчтәнәч, дидең... Нәрсә салды икән соң Хәтимә апаң?

Баргач, Рафат аңа мендәр кадәр төен китереп тоттырды. Хуҗа шатланмады, киресенчә, кызарды, оялды аның өчен. Ник дисәң, Хәтимә

нәп жибәргән иде. Моңа Касыйм белән Гөргери дә игътибар итмичә калмадылар. «Ай-яй культурный кеше икән безнең инженерның хатыны!» дип әйткәннәрдер инде... Бу төенгә, хәтта, шул тирәдә генә эшләп йөргән Аввакумов та сәерсенеп карап алды төсле.

Эш урынына кайткач та төен тирәсендә әйләнгәләп йөрде Кәрам.

— Соң, Хәтимә, җан кисәгем, шушы музей экспонатларына төрмәсәң беткән идеме өйдә сумка, чемодан, саквояжише нәрсә? Син иреңнең кемлеге, аның абруе турында чак кына булса да уйламыйсың мыни?— дия-дия хатынын битәрләде.

Шундый инде аның хатыны — әйтеп тә, күрсәтеп тә, хәтта әнуланып та төзәтеп булмаслык. Өйләнгәндә, бергә тора башлагач өйрәнер, авыл гадәтләрен ташлар дип уйлаган иде Кәрам. Хәтимәнең авылдагы өйләрен калдырып, шәһәр йортына күчтеләр, ләкин аңа карап Хәтимә һич кенә дә үзгәрмәде. Авылдашлары әйтмешли, аңардан һаман булса да читән исе килә. Шәһәрчә булсын, дип Кәрам аңа кыйммәтле пальтолар, туннар, башка хатын-кызларның хыялында гына йөргән пан-бәрхет күлмәкләр, затлы мех бүрекләр, биек үкчәле туфлиләр дә алып карады, ләкин Хәтимәнең үз туксаны туксан. Киемнәренә сөенгән, аларны мактаган була, иренә рәхмәтләр әйтә-әйтә киеп карый, хәлдән таеп көлә-көлә, көзге каршында боргалана, аннан ул киемнәрне сандыгына салып куя да үзенең әлеге дә баягы чуар яулыгын бәйли, мамык шәлен бөркәнә, кара резина итекләрен кия. Аның бит биш былтыр сатып алган иннекләре, пудралары һәм крем-хушбуйлары да бүгенге көнгәчә исән-имин көенчә тумбочка өстендә утырып тора!

Әлеге кызыл киндерле күчтәнәчләре белән кызара-бүртенә кунак йортына кайтып керергә туры килде. Бүлмәдәшләренә күрсәтми генә, төенне карават астына тыкты, кешеләр чыгып киткәч кенә чишәргә булды.

Нигә бу кадәр авыр икән, дигән иде — кат-кат төргән кәгазьләр, целлофаннар эченнән эмаль коштабакка катырып эшләнгән гәрәбәдәй сары чәкчәкләр килеп чыкты. Чәкчәк төрле төстәге борчак-борчак конфетлар белән бизәлгән, хуш ис бөркеп тора иде. Бу әле артык ук гаҗәпләндермәде Кәрамны — андый тәм-томнарны пешерергә Хәтимә оста,— бу кадәр уалучан, йөртергә генә түгел, бармак белән тотарга да үтә нәзберек ризыкны Рафат ничек шушы кадәр ерак җиргә ватмый-җимерми алып килә алган диген!

Икенче бер капчыкка Кәрам бик тә яратып ашый торган каклаган каз тыккан иде Хәтимә. Монысын булдырган, рәхмәт! Күптән каз-үрдәк үстермәсә дә хатыны аларны базардан сатып алып каклый һәм, боларны ул һичкем булдыра алмаслык итеп, бик оста эшли иде. Хәтимә күп нәрсәләрне әнисеннән өйрәнеп калган һәм тормышта аның матур гадәтләрен дәвам итә.

Тагын Хәтимә Кәрамның киткәндә өйдә онытып калдырган пакесен, кырыну приборларын салган, шулар янына, ни өчендер, йоннан бәйләнгән ап-ак оекбашлар, бияләйләр тыккан. Нәрсәгә кирәк инде җәй көне болар?

Оекбаш эчендә хаты да бар Хәтимәнең. Курамшинның, ун ел бергә торып, хатыныннан беренче мәртәбә хат алуы иде — аңа бик кызык тоелып китте. Шакмаклы дәфтәр битенең дүрт ягын да тутырып, укучы балалар белән язылган хат болай башланып китә: «Хат башы, яз каршы». Аннан, кадими заманындагыча итеп: «Сезки чит илләрдә бер күрергә зар вә интизар булып яшәүче хәләл җефетем Курамшин...» дип дәвам иткән...

Хәтимәнең әнә шундый үтә борынгы алымнарыннан, сүзләреннән Кәрам тавышын чыгармаска тырышып, авызын каплап көлеп утырды.

Шаярып язмаган бит, хатлар шулай башланырга, шулай язылырга тиеш дип ышанып, чын күңеленнән язган!

— Их, син, авыл умачы!— дип куйды Кәрам көрсенеп.

Ул, хатынының шулай тормыштан артта калуына хәзер генә төшенә башлады кебек. Әйе, монда гаепнең зурысы Кәрамның үзенә төшә. «Хатынны үтергән дә ир, тергезгән дә ир», дигәннәр бит. Дистә ел бергә торып хатынын тергезү, ягъни якты дөньяга алып чыгу өчен нәрсә генә эшләде соң бу акыллы ир?! Хәтимә урынында нинди генә хатын булмасын, нинди генә семьяда үсмәсен, күпме генә яшәмәсен, беркая бармаса, аралашмаса, гыйбрәтләр алмаса теләсә кайсысы шушы көнгә төшәчәк тә төшәчәк!

Бүселеп, әллә нинди күңелсез уйларга бирелеп утырганнан соң, кинәт исенә килде:

— Нигә дип күтәреп алып кайттым соң әле боларны? Шунда кырда авыз итәргә ник егетләрне чакырмадым? Аввакумовны, Бибиковны, башкаларны дәшәргә дә мөмкин иде...

Үзенчә, кызык ясап, өстәлгә кызыл ашъяулыкны җәйде, аның нәкъ уртасына коштабагы белән чәкчәкләрне китереп куйды, казны ботарлап, ит кисәкләрен чәкчәк тирәсенә тезде. Өстәлдәге бик үк килешеп бетмәгән табынга карап торды да, кул селтәп буфетка чыгып китте.

— Әйдә, авылча икән, авылча булсын инде!

Аннан бер чынаяк чәй белән чәшке-чынаяклар күтәреп керде.

Бүлмәдәшләре кайткач әй гаҗәпләнделәр, әй сокландылар соң табынга карап — мондый ризыкларны беренче күрүләре икән.— Чәй эчеп, чәкчәгеннән, каклаган казыннан авыз итеп алгач, тагын да күңелләре булды. Барысы да Кәрамның хатыны, аның осталыгын, уңганбулганлыгын, татар ашларының тәмлелеген бердәм мактап утырдылар.

Тик иртән, каклаган каздан соң төне буе су эчеп чыккач, берсе:

— Сезнең халык бик тозлыны ярата икән,— дип куйды.

Икенчесе, торды да, иреннәрен ялап:

— Сезнең татарлар гел шулай баллы ашыймы?— дип сорады.

Курамшин ятагында килеш аякларын кәнагатьлек белән сузып җибәрде, ияк чокырларын уйната-уйната, кеткелдәп алды.

Әй, кемнең күңеле нәрсә теләүдә мени соң хикмәт! Хикмәт бит монда Курамшинның хәләл җефете пешергән ризыкның игътибарга лаек булуында, барыннан бигрәк, чит-ят кешеләр алдында йөзгә кызыллык китермәүдә! Булдырган! Молодец! Әйбәт тә хатын соң инде аның Хәтимәсе!..

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

### I

Черелдәп телефон шылтырауга, Хәтимә, кулындагы тегү эшен ташлап, түр бүлмәгә йөгерде. Көтә иде бу звонокны, күптән көтә иде. Курамшинның киткәненә бүген ун көн тулып узды, әмма бер телеграмма кисәгеннән һәм телефончы Фәния җиткергән ике-өч сүздән башка хәбәр юк иде ирҗеннән.

Телефонның ачы итеп, кат-кат шалтыравыннан ук сизеп тора: ерак җир, Себер чакырган өйдәгеләрне. Хәтимә ашыгып, каушап трубканы алды да:— Әйе, мин тыңлыйм, мин!— дип кычкырып җибәрде. Тынына кысылып күкрәген тотты.

— Хәтимә! Хәтимә!— Тавыш әллә кайдан идән астыннан, баздан

килгән кебек тоныкһәм сангырау ишетелә иде. Шулай да бу — аның тавышы, аның ягымлы сүзе.

— Әйе, мин тыңлыйм! Курамшин, синме?

— Мин, Хәтимә. Ничек анда? Барыгыз да исән-саумы? Әкрен генә сөйлә, кычкырма.

— Без — исән. Үзең соң, үзең ничек?

— Яхшы. Урнаштым. Күчтәнәчләрең өчен рәхмәт! Рәхмәт, дим. Молодец!

Хәтимә, авызын каплап, тавышын баса төште. Тамак төбенә килеп тыгылган ниндидер төер һаман тыныч кына сөйләшергә ирек бирми, өскә калка иде.

— Без әйбәт. Алло, Курамшин, ишетәсеңме, барысы да яхшы. Үз хәлләрең ничек?

— Килдем, урнаштым. Яхшы гостиница бирделәр. Люкс! Бер үземә бер бүлмә, ванна, телевизор, радио. Түшәк-ястык, мамык мендәрләр... Ашарга-эчәргә патшалар сые. Минем өчен тыныч бул. Улларым, балакайларым ничек соң? Юксыналар, сагыналардыр?

— Бик сагыналар. Кичесе көн саен тәрәзә төбенә басып: «Әти кайт, әти кайт!» дип кычкыра.

— Әти кайт, диме? Шулай диме? Әтиең дә үлеп сагына, диген. Үзең, соң, үзең? Онытып җибәрмәдеңме?— Кәрам көлә. Көлү тавышы телефоннан да үзгәрми икән.

— Үзем мин ничек тә түзәрмен. Күнгән инде. Кайчан кайтырга диләр? Озак торыргамы дим.

Кәрам тагын кечкелди.

— Эшне башлыйсы да бетерәсе генә калды. Боерган булса, срогым тулгач та кайтып җитәрмен... Җитәрмен, дим. Син мине сорашма, андагы хәлләр турында гына сөйлә!

Ара ераккамы, телефон шундый булгангамы, сүзләр вакыт-вакыт югала, каядыр очып китә, ишетелми, ишетелсә дә аңлашылып бетми. Һәр сүзне тотып алырга, ярты-йорты, өзек җөмләләрдән төшенергә тырышып, алар берничә минут сөйләштеләр. Кәрам тагын үзенең участогы турында, ниндидер эш турында сүз кузгатып җибәргән иде — өзделәр. Вакыт чыкты. Хәтимәнең колагында җылы сүзләр ишетү, хушлашу урынына «цех», «автомат», «участок» дигән шалтыравык салкын тимер чыңнары гына ишетелеп калды...

Рәнҗүле хисләр белән үз бүлмәсенә кереп, яңадан тегү машинасына ябышты. Менә шулай инде аның тормышы. Вакытында әллә кемнәр булырга, әллә кайларда йөрергә, әллә нәрсәләр майтарырга хыялланган кызның язмышы бүген дүрт стена эченә кереп бикләнгән, куллары чүпрәк кисәкләренә уралган.

— Иргә чыксаң, үз тиңеңә чык икән, — дип үз-үзен шелтәләргә, такмаклый-такмаклый, машина әйләндерергә тотынды Хәтимә. — Син аның белеменә кызыкма, буй сынына, матурлыгына алданма, абруена шаккатма — синең белән тигез булган, сине санга санаган, үзеңне якын күргән кеше белән тор икән. Булсын шадра, ямьсез, булсын чулак, чатан, булсын хәреф танымаучы томана, икене икегә куша алмаган надан — тик күңелләрең-хисләрең бер булсын икән...

Боларны нигәдер бик соң, еллар узгач, бала анасы булгач кына төшенә башлады Хәтимә. Торган саен ул тирәнрәк аңлый һәм аңлаган саен үзенең яшьлек хаталарын төзәтү мөмкинлеге дә бетә, югала барганын сизә иде.

Инде Хәтимә, өченче бала анасы, хәзер тормышында нинди дә булса кискен борылыш булыр, дөнья үзгәрер, матурланыр, дип өмет тә итми...

«Тиле яшьлек» дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Шушы Курамшинны күрде, гашыйк булды да капланды. Әллә аның машинасына кызыкты

шунда, әллә йөзенә, әллә буй-буй сырлы зәңгәр галстугына — аңламассың. Барысы да егетнең үзенә килешә: башын кыйгач салып машинада руль тотып утырулары да, ак күлмәк якасын буган буй-буй зәңгәр галстугы да һәм түгәрәк ияген икегә ярып торган чокыры да. Көлгәндә ияк чокырының әле уңга, әле сулга күчеп биеп торулары бигрәк тә сөйкемле ясый иде үзен.

Әй, гашыйк булу өчен күп кирәк мени житкән кызга!

Хәтимә ирен бары тик шушы хәлендә, бер дә үзгәртмичә, картайтмыйча, элеккечә килеш күз алдына китерергә ярата. Күңеле шулай тели. Аңа бары тик шулай рәхәт.

Шундый чакта Хәтимәнең тегү машинасы да көйләп, жырлап тәкелди кебек. Чәчәкле-гөлле ситсаның ике кисәген ялгап, энә ак жеп белән салмак кына жөй сала. Энәгә юл күрсәтеп баргандай, бармаклар жөй буенча үрмәли. Куллар, аяклар, бөтен тән хәрәкәттә — алар барысы да тегү эшендә, тик күңел генә әллә кайларда.

...Яз көне, май урталары иде. Хәтимәнең унынчы класста укыган чагы, тиздән өлгергәнлек аттестаты алам, дип йөргән чаклары. Көн дә район үзәгенә укырга бара, дәрестән чыккач та, сабакташларын да көтмичә, туп-туры авыл юлына йөгерә. Нигәдер, шушы алты чакрым араны бер үзе узуы күңелле аңарга: юлны тутырып атлыйсың, татлы хыялларга бирелеп барасың. Юл буенда чыр-чу килеп чикерткәләр жырлый, көз утырып калган камыл арасында кошлар чыркылдаша. Ә күңелне ике атнадан башланачак авыр имтиханнар борчый. Аларның барысын да оныттырып күз алдына чыгарылыш кичәсе, аттестат алу көннәре килеп баса. Ул да булмый, үзен тимер юл вокзалында итеп күрә Хәтимә. Имеш, Казанга авиация институтына китү өчен поезд көтә. Тук-тук, тик-тик иткән поезд тәгәрмәчләре тавышы. Гудок биреп паровоз килеп туктый һәм Хәтимә поездга утырып шәһәргә китеп бара. Анда укый, конструктор булачак Хәтимә үзе уйлап тапкан, үзе ясаган самолетларга утырып илнең бер почмагыннан икенче почмагына оча...

Колагында самолет тавышы ишетелеп киткәндәй булды һәм шулчак артына борылып карады Хәтимә. Менә инде гел әкияттәге кебек: ике-өч метр ары гына яшел бөркәнчекле яшел машина килеп туктаган, ә ишегенең ачык тәрәзәсеннән башын тыгып аңа ак якалы, буй-буй зәңгәр галстуклы егет дәшә.

— Әй, сумкалы кыз, утыр, алып кайтам!

— Рәхмәт, безгә болай да яхшы!— ди Хәтимә, кулындагы сумкасын чайкый-чайкый, атлый бирә. Ә машина, куып житеп, әкрен генә аның яныннан бара.

— Бигәшкә кайтасыңдыр бит?

— Әйе,— ди Хәтимә горур гына һәм терек-терек юлын дәвам итә.

— Соң, мин дә шунда бит, утыр!

Кабина ишеге нәкъ Хәтимә турында ачылып китә. Кызның каушап ишеккә тотынуы, ниндидер сихри көч белән машина эченә суырылып керүе бүген дә аңлатып бирә алмаслык гажәп хәл. Кешеләрнең: «Шоферлар тәмле телле, майлы халык, көйләп-жайлап кызларны әллә кайларга алып китәләр икән»,— дигән сүзләрен дә ишеткәне бар Хәтимәнең, ләкин һич курыкмый, башын югары күтәреп, егет кырыенда горур гына кайта. «Игътибар бирмәскә, сөйләшмәскә, елмаймаска, көлмәскә!»— дип ныгыта үзен, каршыдагы түгәрәк көзгедән борчылып, шоферның йөзен дә күзәтеп бара.

Шул чакта көзгедә ялгыш кына күзләр очрашмаган булса һәм егетнең, елмаеп ияк чокырлары уйнаклап куймаса, бәлки икесе дә авызларын йомып авылга кадәр кайткан булырлар иде.

Егет, кызның «хәтәр» хәлен көзгедән күреп аңлады булса кирәк, тынычландырыр өчен генә сорап куйды:

— Ничәнченең кирпечләрен кимерәсең?
Гүя ул моны Хәтимәдән түгел, күзгедән сорый иде.
— Унынчыда укыйм.
— Шулай ук мыни? — дип гаҗәпләнгәндәй була теге. — Ах, үрмә гөлдәй үсә бу кызлар! Димәк, без бер мәктәпнекеләр. Сабакташлар. Ун еллар элек мин дә шулай җәяү йөреп укыган идем. Тик мин Әлмәтнең теге ягынан килә идем. Табанайдан. Хәзер менә нинди генә укучыны күрсәм дә машинамны туктатам. Үземнең сөялле табаннарны хәтерлим...
Кайта-кайта шунысын да белде Хәтимә: шофер дигәне гел дә шофер түгел, ә инженер, нефть мастеры икән. Институт бетереп Әлмәткә килгәненә биш ел ди. Әле өйләнмәгән дә.
Егет үзе Хәтимәгә борылып карамый, елмаеп, әкрен генә көзгегә сөйләп бара. Шулай ук, көзгедәге кызга сорау да бирә:
— Көн саен йөрисеңме? Җәяү? Авырдыр, әлбәттә, кыендыр. Берни дә тормый дисең? Ышанмыйм. Шул хәтле зур сумка, бер пот китаплар белән...
Егетнең салмак кына салдырып, такылдап баруын Хәтимә төшенмәде дисеңме? Барысын да төшенде. Кызлар белән танышасы килгән егетләр шулай инде алар: сүз юктан сүз — ата казың күкәй саламы? Хәтимәгә карт егетләр белән сөйләшү үзе бер кызык иде. Бигрәк тә инженер, укымышлы егет белән. Бигрәк тә кулында легковой кадәр легковой тоткан нефть мастеры белән.
Ә ул көзгегә карап алган да сибә дә сибә генә борчакны. Имеш, мин сине шушылай һәркөн озата барыр, каршы алыр идем. Имеш, телисең икән, сине әллә кайларга, җир читләренә алып китәр идем.
Ә Хәтимәдә соң машинага утырып җир читләренә гизүме кайгы! Алда аның авыр-авыр имтиханнары, зур шәһәрләргә китү, институтка керү хыяллары, тагын әллә нәрсәләр...
Шулай да кыз инженер егет машинасында җилдереп мәктәпкә баруга, ут өереп авылына кайтуга каршы түгел. Әйдә, йөртәсе килгәч йөртсен!
Сүз куешканча, һәр көнне иртәнге сәгать алтыда сумкасы тулы китап-дәфтәрләр белән олы юлга чыгып баса Хәтимә. Һәр көнне арт урамнан, тау буйлап кына тирбәлеп Курамшинның яшел бөркәнчекле легковое килеп чыга. Юлга җиткәч, салмак кына килеп кыз янында туктала. Әкияттәге оҗмах капкасыдай, машинаның ишеге ачылып китә. Шул ук көчле куллар Хәтимәне магнит кебек эчкә тартып кертәләр, һәм алар җилтерәтеп кенә район үзәгенә төшеп китәләр...
Мәктәптә гаҗәпләнәләр бергә укыган иптәшләре: «Кай арада килеп җиттең әле? Әллә син юлга төнлә торып чыгасыңмы?» — диләр.
Хәтимә дәшми, авызын җыя алмыйча көлә генә. Үзе генә белә кай арада килеп җиткәнен. Икегә бүленеп торган киң иякле сөйкемле егет белән машинаданиләр сөйләшкәннәрен дә үзе генә белә. Нәрсәләр ди бит әле инженер башы белән: «Дөресен әйткәндә, бер йомышым да юк минем треста. Анда бары тик синең өчен генә барам. Миңа синең, беләсеңме, нәрсәң ошый? — дип сорый да үзе үк җавап бирә — колак яфракларың. Алар, беләсеңме нәрсәгә ошаганнар? Тамчылы гөл яфракларына».
Кызык та кеше инде бу Курамшин. Инженер, ә үзе бер дә бала-чагадан ким түгел. Тамчылы гөл яфраклары, имеш!
Ул көнне, ни хикмәттер, Хәтимә колакларына әнисенең кызыл тамчылы алкаларын таккан иде...
Алар өч-дүрт көн рәттән бардылар машина белән. Бер тапкырында әлеге инженер Хәтимәнең озын керфекләрен мактады, икенче мәртәбәсендә кечкенә кулларын, нәфис бармакларына сокланды, өченчесендә муенындагы янәшә ике бөртек миңен күреп гаҗәпләнде. Янәшә миңле

кызлар тормышта пар, бәхетле булалар, имеш. Астыртын булса да тәм ле телле бу Курамшин.

...Тегү машинасы кинәт көен югалтты, энә салулап, бер читкә керен китте. Менә син, әй, Курамшин машинасының тормозына басам дип онытылып, төбәлдереккә ялгыш басып куйган Хәтимә.

Шул көннәрдә аның машинасына утырмыйча җәяү генә барасы булган да бит, күрәсең — тәкъдир. Күнде дә китте Хәтимә бу машинага, иялəщте дә китте Курамшинның чокырлы иягенә. Хәзер инде кыз ул күренмәгән көннәрне дә авыр кичерә башлады: бара-бара да артына борылып карый, атлый-атлый да юл читенә утырып көтә. Ул килмәсә, боега, үпкәли, хәтта каты-каты сүзләр әйтеп тирги дә. Әйтерсең, егет һәр көнне Хәтимәне машинасы белән мәктәпкә илтергә бурычлы!

Соңыннан белде: егет трай тибеп йөри торган җилбәзәкләрдән түгел икән. Аның эше галәмәт тә күп, авыр, катлаулы, ул булмаса скважиналар туктап кала да нефть бөтенләй чыкмый башлый икән.

Бичара, бер көнне, үзе килә алмагач, Хәтимәне илтү өчен ниндидер шоферны утыртып җибәргән машинасына. Кайдан тапкан диген шундый холыксыз кешене. Хәтимә янына килеп туктады да: «Син буласыңмы ул ханым-солтаным? — дип сорый.— Утыр! Юкса җәяү йөри башласаң, чабатаң кыйгаер!» — ди. Нинди чабата инде бу заманда!

Юл буе тиргәп, үгет-нәсихәт биреп барды бу. «Син, сеңелем, танавыңнан юеш кипмәс борын ук безнең мастерның башын әйләндермә, яме. Аның эше тыгыз, вакыты юк синең белән буталырга. Ул кырыкка якын эшченең житәкчесе, дистәләгән скважинаның хуҗасы. Ул сиңа пар түгел. Беләсең килсә, ханым солтаным, ул — тирә-якка даны таралган оста, автоматлар ясаучы, уйлап табучы. Ә син кем? Юеш танаулы мәктәп баласы. Шулай булгач, сабагыңны гына бел, сабагыңны гына кара инде».

Эх, ачуы да килде соң бу җен холыклы, ямьсез телле шоферга Хәтимәнең! Аңа үч итеп, юри киерелеп барды машинада. Әйе, мактана иде ул үзенең Курамшины белән бу минутта, горурлыгы аның машинага гына сыярлык түгел иде!

Бер мәлне Курамшинны Хәтимә иске фуражкадан, майлы комбинизоннан, катып беткән кирза итекләрдән күрде. Егетне ак яка, зәңгәр галстук, чиста костюм белән каршыларга өйрәнгән кыз өчен бу кыяфәт үтә гаҗәп, иренеңне тешләрлек яңалык иде. Менә сиңа тирә-якка даны таралган оста, автоматлар ясаучы, уйлап табучы кеше! Шушымы инде кырыкка якын эшченең җитәкчесе, дистәләгән скважиналарның хуҗасы!

Егетнең куллары мазутка баткан, битләре майга буялган, чокырлы ияген кара төк баскан.

— Гафу ит, Хәтимә, эштән генә... Сине күрәсем килде,— дип күрешергә кулларын суза бу.

Хәтимә беравык аптырашта торганнан соң гына исенә килде. Инженер дигәнең дә күктән төшкән ак фәрештә түгел, ул да башкалар кебек үк буяла, карала белә, бүтәннәр кебек үк тимер тотып эшли ала икән, әй!

Бу хәлләрдән соң егеттән бизәрмен дип уйлаган иде, киресенчә, аны тагын да ныграк ярата, тагын да көчлерәк сагына башлады. Курамшинның килми калган көннәре өчен ул инде ачуланмый, электәгечә үпкәләп йөрми иде.

Һич көтмәгәндә алар чыгарылыш кичәсендә очраштылар. «Аттестат алучыларны котлау өчен сүз нефтьчеләр вәкиле мастер Курамшинга бирелә», дигәч, дикъкатьләбрәк караса, я ходай, трибунага, чыннан да ул меңеп бара. Шул кадәр дә кызарды Хәтимә, шул кадәр дә каушады — үзен, кинәт убылып, кайнар күлгә төшкән кебек хис итте. Укучыларның барысы да Курамшинга түгел, Хәтимәгә борылып карадылар

сыман. Хәтта президиумда утыручы укытучылар да күзләрен Хәтимә утырган рәткә текәде кебек. Сизгәннәрдер. Беләләрдер...

Нәрсәләр сөйләде Курамшин. Хәтердә юк. Урта мәктәп бетерүчеләрне котлаудан бигрәк, ул аларны нефть эшенә килергә чакырды бугай. Аның соңгы сүзләре генә бераз колакка кереп калган: «Кара алтын тирәндә ята, аны көрәк белән чыгарып булмый. Безгә сезнең кебек белемле, гайрәтле яшьләр кирәк».

Соңыннан танцы булырга тиеш иде, Курамшинның биергә чакыра башлавыннан куркып, Хәтимә башта коридорга, аннан урамга чыкты.

Шунда аның кулыннан Курамшин килеп тотты.

— Кайтабызмы, аппагым?

Егетнең тәкъдимен кире кагасы, иптәшләре янында кичәдә генә каласы булган. Юк, ниндидер явыз шайтан: «Утыр кызый машинага, бергә кайт!» дип котыртып тора.

Гадәттәгечә, янәшә утырдылар. Киттеләр.

Төн якты булса да, машина эче караңгы иде. Хәтимә шунда, узган көннәрне исенә төшереп, юләрләрчә көлеп җибәрде.

— Я, Курамшин, хәзер минем миңнәремне дә, колагымны да күрә алмыйсың, инде кай җиремне мактарсың? — дигән иде ул.

Егет монда да тапкырлыгын югалтмады:

— Тавышың гаҗәп моңлы икән синең! Билләһи, беренче мәртәбә ишетәм!

Көлгәндә, Хәтимә, онытылып китеп, Курамшинның иңенә башын куйган икән — егет, иелеп, аның «тамчылы гөл» кебек колак яфрагын үбеп алмасынмы? Тагын, тагын кабатланды. Егетнең җылы сулышыннан исереп, шулай җилкәгә башын салган килеш тын да алмый кайта бирде Хәтимә...

Соңгы очрашу булыр дип уйлаган иде кыз. «Укырга китәм, бүтән күрешә алмабыз, сау бул,» — дип тә әйткән иде Курамшинга. Тормыш дигәнең син уйлаганча гына түгел икән.

...Җайлы гына барган җиреннән, тегү машинасы тагын көйсезләнә башлады. Аяк тигез басмый төбәлдерекккә. Нерв галәмәтләре. Кай вакытларда балтырлар тартышып-тартышып алса да, болай ук булганы юк иде әле.

...Институтка китәм дип җыенып йөргән көннәрдә, бәхетсезлеккә каршы, Хәтимәнең әнисе бик каты авырып китте. Элек тә сырхаулап, ашау үтми йөри иде, хәзер бөтенләй түшәккә егылды.

Нишләргә, кая барып бәрелергә белми аптырап калды кыз.

Туганнары юк түгел иде аларның. Ана ягыннан булмаса да, Түбән очта абзыйлары, ягъни әтисенең бертуган энесе, Урта урамда җизнәсе һәм тутасы тора. Тута кеше — әтисенең апасы була.

Хәтимәнең әтисе сугыштан кайтмаган, хәзер шул Түбән очта яшәүче өйләнмәгән энесенә димләгән булганнар икән Хәтимәнең әнисен. Бик яшь тә, чибәр дә, уңган да булган заманында Мәһибәдәр апа, кияүгә чыгарга каршы килгән, кырт кискән. Ир ягыннан килгән туган-тумача, кайниш-ыру җыелып ничаклы гына үгетләмәсеннәр, ачуланмасыннар — сүзендә торган тол хатын — яңа гаилә корып җибәрергә баш килли каршы булган. Мәрхүм иренә хыянәт итәсе килмәгән, кызы Хәтимәне, улы Фәритне үги ясарга теләмәгән. Шуннан ата ягы, тәмам хәгере калып, Мәһибәдәр белән бөтенләйгә очны өзгән, туганлыктан ваз кичкән.

Тормышлары авыр булса да Мәһибәдәр аларга беркайчан да барып егылмады, ялынмады, сер бирмәде, түзде, кичерде.

Хәтимәнең:

— Әллә әни, абзыйларга, тутәйләргә барып килимме? — дигән аптыраулы соравына да:

— Кирәкми, кызым, үтәр әле, — дип кенә җавап бирде Мәһибәдәр.

Кайгысын кемгә сөйләргә, кемнән киңәш-ярдәм сорарга аптырап

йөргән кыз, бер көнне караңгы төшкәч, тотты да күз яшен коя-коя, Курамшиннарның өенә китте.

Ул тау буенда, бер ялгыз карчыкта, алты почмаклы иске йортның алгы ягында тора иде. Үзе шулай дип сөйләде Хәтимәгә «Минем фатир иркен, бер үземә бер мич, мич башы һәм мич башында биш мәче»,— дип шаярткан иде.

Шакып, ишеген ачтырды Хәтимә, шунда сүзен әйтә дә алмыйча, егетнең күкрәгенә капланып елап җибәрде.

Егет каушап калды, ни эшләргә белми кызны кочаклап алды.

— Нәрсә булды, Хәтимә? Я, әйт инде, ни булды?

Кочагындагы кызның чәчләреннән сыйпый-сыйпый юатырга азапланды. Ахырда, эшнең нәрсәдә иканенә төшенгәч, киенә башлады.

— Әйдә, больницага төшерик, районга!

Бераздан өйгә машина килде. Әнисен әйбәтләп киендерделәр, машинага утырттылар һәм китеп тә бардылар.

Көн саен диярлек төшеп йөрделәр алар Хәтимәнең әнисе янына. Күчтәнәчләр илттеләр, больницада булмаган төрле дарулар табып алып килделәр, ләкин аңа тернәкләнмәде. Алай гына да түгел, көннән-көн ябыга, сулыга, хәлсезләнә барды. Врачлар да белгән, Курамшин да ишеткән, тик кызга гына әйтмәгәннәр — Маһибәдәр апаның ашказанында рак дип аталган төзәтеп булмаслык шеш икән...

Ике айдан соң авыруны китергәннән дә начаррак хәлдә яңадан алып кайттылар.

Хәтимәнең хәле дә бик мөшкел иде. Хәзер бөтен хуҗалык аның җилкәсендә. Йорт-җир, ишек алды тулы терлек-туар. Аның өстенә, үзеннән ике генә яшькә кече, йортны бар дип тә белми торган, урамда кәшәкә сугып йөрүче энесе. Аш пешереп ашаткан да Хәтимә, мал-туарны барлап, сыер савып, көтү куып йөргән дә, бакчада бәрәңге утап, бәрәңге күмеп йөргән дә шушы кыз.

Барыннан да бигрәк әнисе. Ул авыр сулап, көчкә тын алып ята. Ята-ята да корсгаксыган кулларын сузып Хәтимәне үз янына чакыра.

— Утыр әле, кызым, китмә янымнан. Башымны тот әле.

— Әллә әни, тагын врачларга күрсәтеп карыйкмы? — дип сорый Хәтимә өмет белән, күз яшьләренә тыгылып.

— Кирәкмәс, кызым...

Көннәре санаулы гына калганын хәзер авыру үзе дә аңлый, шуңа күрә кызына соңгы сүзен әйтергә, соңгы киңәшләрен биреп калырга ашыга:

— Бик әйбәт егет икән бу Курамшин дигәнең. Тәүфикълы, акыллы. Сине яратса, аны ташлама, кызым.

Хәтимә ояла, кызара, көлә:

— Бабай бит ул, әни! Ун яшькә зур...

— Алай димә. Әтиең дә миннән олы иде. Олы кеше хөрмәт итүчән була ул. Васыятем шул: рәнҗетмә. Миннән сиңа фатиха. Ташласаң — бәхиллегем юк.

...Тегүдән туктап, шул кайгылы көннәрне кичереп утырды Хәтимә. Машина тынды — ул тынды.

...Сентябрь урталарында җирләделәр аның әнисен. Авыр булды җеназа озату, кызга үлем белән бер булды.

Газиз әнисе өчен дә, үзенең ялгыз калуы, хыяллары җимерелүе өчен дә ауный-ауный елады кабер өстендә. Әнисе исән булса, бу көннәргә калыр идемени ул? Бу вакытта инде Хәтимә, шатлана-шатлана, шәһәр урамнары буйлап институтка барыр иде, сөенә-сөенә классына керер, бирелеп-мавыгып күзлекле-сакаллы ниндидер профессорның лекцияләрен тыңлар иде. Дәрестән кайткач, китапларын куеп, тагын урамга чыгып китәр, шәһәрнең паркларына барыр, музейларын карар, кинотеатрларына йөрер иде. Нинди зур кеше булып кайтыр иде ул аннан!

Юк, насыйп булмаган икән аңа институтка керүләр, укулар, шәһәрнең гүзәл һәм атаклы урыннарын күрүләр. Юк икән, беркем дә чыгачак түгел икән хәзер Хәтимәдән, бернәрсә дә булмаячак икән гомергә.

Энесе Фәрит белән йортта икәүдән-икәү ятим калган кызның хәленә керүчеләр, аны кызганучылар булмады түгел, булды. Әнисен күмгәндә ике ятимне юатучылар, ярдәм итәргә вәгъдә бирүчеләр дә шактый күп иде. Әмма кеше кайгысы кешегә, чыннан да, иртән керә, кич чыга икән. Һәркемнең үз мәшәкате, үз дөньясы, күрәсең. Баштагы атналарда туганнары яки күршеләре ишек алдына берәр машина утын ташлап, я берәр олау печән аударып киткән булдылар да, шуның белән вәссәләм. Аннары тагын, йортны ничек алып бару, кышка кайсы малны сую, кайсын нәселгә калдыру хакында киңәшләр биреп чыккалаулар булды. Ә менә Хәтимәнең киләчәге, аның уй-хисләре, омтылышлары, хыяллары турында ник берсе кызыксынсын!

Ә Курамшин бөтенләй башка иде. Ташламады кызны авыр вакытларда, моңаерга ирек бирмәде.

— Яле, аппагым, бүген ниләр эшләдең? — дип килә дә җитә иде кичен.

— Сыер саудым, аш пешердем, бәрәңге казыдым, — дип тезеп китә Хәтимә.

— Юк, болай ярамый! Болай бармый тормыш!— дип әрләргә тотына Курамшин. Синең нинди китаплар укуыңа, кинолар каравыңа кадәр төпченә. Аннан, Фәритнең дәфтәрләрен алып утыра. Ой, гыйлемле дә икән бу Курамшин! Математиканы, физиканы, химияне күңелдән белә. Фәрит чишә алмаган мәсьәләләрне минуты белән чишә, ничек эшләргә икәнен өйрәтә, кирәк булса малайны яхшы гына кыздырып та ала:— Ялкауланасың, почык борын,— дип шелтәли аны,— укырга иренәсең!

Рәхәт, күңелле иде Хәтимәгә Курамшин белән кич утыру. Егет үзенең институтка ничек керүен, анда ничек итеп укуларын ярты төнгә кадәр диярлек кызык итеп сөйли. Аннан армиядә булганнарын, самолетта радист булып хезмәт итүен, бер шәһәрдән икенчесенә очканнарын мавыктыргыч итеп сурәтли. Дөньяны аз күрмәгән егет.

Хәтимәнең дә шулай Курамшин кебек илнең төрле җирләрендә буласы, төрле кешеләр белән очрашасы, аралашасы килә. Тик берсенең дә хәзер тормышка ашасы юклыгын, монда бары тик әнисенең үлеме сәбәпче икәнен исенә төшерә дә, тагын күз яшенә буыла иде Хәтимә.

Төрлечә юатып карый аны Курамшин: чәчләрен, битләрен сыйпап та, мәзәк сүзләр әйтеп тә, шелтәләп тә, ләкин Хәтимә һич кенә дә елаудан тыела алмый.

— Я, гел күз яше түгеп кенә эш чыкмый,— ди Курамшин.— Насыйп булса, без синең белән әллә нинди матур җирләрне гизәрбез әле. Хәтта, Себер тайгаларына аюлар янына кунакка да барырбыз,— дип шаярта.

Күп җирләрдә булган ул үзе, тик Себер ягында гына булмаган икән. Төмән якларында бер институтта укыган дусты бар, шул кунакка чакырып ята, имеш.

— Чыннан да, кайчан да булса шул якларга алып барырсыңмы? — дип балаларча ышанып сорап куя Хәтимә.

— Әлбәттә! Ә син аюлардан курыкмассыңмы соң?

Моннан ун ел элек шаярып әйтелгән шушы сүзләрне исенә төшерә Хәтимә һәм кузгалмыйча авылда яшәп калуына әле дә булса гаҗәпләнә.

Әх, бу ир-ат, алганда нинди генә вәгъдәләр, антлар биреп бетерми дә ниләр генә өметләндерми! Курамшин да бит кавышкан, бергә тора башлаган чагында Хәтимәне институтта укытырга да, курортларга алып барырга да, туристик сәяхәтләргә чыгарга да, һәм ниһаять, трамвайлы-троллейбуслы, күп-күп институтлы зур шәһәргә күчәргә дә сүз

биргән иде. Тордымы соң ул хет бер генә вәгъдәсендә? Кайда аның вөҗданы?

Сылтауга сынык табылды да торды. Курамшин башта: «Сабыр ит, Фәрит сигезенче классын бетерсен, техникумга керсен»,— диде. Хуш, Фәрит мәктәпне тәмамлады, студент булды. Аннан: «Бала бераз үсә төшсен, аякка бассын», — дип йөрде. Кечкенә Фәргат тәпили башлауга, Хәтимә икенчесенә узды һәм Курамшинга тагын сәбәп табылды. «Бу кыяфәт белән кая бармакчы буласың? Сине дә, туачак баланы да кабергә кертәсем юк»,— дип каршы төште. Инде олы улы Фәргат укырга керде, кечкенәсе бакчага йөри. Хәзер Курамшинның җиле бөтенләй икенче яктан исә: «Кайда да бер кояш, әнисе. Андагы бер сум — монда да бер сум».

...Тегү машинасы бер туктый, бер китә, үз эшен эшли бирә, инде күлмәк әзер диярлек — яка гына куясы.

Хәтимә җепне, гадәтенчә, теше белән шырт итеп кенә кисте дә, күлмәкне машина астыннан алды, үз гәүдәсенә куеп, аңа сокланып карап торды. Күлмәк менә дигән булачак. Нәкъ модалар журналында күрсәтелгәнчә. Юк, аннан да матуррак. Нигә дисәң, Хәтимә аны үзенчәрәк, тагын да хикмәтлерәк итеп эшләде. Кесәләрен журналда күрсәтелгәнчә шакмак итеп түгел, ярымтүгәрәк итеп алды, як-якларына кыскакыска ике балитәк тотты. Шулай итеп, французлар үрнәге шактый диярлек үзгәреп, татарчалашып китте. Якасын да ул бераз үзгәртәчәк — тирән декольтега аркылы каплама куячак. Ник дисәң, ачык күкрәгеңне күрсәтеп йөрү безнең халыкка килешми.

Тегү эшенә Хәтимә бала чакта ук диярлек, әнисеннән өйрәнгән иде. Бик оста җөйче диләр иде Мәһибәдәр апаны авылда. Заманында юк кына материалдан да карап туймаслык кием тегә алган ул, үзенең эше белән кешеләрне куандырып яшәгән.

Җөйче булу Хәтимәгә ләззәт бирә, вакытлыча гына булса да, укырга китә алмау ачуларын онытгырып тора иде. Ни дисәң дә, аның кечкенә генә һөнәре бар, ике кулына бер эше бар.

Былтыр шәһәрдә тегү фабрикасы ачылгач, шунда эшкә кереп караган иде Хәтимә — ике ай дигәндә ташлады. Чөнки аны гомерендә тегү машинасы күрмәгән япь-яшь кызлар белән бергә өйрәнчек итеп кенә алдылар. Һичнинди кызыгы, киләчәге, өмете юк иде эшнең. Өлге белән киселгән бер үк төрле әйбер тегәләр икән анда. Айлар, атналар, еллар буена.

Хәтимә өлешенә трусикның сул балагы эләкте. Конвейрда ике ай буена шуларны тегеп утырганнан соң, эшен күтәреп мөдир янына керде. «Бу ыштанның, бәлки, уң ягын да бирерсез?» ——дип сорады усал итеп. Тик мөдир анысын да тиз генә өметләндермәде.

Нигә дип ыштан балагы белән кул пычратып, вакыт уздырып ятсын ул фабрикада — үз өендә Хәтимә судагы балык кебек йөзә: тели икән— менә дигән затлы күлмәк — чалбарлар тегә, тели икән — Мәскәү фабрикаларыннан да уздырып, өр-яңа модалар белән костюмына, пальтосына заказлар ала. Һич тә боегып торырга ирек бирмиләр аңа кешеләр.

— Эх, модалар ательесы булса икән — менә күрсәтер идем кемлекне! — дип хыялланган чаклары да аз булмады Хәтимәнең, тик шәһәрдә андый йорт һаман әле салынмады.

Дөнья яктысы күрми саргая Хәтимә, илләрне, кешеләрне күрми тилмерә. Дөрес, бер елны ниндидер киңәшмәгә дип Казанга барганда ул, бер яшьләк Кәримен алып, иренә ияргән иде. Курамшин, гостиница табып алып, аларны урнаштырды да китеп тә барды җыелышына. Утырдылар шунда улы белән көнозын тәрәзәдән карап. Кичен, кайткач, китәргә дә җыена башлады Курамшин: янәсе, бик зур задание биреп җибәргәннәр, иртәгедән эшкә тотынырга кирәк. Былтыр исә үзе теләп Мәскәүгә алып барды Хәтимәне. Халык казанышлары күргәзмәсенә пу-

тевка биргәннәр иде аңа. Кыскасы, Хәтимә шушы яшькә житеп бары тик ике зур шәһәрдә булды һәм шунда да үзенең томана булуын, күз алдында еллар гына түгел, бөтен бер дәвер югалтканын тойды. Ул, баксаң, андый зур шәһәрләрнең урамыннан да уза алмый, адым саен адаша икән. Трамвай, троллейбус кебек машиналарда да йөри белми, метро баскычларыннан да күтәрелә алмый, гостиница ишекләрен дә таба мый икән әле! Әле андый шәһәрләрнең Хәтимә белмәгән лифтлары, автомат кассалары, акча ваклый торган урыннары, пәрәмәч, сумса сата торган машиналары да бар икән. Анда ишекләр үзләре ачыла, баскычлар үзләре менә, таксилары выжылдап синең янга туктый, тагын әллә нинди могжизалар...

Дөнья күрмәгән кешене сәер дә итә икән зур шәһәр. Адашмыйм дип, Курамшинга тагылып йөри торгач, метрога шундый ук плащлы бер иргә ияреп киткән дә барган поезда Хәтимә апакаең! Ярый әле, үзләре кергән кунак йортының исеме «Спутник» икәнен хәтерли иде — юкса ничек табар иде Курамшинны, ничек кайтыр иде өенә? Хәлне милициягә аңлатып биргәч, илтеп куйдылар тагын гостиницага... Берсеннән-берсе зур һәм матур ике башкалада булу аның күзләрен бөтенләй ачып жибәргәндәй булды, болай яшәргә мөмкин түгеллекне бөтен кискенлеге белән китереп куйды. «Ташларга! Төялергә дә, балаларны алып кая булса да китәргә!» — дигән чаклары булды. — Курамшин каршы килмәгәе теләсә нәрсә эшләсен, әмма Хәтимә өч малае белән кая булса да чыгып сызачак!»

Шулайлар итеп кабынып, жилкенеп алса да, үз хәлен үзе аңлап, тыелып кала иде Хәтимә. Ачу алдан, акыл арттан йөри, дигәннәр. Тормышта акны карадан аерырлык белемең, кулыңа тотарлык һөнәрең булмагач, ераккамы соң сикерә аласың, дивана баш! Житмәсә, аяксыздан-кулсыз өч бала белән йорт-жиреңне калдырып?!

Аннан соң, Курамшин да бит әле, хатынына игътибары житмәсә дә, бүтән кайбер ирләр кебек юлдан язганнардан түгел. Артыгын эчми, өйдә тавыш күтәрми, теләсә нәрсәгә бәйләнми. Житмәсә, укымышлы кеше, зур инженер. Әллә нинди әкәмәтләр уйлап таба, әллә нинди кызыклы автоматлар ясый, скважиналарга әллә нәрсәләр көйли, дип сөйлиләр бит аның турында. Семьяда да төпле ир булды ул, төрле гайбәтләргә, тәмле телләргә бирелмәде, кеше сүзенә ияpмәде.

Ә бит, һич көтмәгәндә-уйламаганда Хәтимә аңа кияүгә чыгып куйгач, ничек кенә котыртмадылар аны. Имеш, инженер башың белән токмач та җәя белмәгән кыз алгансың, читән исле авыл кызына өйләнгәнсең. «Ирененнән сөте кипмәгән, артык яшь, ул сине барыбер ташлап китәчәк», — дип йөрделәр. Хәтимәгә килеп, дус-ишләре исә киресенчә: «Егетең карт икән. Инженерлыгына кызыккансың инде. Бер дә тик түгел, ул синең белән барыбер тормаячак, күрерсең, калдырып кая булса да китеп барыр әле», — дип куркыттылар.

Тик берсенең дә сүзе өскә чыкмады, юраулары тормышка ашмады. «Читән исле» Хәтимә белән «зур башлы» инженер Курамшин әле дә булса бергә яшәп яталар, тырышып-тырышып оя асрыйлар, йомры башлы малайлар үстерәләр.

Дөнья мәшәкатьләрен куып йөри торгач, Курамшин белән кая булса да китү, я булмаса, аннан башка гына үзе чыгып китү уйларыннан арынган, тынычланган, басылган иде инде Хәтимә.

## ЖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Сүз куешканча, Пичугов кунак йортына нәкъ кичке жидедә килде. Курамшин бу вакытта Черек күлдән кайтып юынып йөри иде әле. Кузьма, коридорның теге башыннан сөлге белән сөртенә-сөртенә килгән Кәрамне күреп, кычкырып ук жибәрде:

— О-о, дустым, сине җигә дә башлаганнар икән! Нигә бу кадәр озакладың?

Бүген транспорт та вакытында килде, юлда да батып ятмадылар, һаман шул Аввакумов тотты. Иртәдән үк сызымнар, схемалар күтәреп икәүләп булачак объектларда йөрделәр, скважиналарны тоташтыру мәсьәләләрен тикшерә торгач, күлнең икенче ягына ук барып җиттеләр һәм, җаяү кайтып, соңга да калдылар. Эштән бигрәк, көн, әлеге дә баягы бәхәсләшү, сүз көрәштерү белән үтте. Шуңа күрә Курамшинның тагын кәефе юк иде.

— Әйдә, Кузьма, бүлмәгә керик, барын да сөйләшербез, — диде Кәрам, дустының иңеннән кочып алды.

— Әйтәсе дә юк, люкс! Югары класслы һотел! Дүртебезгә ике урындык, бер өстәл...

— Киттек ресторанга!

Турысын әйткәндә Кәрам моны көтмәгән иде. Ул элек-электән ресторан, ашханә тирәсен өнәми, кешеләр күзеннән, тавыш, чыр-чудан читтә, тыныч кына өйдә ашап-эчәргә, өйдә утырырга күнеккән. Аннан, хатының пешергән ашка ни җитә?!

Нәфес дигәнең дә каһәр бит ул: Кузьма аны сабакташ, күптән күрмәгән ахират дус итеп өенә чакырыр, квартирасын күрсәтер, хатыны белән күрештерер, бала-чагалары белән таныштырыр дип өметләнгән иде. Булсын Кәрам аның урынында — Кузьманы тын алырга да ирек бирмичә өенә өстерәр иде.

Курамшинның уйларын сизгәндәй, Кузьма юлда акланырга маташып барды:

— Ничего, Кәрам, гел болай булмас әле. Алла теләсә, без дә кешеләрчә яши башларбыз...

Кузьма үзе турында түгел, Себер турында әйтә икән:

— Киләчәктә безнең Себер дә Олы җирдән ким булмас. Сизәсеңме, Европа хәзер безгә үзе килә! Себер тиздән дөньяны шаулатачак!.

— Әйе, гомер буе шулай өмет белән яшибез инде...

— Дустым, әгәр син бу урыннарны өч-дүрт ел гына элек күрсәң иде! Бу шәһәр егерме-утыз йортлы караңгы авыл иде бит!

— Күрәм, дустым, күрәм...

— Мин сине булачак шәһәрнең генераль планы белән таныштырырмын әле. Вах — гаҗәп матур зур кала булачак. Менә биредә... — Пичугов урам буйлап атлый-атлый иске йортларны күрсәтә. — Биредә бишәр катлы кирпеч йортлар салыныр. Әнә тегендәрәк тугыз катлы корпуслардан торган өч микрорайон... Синең Казанның бер якта торсын!

— Алай икән.

— Әнә, теге урманны күрәсеңме? — Кузьма сул яктагы чыршы урманына таба кулын сузды. — Анда мең койкага исәпләнгән больница шәһәрчеге планлаштырыла. Арырак стадион, кинотеатр, культура сарае, су бассейны...

Кәрам хәйран булып Кузьмага карап ала. Зур йортлар, стадионнар һәм су бассейннары шаккатырмый, Кузьманың шулай мәктәп балаларыча мавыгып, авыз суларын корытып сөйләве кызык. Ул Пичуговны хәзер бөтенләй аңламый: әллә зур урыннарда утыра торгач, күп сөйләргә, мактанырга өйрәнеп киткән, әллә гади кешеләр белән аралашып яшәмәгәнгә тыйнаклыгын югалткан? Ни дип әйтергә дә белми.

Бара торгач, алар нindидер бер иске базарны аркылы кисеп чыктылар, бер-ике зур канауны сикереп үткәч, таш түшәлгән тигез юл күренде.

— Бу безнең үзәк урам була инде.

— Мәскәүдәге Горький урамыннан бер дә ким түгел икән.

— Көлмә, дустым. Генераль планда бу киң, яшел проспект итеп

күрсәтелгән. Йортлары — патша сарайларыннан ким түгел! Небоскреблар! Коллезей!

— Проспект буйлап ялтыравыклы туфлиләрдән шарт-шорт басып йөриселәрең дә бар икән әле.

Урам почмагындагы бер йортның ишек алдыннан икенче урамга чыгып, эре нарат бүрәнәләрдән борынгы сәүдәгәр йорты кебек биек, зур итеп салынган искерәк кенә өй каршына килеп туктады Пичугов.

— Безнең ресторан әлегә шушы була инде, Кәрам туган,— дип Кузьма үзенең кунагын алга уздырып җибәрде, итәгатьле генә итеп кулы белән ишеккә таба күрсәтте. Рәхим ит, янәсе.

Күтәрелеп өскә, кәрнизгә таба караса, анда чыннан да зур хәрефләр белән «Ресторан кедр» дип язылган, җитмәсә зәңгәргә буялган ул тактага кедр рәсеме дә ясап куелган иде.

— Тапканнар бит исемен дә: ыштансызга каеш бау,— дип иренен турсайтып, үчекләп алды Кәрам.

Тышы болай шыксыз күренсә дә, бинаның эче шактый зур, ярыйсы матур, якты икән. Ресторан дигәненең биш-алты гына өстәле булуга карамастан, үзенә күрә эстрада оркестры да бар ахры — түргә сәхнә сыман кечкенә мәйданчык ясалган, анда пианино куйганнар, микрофон белән тавыш көчәйткечләр көйләгәннәр. Һәр ашханә һәм ресторанның аерылмас юлдашлары «Өч баһадир» картинасы белән Шишкин аюлары биредә дә стенаны бизи.

Ныклап кич җитеп бетмәгәнгәме, әле ресторан эче буш, тик түр өстәлләрнең берсендә генә шактый кызмача ике егет кычкырып сөйләшеп утыралар иде.

Пичугов белән Курамшин урынны тәрәзә яныннан алдылар.

— Проектта ресторан да каралган,— дип тагын сөйли башлады Кузьма акланырга теләгәндәй.— Бер дә башкала рестораннарыннан ким түгел. Ике катлы, йөз илле кешегә исәпләнгән.— Ул, башын артка ташлап, урындык артына ауды, түшәмдәге люстраларга күпмедер карап торды.— Эх, Кәрам туган, булачак әле шәһәр. Теләсә кайсы Европа шәһәрен көнләштерерлек булачак!

— Ышанам, дустым, барына да ышанам!— дип ясалма пафос белән Кузьманы бүлдерде Курамшин.— Тик, болары калып торсын әле. Шәһәр күрмәгәнме мин? Я, үзеңнең хәлләр ничек соң? Тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен әйтәм. Татьяна исән-саумы? Бала-чагаларың ничәү?

Шул вакытта каршыдагы кухняны каплап торган калын штор ачылып китте һәм аннан челтәрле ак калфак кигән, кечкенә алъяпкыч белән билен буган яшь официантка чыкты. Туп-туры болар янына килде, мөлаем елмаеп баш иде. Тезен чак кына бөгеп, артистларча реверанс та ясады бугай әле.

Кузьма урыныннан торды, официантканың беләгеннән тотып Курамшин янына китереп бастырды.

— Менә, таныш бул, Зоя, шушы була инде минем дустым Кәрам.

Курамшин читенсенеп кенә баш какты. Теләсә кайда, теләсә кем белән танышуны да, таныштыручыларны да җене сөйми иде аның.

— Нәрсә китерим? — дип сорады официантка йомшак кына итеп һәм Пичуговның колагына иелеп.

— Нинди тәмлерәк нәрсәң бар, шуны китер, Зоя!

Пичугов белән официантка арасындагы эшнәлек галәмәте Кәрамнең тагын ачуын китерде. Газиз акчаңны кесәңнән чыгарып түлисен икән, рәхим итеп йөгерсен, эше шул! Яшерә-посына колактан-колакка пышылдашуның нигә кирәге бар?

Күрәсең, Кузьма ресторанга алдан заказ биреп куйган — Зоя дигәне тиешле ашамлыкларны үзе белеп, тәртибе белән генә китерә башлады. Өстәлгә бер шешә коньяк, бер шешә ак аракы утырды, закускага

Себер яклары өчен тансык булган кыярлы-помидорлы салатлар куелды.

— Безнең кунак балык ярата,— дип искәртеп алды Пичугов официанткага.

Әйе, онытмаган икән әле Кузьма, балык дигәндә җанын фида кыла инде Кәрам. Студент чакта кибеттән һәр көнне диярлек килька сатып ала иде. Дусты, күрәсең, шуларны искә төшергән.

Табынга чөгә, севрюга кебек кыйммәтле балыклар, кызыл, кара икралар, өстәвенә, үзенә хас тәмле ис аңкытып балык шулпасы да килгәч, Кәрам, Пичуговка булган бөтен суынуларын онытып, чәнечкегә үрелде.

Матур итеп, рюмкаларны зыңгылдатып чәкешеп алдылар. Мондый чакта купшы тостлар әйтешүнең кирәге юк, алардан башка да мәгълүм: дуслар озак еллар күрешмәгән, бер-берсен сагынганнар, рәхәтләнеп гәпләшер нәрсәләре байтак.

Берәү дә сүз башламады, серле, ләззәтле тынлыкны берәү дә бозарга ашыкмады. Караштылар һәм бер-беренә елмаештылар гына. Кыстатмый-нитми тагын бераз кабып алгач, папирос кабыздылар.

Башлап җибәрергә һаман сүз табылмый иде әле. Болай тын утыру, шулай да, озак дәвам итмәскә тиеш. Ниһаять, Кузьма онытылган, кызыклыгы шул кадәр генә булган бер вакыйганы сөйләп китте:

— Хәтерлисеңме, Кәрам, бервакыт без синең туган көнеңне уздырган идек? Пристаньга төшеп, барлы-юклы акчама бер кило вобла алып кайткан идем. Өстәлгә карасам исем китте; бөтен табын балык белән тулган! Валлаһи, сөйләшеп-килешеп тә куймаган идек: группадагылар барысы да сиңа балык бүләк иткәннәр булып чыкты! Кайсы селедка, кайсы килька, кайсы пешергән балык... Сиңа бер семестр буена ашарга җитте бугай ул ризыклар!

— Анысы бик үк әкәмәт түгел! — дип, Кәрам да бер мәзәк хәлне искә төшереп көлә башлады,— менә син Маргарита Семеновнаның туган көненә ничек бүләк тапшыруыңны сөйлә!

— Ә-ә, теге мыеклы хатынны әйтәсеңме? — дип, гадәтенчә башын артка ташлап, хихылдарга кереште Кузьма.— Сез мине тәмам кыен хәлдә калдырдыгыз ул чакта!

Бу болай булган иде. Институтта Маргарита Семеновна дигән бик усал математика укытучысы бар. Экзамен, зачет вакытларында көн күрсәтми иде инде студентларга — икелеләрне рәттән тезеп кенә чыга. Көннәрдән бер көнне моның илле яше — юбилее җитте. «Маргарита Семеновнага берәр бүләк алыйк, бәлки шуннан күңеле бераз йомшарыр»,— дип фикер йөртте студентлар. Тик нәрсә алырга — студентның кесәсе сай бит. Мондый чакта, һәрвакытта, чәчәк букеты коткара, әлбәттә. Арзанга да төшә, күркәм дә. Акча җыеп, берничә студент белән шәһәргә Кәрамны да чыгарып җибәрделәр. Чәчәк кибетенә кереп карадылар, базарга да кагылдылар, тик, гөнаһ шомлыгына каршы, бер кайдан да таба алмадылар чәчәк дигәнен. Кесәдәге биш-алты сумга инде нәрсә алырга? Аптыраешта калды студентлар. Шул чак, — каян башына килгәндер ул шуклык,— Кәрам әйтеп ташламасынмы: «Әйдә электробритва алабыз үзенә!»

Иптәшләре дә хуплады бу кызык фикерне. Ник дисәң, Маргарита Семеновнаны, иреннәре өстендә сызылып киткән куе кара төкләре өчен студентлар юкка гына я «мыеклы хатын», я «гусар», я «Кардинал Ришелье» дип йөртмиләр иде. Шулай итеп, тоттылар да электр пәкесе алдылар. Әйдә, беткән баш беткән, икелеләр өчен үч алырга кирәк! Тик бүләкне берәүнең дә үз кулы белән бирәсе килмәде. Моны хушбуй дип алдап, тартма эченә салып, Кузьмадан тапшыртырга булдылар. Янәсе, син актив егет, математикадан да яхшы сукалыйсың, өстәвенә матур итеп сөйли дә беләсең, студентлар вәкил итеп сине билгеләделәр. Һәм, чыннан да, вәкил ролен Кузьма менә дигән итеп үтәде. Дәрес барганда әдәпле генә алга чыгып басты, Маргарита Семеновнаның юк хезмәтлә-

рен бар итеп, һич булмаган «яхшылыкларын» мактап, аны алтын юбилее белән котлап ун минутлык речь сөйләде һәм нәзакатьле генә итеп тартманы бирде. Менә ачар, менә карар, дип класс ут йотып утырган иде, бәхеткә каршы, Маргарита Семеновна дәрестә тартмага кагылмады. Давылны икенче көнне көттеләр, ләкин, син күр дә мин күр, укытучы студентларга ләм-мим димәде. Аннан соң да юк-бар белән бер генә студентка да бәйләнмәде Маргарита Семеновна — яхшырды да китте бит усал дип йөрткән укытучыбыз! «Яратам мин 23-нче группа студентларын. Башлы малайлар, оригиналь бүләк бирделәр»,— дип әйткән имеш.

Пичугов нәрсәдер сөйләшмәкче иде, шул чак эстрада оркестры уйнап җибәрде дә, аның сүзләре барабан, саксафон тавышларына күмелеп калды. Бу вакытта инде рестoранда шактый кеше җыелган, аларның кайберәүләре ярыйсы гына кызарга да өлгергән, залда яңгыраган фокстротка кушылып идән селкетеп аяк тибәләр, музыка ритмына няреп кул чабалар иде.

Яшьлеккә, студент елларга — матур, хәсрәтсез, гамьсез чакларга кайтып, көлә-көлә тагын шактый вакыйгаларны, шуклыкларны искә төшереп байтак утырдылар дуслар. Әмма сүз һаман бүгенгедән читтә йөрде, хәзерге тормышны уратып әйләнде. Кәрам ачыктан-ачык сизде: Пичугов бу турыда сөйләшергә дә теләми, аннан кача иде.

«Шулай да, семья хәле ничек икән соң Кузьманың?» Ул бит хатларында, үзеннән битәр, Танясы турында яза иде. «Мин бәхетле, минем Танюшам менә дигән хозяйка». «Минем Татьяна яхшы ана гына түгел, яхшы геолог та». «Таням минем мактауга лаек җырчы». Хат саен минем Таням да минем Танюшам... Әйтерсең, аңарда гына хатын!.. Ник ул хәзер бөтен яктан килгән, уңган, булган Танясы турында бер сүз дә ычкындырмый әле?

Ә менә официантка белән якын мөгамәләсе ярыйсы гына сизелә. Әйтәсе дә юк, Зоя теләсә нинди ир-атны кызыктырырлык матур. Ул, кылган үләне төсле аксыл чәчен өскә җыйнап, челтәрле калфагы белән кыршаулап куйган. Ачык зәңгәр күзләре тирәсенә чамалап кына зәңгәр сөрмә тарткан. Бу Зояның күзләрен тагын да зуррак, тирәнрәк итеп күрсәтә. Юка борыны, нечкә иреннәре дә битенә бик килешле. Шулай да, иң матуры — Зояның тешләре. Ул елмаеп алса, тип-тигез, ап-ак тешләрендә түбәдәге люстра утлары чагыла сыман.

Дуслар әкрен генә ашап-эчеп, тәмәке тартып, яшьлек тилелекләрен искә алып утырган арада, Зоя, аерым бер игътибар күрсәтеп, өстәл янына әллә ничә тапкыр килеп китте. Ашалып бетмәсә дә, закускаларны алыштырды, ашларның яңа төрләрен, кайнарракларын китерде. Табынны сөрткән булды һәм, шул арада мөлаем елмаеп, Пичуговның җилкәсенә кагылгалап алды, аның чәчләрен рәтләп куйды, хәтта, бөтенләй үз итеп, кабарынкы куллары белән моның битләрен дә чәбәкләде. Кузьма да үз чиратында җавапсыз калмады. Курамшиннан да, тирә-як өстәлләрдә утыручылардан да тартынмыйча, үзенә я түшләре, я янбашлары белән ышкылып,·орынып йөрүче официантканың кулларыннан тоткалады, биленнән кочаклады. Тәмам азган бу Пичугов Себердә!

— Синең Танюшаң көнләшмимe соң? — дип, Зоя киткәч хәйләкәр генә күз кысып елмайган булды Курамшин.

— Танюша? — дип куркынып сорады Кузьма, ни өчендер як-ягына каранып алды. Әле генә егетләрчә үтә гайрәтле булып утырган Пичуговның иреннәре күгәреп, йөзе агарып китте. Терсәкләре белән өстәлгә таянып, башын аска иде. Бераздан авыр итеп көрсенде дә:

— Таня юк инде... Без аның белән күптән бергә тормыйбыз,— диде.

— Ничек?..

Кузьма, хәзерге халәтен авырлык белән генә җиңеп, башын күтәрде, елмайгандай, авызын кыйшайтып алды:

— Гафу ит, Кәрам, ничектер, т-т таныштырырга батырчылык итә алмадым. Минем хатын менә бу — безгә ашлар китереп йөрүче Зоя була инде...

Бу турыда әйтү Кузьмага кыен булган кебек, моны ишетү Курамшинга да җиңел түгел иде. Ул, уен белән мавыккан бала шикелле, өстәлдәге чәнечкене ике бармак арасында әйләндерә-әйләндерә уйланып утыра. Хикмәтле бу тормыш. Элек «Танюшам, Танюшам» дип өзгәләнеп йөргән кеше хәзер икенче хатын белән яшәп ята?!

— Ә балагыз?

— Улым аның белән.

Кузьма, тәмәке савыты дипме, папиросның көлен винегрет өстенә какты да, рюмкаларга тагын эчемлек салды. Өстәлдәге буш савытларын җыештырырга килгән Зоя борчылып сорады:

— Күп булмасмы соң, Кузя? — Шунда ук Пичуговның битен тагын сыпырып алды.

Менә гаҗәп: Кәрам каршында Зоя әле генә клиентлары тирәсендә артык кыланып, кымырҗып йөрүче җиңел холыклы официантка иде. Хәзер, Кузьма Пичуговның хатыны икәне билгеле булгач, Зояның Кузьмага карата игътибары аз, мәхәббәте җитми кебек күренә башлады. «Таня булып Таня бәхетле итә алмаган икән — бусыннан юк та юк!» — дип куйды Кәрам эченнән.

Бу авыр тынлыктан котылу өчен кемгә булса да сүз башларга кирәк иде. Курамшин иплән, Кузьманың бәгыренә артык кадалмыйчагына:

— Ничек болай булды соң әле? — дип сорады.

— Их туганкай, әйтсәң сүз, төртсәң — күз диләрме әле, үзем дә белмим инде ничек килеп чыкканын...— Кузьма рюмкадагы аракысын йотып куйды, папирос алып бармак арасына кыстырды.— Сөйләсәм дә ышанмассың... Әйе, аерылу кайчан да бер булырга тиеш иде инде... Шеш тула, тула да тишелә бит ул.

Бу җөмләләрдән бер нәрсә аңлашылмаса да, Кәрам аның сүзен бүлдереп бер сорау да бирмәде. Мондый вакытта кысарга ярамый кешене.

Кузьма, тәмәке төпчеген нигәдер һаман винегрет савытына кага-кага, Кәрам өчен мәгънәсез тоелган сүзләрен тезә бирде:

— Әйе, миңа ир була белергә,. хатынны вакытында кулга алырга кирәк иде. Син авыл малае, күргәнең бардыр, кырыкмыш тайны ничек җигәргә өйрәтәләр? Ул чәбәләнә, бәргәләнә, ә аны барыбер йөгәнлиләр, каерып авызлыклыйлар да камыт кигерәләр! Теге тибенә, үрле кырлы сикерә, тәртә арасына кермәскә тырышып чыгымчылый. Ай-яй усал кылана бит, ә? Шулай да аны җигәләр, арытканчы дулатып-дулатып чаптыралар! Шуннан, син күр дә мин күр, майлап куйган кебек була!

Кузьма инде үзе дә, тәртә арасына беренче мәртәбә кергән яшь ат кебек, ярсыбрак, пошкыргандай сөйли иде. Бераз тынычланып, папиросын суырып алгач, аргы башта табыннар җыештырып йөрүче Зояга таба ымлап, әйтеп куйды:

— Беләм, син инде ничек табыштыгыз, дип сорамакчы буласың. Табышасың икән аны башыңа төшкәч! Безнең кавышуларны әкиятләрдә дә очрата алмассың!.. Шулай, Кәрам дустым. Акылың булса — геолог кызны алма икән хатынлыкка. Көлмә, көлмә, туган. Алар бит, геолог дигән бәндәләр, чегән кебек: чыгып китәләр дә, айлар буе кайтмый йөриләр. Кем белән йөри, ничек — көтеп ят син аны өендә?! Ниһаять, Таняга ияреп йөрергә калдым. Үзең беләсең, без синең белән автоматчылар, кая безгә тирән катламнарга төшәргә, җиде кат җир астындагы нәмәстәкәйләрне белергә! Ә эш кирәк! Куйдылар шунда үземне арба-

ның бишенче тәгәрмәче итеп. Геологик партиядә начхоз кебегрәк нәрсә инде бу. Минем вазыйфа — тегеләргә иләк-чиләк ташудан алып аш пешерүгә кадәр дип әйтерлек. Түздем, биш-алты ел буталып йөрдем. Гарьлек бит инженер башың белән мондый эшләрдә йөрү. Әйдә, Таня, мин әйтәм, киттек моннан, шәһәргә кайтып кешеләр кебек төпләнеп яшик. «Анда мин кайда эшләрмен соң?» ди бу. «Ә мин нишләргә тиеш монда?» дим... Килешеп булмады, кайтып киттем.

— Шуннан ара өзелдеме? — Курамшин һаман төп мәсьәләгә, Кузьма белән Таняның ташлашуларына, ниһаять, Пичуговның Зояга ничек өйләнүенә якын килергә тырыша иде.

— Сирәк булса да Таня башта кайткалап йөрде, соңыннан еракка-рак киттеләр һәм айга бер, кайда бер генә кайтып күренә башлады.

— Аңлыйм, ялгыз яшәү күңелсез. Син инде Зояга гашыйк булып киттең...

Кузьма, әйтергәме-юкмы дип, бераз гына икеләнеп торганнан соң:

— Беләсеңме, Зоя кемнең хатыны? — дип сорау куйды. — Ул Таня эшли торган геологик партия начальнигының бикәче! Сергей Петровичның! Мин геологларның төрле йомышлары, аларны тәэмин итү мәсьәләләре белән Вахка еш кайтып йөри идем. Шунда Сергей Петрович минем аша тайгадан Зояга үзенең сагыну сәламнәрен озата, «күчтәнәч» итеп хатынына юарга керләрен бирен җибәрә торган иде.

— Шунда бу ялгыз бичара белән таныштыгыз инде?

— Танышу соңыннан, мин монда кайтып эшкә урнашкач, ресторанга ашарга йөри башлагач. Көз күргән кеше булгач, ашны Зоя һәрвакыт миңа чиратсыз гына китерә иде. Шунда ялгызлыктан зарланып еш кына сөйләшеп алабыз. Зояның ире, минем хатын юк. Монда кайткан чакларда шушы ресторанда берничә мәртәбә дүртәү бергә утырган чаклар да булды. Аннан ерак сәфәргә ул ирен, мин хатынны озата чыга идек. Өйгә кайтканда тагын зарлану: менә бит, дибез, ирекле көннән буйдаклар кебек яшә инде. Ә Зоя, хатын-кыз бит, иреннән дә көнләшә. Син, Кузьма Николаевич, ди, аларны әллә тик йөриләр дип уйлыйсыңмы, без монда тугрылыклы булгач та, аларны шулай дип беләсеңме, ди.

Зояны юатам: «Сергей Петровичың аю кызлары янына барсынмы, анда, кая карама урман, куе тайга». Ә бу: «Эх, Кузьма Николаевич, — ди, — хатыныңны бөтенләй фәрештәгә санныйсың икән! Әллә аның җаны юк дип беләсеңме?»

Кузьма Николаевич, якын-тирәдә Зоя тыңлап тормыймы дип, артына борылып карады да, көрсенеп дәвам итте:

— Мин бит, дустым Кәрам, Танюшага үземә ышангандай ышана идем. Юк, мин әйтәм, хөрмәтле Зоя, минем хатын андыйлардан түгел. Танюшам миңа һичбер вакытта да хыянәт итәчәк түгел!

Ресторанга бер кердем, ике кердем, ә бу җае чыккан саен миңа берәр тамчы гына үзенең көнчелек агуын тамызып тора бит: «Хатынның ир-ат арасында ялгызы, көн саен я бер палаткада, я бер өйдә йоклыйлар, бергә ашыйлар, бергә эчәләр. Шулай булгач, җаны юк, дип уйлама», — ди.

Ачуланып та ташладым Зояны: «Мин анда булган, торган, эшләгән кеше, нәрсә син җыен чепуханы сөйлисең? Сазда, пычракта, салкында, яңгырда көн саен унар, егермешәр километр җәяү йөреп, калган ди аларда мәхәббәт кайгысы!» Шулай да үзем эчтән генә уйлыйм: «Ә бит, мин әйтәм, чыннан да Танюша белән безнең яратышуга ерак юллар да, ару-талчыгулар да, җил-давыллар да комачауламады. Брезент белән капланган машина кузовына икәү кереп урнаша идек тә, шунда матрац җәеп, җылы юрган ябынып кочакланышып ята идек».

Бер чакны кичен ресторанга ашарга кердем. Әллә инде Зояның гелгел ире белән минем хатын турында искә төшереп, күңелгә васвәсә салулары тәэсир итә башлады, нигәдер эчем әрни иде — ике йөз грамм

аракыга заказ бирдем. Яныма Зоя үзе дә килеп утырды. «Таня кайттымы?» — ди бу. «Юк, мин әйтәм, әллә Сергей Петрович кайттымы?» «Юк, — ди. — Ә иптәшләре барысы да кайтканнар, ништмәдем мени әле? Өч көнлек ял биргәннәр бит».— ди. Карыйм. Зоя иреннәрен тешләгән, менә-менә елап җибәрергә тора. Минем дә тән чымырдап китте. Шулай да үземне кулга алдым: «Ай азагы, Зоя, мин әйтәм, анда шундыйрак хәл килеп чыккалый. Отчет әзерләргә калганнардыр». «Әйе, тайгада икәүдән икәү генә... яхшы отчет!» — ди Зоя, яшьле күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора. Тынычлансын дип, аңа бер рюмка эчемлек салып бирдем һәм, йөрәк әрнүгә түзә алмыйча, үзем дә эчеп җибәрдем. «Булмас. Сергей Петрович та, Татьяна да андыйлардан түгел», дим ә үземнең эчемә ут капкан мыни — яна, көя...

Кузьма моны инде көлмәгән умырып тоткан килеш, аны йолка-йолка ачынып сөйли. Сүз арасында онытылып кычкырып җибәрә дә, исенә килеп, тирә-ягына карана һәм бөтенләй пышылдауга күчә. Тора-бара тавышын тагын көчәйтә башлый һәм бөтен залга ишетелерлек итеп: «Их, Кәрам дус, ничек түзәргә кирәк? Икәүдән-икәү калганнар бит урманда!» — дип акыра.

— Я, Пичугов, кызма әле,— дип туктатты аны Курамшин. Ул, әйтерсең, бик гадәти нәрсәне тыңлап утыра иде.

Кайдалыгын хәзер генә төшенгәндәй, Кузьма тынычрак сөйли башлады. Күренеп тора: ул көнләшкән. Көнләшергә Зоя мәҗбүр иткәндер. Пичуговны тәмам саташтырган.

Кузьманың сөйләве буенча, Таня белән Сергей берничә көннән ялга кайтканнар. Гадәттәгечә, ресторанга җыелып ике пар бергә утырганнар, һични булмагандай табында тайга хәлләрен сөйләшкәннәр, көлгәннәр, шаярганнар. Алар яңадан эшкә киткәч, Зоя Кузьманың Таняга карата таралып бара торган шиген яңадан укмаштырып куйган. «Сизденме, ничек бер-беренә карашып утырдылар? Хәтта күзләрен алалмыйлар, сөйрәлчекләр!» — дигән. Пичуговка шул җитә калган булса кирәк.

— Мин игътибар итмәгәнмен, чыннан да Таня Сергей Петровичка карап утырды,— ди Пичугов.— Елмаеп, хәтта каш сикертеп утырды төсле... Ә Зоя әйтә,— хатын-кыз сизгер бит ул,— син күрмәгән арада Сергей өстәл астыннан гына өстерәлчегенең ботларын да тотты, ди. Менә бит ул ничек, туган!

Кеше күңеле — караңгы урман диләр. Ир белән хатын арасы исә бөтенләй томан. Кузьмага ни дип әйтергә дә, аны ничек юатырга да белмәде Курамшин.

Таня белән ташлашып, Зоя белән торып китүгә сәбәпләр күп булган икән әле, бик күп. Теге очрашулардан, көнләшүләрдән соң Пичугов ресторанга ешрак керә һәм кергән саен йөрәген басу өчен һәрвакыт «яшел еланны» да китертә торган булган. Ара-тирә аның янына Зоя да килеп утыргалаган. Чәкешеп эчкәннәр дә ялгызлыктан зарланырга керешкәннәр... берсе ирен, икенчесе хатынын хурларга... «Әйдә, икенче кайтуларында кызык итәбез үзләрен,— дип тәкъдим ясаган Зоя. — Әллә без алар кебек күз кысышып, каш сикертә алмыйбызмы? Шартласыннар әле көнләшеп!»

— Икенче атнада геологларның кайтасын ишеткән идек, тик без, белмәгәнгә салышып, икәүдән-икәү генә каршыларга булдык,— дип сөйли Кузьма.— Ул көннәрдә халык арасында Зоя белән минем турыда төрле гайбәтләр дә таралып өлгергән иде инде. Уйлап кара: Таня белән Сергей турында түгел, бер гаепсез Зоя белән минем турыда! Имеш, мин ресторанга көн саен тикмәгә генә йөрмим, юкка гына Зоя белән эге-җөге килмим, имеш берсенең хатыны, икенчесенең ире ерактa эштә, болар шуннан файдаланып ачыктан-ачык типтерәләр!.. Идарәдә бергә эшләгән иптәшләр дә колакка чәжгыра башладылар: янәсе мин моло-

дец, яшьне, чибәрне тапканмын. Аннан киңәш бирел, кисәтеп тә куялар: «Мәхәббәт кабынса — уттан яман, исләнсә — сасыдан сасы». Ирε бар. Һәм башкалар... Зоя белән минем «типтерүне» Сергей Петровичның белүе, Танялың сизенүе безнең өчен бик тә кулай иде. Аларның йөрәген яндыру, үч алу иде максатыбыз.

Көткәнчә, тайгадан кайту белән Таня да, Сергей да безне эзләп ресторанга килделәр. Табын мул, алда зәм-зәм сулары. Рюмкаларны Зоя белән гамьсез генә чәкештереп эчкән, сөйләшкән-көлгән булып утырабыз. Таня белән Сергей өстәл янына килделәр, күзләрен шар итеп гаҗәпләнеп торалар. Хыянәт өстендә тоттылар, янәсе. Зоя каушаган була, артистлана, ә мин аларны табынга кыстыйм. Утырыштылар. Тегеләрнең кайту хөрмәтенә тост күтәрдек. Ә Зоя еланның да еланы — аерым илтифат күрсәтеп, мине сыйлый, хәтта үз чәнечкесе белән алып закускаларны авызга каптыра. Кызарып, оялып утырам, әмма тегеләрне көнләштерәсе килү, үч алу тойгысы көчлерәк. Астыртын гына Таня белән Сергейга карыйм. Аларга безнең кыланмышлар ничегрәк тәэсир итә, янәсе. Зоя кызмача булып алды да, яныма ук килеп, мине кочаклый, үбә башлады. Таня чыдамады, рюмкасын күтәреп торды да, тост әйткәндәй: «Күрәсең, Сергей Петрович, без туйга килеп элэккәнбез икән, әйдә ике бәхетле парга уңышлар телик!» — диде һәм эчеп җибәрде. Аннан Зоя торып басты. «Танюша, җаным, син минем Сергейга, мин синең Кузьмаңа гашыйк. Нигә интегеп яшәргә? Әйдә, алышабыз ирләрне»,— дип зәһәр итеп көлә. «Ирләр нәрсә әйтерләр бит, ризамы юкмы, алардан да сорыйк», — ди Таня, исе китмәгән булып.

— Мин риза! — дидем, күп уйлап тормыйча.

— Мин дә риза! — ди Сергей. Үзе сөзәргә торган үгез кебек күзен акайтып миңа карый.

Мәҗлес көтмәгәндә, ничектер, үзеннән-үзе таркалды. Башта, горур гына торып баш иде дә, Таня чыгып китте. Аннан, безгә төкереп, Сергей кузгалды... Мин Таня артыннан йөгермәкче идем — җиңемнән Зоя тотып алды. «Утыр! Бәхетләренә комачаулама, минем белән безгә кайтабыз!» — диде. Шулай да ул көнне Зоя кулыннан ычкындым. Аңлашырга исәпләп өйгә кайтсам, Таня юк иде...

— Бөтенесе дә көнләшүдән килеп чыкты, Кәрам дус,— дип, ниһаять, нәтиҗә ясады Пичугов. Залда аш ташып йөргән Зоя ягына ымлап.— Менә шул еланның коткысына биреләдем!

Мондый хәлләргә Кәрамның бер дә ышанасы килми иде. Ничек инде шулай гаилә язмышын уйламыйча, шаярып, җиңел баштан хәл итәргә кирәк?

— Таня белән Сергей бергә торалармы?

— Шулай дип уйлап йөри идем. Таня киткән булып чыкты. Бөтенләйгә... Нахак бәла якканбыз икән Таня белән Сергей Петровичка...

Рестораннан кешеләр таралып, Пичугов белән Курамшин урамга чыкканда төн уртасы җитеп килә иде.

Яңгыр туктаган. Гаҗәп ачык. Түм-түгәрәк айлы күк аязган, хәтта аз гына да җил исми. Ничәдер сәгать эчендә елның бөтен бер фасылы алышынган кебек. Кара яздан бирле дәвам иткән суыклар, ачы җилләр, тоташ яңгырлар, томанлы юеш иртәләргә аллаһе әкбәр, ахры.

— Көн утыра. Чын Себер җәе башлана,— диде Пичугов, йолдызлар санагандай, күккә башын күтәреп, урынында бер кат әйләнеп алганнан соң. Ул Зояның рестораннан чыкканын көтә иде.

— Бәлки без Зояларга кайтырбыз? — дип сорады ул. «Безгә» димәде.

Кәрам, китәргә җыенганын белдереп, дустына кулын бирде.

— Рәхмәт. Иртәгә бәйрәм түгел. Башка вакытта. Хушыгыз!

Кайдан килгән булса шул җирләрдән урап, Курамшин йокларга кайтып китте, ләкин дустының язмышы юлда да, кайткач та уйландырды, борчыды, бер туктаусыз җанын талкыды аның. Күз алдына алмаштилмәш әле Татьяна, әле Зоя, әле Кузьма килеп басты. Алар бергә буталдылар, тагын аерылдылар, янә кушылдылар.

## СИГЕЗЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Дәрәҗә баскычларыннан әллә ни күтәрелә алмаса да, үзенең автоматчы-инженер булуы белән горурлана иде Курамшин.

Ул нефть институтының автоматика һәм контроль-үлчәү приборлары факультетында укыды. «Бөҗәкләр классы, үрмәкүчләр семьялыгы» дип йөртәләр иде бу факультетны студентлар.

Ни өчен «бөҗәк?» Ни өчен «үрмәкүч?» Чөнки бу факультет студентлары пәрәвез кебек чуалчык схемалар, сызымнар белән эш итәләр, бөрәр прибор яки механизмны өйрәнә башласалар, төрле нечкә чыбыкларны сүтү, ялгау белән мәшгуль иделәр. Бу чыбыклар бихисап, буталчык, чыннан да үрмәкүч оясын, пәрәвез челтәрен хәтерләтә иде.

Бүтән факультет, бүтән бүлекләр дә үзләренчә атала иде: скважиналарны эксплуатацияләү факультеты студентлары, мәсәлән, «эксплуататорлар», бораулау бүлегендәгеләр — «тишкечләр», газ чыгаручылар — «противогазчылар», ә геология факультеты студентлары — «сукбайлар»...

«Үрмәкүчләр» үзләрен бүтәннәрдән бер башка югары тотып, автоматчы булулары белән горурланып, күкрәк киереп йөриләр иде. Аларның укый торган предметлары яңа, үзгә, дәрестән бигрәк фәнгә якын, катлаулы теорияләр белән бәйләнгән. Автоматлар теориясе буенча лекцияләр укучы профессор Кабулов алар өчен «Ата үрмәкүч». Ул кафедра мөдире дә. Аны бөтенесе аеруча ярата. Ишекне ачып керү белән үк:

— Тыңлагыз, юньсезләр, шаярып утырмагыз, юкса имтиханнарда еларсыз! — дип кычкырып белдерә һәм чираттагы кәгазьләрен укырга тотына: — Автомат ул — бу заманның башы, мие, йөрәге һәм мускуллары. Аннан башка дөньяда прогрессның булуы мөмкин түгел...

Шуннан китә сөйләп, китә тезеп. Борынгы Архимедлардан алып Ньютоннарга, Ломоносовларга килеп җитә, хәзерге заман галимнәренә килеп тоташа. Барысын да автоматлар теориясенә, уйлап табуларга бәйли.

Әкәмәт тә кызык кеше иде Кабулов. Зачетта яки экзаменнарда аннан автоматлар, механизмнар турында төпченер инде, дип котың алынып тора, ә ул капылт кына:

— Тараканның мыеклары нинди роль уйный? — дип сорый.

Аптырап каласың.

— Өйрәнеп кил,— дип тирги башлый «Ата үрмәкүч»,— Таракан мыеклары дөньяда иң сизгер антенна! Иң камил радиолакатор! Алар ярдәмендә ул тәләсә нинди ультродулкыннарны тота, инфракызыл нурларны аулый! Шул ук мыеклар температура градусының хәтта меңнән бер өлешен сизә! Шул бәп-бәләкәй таракан — үзе бер фәнни лаборатория! Ә син? Йөрисең ипи черетеп.

Кәефләре кырылган студентларның кайберләре хәтта төкеренеп чыга:

— Үзе фәннәр докторы, электроника, телемеханика буенча зур теоретик, ә үзе кандала-таракан ише хәшәрәтләр белән мавыга, тфу!

Һәр нәрсәдә гадилеккә, камиллеккә омтылырга өйрәтүче Кабулов кебек исемнәре бөтен илгә билгеле галимнәр кул астында, Мәскәүнең

атаклы институтында уку, аның да бүгенге фән-техника таләпләренә туры китереп җиһазландырылган укыту кабинетларында, лабораторияләрендә шөгыльләнү, шунда практика алу күп нәрсәләр бирде Курамшинга. Аның хыялы киләчәкчә инженер-конструктор булу иде.

Яшь белгечне үз теләге белән туган якларына, ул чакларда искиткеч тизлек белән үсеп баручы Әлмәт промыселларына җибәрделәр. «Барасы урыныңны дөрес сайладың. Гаять перспективалы район. Кемлегеңне шунда күрсәтсәң генә күрсәтә аласың»,— диделәр аңа деканатта.

Вагон тәрәзәсеннән таныш кырлар, урманнар, басулар күренү белән, әйтерсең, ялкын урап алды егетне. Бөтен су буйлары, әрәмә әчләре, тау башлары кояш яктысында көмеш төсле ялтырап торган скважиналар белән тулган. Кая карама — буровой вышкалары, нефть чаннары, газ факеллары...

Менә кайда икән Кәрамга дигән эш фронты, менә кайда ул уйлап табасы автоматлар, ул ясыйсы механизмнар, ул көйлисе телемеханика һәм электроника системалары!

Профессор Кабулов һәр лекция саен: «Автоматчылар тырыш кына түгел, әйле-шәйле һәм хыялый да булырга тиеш»,— дип әйтергә ярата иде. Аның дәресләрен тыңлый-тыңлый әллә чыннан да шундыйрак була башлаган иде Кәрам. Кайту белән кырга китте, скважиналарга барып, алардан үзе укыган электроника, телемеханика системаларын эзләп йөрде. Кая әле монда андый нәрсәләр! Гади автоматларның да исе-төсе юк. Операторлар скважиналарның эшен тикшереп җәяү йөриләр. Нефть юлын кранны кул белән борып ачалар һәм ябалар. Күләмнечаң өстенә менеп, чыбык тыгып үлчиләр. Нефть көпшәсенә утырган парафинны скважинага кыргыч төшереп, аны чыгыр белән күтәртәләр...

Һич кенә дә болай булыр дип күз алдына китермәгән иде шул кадәрле «перспективалы нефть районын» Курамшин.

Аның дәгъваларына идарәнең кадрлар бүлегендә дә артык игътибар бирелмәде. «Гафу итегез, без автоматчылар сорап заявка бирмәдек. Андый урын бездә юк. Теләсәгез, промыселга өлкән оператор итеп алабыз»,— диделәр.

Курамшинның башына тимер таяк белән суккандай булды бу сүз. Өлкән оператор... Алтынчы разрядлы эшче... Гади эшче булу өчен шулай интегеп биш ел укыдымы Кәрам?

Ике-өч көн уйланып, өзгәләнеп йөрде дә егет тагын идарәгә килде. Нишләсен, кая да булса бүтән тарафка китәргә теләге дә, урыны да, акчасы да юк иде аның — кайчандыр үзе хурлап йөргән «эксплуататор» урынына эшкә керергә ризалык бирде. «Нигә аһ орасың, егет? Бүген оператор, иртәгә мастер ярдәмчесе, аннан мастер булырсың. Сабыр итәргә кирәк. Сабыр төбе сары алтын»,— дип юаттылар аны идарәдә.

Шулай итеп тормышны да, эшне дә яңадан башларга туры килде яшь белгечкә. Нәрсә уйлап, нинди баш белән ул урынга керергә җөрьәт иткәндер — хәзер үзе дә аптырый. Аның бит нефть ятмаларын эксплуатацияләү өлкәсендәге белеме дәрестә алган «гомуми танышлык» белән практикада күргән скважиналардан гына иде.

Бригадада аңа, өлкән оператор, яңа звено башлыгы итеп, Әлмәт нефть мәйданындагы иң еракта, Зәй елгасы буенда утырган скважиналарны беркеттеләр. Алар янына җәяү барырга-кайтырга гына алты чакрым. Җитмәсә, бу участок скважиналарның көйсезләнүе, ватылулары, нефть түгелүе яки аның нефть торбасына парафин тыгылуы белән дә иң каргалган участок икән. Ерак булгангамы, операторлар бу скважиналарны юньләп карамаган, хәтта кабул итеп алмаска тырышканнар.

Промыселда шулай эшли башлавына һич тә үкенми хәзер Курамшин. Нефтьне учыңа алып үзең иснәргә, скважинадагы барча механизмнарны үз кулларың белән тотып карарга, сүтәргә, җыярга, кайчагында хәтта вата-җимерә дә белергә — һәр автоматчыга кирәк икән бу

Шунсыз скважиналарның кимчелекләрен табу да, аларны автоматлаштыру да мөмкин түгел.

Автомат дигәннән, ул турыда Кәрам әлегә уйламаска, онытырга тиеш кебек иде. Чөнки ул биредә «үрмәкүч» түгел, ә вакытлыча «эксплуататор». Аның төп эше җир астыннан «кара алтын» суыртып алу. Ә шулай да үзенең укыган, өйрәнгән, үз иткән һөнәренә талак әйтә алмады. Промыселдагы иске ысуллар, һәртөрле артталык эчен пошыра иде аның. Россиядә нефть табылганга инде йөз ел — ә аны чыгаруда һаман кул көче, примитив алымнар кулланыла. Кәрам эшли торган бригадада гына да илледән артык скважина һәм һәр скважина төбендә өч оператор сменалап вахтада тора. Аның өстенә нефть үлчәүчесе, насос белән нефть кудыру машинисты, звено саен өлкән оператор һәм башкалар... Моңа тагын бригадирны, промыселдагы авария бригадаларын да китереп кушарга кирәк. Кыскасы, күңелне тырнаган, эчне пошырган нәрсәләр күп әле бригадада. Звено җитәкчесе булгач, нефть чыгарудагы кимчелекләр турыдан-туры Курамшинның үзенә дә бәреләә иде. Җитешсезлекләргә күз йомып булмый. Мөмкин булган хәтле нәрсәне кылырга кирәк...

Ул елларда Курамшин эшли торган бригадада — Бигәш нефть мәйданында электр кертелмәгән, нефть кудыруда дизель двигательләре эшли иде. Бер көнне машинистның двигательне «Примус»ка тутырган бензин белән жылытып интегүен карап торды да Кәрам: «Тукта әле, моңа газ ягып та була ич»,— дип уйлап алды. Газ шунда ук — скважина янында үкереп факелда яна бит. Икенче көнне Курамшин машинист егет белән икәүләп факелдан бер кечкенә торба сузып двигательне газ белән жылытуга көйләделәр. Моны күреп мастер Шәйдуллинның түбәсе күккә тиде: «Менә әйттем бит гыйлем иясеннән ни дә булса чыгарга тиеш дип!»

Аннары операторларның парафин белән җәфаланулары күңелен тырный иде яшь инженерның. Татарстан нефте гаять парафинлы, торбаны чистартып тормасаң скважинадан нефть килү туктаганын көт тә тор. Бу бәладән котылу өчен парафин кыра торган җайланманы тимерчыбыкка асып аны чыгыр ярдәмендә скважинага төшерәләр дә, яңадан тарттырып менгезәләр. Ярты чакрым тирәнлектәге коедан чиләк белән су чыгару кебек. Чыгырны исә операторлар көн дә өч-дүрт сәгать кул белән әйләндерәләр. Скважиналарга электр кертү, чыгырларны мотор көченә көйләүдә башлап йөрүчеләрнең берсе булды Курамшин. Күп мәшәкатьләрдән соң, бармак белән кнопкаларга гына басып йөрергә калды бу эш.

Ләкин һәр уңай нәрсәнең кире яклары да бар икән. Чыгырлар электрга көйләнгәч, кыргыч асып куйган чыбык өзелә башлады. Өзелә һәм чыбыгы ние белән девон тирәнлегенә төшеп китә. Скважиналарда авария. Кыргычны забойдан алу өчен җир асты ремонтчыларын чакыртырга, акча түләргә кирәк. Ә алар, скважинаны эштән туктатып, торбаларны сүтәргә тотыналар — күпме вакыт китә һәм йөзләрчә тонна нефть чыкмый кала. Юкмы забойдан кыргычны тартып алуның бүтән бер ысулы?

Атналар буе уйланып йөрде-йөрде дә, бер көнне гап-гади ыргак ясап килде Кәрам. Алай бик гади дә түгел — берничә яньле, кармакка охшаган. Тимерчыбыкка тагып скважинага төшерделәр шул «кармакны». Капты бит «балык», әләкте! Кыргычны тирән девон катламыннан тәки сөйрәп чыгардылар. Карап торырга үзе мыштым гына, ә башы бар бу егетнең!— дип тагын гаҗәпләнде мастер.

«Башлы» кешеләр бригадада бер Курамшин гына түгел икән. Мәснәви дә нинди дә булса могҗиза чыгарырга яратучыларның берсе булып чыкты. Бер көнне аның скважинасына барса, оператор ыргакны кул белән түгел, электр чыгыры белән тарттырып ята. Авария турында

берәүгә дә бәйдерәсе килмәгән, берәүне дә чакырмыйча үзе генә башкарырга булган эшне. Курамшинны күргәч, тәмам куркып китте бичара. Ә моның өчен ничек ачуланасың кешене?

Атна-ун көн дә үтмәде, Курамшин янына яңа төр ыргак тотып килгән Мәснәви. Игътибар беләнрәк караса, исләрең китәрлек: аның ыргагы бармаклар кебек йомарлана торган итеп ясалган. Бу инде скважина төбенә тию белән бикләнә дә куя һәм парафин кыргычны чыбыклары-ниләре белән учына йомарлап алып чыкмыйча калмый!

— Менә мыштым дисәң дә мыштым!

Шундый һәм бүтән яңалыклар скважиналарга куелып, нефть чыгаруда ярдәмнәре күзгә күренеп сизелә башлагач, мастер Мәрдәнша Шәйдуллин бригадасы да гомерендә беренче мәртәбә уңай яктан телгә керде. Бригададагы кискен үзгәрешләр турында промысел, идарә, хәтта берләшмә җыелышларында сөйли башладылар, газеталарда язып чыктылар. Бу нефтьчеләр инде хәзер «Социалистик ярыш алдынгылары», «Скважиналарны автоматлаштыру инициаторлары», «Рационализация һәм уйлап табу осталары» иделәр. Кәрам белән Мәснәвинең кочакланып диярлек төшкән фотосы нефтьчеләр журналында басылып чыкты.

Автоматлаштыру өлкәсендә беренче ачышлар Курамшинны канатландырып җибәрде, аның нефть чыгару эшендә калуына сәбәпче дә булды бугай. Хәзер инде ул яңадан-яңа идеяләр белән янып йөри иде.

Әле промыселдагы механизмнарны камилләштерәсе нәрсәләр күп. Мәсәлән, нефтьчеләр парафин кыргычны төшереп-менгерү өчен кнопкаларга скважина саен йөреп басарга тиешләр. Ни өчен һәр скважинага да реле куеп, кыргычны кирәк сәгатькә генә үзе төшәрлек итеп көйләмәскә?

Шуны нигезләп, сызымнар, схемалар белән ныгытып биргәч һәм экономик файдасын да санап күрсәткәч, җитәкчеләрне ышандырды Курамшин. Аңа бригада йортының бер кечкенә бүлмәсендә мастерской ачарга һәм шуның белән җитәкчелек итәргә куштылар. Курамшинның ялан кыр уртасындагы мастерское тиздән сәгать механизмнарына көйләнгән вакыт релеләре эшләп чыгара башлады.

Ләкин әле парафин кыргыч төшерүне автоматлаштыру белән генә скважиналардан операторларны азат итеп булмый иде. Нефть түгелүләрне бетерәсе бар. Карап, сагалап тормасаң, чаннар тула да нефть ташый. Аны булдырмас өчен нефть юлын тиз генә ябарга, «кара алтынны» насослар белән товар паркларына кудырырга кирәк. Монысына нинди автомат уйлап табарга? Һәм ул кеше катнашыннан башка бер үк вакытта чанга нефть тулганын белдерә торган, нефть юлын үзе яба торган, нефтьне товар паркына кудыра торган һәм соңыннан тагын нефть юлын ачып җибәрә торган автомат булсын! Катлаулы мәсьәлә бу.

Институтта профессор Кабулов студентларның игътибарын әзер автомат һәм механизмнарны көйләүгә һәм куярга гына түгел, әнә шундый иҗат эшенә юнәлтә иде. Укуының соңгы ике елында Кәрам студентларның фәнни-техник түгәрәгенә йөрде. Бу түгәрәккә дә профессор Кабулов үзе җитәкчелек итә, шәкертләрен һәр даим уйлап табу теориясенә, алгоритм серләренә өйрәтә иде. Алар лабораторияләрдә һичкайчан булмаган, күрелмәгән механизмнар, автоматлар көйләделәр. Түгәрәк членнары, күпләрне шаккатырып, хәтта кеше сыман робот та ясадылар. Ул бөтенесен көлдереп, аю кебек як-якка чайкалып атлый, рупор тавышы белән сөйләшә, кул чабып такмак әйтсәң, аякларын алмаш-тилмәш күтәреп биеп тә китә иде.

Курамшинның һәр механизмга тәнкыйть күзе белән каравы, һәр нәрсәдән «идея» эзләве әнә шул еллардан калган.

Автомат япкычларның идеясен ул күктән эзләде, ә юк кына нәрсәдән, җирдән тапты.

Бригадада элек слесарь, шофер, тракторчы булып эшләгән, электр-

ны, машинаны, тимер-томыр тирәсен, аңлый торган операторлар байтак иде. Алар элек колхозда эшләгәннәр, хәзер нефтькә күчкәннәр, вахтага якын-тирә авыллардан килеп йөриләр иде. Әле аларның күңелләре ни авылдан китеп бетмәгән, ни нефтькә күчмәгән. Шулар арасында элекке комбайнер, бик хәйләкәр һәм астыртын Әюп абзый да бар. Кешеләр белән сөйләшми, аралашмый. Авылда алты почмаклы үз йорты белән тора, сыер асрый, бик күп сарыклар, кәҗәләр тота. Яз житүгә, скважина тирәләрен казып, буш урыннарга бәрәңге утырта (янгыннан саклану өчен скважина тирәләрен болай да казыталар иде!) Җәйгә керсә, Әюп абзый шул тирәләрдән үлән чаба башлый, чүмәлә-чүмәлә печән өя. Көз көне якындагы урманнан утын әзерләргә дә вакыт таба. Болар барысы да эштә чакта, вахтада торганда эшләнәләр. Шулай да аның скважиналарында нефть бер дә түгелмәс, ул караган территория һәрвакыт чиста булыр, нефть җиһазлары ялт итеп торыр. Бригадада операторлар Әюп абзыйның уңганлыгына бик сокланалар һәм аңардан көнләшәләр дә иде. Курамшин, нәрсәгәдер, шикләнә иде бу операторның эшеннән. Скважиналары бик пөхтә булса да, аларның нефть бирүе башкаларныкыннан никтер ким.

Үз звеносында булмаса да, тәҗрибә уртаклашырга дигән булып, Мәснәвине ияртеп Әюп абзый скважиналарына китте Кәрам. Әюп абзый үзе юк, ә мерник нефть белән мөлдерәмә тулган иде. Ташып та түгелми, нефть нефть җыю пунктына да китми. Мәснәви баскычтан үрмәләп, резервуар өстенә менеп китте.

— Калкавыч куйган бит бу, явыз! — дип кычкырып җибәрде ул, каравыл кычкыргандай, кулларын югары күтәреп бутый-бутый!— Җинаять бит бу! Бригаданы алдау!

— Тукта, май кап авызыңа!— диде Курамшин шыпырт кына, бармагын авызына аркылы куеп. Үзе дә Мәснәви янына менде.

Алар калкавычка бик гаҗәпләнеп карап тордылар: «Күр инде син, кеше дигәнең ниләр генә уйлап бетерми үзенә дигәндә!»

Төшеп, нефтьне торба буйлап үз агымы белән бераз җибәрделәр дә, карап тордылар. Калкавыч аска төште. Тагын нефть җыела башлады, калкавыч өскә күтәрелде. Нефть тулып ташыйм дигәндә генә калкавычка беркетелгән чыбык тартылып, скважинаның эшен туктатты.— Ах, дизертир, ах мәлгун! Судка бирергә кирәк моны, башын себер җибәрергә! — дип Мәснәви йодрыгын Курамшинның борыны төбендә йөртә башлады. Әйтерсең, бу эшкә Әюп түгел, ә Кәрам гаепле иде.

— Кычкырма. Әюп абзыйны моның өчен мактарга, күтәреп күккә чөяргә кирәк! Беләсеңме, ул бит гениаль нәрсә ясаган!

Күп тә үтмәде, Курамшин мастерское скважиналар өчен тагын бер яңа нәрсә — калкавыч принцибына көйләнгән автомат япкычлар чыгара башлады.

Промыселда гына түгел, нефть идарәсендә дә Курамшинның абруе күзгә күренеп үсте, бәясе күтәрелде. Аңа инде хәзер читтән үк сәлам биреп йөри башладылар. Ул кешеләр телендә «башлы инженер» дип аталса, идарә һәм промыселларда «алдынгы рационализатор», «уйлап табучы», «автоматлар короле» иде. Курамшинның мастерское, законлаштырылып, идарә штатына кертелде һәм «конструкторлар бюросы» дип йөртелә башлады. Аның начальнигы итеп Кәрам Ризванович Курамшин билгеләнде.

## II

Кәрам бүген әнә шул, баскыч артыннан баскыч булып менгән, басма артыннан басма булып югарыга үрләгән автоматлаштыру этапларын күз алдыннан кичерә һәм үзенең ул чактагы янып торган яшьлек дәртенә соклана, гаҗәпләнә иде.

Моны яшьлек дип тә түгел, ә малайлык мавыгулары, шашкын хисләр дип бәяләргә дә булыр иде.

Уйлап табу теориясе өйрәткәнчә, бернинди перспективалар турында да, киләчәкләр-булачаклар хакында да башыңа китермисең бит ул чакта, уена-күңеленә ни туры килде шуны эшләргә тырышасың. Барып чыгамы-юкмы, яхшымы-түгелме — аларында да эшең юк: тизрәк ясарга, куярга, сынап карарга гына ашкынасың. Романтика!

Шуларны исәпли китсә, Кәрам Ризвановичның күңеле нечкәрә, башыннан кырыкмаса-кырык төрле уйлар уза. Әллә кайчан үтелгән еллар, авыр вакытлар, шулар арасында кыска гына, елмаеп кына алган бәхетле минутлар, шатлыклы көннәр — бары да күз алдына баса, әйләнә-тирәсендә очып йөри башлый. Әллә узгангамы, авырлыклары да аның гел дә авыр булмаган, уен гына булган шикелле...

Курамшинның нефть өлкәсенә керткән берничә хезмәте, әле бүген дә эштә урын таба алмыйча, һавада асылынып тора. Шулар арасында иң кызганычлысы, күп хезмәт куйганы — термохимик установка бугай... Әй, ул гынамы соң!.. Гомумән, уйлап тапкан, камилләштергән нәрсәләрен вакытында эшкә ашыра алмый калулар бик күпләрнең фаҗигасе.

Аннан да яманрак икенче бер фаҗигасе да бар әле аның. Киләчәккә, еракка карап, перспектива белән эшләмәү, вакытлы эффектлар белән мавыгу, зур яңалыкларны алдан күрә белмәү. Һәм, ниһаять, уйлап табылган нәрсәләрне башка предприятиеләргә тарата алмау, ачышларны координацияләмәү.

Парафин проблемасын гына алыйк. Татарстан нефтендә парафин кушылмасы бик күп. Ун ел буена нефтьчеләр шул парафиннан зарландылар, шуны каргадылар. Нинди генә җыелышта, кайсы гына киңәшмәдә булмасын — сүз барысының да теңкәсенә тигән шул парафин турында барды. Нинди генә явызлыклар эшләмәде, нинди генә мәшәкатьләр тудырмады ул парафин дигәнең!

Торбаларга юшкын кебек утыра, нефть юлын тыгылдыра торган парафиннан котылу өченниләр генә уйлап тапмадылар да, ниләр генә эшләп карамадылар! Нефть юлларын гади кыргычлар белән дә, оча торган, үрмәли торган кыргычлар белән дә, «керпеләр» белән дә чистартып карадылар — парафин һаман сылана да сылана. Скважиналарга автомат кыргычлар көйләү дә бу каһәр суккан парафиннан коткара алмады.

Шунысы аяныч, парафиннан котылу чарасын ничектер бергәләп түгел, һәр бригада, һәр промысел үзенчә эшләде, үзенчә табарга тырышты. Аны чистарту установкаларын Башкортстан нефтьчеләре бер, Татарстаннныкылар икенче төрле итеп ясадылар. Өченче төрлесен нефть фәнни-тикшеренү институты эшләде. Ә дүртенче варианты белән Курамшин җитәкчелегендәге конструкторлар бюросы мавыкты.

Баксаң, парафинны чистартуның һич тә кирәге юк икән. Аннан котылу юлы бары бер генә — торбага утыруын гомумән булдырмаска. Пожарниклар әйткәнчә, «янгыннан котылу чарасы — янгынны булдырмау». Моның өчен нефть торбаларының эчен шома нәрсә белән каплату гына таләп ителә.

Бу хакыйкатькә беренчеләрдән булып Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәре төшенде. Тикшеренү эшләрен моңа кадәр яңалыклары белән танылган һәвәскәр уйлап табучы Курамшин карамагындагы скважиналарда алып бардылар. Аларның эшен бик кызыксынып күзәтте Кәрам Ризванович, галимнәргә мөмкин булган кадәр шартлар тудырырга, ярдәм итәргә тырышты.

Дөрес, алар да әле торбаларның эчен нинди материал белән каплатырга кирәк икәнне тиз генә таба алмадылар. Торбаларга лак буяп карадылар — аны нефть ашады. Сынау өчен скважинага корыч та, бакыр да, алюминий да төшереп карадылар — парафин аларга да ябышты

Төрле пластмассаларны да үз итте парафин. Бары тик пыяланы гына сөйми булып чыкты, пыялага гына сыланмады ул.

Ә пыяланы нефтьчеләр өнәмәделәр. Скважинага төшергәндә генә түгел, алып килгәндә үк торбаларның пыяласы ватылып, коелып бетәр дип хәвефләнәләр иде. Юк, көткәннең бөтенләй киресе килеп чыкты.

Курамшин да, нефть чыгаручы операторлар да гаҗәпләнеп бетә алмадылар: эче пыяла белән каплатылган торбаларны алар скважинасына бүрәнәләр урынына тәяп, йөк машинасында алып килделәр. Бәрәсуга шалтыратып җиргә аудардылар. «Пыяласы уалып беткәндер инде», — дип Кәрам да, операторлар да, күзләрен торба көпшәсенә куеп, эчен карадылар. Торба эче көзге кебек ялтырап тора иде.

— Ышанмасагыз кувалда белән сугып карагыз! — диде аларга галимнәр, бераз мактана төшеп.

Кәрам Ризванович: «Менә хәзер күрсәтәм ул пыяланың нәрсә икәнен», — дия-дия, чыннан да зур чүкеч алып торбаны бар көченә «кыйный» башлады. Тагын торба эчен карадылар — пыяла урыныннан кубарга уйламаган да иде. Алай гына да түгел, галимнәр болар алдында торбаларны тиштертеп, юындырып, пычкы белән кистереп тә карадылар — барысына да чыдам булып чыкты бу пыяла дигән нәфис зат. Сварка аппараты белән торбаны эретеп ялгарга да була икән хәтта!

Пыялаландырылган торбаларны оператор Мәснәви карамагындагы бер скважинага төшерделәр. Бу скважина парафин утыруы белән дан тоткан, Мәснәвинең каргаулы бер скважинасы иде. Аңа тәүлек саен өч-дүрт мәртәбә кыргыч төшергән иде ул, алай да нефть юлы тыгылудан иза чиккән. Галимнәрнең бу скважинаны эксперимент өчен сайлап алулары тикмәгә түгел.

Торбалар ике чакрым тирәнлеккә төшеп беткәч, нефть юлын ачтылар. Могҗиза! Парафин сылану дигән нәрсәнең эзе дә юк!

Курамшин монда нинди хисләр кичерде? Дөресен әйтергә кирәк, йөзе көлгәнгә дә, елаганга да охшап җыерчыкланды, иреннәре бер җәелде, бер бөреште. Үзенә дә сизелерлек булып ияк уртасындагы чокыры тартышты. Яхшы, рәхмәт моны уйлап тапкан галимнәргә! Ләкин ни өчен бер ун ел элек табылмаган бу хикмәт?

Ул көнне Курамшин сөенүдән бигрәк, үзенең дә, башкаларның да ничә еллар сарыф ителгән көчен, бушка тамган тир тамчыларын кызгана иде.

Нәтиҗә ясап шуны әйтмәкче була Курамшин: Татарстан үрнәге, әлмәтлеләр тәҗрибәсе, һичшиксез, монда, Себергә күчәргә тиеш! Тормышның ачы сабакларыннан гыйбарәт алырга, кирегә кайтмаска! Себер нефтенең юлын икеләнүсез яңа техникадан — читтән торып идарә итү системасыннан башларга, барлык эшләрне электрон мие күзәтүенә тапшырырга! Әйе, әйе, вакытлы проблемалар белән мавыкмаска, вак маймычларга алданмаска!

Үрнәк-тәҗрибә өчен Курамшин участогында куелган өр-яңа аппарат һәм приборларның да әле барысы да ал да гөл түгел. Әлмәт промыселларында, мәсәлән, бүгенге көндә нефтьнең яртысыннан артыграгы су белән чыга. Катлам басымын саклау өчен скважинага су кудыруның хикмәте. Ә суның күләме һәр скважинада төрлечә. Монда су гына да түгел, приборларга нефть белән бергә скважинадан чыккан газ да, ком да, күкерт, тоз кебек башка кушылмалар да комачаулый. Шул сәбәпле нефть үлчәгеч дебитомерлар ялган мәгълүматлар бирә. Ялгышлык — бер проценттан алып өч-дүрт процентка кадәр. Мондый очракта саф нефтьнең, газның күләмен төгәл генә ничек белергә, ялгышларга каршы нинди чара күрергә?

Бүген әнә шулар борчый, шулар җәфалый иде Курамшинны. Скважиналарга куеласы автоматларның кимчелекләрен Себергә кертмисе, аңа киртә куясы иде!

Курамшин, эштән кайтышлый телефон станциясенә керде, ни булса шул, дип үзенең участогын алды. Бу вакытта башка кеше булмаска мөмкин иде. Бәхеткә каршы, трубканы Мәснәви алды.

— Син ни эшләп утырасың әле анда? — диде Кәрам, ничектер тупасрак итеп.

— Кәрам Ризванович, бу синме? Ник дип диспетчер янында утырам дисезме? Башыңа төшкәч утырасың икән аны...

— Мәснәви, ни хәлләр бар анда? Барыгыз да исән-сау-сәламәтме?

— Хәлләр изге, тегеләр генә бизде...

— Шаярып торырга вакыт тар, әйдә, докладывай: план үтәләме? Хезмәт житештерүчәнлеге ничек?

— Син, Кәрам Ризванович, читтән торып идарә итү системасын төзедең дә, үзең дә читтән торып кына идарә итмәкче булдың, ахры! Кайчан кайтасың?

— Килеп житмәс борын нинди кайту әле? Я, ничек анда?

— Ничекме? План үтәлә, тик бу АСУ[1] дигәннәре генә муеннан аса. Бик иркә булып чыкты, назландыра! Көйләүдән-төзәтүдән арынып булмый.

— Дебитомерлар ничек эшли?

— Һаман да бер-ике процентка аерма бар. Алдый, каһәр... Дөрес булса, Куйбышев промыселларында икенче төрле дебитомерлар кулланалар икән. Нәтиҗә әйбәт, ди.

— Кызыксын әле син алар белән, Мәснәви. Обязательно белеш һәм миңа хәбәр ит!

Мәснәви сүзне борырга маташа:

— Ничек соң анда, Кәрам Ризванович, Себер әйбәтме?

— Әйтәсе дә түгел! Кайткач гомер буе онытa алмый интегермен инде.

Бераз тын торганнан соң, Мәснәви, ярым пышылдауга күчеп болай ди:

— Кара әле, Кәрам Ризванович, анда сезнең тирәдә Фәнүзә күренмиме?

— Фәнүзә? — диде дә телсез калып торды Кәрам. Әйтерсең, бу исемне беренче мәртәбә ишетүе иде.— Син аны онытмадың мыни әле?

— Шунда, син торган шәһәрдә, дигән сүзләр йөри...

— Калдыр әле, Мәснәви! — дип кычкырды Кәрам туры җаваптан качып. Сүзен тәмамларга ашыкты: — Ярый, вакыт бетте! Сарага сәлам әйт, хуш...

Онытылып, телефон кабинасында утырып торды. Һич тә урынсызга, аптыраганнан әйтеп куйды:

— Минә синә мә: Сарага сәлам әйт, бабаң утырмага килсен...

## ТУГЫЗЫНЧЫ БҮЛЕК

### I

Черек күл турында Курамшин беренче мәртәбә мең тугыз йөз алтмыш дүртенче елның язында ишеткән иде. Барлык үзәк газеталар диярлек дәррәү язып чыктылар: «Төмән өлкәсенең төньягында, Обь елгасының урта агымында, 2500 метр тирәнлектәге 1 нче номерлы разведка-бораулау скважинасы илдә тиңе булмаган яңа нефть чыганагы ачты...»

---

[1] АСУ — идарә итүнең автоматлашкан системасы.

Бу елларда Көнбатыш Себердә нефть ятмалары табылу турында ай саен, атна саен, хәтта көн саен диярлек ишетелеп торган яңа хәбәрләрне Татарстан нефтьчеләре игътибар һәм көнләшү белән күзәтеп бардылар.

— Безнең борынга чиртә бит бу Себер!

— Үкчәгә басып килә шул! — дип, Түмән нефте турында исләре китеп, хәйран калып сөйли башлаганнар иде инде.

Моңа кадәр Ромашкино нефть ятмасы илебездә бердәнбер ятма, уникаль чыганак дип исәпләнеп йөргәндә, яңадан андый хәзинәнең кайда да булса табылу ихтималы шикле булган бер заманда, баткак сазлыклар эчендә, мәңгелек туң җирләр башланган урында көчле «кара алтын» фонтаны бәреп чыгу искиткеч яңалык иде.

...Себер нефтенең тарихы еракларга барып тоташа.

Академик Губкин, утызынчы еллар башында ук Көнбатыш Себер тигезлегенең структурасын өйрәнеп, биредә сыек ягулык запаслары булу ихтималын әйткән. Зирәк акыллы галим бу турыда үзенең үлмәс хезмәтләрен дә язып калдырган. Әмма мондагы табигый байлыкларны ныклап тикшерүгә, барлауга керешүләр бары тик кырыгынчы еллар азагында гына башлана. Зур адымнар белән үсә торган социалистик индустрия, авыл хуҗалыгы торган саен күбрәк күләмдә ягулык сорый. Җитмәсә, Европада дары сөреме таралып килә, дөньяның төрле почмакларында бер-бер артлы сугыш учаклары кабына. Капиталистик илләр белән бәрелеш буласы көн кебек ачык. Яңа чыганакларның тирән тылда, ил чикләреннән еракта булуы хәерле.

Нефть эзләү буенча зур походка хәзерлек эшләре башлана.

Иртыш яры буена баржа белән бораулау җиһазлары, пар казаннары, двигательләр, арбалар, бүрәнәләр китерелә. Төркем-төркем геологлар, нефть белгечләре килә. Яр буйларына палаткалар корыла, вакытлы базалар төзелә. Иртә-кичләрен караңгы тайганы җанландырып учак утлары кабына...

Һәм менә зур хәвеф белән күзәтеп барылган халыкара хәлнең фаҗигале финалы — Бөек Ватан сугышы башланып китә. Барлык нефть белгечләрен, геологларны, бораулаучыларны Новосибирскидагы төп базага чакыртып алалар. Аларның күбесе фронтка озатыла. Себердәге разведка эшләре вакытлыча туктый.

Дүрт елга сузылган кан коюлы сугышлардан соң, илгә иминлек килгәч, партиябез карары белән яңадан геология экспедицияләре оештырыла. Кичәге саперлар, артеллиристлар танкистлар һәм башка хәрби һөнәр ияләре, рюкзакларын асып, чүкеч-кайлаләр тотып, янә караңгы тайгага керер китәләр. Тыныч хезмәтнең зур романтикасы белән дәртләнгән геологлар эшкә керешә.

Ләкин ул чакта әле примитив инструментлар белән коралланган, начар техника белән тәэмин ителгән геологлар тирәндә яшеренгән җир асты байлыкларын ничек ачсын? Экспедиция таркала.

Тайга урманнарына разведчикларның тагын яңа төркемнәре җибәрелә. Тик алар да шундый авыр хәлгә төшәләр: азык запаслары, ягулыклары бетеп, урманда киемнәре теткәләнеп төшкән, чебен-черкиләр талап, тәннәре кутырлаган геологлар базага нәтиҗәсез кайталар.

Иң комачавы — разведка башлыкларының үзләрендә төпле белем, ышаныч диган нәрсәнең җитмәве, алардагы бюрократизм чире була. Ерак шәһәрнең җылы учреждениеләрендә, фәнни-тикшерену институтларында утыручы бер төркем консерваторлар Себердә нефтьнең юклыгы, эзләнүләрнең файдасыз икәнлеге турында көн саен кызу бәхәсләр алып баралар, тузга язмаган дәлилләр китереп, нефть табылу мөмкинлекләрен инкарь итәләр. Җитмәсә, зур җыелышларда, киңәшмәләрдә, газета-журнал битләрендә чыгышлар ясап, «фәнни хезмәтләр», «монографияләр» язып, энтузиастларның күңелен һәр даим төшереп торалар.

Капма-каршы ике лагерьга бүленеп җаваплы кешеләр бәхәсләшә. Бер якта — фән теориясенә, геологик күрсәткечләргә, хәтта гипотезаларга, ихтималлык теориясенә таянган оптимистлар, икенче якта — фәнне, теорияне кире кагучы, кешеләрнең булдыра алу сәләтенә ышанмаучы консерваторлар...

Бәхәсләр дәвам итә, тик аңа карап оптимистлар бирешми — тирән катламнарга разведка эшләре дәвам итә. Эзләнүләргә киткән утыз ел эчендә Себердә егерме биш скважина бораулана һәм тикшерелә. Әмма... нефть һәм газ ятмалары табылмый.

Шулай да геологларның фидакарь эшләре эзсез югалмый. 1948 елда, Коровин, Кудрявцев, Рябухин, Степанов һәм Тыжновлардан торган бер төркем галим һәм белгечләр Көнбатыш Себердә сиек ягулык эзләүнең беренче этабы йомгаклары турында фәнни хезмәт язалар. Анда, геологик мәгълүматлардан чыгып, Себер җирендә нефть һәм газның зур запаслары булуын раслаган төпле фикерләр әйтелә, кире кагып булмаслык дәлилләр китерелә. Галимнәрнең бу хезмәте разведчикларга яңа яңа көч һәм дәрт бирә. Тайгага кабат геологик партияләр, экспедицияләр чыга. Алар урманнарны, елга буйларын, сазлыкларны, күлләрне тикшерәләр, картага төшерәләр, җирне бораулап та, казып та карыйлар, балчык, ком, таш үрнәкләрен алалар — тик... нәтиҗәсез.

Илле өченче елның язында Әзербайҗан мастеры Ходайбирде Кулиев җитәкчелегендә тагын бер экспедиция оештырыла. «Монысы соңгысы, әвәле-ахры шул булыр»,— дип озаталар аны төп базада утыручылар. Аларның принцибы: ничек булса да бу тынгысыз разведчиклардан, үзсүзле геологлардан котылу.

Соңгы экспедиция. Соңгы омтылыш. Соңгы өмет. Әнә шулай ахырынача ныклы терәге, зарланырга урыны, сорарга, таләп итәргә ышанычлы кешеләре булмаган хәлдә, искергән җиһазлар-инструментлар һәм чамалы азык запасы төягән баржалар ерак сәфәргә чыгып китә. Алар Обь елгасы буйлап төньякка таба көннәр, атналар баралар. «Нефть булырга мөмкин»,— дип картада геологлар күрсәткән нокта Обьның түбән агымында, уң якта, Казым елгасы буенда утырган Казым поселогы. Кешеләрнең күңел күзләре шул якка төбәлгән, өметләре һәм теләкләре бары шунда, берсенә дә билгеле-таныш булмаган Казымда.

Ләкин... кинәт көннәр җылытып Обь елгасы өстендә яңгырлар ява башлый, елгада көчле ташу кузгала. Болай да язгы сулар белән кушылып, күз күреме җитмәс тоташ бер диңгез хасил итә. Көчле агымга ияргән пароход, өй тәүмәллеге дулкыннар белән кагыла-сугыла, баржаларын көчкә өстерәп сулга, Сосьва елгасына кереп китә. Кәраваннары белән экспедиция Березово авылына килеп төртелә...

Әгәр нефть эзләүче батырлар мондый язгы ташкында тәвәккәллекләре җитеп юлга чыкмасалар, очраклы рәвештә Березовога кереп сыенмасалар экспедициянең эше әлбәттә, чираттагы уңышсызлык белән бетәсе булган. Ник дисәң, базада күрсәтелгән бораулыйсы урын Казымда, соңыннан билгеле булганча, нефть юк икән. Димәк, экспедицияне, гадәттәгечә, базага чакыртып аласылары, киләчәктә берниндн бәхәсләргә, юрауларга, яңа омтылышларга урын калдырмыйча, «Себердә нефть юк» дип ансат кына мөһер сугасылары һәм эшне ябып куясылары булган.

Бәхеткә каршы, экспедиция членнары, пароходны борып, базага кире кайтырга чыкмыйлар. Язгы сулар тынганны көтеп, айлар буе кул кушырып утырасылары да килми аларның. Разведчиклар «кире беткән», тәвәккәл үҗәт халык, белергә, эзләнергә, табарга тырышучан зат. Алар Березово янында скважина салырга һәм бораулый башларга, дигән бердәм карарга киләләр.

Җаваплылыкны бораулау остасы Ходайбирде Кулиев тулысынча үз өстенә ала. Әйе, бу скважина үзенең генә түгел, бөтен коллектив язмышын һәм, ниһаять, Себер нефтенең дә язмышын хәл итәчәк. Чөнки бу, төп базадан әйтеп җибәрүләренчә, Себер байлыгын эзләүдә соңгы омтылыш, соңгы һөҗүм...

Березовода атналар, айлар үтә. Борау җир астына йөзенче метрын, биш йөзенче, меңенче метрын төшә. Күренми әлегә нефть дигәне, сизелми нефть билгеләре. Җәй үтә, көз җитә. Илле өченче елның 23 сентябре килә. Буровой журналына 1300 метр тирәнлек теркәлеп куела. Тагын күпме төшәсе, озакмы көтәсе булыр ул җир асты маен?

Һәм кинәт скважина улый, үкерә, забойдагы бораулау инструментын дер селкетә башлый. Ул да булмый, астан үкереп менгән куәтле газ басымы бер чакрым озынлыктагы торбалар колоннасын җирдән суырып алып күккә чөя, якындагы урманга илтеп ташлый. Тын тайгада, елга өстендә гөрселдәгән кайтаваз яңгырый. Кешеләр исән! Могҗиза белән генә исән калганнар бораулаучылар!

Ни дип уйларга белми куркынган авыл кешеләре өйләреннән йөгерешеп чыга. Этләр өрергә, сыерлар мөгерәргә, кәҗә-сарыклар кычкырырга тотына.

Көчле басым белән тәүлегенә миллион кубометр газ, ярты миллион тонна су, ком, балчык атып, уннарча чакрымнарга кыргый аваз бирен торган скважинаны нефтьчеләр тугыз ай буена бастыра алмый интегәләр.

— Бу — бер караганда фаҗига, кешеләр өстенә төшкән зур бәла, афәт, икенчедән, Себердә нефть һәм газ барлыгын игълан иткән көчле залп булып яңгырый. Дистә еллар буена җыелып килгән иске карашларны, Себердәге нефтькә кагылышлы шик-шөбһәләрне җимереп ташлаган гайрәтле аваз, тантаналы салют.

Моннан утыз еллар элек, Татарстанда бер-бер артлы нефть ятмалары табылып шулай көчле фонтаннар露 аткач, аны «Икенче Баку», дип атаганнар иде. Себер инде хәзер икенче, өченче Баку гына да түгел. Ул дөньяда тиңдәше булмаган яңа нефть материгы, планетабыз масштабындагы гигант! Якын елларда Черек күл үзе генә дә унлап Бакуга торыр, дип уйлыйлар. Биредә эшләүчеләрнең моңа ышанычлары бик зур була.

## II

Себереннән бигрәк күле, күленнән битәр исә аның исеме ошамады Курамшинга.

«Кайсы юләре шундый ямьсез ярлык ябыштырган бу атаклы күлгә?» дип ачуланып сорады ул килгән көнне егетләрдән. Хәзер белде: чыннан да исеме җисеменә туры килә икән.

Эшне каян башларга белми күл буйлап аптырап йөргәндә, аның күзенә бары тик очсыз-кырыйсыз җәелгән болганчык су, ул суның быкырдап ятканы гына күренде. Монда балыкка түгел, бакалар бакылдарга да шартлар юк. Хәтта күл тирәсендә чеметеп алырлык үлән дә, бер генә куак та үсми. Аның суы сасы, яман исле, сыек чәй төсендә. Шуңадыр, күл янына кошлар да, җәнлекләр дә иялэшмәгән. Гомер буе аучылык, балык тоту белән шөгыльләнгән хантлар үзләре дә бирегә килергә курыккан дип сөйлиләр.

Бу күл турында халыкта телдән-телгә күчкән төрле риваятьләр, легендалар йөри икән. Шуларның берсен дүрт-биш ел элек бу тирәләрдә нефть эзләүдә катнашкан Кузьма Пичугов болай дип сөйләде:

— Имеш, моннан мең еллар элек күл ифрат чиста, матур, бихисап балыклары булган. Алар торган саен үрчегәннәр, ишәйгәннәр икән. Күл

бу балыклардан үзенең азыгын да, суын да күпсенә башлаган. «Файдагыз юк, ашап-эчеп ятырга гына беләсез»,— дип зарланган, ди. Көннәрдән бер көнне балыклар җыелганнар да үзара сөйләшкәннәр-киңәшкәннәр: «Күл бездән суын да, азыгын да кызгана, әйдәгез Обь елгасына күчәбез»,— дип әйткәннәр, имеш. Күл, иртән уянып караса, бернәрсә юк икән суда: ни чабаклар, ни чуртаннар, ни корбан балыклар... бер җан иясе калмаган, хәтта бакаларга чаклы ташлап киткәннәр, ди күлне. Шуннан соң күл үзенең тереклек ияләрен сагына башлаган. «Сездән башка ямем дә, тәмем дә юк, кайтыгыз, зинһар, бөтен суымны эчеп бетерсәгез дә сүз әйтмәс идем»,— дип ялынган аларга. Тик күпме генә ялварса да җан ияләре яңадан әйләнеп кайтмаганнар. Сагынуыннан күл кипкән, саргайган. Күлнең әле булса да быкыр-быкыр итеп ятуы— үзенең балыкларын чакырып ятуы икән...

«Гаҗәеп матур легенда бит бу! Өйгә кайткач балаларга сөйләргә булыр моны»,— дип сөенде Кәрам.

Шунда ук алдына ике улы — Фәргать белән Тәлгать йөгереп килеп баскандай булды. Эштән кайтып, ашап-эчеп ял итәргә утыру белән үк чаптырып килеп җитәләр иде бит алар. «Әти, әкият сөйлә дә әкият сөйлә!» Әтиләренең әкияткә осталыгы — әлбәттә ташка үлчим инде. Әмалайлар өчен нәрсә сөйләсәң дә, ничек сөйләсәң дә кызык, тик авызың гына тик тормасын. Әтиләренең әкият белән мавыгырга вакыты тарлыкта да эшләре юк: сөйлә булгач сөйлә! Иødәтеп бетерәләр. Алардан котылу, балаларны йоклатып җибәрү өчен, әтиләре, гадәттә, үзенең сыналган алымын куллана: «Борын-борын заманда булган ди, торган ди бер әби белән бабай. Булган ди боларның ак кәҗәләре. Ап-ак булган ди, үзенең сөтеннән да аграк булган ди. Ап-ак булган ди, сөтеннән дә аграк булган ди...»

Бер үк сүзне шулай бик озак кабатлап утыра торгач, малайлар аны туктаталар, икенчене сөйләргә кушалар. Икенчесе инде тагын очсыз-кырыйсыз:

«Йорт түбәсенә саескан килеп кунган ди, борынын ала, коерыгы ябыша, коерыгын ала, борыны ябыша...» Сөйли торгач, ике «ташбашы» ике ягында йоклап та китә.

Артында кеше басып торганын тоеп, Курамшин сискәнеп китте.

— Ник болай бик уйга калдың, начальник?

Шома таягына таянып, аңа игеп терәгән бу карт теге көнне кысан, тәбәнәк өйдә мич ягып утырган Ишәй абзый иде. Кәрамның күзенә ул әле һаман да шуннан бер дә тормаган кебек. Һаман бүкән өстендә мич каршында махрасын тартып, туймас корсаклы мичкә утыннар ташлап утыра төсле күренде.

Бик кызганыч тоелды бу ялгыз карт Курамшинга. Бик бетәшкән, кыяфәте мескен иде аның.

Хәер, Курамшинның үз хәле дә биредә Ишәйнекеннән бер дә артык түгел. Бәлки начаррактыр да әле. Карт хет эшли, үзенә күрә төпле шөгыль тапкан — мич булса да ягып утыра. Аның монда үз иткән кешеләре, таныш-белешләре бар. Ә менә Кәрамның төпле генә эше дә, ачылып сөйләшер кешесе дә юк. Аһ итеп торган бер дусты Кузьма бар иде, анысы да үз тормышындагы хикмәтләре белән, ничектер, җанны өшетеп җибәрде.

— Син үзең кайсы якныкы, абзый? — дип сорап куйды Курамшин. Аның бу карт белән сөйләшәсе, танышасы килә иде. Нигәдер сәеррәк төсле бу абзый, ни өчендер күңелсез, хәсрәтле сыман.

Кәрам татарча дәшкәч, Ишәй җанланып китте, башын күтәреп чекрәеп карап торды да:

— Син татар мыни? — дип сорады.

— Әйе, мин Әлмәт якларыннан булам. Ишеткәнегез бардыр инде андый шәһәрне?

— Монда ул тирәләрдән кешеләр күп! Әнә, трактор белән йөри торган Фәнүзә дә бит Әлмәтнеке дип сөйли.

— Мин аны яхшы беләм.

— Бик унган хатын. Ир-атларың бер кырыйда торсын.

Ишәй кулындагы таягын кайдадыр көнбатышка, өердәй агылып килгәнен ак болытларга төбәде.

— Мин ә-ә-нә теге яктан, Арча районыннан булам,— диде. Әйтерсең Арча шул болытлар өстенә менеп утырган.

«Ни калды инде сиңа карт көнеңдә монда килергә? Мич ягу өчен үзебездә әллә утын беткәнме?» — дип катырак та бәрелмәкче иде Кәрам, ләкин базынмады. Кеше белән беренче танышлык, алай ярап бетмәс. Иң яхшысы сүзне әлеге күлдән башлап җибәрү...

— Син, абзый, мондагы кеше ахры, бу күлне элек белә идеңме?

— Белә идем... Озак еллар урманда яшәдем... Монда түгел, Вах елгасы буенда. Нефтьчеләр алып килде мине монда, Кузьма Николаевич... Заманында бик матур булган бу күл!

— Балыклар ташлап киткән дә, сагынуыннан күл саргайган, шулаймы?

— Алай түгел ул, дөрес түгел! — дип, чын-чынлап очынып куйды Ишәй.— Сиңа ялган сөйләгәннәр. Балыкларның монда катнашы юк!

Ишәй, кәҗә боты калынлыгы махра төреп авызына капты да шырпыдан ут элдереп, сөйли башлады:

— Черек күл заманында мондый сары булмаган, төбе күренеп торган, көмештәй саф сулы булган. Бирегә иртә-кичләрен су эчәргә, су коенырга көтү-көтү җәнлек, кош-корт җыелган. Шул хәтле дә дус яшәгәннәр алар бер-берсе белән — бүреләр боланнарны, төлкеләр кош-кортларны рәнҗетмәгән. Хәтта аларның кәефләрен бозарга аучылар да җөрьәт итмәгәннәр, нитукмышты киек җанварлар. Менә шулай... Ләкин көннәрдән бер көнне бу тирәләргә явыз ханның гаскәре килеп чыккан. Күрәләр: күл буенда көтү-көтү маллар, җәнлекләр, башка төрле киек җанварлар утлап йөри. Хан гаскәре боларны күл тирәли камап ала. Ала да берсен дә калдырмый кырып бетерә. Күл янындагы камышлар, тирәкләр яна, агачлар, үләннәр кара күмер булып көя. Күл өсте кызыл кан белән тула. Менә шулай... Шул көннән башлап күл буенда бер нинди үсемлек үсми, терлек иясе калмый. Күлне судагы кан сары төскә мана. Күл үлә. «Үле күл» исеме шуннан калган ул. Безнеңчә әйтсәк, Черек күл була инде. Менә шулай...

— Матур әкият бу,— диде Курамшин үз-үзенә әйткәндәй.

— Дөресе шулай. Моны миңа хантый сунарчысы Савелий сөйләгән иде. Ул Себердә туган, бу якларны бетереп белә. Менә шулай...

Моннан соң да әле Курамшинга күп тапкырлар күл буена чыгарга, эш мәшәкатьләре белән көненә әллә ничәшәр тапкыр скважиналарны урарга туры килде, ләкин бу урыннар белән кызыксынуын, аңа гаҗәпсенүен ташламады. Әйе, халык дөрес сурәтләгән күлне. Күл үзе түгел, аның тирә-ягы да җансыз. Кая карама вак-вак күлләр булып яткан күгәрек су, сары сазлык, коточкыч баткаклык. Уннарча километрларга сузылган сазлык патшалыгында үлем тынлыгы. Хәтта кырык градуслы кышкы салкыннарда да туңмый дип сөйлиләр биредәге сазлыкларны. Кар көрте астында, ысылдап, чергән йомырка исе таратып ята икән.

Юлда батып ятканда, монда килеп эшләүне дә батырлыкка тиңләгән иде Курамшин. Черек күлдәге буровой вышкаларын, галәмәт күп техниканы, төзелешләрне күреп таң калды. Разведчиклар җөрьәт итеп бирегә ничек кергәннәр? Күз алдына китерү мөмкин булмаган искиткеч тәвәккәллек бит бу! Ярый, эшкә вертолет белән дә килсеннәр ди. Ә бер-

се-берсе иллешәр тонналы вышкаларны, куәтле краннар да көчкә күтәргән насосларны, дизель моторларын, пар казаннарын, төрле авыр буровой җиһазларын ничек китергәннәр? Әйтик, аларны сүтеп, бүлгәләп тә ташысыннар ди. Ә аяк та басарлык булмаган сазлыкка вышкаларны ничек утыртмак кирәк, аларны кайда ныгытмак кирәк? Өстәвенә, буровой тирәсендә бөтен бер завод кадәр корылмалар, буровой эчтулы агрегатлар, инструментлар, йөзләгән торбалар да булырга тиеш бит әле. Һәм болар бөтенесе дә дерелдәп-калтырап торган сазлык уртасында!

Нефть эзләүче разведчикларның Обь ярына төшкән беренче десантыннан соң Черек күлгә кадәр илле чакрымнар араны унсигез тәүлек буена үтүләре бүгенге исәп белән, бәлки, кубрәктер дә. Ләкин кул пычкылары белән калын урманнарны кисеп, лычкылдап торган саз эченә кат-кат бүрәнә түшәп, үзләре белән зур буровой хуҗалыгын, авыр һәм җайсыз вышканы тарттырып, ярты йөз чакрым араның һәр метрын капшана-капшана үтүләрен искә төшерсәк, тарихта калырга лаеклы хәйран вакыйга бу.

Кеше дигәнең бирешмәгән. Мәкерле баткаклар тракторларны мәңгегә суырып алган, йөк машиналарын, озын-озын краннарны йоткан. Тик разведчиклар куркып калмаганнар, юлларын дәвам иткәннәр — киң сукмак ярып һаман эчкәрәк, Черек күл дигән шушы күлгә таба үрмәләгәннәр. Зур су кирәк булган аларга, бик күп су: җирне сусыз бораулап булмый, нефтьне сусыз чыгарып булмый.

Кеше дигәнең табигый шартларга ничек яраклаша алган! Юк, яраклашу түгел, табигатьне үзенә буйсындыру кирәк булган аңа. Биредә буровой корып булмый дип аптырап тормаган, саз эченә агачлар түшәп, өстенә балчык, ком өеп, аның да өстенә бетон плиталар җәеп кергән дә утырган, эшли башлаган.

Әмма скважина тәмамланган саен яңа урынга яңа юл салып күчену, утрау ясап вышка кору гаять мәшәкатьле, вакытны күп ала, артык кыйммәткә төшә. Кеше бу очракта да аптырап калмаган! Тоткан да шушы әзер утрауда рельслар сузып, вышканы сузып, вышканы аңа утыртып, арасын бер метрлап күчерә башлаган һәм авыш скважина борауларга керешкән. Болай иткәндә бер урыннан дистәләрчә диярлек салынган скважиналар тирәнгә киткән саен бер-берсеннән ераклаша, тармаклана бара һәм үзенә нефть суырырлык ара калдыра.

Курамшин күргәндә Черек күл тирәсендә, сазлык эчендә бер-берсеннән икешәр-өчәр километр ераклыктагы мондый утраулар дүртәү иде. Бүген инде биш булган. Ул утрауларны нефтьчеләр төбәк дип йөртәләр. Бер җирдә вышкачылар буровой корсалар, шунда ук рәттән бораулаучылар скважина төшерәләр. Төбәк саен унар, унбишәр скважина борауларга тиеш икән. Күбесендә инде, нефть чыкканны белдереп, җир астыннан штурваллары белән торба башлары калкып тора. Утраучык нефтькә, мазутка баткан.

Татарстан промыселлары белән чагыштыргач монда нинди дә кыргыйлык һәм әйтеп бетергесез тәртипсезлек күрде Курамшин. Үзе эшкә йөргән такыр юллар, бодай яки арыш басуы эчендә, тау итәкләрендә сибелеп утырган скважиналар, алар янында көмештәй ялтырап торган трап һәм мерниклар, группалы установкалар күз алдына килә. Бигрәк тә аның елга буенда, имән урманына терәп диярлек салынган җыйнак культбудкасы — бригада штабы шәп иде. Нинди пөхтәлек, чисталык! Үзәк культбудка ерактан ял йортын хәтерләтеп тора. Рәшәткә белән әйләндереп алынган ямь-яшел ишек алды, шунда ук теннис мәйданчыгы, бассейн, душ. Эштән соң рәхәтләнеп су кер, ял ит! Культбудка артында бер гектарлап җирне билән алган алма, җиләк-җимеш бакчасы. Анда җәй-көз көннәрендә туйганчы карлыган, крыжовник, кура

җиләге, алма белән сыйланырга була. Боларны бит бригада коллективы үз көче, үз куллары белән булдырган!

Ә будканың эче нинди иде — үзе бер җәннәт! Укыйсың килсә газета-журналлар, китаплар дисеңме, уйныйсың килсә биллиард, шахмат-шашка дисеңме — барысы да бар. Хәтта бүләккә бирелгән телевизор, радиола, магнитофон да шунда яшәүчеләр карамагында.

Шуларны искә төшергәч, Курамшинга бу Черек күл мәйданын айлар, еллар буена, көн-төн эшләп тә чистартып бетереп булмас кебек тоелды. Бәс, шулай икән, мондагы скважиналарны да гомергә нефть бирер хәлгә җиткерү мөмкин түгелдер дигән шиккә калды. Әле бит, скважиналарны җиһазлаудан алда, кешеләргә җил-яңгырлардан, суыклардан ышыкланыр, кипшенер, җылыныр йоклар урыннарын булдырырга кирәк... Курамшин авыр итеп көрсенде дә: — Юк, килмәскә кирәк иде миңа. Сәбәпләр табып, теш-тырнак белән каршы торырга иде! — дип кычкырып диярлек әйтеп куйды.

Шулай да биредә күзгә ташланган бер нәрсәгә игътибар итми калмады Кәрам. Бу — күлнең шәһәрдән килгән башында баткак сазлыклардан яулап алынган бер кечкенә мәйданчык. Авылның бәрәңге бакчасы кадәр җир ул үзе. Аны саз пычрагыннан әрчеп, ком тутырып, цемент плитәләр күтәрткәннәр. Өсте шома асфальт. Мәйдан уртасында диярлек кирпечтән бик матур итеп ике катлы кечкенә генә йорт салып куелган. Тәрәзә-ишекләре булса да, хәзергә әле эче буш. Йорт янында, будка сыманрак тагын бер-ике кат корылма бар. Бу Черек күлнең төп базасы булачак, дип аңлаттылар Кәрамга. Ике катлы йорт — административ бина икән. Аның аскы катында диспетчер пункты урнашачак.

Кәрам, гадәттәгечә, үзенең яраткан әйтемен кабатлады:

— Ну, чыгарсың кояш чыгуга, тик мин генә булмам...

Ул агач түшәлгән юл буйлап күлнең уң як ярына китте. Мондагы ике төбәкнең берсендә, тездән пычракка батып, ун-унбиш кеше белән Аввакумов эшләп ята иде.

Виталий Иванович, кулында майланып беткән схемаларга, сызымнарга карап эшчеләргә күрсәтмәләр биреп, бармаклары белән әле кәгазьгә, әле торбаларга төртә-төртә, аларны өйрәтеп йөри.

Кәрам, үзенең көне буе диярлек тик йөрүенә читенсенеп, Виталий Иванович янына килде, аның кулында бармак эзләре ярылып яткан сызымнарына карап торды. «Схема обвязки скважин» дип язылган иде анда. Скважиналарны автоматлаштыру турында ник бер сүз булсын!

— Миңа ни эшләргә, Виталий Иванович? — дип аптырабрак сорады Курамшин.

Аввакумов сакалын кашып алды. «Моңа ниндиерәк эш кушарга икән?» дигән сыман, тирә-ягына каранды.

— Эш дисең инде? Син, Кәрам Ризванович, бераз хәл ал, ял ит. Карап-күреп бетердеңме соң әле безнең күл патшалыгын?

— Бетердем.

— Яхшы! Тагын бер тапкыр кара! Баш инженерның әмере шундый.

Кәрам сизеп тора: Аввакумов боларны чын күңеленнән түгел, көлеп-мыскыллап әйтә.

— Эш ул, туган, булыр, күңеленне генә киң тот. Черек күлдә аллага шөкер, эшсезлектән аптырап юк. Син соң нәрсәгә борчыласың әле. Солдат йоклый — хезмәте бара... Күр дә тор менә: кайтыр көннәрең дә килеп җитәр... Вакыт ул яшен яктысы кебек.

— Әйдә, Виталий Иванович, җитдирәк булыйк әле. Килгәч, чыннан да, ике кулга бер эш кирәк бит инде.

— Анысын дөрес әйтәсең, туган. Ике кулның берсе булса да эшләргә тиеш...

Аввакумов сызымнарын эреле-ваклы торбалар өеме өстенә куйды да, аны түш кесәсендәге штангенциркуле белән бастырды. Папирос кабызды, төтенен мул итеп борын тишекләреннән чыгара-чыгара:
— Бүгенгесе көндә безнең төп эшебез менә шушы төбәктә,— диде.— Иң беренче нефть менә шушы скважиналардан китәчәк. Син автоматчы бит? Автоматчы. Шулай булгач, күп бир мина менә боларны. Виталий Иванович ачык әрҗәләрдә күренеп торган манометрларны күрсәтте.
Кәрамнең йөзе чытылды:
— Болар вак мәсьәлә. Аны, күрсәтеп бирсәң, теләсә нинди эшче дә куя.
— Алайса, узьяпкычларны куй...
Кәрам Ризванович, бик ачы нәрсә капкандай, авыз тирәләрен җыерды.
— Монысы да монтажчылар эше. Бездә аны дүртенче разряд белән эшлиләр.
Аввакумовның да кәефе китә башлады. Ул, нефть бакларына таба кулын сузып:
— Ә датчиклар куярга алынсаң? — диде. Үзе, тагын да кызыксынып, сынау белән Кәрамнең йөзенә карап торды.
— Сез нәрсә, Виталий Иванович, көләсезме әллә? Мин бит монтажчы түгел, ә инженер! Шулай ук промысловик та түгел, ә автоматчы! Сез мине бутамагыз әллә кемнәр белән!..
— Алайса, миндә бүтән төрле эш юк, сезгә кайтып китәргә мөмкин!..
Аввакумов кырт борылды да, торбалар өстендәге кәгазьләрен алырга да онытып, скважиналар янына китте.

Бу көнне Фәнүзә белән очрашты Курамшин. Кырда түгел, ашханәдә. Арты өстәлләрнең берсендә ашап утырганын күреп, туп-туры аның янына барды. Фәнүзәнең бирегә ничек, кайчан килеп чыгуы кызыксындыра иде. Нигә дисәң, Себергә китәсе көннәрне генә коммутатордан сөйләште, анда телефонда Фәнүзә җавап биреп ята иде. Исәнлек-саулык сораганнан соң Кәрам:
— Син кайчаннан бирле монда соң әле, Фәнүзә? — дип әйтергә мәҗбүр булды.
— Ике ел була инде.
— Ике ел? Ә мин синең тавышны Әлмәттә ун көн элек ишеттем!
Фәнүзә, ашавыннан туктап, иелеп-бөгелеп көләргә керешге:
— Әх, Кәрам Ризванович! Үзең инженер, үзең кеше тавышын да аермыйсың. Минем сеңелем Фәния ич ул!
— Сеңелең? Тфу, черт, мин аңардан гафу үтенеп ятам тагын!..
— Нигә миннән гафу сорарга? Барысына да үзем гаепле. Ярамаган эш эшләдем, хатынлы кешене яраттым. Сезнең тынычлыкны боздым.
Фәнүзәнең кәефе кырылды бугай: өстәлдәге ашларын калдырып урыныннан торды.
— Ярый, Курамшин, монда урыны түгел,— диде.— Әгәр түбәнлек санамасаң — безнең торакка килеп чык. Барам дигән идең бит, оныттың мыни? Әллә хатын-кызлардан шөлләисеңме?
Ул, бөтен ашханәне яңгыратып көлде дә, юри гәүдәсен уйната-уйната чыгып китте.
— Ах, пәри кызы! Ах, албасты! — дип башын чайкап калды Кәрам бүтән сүз таба алмыйча.— Юаш Мәснәвинең генә түгел, әллә кемнәрнең башына житәр.
Шунда Фәнүзә белән Мәснәви вакыйгаларын, бу кыз турында кешеләр сөйләгәннәрне, бөтен күргән-белгәннәрен исенә төшереп утырды. Елмайды, көлде, ачуланды, үкенде...

## УНЫНЧЫ БҮЛЕК

### I

Ризатдинның өченче кызы Фәнүзә дөньяга килгәч, авылда бу семьяга карата әйтелгән төртмәле сүзләр дә, мәзәкләр дә калмагандыр шәт. Ул яка астыннан мыштым гына көлүләр дисеңме, ул колактан-колакка пышылдаулармы... Ризатдинның өченче кызы, әйтерсең, бу фани дөньяга артык кашык булып килгән дә, гуҗ кавымыдай башкаларның өлешенә тыгылган!

Төрле авыз чайкауларга юл калдыруда авылның беренче тракторчысы Ризатдинның да гаебе зур. Өч кыз кемдә юк та, бер дә күрелмәгән хәлме? Андыйлар дөнья тулы. Тик хикмәт шунда: Ризатдин ачыктан-ачык малай көткән иде.

Бер кызын да кимсетмәде, рәнҗетмәде Ризатдин, һәммәсен дә үз итте, барысына да яхшы ата булды, шулай да өченче кызы Фәнүзәне аеруча ярата, үтә якын күрә иде ул.

Бу юеш борыны да бит, ни хикмәттер, бәләкәйдән үк әтисенә сырышты, аның аяк астында уралды. Әтисе эштән кайтмыйча кашык-савытка тотынмас, әтисе бер үчти-үчти иттереп түшәмгә кадәр сикертмәсә башын мендәргә салмас иде.

Әти кеше, баштарак, үзе кая барса да Фәнүзәсен ияртә торган булды, кызы бераз үсә төшкәч кырга, эшкә үк алып йөри башлады. Рульдә, әтисенең җылы итәгендә, әнисе сырып биргән бишмәт якасыннан оядагы кош баласыдай башын гына чыгарып, кечкенә Фәнүзә көннәр буе сабан сөрә, тырма-тырмалый, чәчү чәчә.

Ул инде дәү булган — әтисенең эчәсе килсә, савыт тотып чишмәгә йөгерә, юынганда муенына чүмеч белән су салып тора, хәтта тракторга май, керосин салганда бакның капкачын ябарга булыша. Нindидер сәбәп белән трактор туктап калса, алар икәүләп мәж киләләр. Әтисе чирәмгә капчык җәя дә, ачкыч-мазарларын туздырып ташлый, эрелеваклы төрле детальләр китереп куя, ә Фәнүзә алар белән курчак уйнагандай уйнап утыра, юа, майлый, сөртә, тигез итеп тезә.

Бигрәк тә яз көне күңеле кырда. Көн җылы, рәхәт. Тирә-якта бертуктаусыз тургайлар сайрый. Алар сабан артыннан гына күккә атылып меңәләр дә һавада асылынып калалар. Канатлары гына җемелди. Бераздан яңадан таш кебек атылып түбәнгә төшеп китәләр. Тагын җир өстенә тияр-тимәс талпынып торалар — өстән дә, астан да боларның эшен тикшерәләр кебек. Кайдандыр, Камышлы күл буеннан, бытбылдык тавышы килә: «Бытбылдык, бытбылдык, тотылдык, юк булдык, тотылдык, котылдык», дип такмаклыйлар төсле. Аларга шунда ук тартай кушыла: «Тар-рт, кар-рт, тар-рт...»

Ә Фәнүзәнең әтисе тракторы белән җир буйлый һәм борын астыннан иртәдән бирле бер үк көйне көйли: «Әнә килә трактор, Сука бабай ерак тор!..»

Кичкә таба туры алашага атланып трактор бригадиры килә. Аз сөргәнгә риза түгел, борчылган, күзе-башы җимерелгән. Ризатдинны ачуланмакчы, ләкин бит-куллары, хәтта тәпиләренә кадәр майга буялган баланы күреп көлми түзә алмый.

— Кайсыгыз сезнең тракторчы, кайсыгызны җавапка тартырга! — дип кычкырган була.

Килеп кызның аркасыннан сөя дә:

— Ничу синә, Ризатдин, малай даулап йөрергә! Чын танкист булып туган бу! — ди.

Фәнүзә үзе дә, ни сәбәптер, кыз-кыркын затын өнәми, аларны санга сукмый иде. Бервакытта да анасына ияреп йөрмәс, сеңелесен ияртмәс. Кача ул алардан, әтисе янына кырга, машиналар, тракторлар янына ка-

ча. Аның өчен чүпрәк-чапрак та, курчак та, буяулы көянтә-чиләкләр дә дөньяда юк кебек, аның кулында һәрвакыт үзе каяндыр табып алган подшипниклар, күгәргән тимер тәгәрмәчләр, янган лампочкалар гына булыр. Кесәсендә төрле кадак, шөреп, гайка...

Кызының малайларга хас шул гадәтләрен күреп Ризатдин абзый сөенеп бетә алмый. «Малай булмаганга ходай шулай кушадыр»,— дип мыек астыннан көлеп йөри.

Аның каравы Сәхибә апаны хафага төшерә бу «чегән кызы».

— И ходаем, бу нинди җен алыштырган бала булды соң әле?— дип кайгыра иде ана.— Күр инде, юып-юып та агартып булмый, тач атасы! Тфу-тфу, бер генә дә кызларга ошамаган бит, тамчы да!..

Мәктәпкә йөри башлагач, Фәнүзә иптәш кызларына иярер, бу килешсез гадәтләрен ташлар, дип көткәннәр иде өйдә — юк шул, булмагач булмый икән. Инде малайлар белән сугышып, тырналып, өс-башларын ерттырып кайта башлады кыз.

Кәрам Фәнүзәне әнә шул мәктәп елларыннан белә башлады. Аны исеме белән дә әйтмиләр, «Ризатдин ирдәүкәсе» дип кенә йөртәләр иде.

Фәнүзә һәркайда малайлар янында: ул алар белән балыкка китә, һич тартынмыйча күлмәген салып ташлап, алар белән елгада су керә, юртакка атланып төнге ат көтүләренә чаба.

Әнисен тәмам чыгырыннан чыгарды Фәнүзә.

— Җитәр сиңа, кызый!— дип уклау тотып чыга иде Сәхибә апа урамга.— Кайт, әнә күлмәгеңне яма, мәлгун!

Чыннан да, авылда Фәнүзә яшендәге кызлар, чиләкләрен ялтыратып, суга баралар, чишмәдә җырлый-җырлый кер чайкыйлар, тегү тегәргә, чигәргә өйрәнәләр, ә моның хатын-кыз эше гамендә дә юк!

Әйтеп-әйтеп тә кызын тыңлата алмагач, Сәхибә Ризатдинга килеп бәйләнде:

— Ни гозерләп әйттем сиңа кызыңны азындырма дип! Тыңламадың, тракторыңа атландырып йөрттең! Әнә хәзер кара инде, ни кылана Фәнүзәң!

— Тимә, анасы, аңа!— дип кырт кисеп куя Ризатдин.— Ходай ир бала урынына биргән аны...

Әтисе белән әнисе арасында көн саен булып торган мондый тавышларны ишетеп кызга да азрак тыелырга кирәк иде, ә ул юк, аның саен ирәя. Чормада әтисенең иске ватык велосипеды аунап ята иде, соңгы вакытта Фәнүзә шуның белән мавыгып китте. Сүтеп, майлап рәткә кертте дә хәзер шуңа атланып чаба.

Инде Сәхибә апаның бердәнбер өмете кыз үсүгә терәлеп калган иде: «Җитлегә төшкәч, акылына утырыр, үз-үзен җыештырып йөри башлар»,— дип юана. Булмаса булмый икән. Җиденче класска күчкән елны Фәнүзә, парикмахерскийга барып, үсеп килә торган шомырт кара толымнарын кистереп кайткан. Яшел береткасы астыннан, егетләрнеке кебек кыска чәч чуклары тырпаеп тора. Аны күргәч Сәхибә апа, сыер савып кергән җиреннән туктап, кулындагы сөтле чиләген төшереп җибәрде.

— Әстәгъфирулла тәүбә, бар икән күрәселәрем!..— дип кенә әйтә алды ул.

## II

Шушы елның җәендә, Фәнүзә җиденче классны тәмамлаган көннәрдә, авылга нефтьче разведчиклар килде. Нинди дер өчаяклар тоткан кешеләр авылның тирә-ягын карап йөрделәр-йөрделәр дә, нәкъ Ризатдин абыйларның бәрәңге бакчасы башында буровой вышкасы корырга то-

тындылар. Ике-өч йөз метр гына ары, Тавыш елгасы буенда берничә яшел палатка корылды. Төннәрен нефтьчеләр яккан учак яктысы багана булып һавага күтәрелә, урамнарга, йортларга, каралтыларга төшә иде.

Бигрәк тә Фәнүзә яткан карават янында, тәрәзәдә уйный ул яктылык. Һәркайда: күктә, урман өстендә, тау башларында җемелдәгән ялкын шәүләләренә карап, тәрәзә төбендә керфек тә какмаган төннәре күп булды Фәнүзәнең. Җитмәсә, таң алдыннан гына кайсыдыр моңлы итеп җырлап җибәрде:

Үрдәк күлләргә төшә,
Күлдән күлләргә күчә.
Сөю уты йөзгә күчә,
Йөздән йөрәккә төшә.

Гел бер вакытта диярлек, гел бер көйгә, гел шушы җырны җырлый.

— Сөюнең дә уты була микәнни? Нинди икән соң ул ут? Болытларга менгән, тауларга барып кунган учак яктысы кебек йөрәккә дә төшә ала микәнни үзе? — дип җырлаган кешедән көлеп, аны үртәп ята Фәнүзә.

Фәнүзәнең күңеле тыныч түгел. Инде җиденчене дә бетереп чыкты, ә нәрсә эшли башларга, кая барырга? Әллә берәр техникумга яки училищега китәргәме? Алай дисәң, белем турындагы таныклыгында өчтән башка билгеләр дә юк диярлек. Бер физикадан, аннан химиядән генә дүрт — аның белән еракмы сикерәсең. Аннан, укыйсы да бик килеп тормый әле. Әнисе әйтә: «фермага сыерлар саварга кер», ди. Тапты эш! Тфү, гомерен сыер савып уздырамы соң әнисе кебек. Кичә таң тишеге белән бригадир кереп җиткән. «Син, тәти кыз, озакмы трай тибеп урамда йөрергә уйлыйсың?» — дип җикеренә. Колхоз эшенә, чөгендер утарга җибәрмәкче. «Чөгендергә әнә хатыныңны куш!» — дип кенә чыгарды аны Фәнүзә.

Фәнүзә бары тик тракторчы гына булачак. Әтисе кебек механизатор! Менә ичмасам эш дисәң дә эш! Әмма Фәнүзәнең бу хыяллары тормышка аша торган түгел иде. Беренчедән, яше җитми, икенчедән, тракторчылар курсына бары тик ир-атларны гына алалар икән.

— Конституциядә ир-атлар белән хатын-кызлар тигез хокуклы,— дип язганнар. Кайда ул тигез хокук? Нигә аны бозалар? — дип кемнәрнедер тиргәп ята иде ул. Төне буе тынычлана алмый караватында ауный.

— Кай җирем минем егетләрдән ким? — дип үз-үзеннән сорый, аякларын сузып, буен үлчәп карый.— Нормально. Яшьтәш малайлардан бер дә ким түгел.— Терсәкләрен бөгеп, кулындагы мускулларын тикшерә.— Йомшаграк булсалар да, шактый юан. Бора-бора трактор кабыза башласаң мускуллар да ныгыр әле...

Киерелеп, күкрәк киңлеген чамаламакчы була Фәнүзә һәм шунда куллары йодрык кадәр булып кабарган каты бизләргә тиеп китә. Тәненә эссе бөркелә кызның. Сикереп торып утыра, кулларына ышанмый; күлмәк изүен ычкындыра.

— Кай арада әле бу, кай арада! — дия-дия куркып пышылдый Фәнүзә, күкрәкләрен тагын капшап.

Әйе, моңа кадәр ул үзен малайлар итеп кенә хис итте, аларча уйнап, аларча кыланып йөрде, аларга охшарга тырышты. Малайларның «ирдәукә», дигән үртәүләренә дә исе китмәде — үзенекен итте. Ә хәзер, кай арададыр түшләре үсеп, ботлары юанаеп киткән, карга чукырлык та булмаган тәненә ит куна башлаган. Ничек әле ул сизми-абайламый калды шулай үсүен? Чыннан да, апасы кебек юан балтырлы, зур күкрәкле кыз була калса Фәнүзә кеше күзенә ничек күренер?

— Иртәгә үк бәйләп куярга кирәк күкрәкләрне. Ныклап кысып, һич тә беленмәслек итеп!..

Җәйге төн бер карыш — инде таң да беленә башлаган. Тик Фәнүзәне йокы алмый, әллә нәрсәләр уйлап, шушында гына, тәрәзә артында гына кебек ишетелгән буровой гөрелтесен тыңлап ята. Уйлана һәм офтанып үз-үзенә сорау бирә:

— Ник малай булмадың син? Нигә сине кыз кеше итеп тапты әни?

Август башларында бакча артындагы буровой тып-тын булып калды. Күп тә үтми, аны тракторлар белән тартып алып киттеләр.

Фәнүзәгә генә шулай тоелгандырмы, ниндидер күңелсезлек басты тирә-якны.

Киттеләр... Ни булган, нефть чыкмаганмы? Әллә безнең авылны яратмаганнармы бораулаучылар?

Элек буровой шавыннан, тәрәзәләрдә уйнаган ялкын шәүләләреннән әсәрләнеп йоклый алмаган кыз инде эчпошыргыч үтә тынлыктан интегеп ята башлады. Күңеле уйный, йөрәге яна. Ни өчен — үзе дә белми.

Ярый әле, бәхеткә каршы, озак тормады бу тынлык. Атна-ун көн дә үтмәгәндер, кичкә кадәр бакча башында — буровой утырган җирдә казына башладылар. Болары вышка төзүчеләр дә, бораулаучылар да түгел, нефть чыгаручылар икән. Бораулаган урынга, тирәнгә торба төшереп, шуннан нефть суыртачаклар, дип сөйли халык.

Менә шунда Сәхибә апа беренче мәртәбә Фәнүзәнең иңенә көянтә салуын һәм тыкрык буйлап кызларча, бөгелә-сыгыла, бил уйнатып суга китүен күрде. Күрде һәм, өнсез калып, озак кына бот чабып торды.

— Әстәгъфирулла! Бу пәри кызына да акыл керә башлады микәнни! Тфу, тфу, күзем генә тия күрмәсен!..

Ә Фәнүзәнең максаты башка. Ул иртә-кичләрен тыкрыктан яланаяк кына суга төшкән була да, туктап, киртәләргә сөялгән хәлдә нефтьчеләрнең ыгы-зыгысына карап тора.

Бакча артындагы бу дөнья аңа бөтенләй ят һәм гаҗәеп тоела. Анда моңа кадәр күрелмәгән зур-зур машиналар, чыгырлы тракторлар, озын торбалар төялгән әкәмәт арбалар һәм тагын әллә нәрсәләр...

Кешеләре дә бу якныкыларга охшамаган: каралар, эре гәүдәлеләр, җитезләр. Алар эшләмиләр, гел йөгереп кенә йөриләр төсле. Ә үзләре бер-берсе белән, саңгырау кешеләр сыман, кычкырып сөйләшәләр һәм усал итеп сүгенәләр, килбәтсезләр...

Арттарак — такталардан корыштырып ясаган зур сарай. Сарай эчендә ниндидер моторлар гөрелди, двигательләр дөпелди. Сарай түбәсендәге юан морҗадан куе зәңгәр төтен күтәрелә.

Шул лапас корылмалар арасыннан, тыз-быз чабышып йөри торган кешеләр яныннан үтеп суга барырга кирәк Фәнүзәгә. Чишмә яр астыннан саркып чыга. Шул урынны тирәнәйтеп, чуер ташлар белән урап, кое сыман нәрсә ясалган, аңа ак сөяннән чокып улак куелган. Бу — Ризатдин абзыйның карап, чистартып торган үз чишмәсе.

Нефтьчеләр килгәнче тып-тын иде бу тирә. Бакча башы — яшел болын, чирәмлек. Биредә бәбкә үләне генә үсә һәм авыл балалары гомергомергә шушында каз көтәләр, бәбкә саклыйлар иде. Буровой килеп утыргач, берничә ай эчендә үләнне ялап алган кебек булды — машиналар, тракторлар, кешеләр таптап бетерде.

Бу тыкрыктан чишмәгә дә хәзер нефтьчеләрдән, машиналардан курыкмыйча бер Фәнүзә генә суга төшә бугай. Фәнүзәгә кызык: көянтәчиләк күтәреп килгәнеңне күрсәләр, скважина тирәсендәге бөтен ир-ат коралларын ташлап моңа төбәлә. Күзгә бәреп сокланулар, сүз катулар китә. «Ах, кызы да кызы,— дип тел шартлаткан булалар.— Тәпи-

ләрен генә кара инде син аның, йөрми, ә язу яза!» Бер әрем теллесе өстәп тә куя: «Ә язуы — кыек-мыек!» Гөж килеп көлешү башлана.

Кайта башласаң да котылып булмый шул гадәтсезләрдән — төрлесе төрле яктан каршыга йөгереп чыга. Гаять итагатьле булып кыланалар үзләре. Имеш, тамакны гына чылатып алырга рөхсәт итмәссеңме, кызыкай. Рөхсәт бирү белән, китәчүгәләп, чиратлашып чиләк кырыеннан су чөмерүләр — гомердә су күрмәгәннәр диярсең!

— Чишмә янығызда гына бит, ник төшеп эчмисез, нигә алып кайтмыйсыз? — дип шелтәли аларны Фәнүзә.

Кызлар алып кайткан су шифалы, имеш, кызлар алып кайткан суга фәрештәләр канатын тыккан була. Чиләктәге суны күз ачып йомганчы юк итеп тә куялар, килбәтсезләр. Фәнүзәгә борылып, чишмәгә янадан китәргә кала.

Кайтканда, кулларын болгый-болгый, эшчеләрнең икенче төркеме каршы чыга. Болары тагын да әрсезрәкләр:

— Безнең чибәркәй су китергән, егетләр, су алып килгән!

— Әй, рәхмәт яугыры, күктән төштеме, җирдән иңдеме бу кыз! — диешә-диешә мазутлы куллары белән Фәнүзәнең чиләгенә ябышалар. Тәмле итеп, эх тә эх килеп, тамак кыра-кыра эчәләр. Суны мактыйлар, су белән бергә кызны да мактыйлар:

— Чишмә суы түгелдер бу, зәм-зәм суыдыр, егетләр.

— Зур үс, чибәркәй, юлыңа гөлләр тамсын!

Бер япь-ямьсезе, чуен китеге кебек карасы:

— Минем кебек матур кияүгә тап бул! — дип әчпошыра җитмәсә.

Фәнүзә көлеп, ат эчергәндәге кебек боларны кыстап тора:

— Әйдәгез, баһбайлар, чөмерегез, чөмер, чөмер!.. Нык кына сугарыгыз! — Чиләк төбендә калган су белән шунда ук егетләрнең бер-икесен коендырып та ала. Тегеләр рәхәтләнеп салкын суга битләрен куеп, муеннарын сузып тора.

Битендәге кара тутлысы:

— Әллә бу чибәркәйне үзебезгә су ташучы итеп алыйкмы, мастер,— дип янындагы озын буйлы, чокыр иякле егеткә күз кыса.

— Килсә, бүген үк алам! — дигән була мастер, Фәнүзәгә борыла.— Я, алсак, киләсеңме?

— Нефтьче итеп алсаң — киләм!

— Нефтьче? Кара аны кая үрелә! — дип һавага карап көлә дә.— Алыр идем дә, буең кыска бит. Үсәсең бар! — дип күрсенгән була.

Ул чакта Фәнүзә бу яшь мастерның Курамшин икәнен, ә Курамшин бу кызның киләчәктә теңкәсенә тиячәк Фәнүзә буласын белми иде әле.

...Фәнүзәнең тормышында кискен борылышка да менә шушы чишмә сукмаклары китерде инде.

Судан кайтышлый нефтьче егетләр бу көнне дә юлына аркылы төштеләр кызның. Туктаттылар, берәм-берәм, тәмләп су эчә башладылар.

Курамшин дигән башлыклары да шунда, бер хатын белән русча сөйләшеп тора. Фәнүзәне күрсәтә:

— Менә, Татьяна Макаровна,— ди,— син телефончы юк дисең. Ал менә бу кызны үзеңә.

— Яшь бит, бик яшь күренә.

— Яшь булса да Ризатдин абзый кызы диләр аны!..

— Ишеткәнем бар! Ризатдин абзыйның кыз-малае! Шулмы?

— Юк, түгел. Малай-кызы!..

Татьяна Макаровна дигәне, аксаклап, Фәнүзә янына килә, мал сатып алгандай, кызның беләкләрен, муеннарын капшап карый.

— Исемең ничек? — дип татарчалап сорый.

— Фәнүзә.
— Фануза. Фанузушка... Керәсеңме безнең коммутаторга эшкә? Телефонистка булып...
— Алсагыз...

Хәзер Курамшин, онытылып беткән нәрсәләрне исенә төшереп, күпме еллардан соң үкенеп, үз-үзен битәрләп йөри. Туган йортын ташлап Фәнүзәнең чыгып китүендә шактый гына дәрәҗәдә үзен дә гаепле саный. Әйе, яшь кызны эшкә урнаштыруда ярдәм итте, ләкин аны саклый алмады. Каты кыланды, рәхимсез булды...
Әле Фәнүзә генә түгел, аның вөжданында Рафатның да, Җаен Җәмилнең дә язмышлары ята. Боларны син туган якларында сизмисең, читкә киткәч, ялгызлыкта, аеруча кыен шартларда гына тоясың икән...
Бу араларда ул нигәдер бик ямансылый башлады һәм гел читтәге кешеләр турында, бигрәк тә якташларының төрле язмышлары турында гына уйланды.



## УНБЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Илнең кайсы гына почмагына барма, нинди генә шәһәргә сугылма — син анда татар кешесен очратмый калмыйсың. Күрәсең, гадәте, холкы, язмышы читкә китү белән бәйледер безнең милләтнең. Әүвәләүвәлдән килгән ул читкә китүләр. Өенә ачлык килсә дә чыгып киткән, күршесе белән тынышмаса да, дуслары белән килешмәсә дә, мәхәббәтән уңмаса да... Булган ачудан бай өенә ут төртеп качулар, булган дошманын кыйнап, үч алып китүләр, булган һич сәбәпсез ил гизәргә чыгулар, зимагорлыкта сәфәр кылучылар. Төрле сәбәпләр булган туган ягын ташларга, әмма кешеләрнең зур күпчелеге бәхет эзләп чыгып киткән. Булмаган, тумаган бәхетне эзләп. Авыр булган туган туфрактан аерылулар, әйтеп бетергесез читен булган. Ишек бусагаларына ятыпятып елаганнар кешеләр, киткән чакта офыкта күмелеп баручы авылга карап үзәк өзгеч итеп җырлаганнар:

Без авылны чыккан чакта
Күтәрелде томаннар,
Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар...

Ялланып, Баку промыселларында нефть чыгарган безнең якташлар, Донбасс шахталарында күмер чапкан, Урал тауларында руда актарган, Каспий буйларында балык тоткан. Бер сынык икмәк бәрабәренә, бер кат күлмәк-ыштан, кунып чыгар өчен куыш хакына эшләгәннәр. Күп сорамаган безнең халык, түзгән, сер бирмәгән. Һаман «Бер кайтмасак бер кайтырбыз»,— дип яшәгән кеше, нужа куган, хыялланган, өметләнгән, тик күбесе кайта алмаган, ерак җирләрдә төпләнеп калырга мәҗбүр булган. Үзе шул җирләрдә гүр иясе булса да, аның улы, кызы калган, нәселе калган. Нәселе белән аның йомшак ана теле калган, буыннарга җитәрлек моңы калган.
... Яшьрәк вакытта Кәрамда да бар иде «читкә китү» шаукымы.
Институтның өченче курсыннан башлап практикага җибәрә башладылар. Ул Бакуга барды. Кавказ промыселларында булды, Башкортстан нефть чыганакларында эшләде. Соңгысында автоматика цехы ачтылар һәм аңа, укып бетермәс борын ук, инженер урынын тәкъдим ит-

теләр. «Тулай тороктан ялгыз бер бүлмә бирәбез» дип тә кызыктырдылар. Моңа кадәр институт бетергәннәрнең дә беренче елларда мастер, мастер ярдәмчесе генә, хәтта гади эшче булып йөргәннәрен ишетеп торган студент, кызыкты да куйды бит инженер постына. Калырга ризалык бирде.

Курамшинның практикадан кайтмыйча, эштә калу хәбәре группадагы бөтен иптәшләре арасында таралды, аннан курсташларына, деканатка кадәр барып ишетелде. Барысы өчен дә көтелмәгән хәл, гадәттән тыш вакыйга иде бу. Институт халкы, студентлар гөж килде.

Үзенең бердәнбер өметле укучысын югалткан кафедра мөдире профессор Кабулов класста, такыр башын чәбәкли-чәбәкли:

— Шашкан ул малай! Я, әйтегез, кем инде диплом елында институт ташлый? Тараканныкы кадәр дә аңы юк мәллә? — дип кычкырып йөрде.

Бер ай дигәндә студентыбыз Кәрам, сөмсере коелып, яңадан институтка әйләнеп кайтты. Ни өчендер артык әрләмәделәр, укудан чыгару белән дә куркытмадылар — «соңга калган өчен» дип, ректор приказы белән шелтә генә бирелде. Бары шул.

Кәрамның моңа артык исе китмәде. Ул әле һаман да Уфадагы рәнҗетелү белән килешми иде. «Алдадылар. Сынау срогын акламады дип, куып чыгардылар. Урыныма дипломлы инженер чакырып китерделәр», — дип сүгенеп йөрде. Студентны кичекмәстән институтка кайтаруны таләп итеп җибәрелгән ректор язуы да, профессор Кабулов хаты турында да бер нәрсә белми калды Курамшин.

Шул вакыйгадан соң егетнең институтны ташлап каядыр китү, эштә калу уйлары юып ташлагандай булды.

Моңа тагын бер сәбәп килеп кушылды. Татарстанның Ромашкино мәйданында беренче тапкыр тирәннән нефть бәргән, ярдәм кулын сузып, илнең бөтен нефть районнарыннан, техника белән бергә, төркем-төркем геологлар, бораулау мастерлары, «кара алтын» чыгару осталары, инженер-техник кадрлар, йөзләгән эшчеләр килә башлады.

Ул елларда Татарстанның нефть якларында «читкә китү» дигән кызыктыргыч нәрсә тәмам юкка чыккан иде. Курамшин да:

— Ниемә кирәк чит җир? Читләр хәзер үзе безгә очынып килә ләбаса,— дип йөри иде. Эшли торган җирендә таш булып ятты: «китәм» дип беркайчан да авыз ачмады. Кыска-кыска сроклы командировкаларга, киңәшмәләргә, тәҗрибә уртаклашу өчен төрле очрашуларга барса барды, әмма эшли торган урыныннан кубынып кузгалмады.

Ә аның күнеленә вәсвәсә салып, үз якларына аударырга тырышып караучылар булмады түгел. Болары соңыннанрак — Курамшин тәҗрибәле инженер, танылган кеше, уйлап табучы булып житешкәч.

Алтмышынчы елның көзендә үзенең автоматлары белән Мәскәүдә Бөтенсоюз күргәзмәсендә катнашу хокукын алды Курамшин. Яшь инженер өчен бу зур дәрәҗә иде. Аның стендлары янында кешеләр шактый күп булды. Алар, тукталып, нефть чыгаручының автомат ысулларын сәгатьләр буе карадылар. Бигрәк тә Әзербайҗан нефтьчеләре кызыксынды бу әкәмәтләр белән. Шунда үзе белән бергә укыган иптәшләрен күреп исе китте Кәрамның. Кай арададыр симереп алырга, мыек җиткерергә өлгергәннәр, «солидный» булып киткәннәр. Берсе — Осипьян атлысы, мәсәлән, баш инженер, икенчесе — конструкторлар бюросының өлкән инженеры икән.

Курамшин эшләренә карап хәйран калсалар да, промыселда биләгән урыны, дәрәҗәсен өнәп бетермәделәр:

— Кит, булмаганны! Шул башың белән гади мастер булып йөрисеңме? Ташла, киттек кояшлы Бакуга. Урының — трестның түрендә булыр!

— Бүрегем белән ант итәм, бару белән я өлкән инженер, я конструктор итеп куям!..

Мәскәү тагын берничә сабакташы белән очраштырды. Алары аспирантурада укыйлар икән. Икенче көнне үзләре белән профессор Кабуловны да алып килделәр. Ул, экспонатларны караганнан соң, Курамшинга институтның автоматика һәм телемеханика кафедрасында калырга һәм бер үк вакытта аспирантурада укырга киңәш итте.

— Өйләнгәнме?

— Семьялы.

— Торырга бүлмә табарбыз, соңыннан квартира да булыр, сез бу турыда уйлап карагыз әле, иптәш Курамшин,— дип мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Институтта укыганда фамилияне дә әйтә алмыйча, басымны Курамшинның соңгы иҗегенә төшереп «шин» ясый иде, хәзер хөрмәт итеп, иптәш дип дәшә профессорың.

Тәкъдим кызыктыргыч булса да, Кәрам Мәскәүдә калырга риза булмады. Хатыны Хәтимәне исенә төшерде, тиздән туачак беренче баласын күз алдына китерде. Мондый вакытта булачак ананы борчырга ярамый — балага да, үзенә дә зыян килүе бар. Аннан, кыр кебек зур квартираны ташлап, бер бүлмәгә күчүдән ни хасият?

Бәлки ул вакытта күченергә теләмәү Хәтимәдән дә, баладан да, зур квартирадан да тормагандыр — бригаданы ташлыйсы килмәүдән булгандыр. Гаҗәп кызыклы, мавыктыргыч эшләр кузгатып җибәргән иде бит ул үз бригадасында. Тартышып-даулашып диярлек скважиналарны автомат режимга көйләргә тотынды, шул нигездә операторларны өч сменалы эштән башта ике, аннан бер сменалы эшкә күчерергә исәпләде. Моны бригада кешеләре дәррәү күтәреп алдылар, автоматлаштыруда бирелеп, мавыгып эшли башладылар. Юк, мондый бригаданы, мондый уңган егетләрне калдырып кая да китеп булырлык түгел иде!

Көнбатыш Себердә моңа кадәр күрелмәгән уникаль нефть һәм газ ятмалары табылу татар халкын да янә кузгатып җибәрде. Себер җирләренә эшкә китү бу елларда дәрәҗәгә, горурлыкка әйләнде һәм, әйтергә кирәк, үзенә бер төрле модага кереп китте.

Курамшинны да быел кыш башыннан диярлек Себергә кыстау белән тинтерәттеләр. Яңа ачылачак автоматика цехына начальник итеп тә чакырдылар, өлкән инженер вазифасын да биреп карадылар, тик Кәрам Ризванович сүзендә нык торды: «Миңа монда да эш муеннан. Әлмәт — җәннәт, аны ташлап ике аягымның берсен дә атламыйм...!»

«Себер» сүзе үзе үк Курамшинның котын ала, боз булып табан асларын өшетә иде кебек. Бер дә гаҗәпләнмәгән кеше калмады Әлмәттә Курамшинның шундый зур урыннарны кире кагуына. Ә ул андыйларга җырлап кына күрсәтте:

— Агыйделнең аръягында
Бер энәгә бер сыер!

Аннан житди итеп өстәп тә куйды: «Ә энә — чуваш телендә сыер дигән сүз! Шул үк сыер! Башка баш!» .

Кайберәүләр кебек, артын-алдын карамый, ансат кына эшен ташлап китәргә Кәрамның башына тай типкән мәллә? Аллага шөкер, яше кырыкка җитеп килә, тиздән бишенче дистәне ваклый башлаячак, аны тына аңларлык.

Эшкә яңа килгән кешегә карашның ничек икәнен бүген генә күрмәгән ул. Үзенә дә килделәр андый кешеләр. Гаризадан, кадрлар бүлегеннән, хезмәт кенәгәсеннән үк башлана бит шикле карашлар. Битләп актаралар кенәгәне, юллап-хәрефләп укыйлар язганнарны. «Бу

кеше әүвәлге эшеннән ник чыгып киткән? Нигә безгә күчергәннәр — әллә берәр гаебе булганмы, куганнармы?»

Аннан әлекке урынына шылтыратып сорашалар, хезмәттәшләренннән белешергә тотыналар: гаризаны киткәндә чыннан да үз теләге белән язганмы, янәсе, әллә мәҗбүр иткәннәрме? Эчмиме, тартмыймы, хатын-кыз белән буталмыймы? Булдыксыз яки ялкау түгелме, фәлән дә фәсмәтән.

Яңа кешене эшкә алгач та әле еллар буе сыныйлар, тикшерәләр, аңа һаман килмешәк итеп карыйлар. Ул, бичара, бер гаебе булмаса да куркып йөрүчән була, үз-үзенә ышанычын югалта башлый. Кешеләрне белмәү, аларның холык-фигыльләренә төшенмәү, коллективка няләшә алмау боларны тагын да куертып җибәрә. Кеше бөтенләй югалып калырга мөмкин. Үзенә булган карашларны үзгәртү, үзен таныту өчен генә дә кырык тиреңне чыгарып батырлыкка тиң нәрсә эшләргә кирәк яңа кешегә.

Боларны Курамшин үз башыннан уздырды, үз җилкәсендә таныды — шулай булгач, чит җиргә китүнең, башка эшкә күчүнең һичбер файдасы юк, дип саный иде.

Ә кешеләр алай уйламыйлар. Хәтта Курамшинның үз цехындагы эшчеләр дә уенын-чынын бергә кушып, болай дип сөйләнәләр иде:

— Кәнишне, Кәрам Ризванович автоматларны ташлыйсы килмәүдән түгел, чөнки тимер-томыр ул кайда да җитәрлек,— Кәрам Ризванович хатыны аркасында бармый. Хәтимәсе яшь, чибәр, монда калдырса урлап китәрләр, алып китсә — тегендә берәрсе гашыйк булыр дип шөлли.

Халыкка көләргә-елмаерга сәбәп бар иде төсле. Мәзәктән дә дөреслек эзлә, диләр. Чыннан да, Курамшин, җариясен бикләп асраган хан кебек, Хәтимәне беркая да чыгармыйча тота. Өйләнүен өйләнде кызга, ләкин аны кеше арасына алып чыгарга читенсенде.

Дөрес, өйләнгән елны авылга театр, концерт-мазар килсә, клубка баргаладылар алар. Кәрамга караганда ун яшькә кече, зифа буйлы, сылу кыз иде Хәтимә. Клубта бөтен кешенең күзе боларда гына булды, яшь кияү Кәрамның колагына һәрьяклап чыш-пыш сүзләр, гайбәтләр ишетелеп кенә торды:

— Шул үзе мени инде безнең авыл кияве — Хәтимәнең хәләл җефете? Әбәү, карт икән! Йөзен җыерчык баскан.

— Моның нәрсәсенә кызыкты икән җиләк кебек кыз? Акчасынадыр инде.

— Белеменәдер. Бик башлы диләр аны. Инженер икән.

— Әйтәм чәчләре коела башлаган.

— Мәхәббәтең бакага төшсә, яр буеннан кайтмый ятырсың, ди...

Көлкеле-шырпылы сүзләр дә, ахмак фикерләр дә түгел, Курамшинның иң җене сөймәгәне авыл егетләренең үткәндә-сүткәндә сүз катып китүләре булды. Хәтимә бүген танцыга калабызмы, имеш, курыкма, үзем озатып куярмын, имеш, тагын шундый ахмак тәкъдимнәр. Соңыннан гафу үтенгән булалар үзләре. Янәсе, Хәтимәнең тормышка чыкканын белми дәшкәннәр. Курамшинны Хәтимә янына болай гына утырган абзый дип уйлаганнар.

Хәтимәгә дә күңелле түгел иде мондый тамаша. Ул авылдаш егетләренең төрле почмаклардан күзләре белән «ашауларын» тоя һәм. алардан оялып, залда ут сүнгәнче аска карап утыра иде.

— Китик авылдан,— дип кинәт кенә тәкъдим ясады көннәрдән бер көнне Хәтимә. «Ни өчен?» — дип тә сорамады Курамшин, моңа әллә ни гаҗәпләнмәде дә. «Минем картлыктан читенсенә бугай»,— дип үзенчә нәтиҗә генә ясады.

Үзенең дә Хәтимә өендә торасы килми иде. Әллә ничек, йортка кергән кебек сизә иде ул үзен.

Яшь белгеч буларак, озакламый аңа ике бүлмәле квартира бирделәр һәм ул өч чакрым ераклыктагы шәһәргә күченде. Дөресрәге — урамын гына алыштырды. Чөнки бу вакытта Бигәш авылы да Әлмәт белән кушылган һәм шәһәр дип атала иде инде.

Ашыгып-атлыгып күченүнең тагын бер зур гына сәбәбе бар иде. Ул да булса — Курамшинның җилегенә үткән бер әйле-шәйле егеттән котылу. Чын, көлсәң-көл, еласаң-ела, Хәтимә белән тора башлаганнан бирле шул яшь кенә егет кисәге боларның капка төбенә килә дә төне буе гармун уйнап утыра. Алай гына да түгел, шунда куна, өелгән агачлар өстенә менеп, гармунын баш астына салып йоклый, каһәр.

Моңа башта игътибар итмәскә тырышты Кәрам. Аз мыни авылда эчеп-исереп, гармун күтәреп йөрүче малай-шалай? Аннары алар белән ваксынып, тавышка кереп йөрисе дә килмәде яшь кияүнең. Иләп кирәк. Культуралы, укымышлы кешеләр алай итмиләр, сабыр булалар. Курамшин шактый салкында урамда йоклап яткан егетне төртеп уята иде дә иртән эшкә китеп бара иде.

Ә инде бу хәлләр бер генә түгел, көн саен кабатлана башлагач, түзмәде:

— Нинди егет ул, безнең капка төбендә аунаучы? — дип сорарга мәҗбүр булды Хәтимәдән, үзенең гаҗәпсенүен белдермәскә тырышып.

Хәтимә, әйтерсең, моңа кадәрле капка төбендә гармун тавышын да ишетмәгән, егетнең йоклавы турында да белмәгән.

— Ә син, Шәфрунны әйтә торгансыңдыр әле! — дип көлә.— Шундый әкәмәт малай инде ул. Бергә укыдык. Мәктәптә дә миңа хатлар язып интектерә иде.

— Димәк, яраткан.

— Әй, ул бит әйле-шәйле! Син, Курамшин, аңа игътибар бирмә! Йөрер-йөрер дә туктар! Шөрепләре урынында түгел аның!

Ләкин Хәтимәнең бу юату сүзләре тынычландыра алмады Кәрамны. Бер дә кызык түгел бит капка төбендә, синең хатыныңны юксынып егетләр гармун моңайтып утырса.

Яхшылап та әйтеп карады ул Шәфрун атлы бу егеткә, аны милициягә әйтәм, судка бирәм, дип куркытып, ачуланып та карады, тик егет көн саен капка төбенә килүен белде, гармун иләвен белде, шуны баш астына салып утыннар өстендә йоклавын белде.

Бигәштән күченеп киткәч тә котыла алмадылар ул Шәфрун дигәннәреннән. Ничектер, егет яңа урынны эзләп тапкан, капка төбе юк, утырырга утыннар юк, дип тә тормаган — икенче катның балкон турысына килеп уйный башлады, юньсезең. Ә көе һаман бер: «Каз канаты». Сузып-моңланып та уйный ул аны, марш итеп тә, бию көенә дә! Төн буе кычкырта, йокларга бирми...

Хәтимәнең дә сабырлыгы бетте, ахырда чыгып, әйбәтләп сөйләшеп карарга булды егет белән.

— Нигә дип монда гармун уйныйсың инде, Шәфрун, килешми бит.
— Килешмәсә, тыңлама, колагыңа мамык тык!
— Соң беткән мени сиңа башка урын?
— Миңа монда да яхшы.
— Я, алай итмә инде, Шәфрун, җаным, син бит акыллы кеше.
— Юк, мин — тиле!

Бер көнне таң алдыннан торып, Хәтимә белән Кәрам, икесе ике яктан култыклап, өенә кадәр озаттылар Шәфрунны. Юл буена үгетләп, ялынып-ялварып бардылар: Зинһар, Шәфрун, кеше көлдереп йөрмә болай, диделәр, син бит инде малай-шалай түгел, сакал-мыек чыгарган егет, ташла бу кыланышыңны, дип үтенделәр. Юк, тыңламады.

Кирәкле язуларны әзерләп, бу хулиганга карата кискен чара күрергә җыенып йөргәндә, Курамшинны командировкага җибәрделәр.

Китүен китте, ләкин теге вакыйгаларның юшкыны Курамшинның эченә таш булып утырып калды. Күрер күзгә үзенең бик үк күркәм булмавы һәм яшькә шактый олылыгы янында төскә-биткә чибәр, яңа торган яшь гармунчы егет килеп баскач, арада нинди дер — киң һәм тирән упкын хасыйл була иде сымак.

Хәтимәсе, юкса, ул Шәфрун дигәнен дөньяда бар дип тә белми, искә алса да сәер гадәтләреннән көлеп кенә искә ала. Ә Курамшин ни хикмәттер, һаман шул тинтәкне уйлап, ни нәрсәләргә борчылып йөри. Авылның бер дигән асыл-асыл егетләре дә түгел, күңелендә һаман шул тилемсә Шәфрун гына. Аның күләгәсе баш очында асылынып тора, өрәк булып артыннан ияреп йөри. Шул күләгә Хәтимәне сихерләр дә үз ягына аударыр, гел алып качар төсле. Йоклаганда да һәрвакыт шундыйрак төшләр белән саташты ул — Хәтимәсен җуйды. Канатланып, хатыны ятактан очып китә дә Кәрам аны эзләп йөри. Таба, аннары, тагын югалта...

— Тормас ул миндә, китәр,— дигән уйлар бер генә көн дә күңеленнән чыкмады Курамшинның. Шуңа да, тегенди-мондый хәлләр килеп чыкмагае дип, хатынын тизрәк балага батырырга тырышты бугай.

— Шулай яхшырак,— дип фикер йөртте ул.— Бала булса — хатынкызның кул-аягы бәйләнә, әллә кая сикерә алмый.

Һәм, чыннан да, Курамшиннар семьясы, өч баласы белән Әлмәттә нык булып, какшамаслык булып төпләнеп калды.

*Дәвамы киләсе санда*

# Шамил Маннапов

## Гипноз сеансында уйлану

— Сез бик тыныч, сезгә шундый рәхәт
һәм борчымый сезне берни дә...

Әй, гипнозчы абый, миңа саулык
Теләвеңне аңлыйм инде дә,—
Тынычлана алмыйм тик менә.

Бик шәп булыр иде бар борчулар
Ташлап китсә кире кайтмаска.
Юк шул, киткәннәре урынына
Яңалары килә алмашка.

Ничек борчылмыйсың?— эфир аша
Гайбәт чәчә төрле «Тавыш»лар.
«СССРдан — ракеталар!» диеп,
Компьютерлар бик еш ялгыша.
Кыл өстендә тора язмышлар.

— Сез бик тыныч,— дисең, гипнозчы абый,
Миңа саулык теләү намына.
Бик шәп булыр иде шул сүзләрне
Без әйталсак бар Җир шарына,
Бөтен кыйтга халыкларына...

## Сынчы җавабы

Дөньялыкта нинди булса кеше,
Киләчәккә бара шундый хәлдә:
Мәрмәр кебек саф-пакь күңелләр
Әверелә мәрмәр һәйкәлләргә.

Аяк-кулы богауланган Җәлил,
Яланаяк Зоя баскан карга.
Күпме батырларның йөрәкләре
Ялкын булып яна мәйданнарда.

Җиргә ут китергән Прометейның
һаман авыр, ай-һай, авыр хәле.

Кешеләр өчен гомерен биргәннәргә
Газаплану тиешмени мәңге?!

Коткарырга иде Җәлилләрне богаулардан!
Араларга иде Зояларны салкыннардан!
Чукытмаска иде Прометейны карчыгадан!
Йоларга иде батыр йөрәкләрне ялкыннардан!

Әйтте сынчы: «Шулчак тереләр өчен
Богаулар тагын күбәер иде,
Салкыннар тагын ишәер иде,
Карчыгалар башкаларның бавырын
Чукыр иде... Шуңа дөньялыкта
Ничек булса кеше, мәңгелеккә
Мин аларны шулай калдырдым...»

## Җәйге яңгыр

*Кадир туганым истәлегенә*

Болыт чабуларын җилфердәтеп,
Күкри-күкри җәйге яңгыр узды.
Җәйге яңгыр хәтерләтә миңа
Уңган агрономны-абыемны...

Ул кояшлы җәйге яңгыр иде,
Күкрәүләре, яшеннәре булды.
Коеп яуды, оеп яуды да ул,
Китеп барды... калды шифа-моңы.

Дымга тиенеп калды басу-кырлар,
Аның төсе булып калды Икмәк.
Кояш төсле Икмәк үлемсез ул,—
Аны үстергәннәр Җирдән китмәс!—

Шулай күкри-күкри еракларга
Китеп барды ул рәхмәтле болыт.
Бу җиргә ул кат-кат кайтыр әле
Сагындырган җәйге яңгыр булып...

## Гомер кичкәндә

Бәхәсләшеп вакыт әрәм итмик,
Бәхәсләшеп торыр чак түгел.
Кара дигән тоташ кара булмый,
Ак дигәнең һәрчак ак түгел.
Яхшы яки начар диеп кенә
Бәяләмик адәм баласын.
Яхшысында аның начарлык бар,
Начарында яхшы табыласы.

...Бәхәсләшеп вакыт әрәм итмик,
Кеше гомере кыска болай да.

Идеалистлар, «Дөнья бармы-юкмы?»
Диеп бәхәсләшкән арада,
Реалистлар уйлап-ясап куйган
Дөнья җимерерлек кораллар...

Бәхәсләшеп гомер әрәм итмик,
Җиң сызганып саклыйк бу Җирне,
Үлемсезлек яулыйк — файдаланыйк
Үзебезгә тигән гомерне...

## Бабайлар һәйкәле

Йөргәннәр үзләре
Чабата, чикмәннән —
Оныклар бәхете, дип,
Нәфсене чикләгән.

«Кәрәчин»— яндырган
Җиделе лампада —
Нефтьне, әйтерсең,
Безгә дип саклаган.

Калдырган бабайлар
Урманны — киекле,
Суларны — балыклы,
Ватанны — ирекле...

Ничә кат уянып,
Ничә кат уйланмыйк,
Бабайлар рухына
һәйкәлләр куярлык.

Ул һәйкәл бар инде!
Тик аңа булыйк сак.
Ул һәйкәл — бездән соң
Калачак Табигать,
Сәламәт Табигать.

## Ләис Зөлкарнәев

●

*Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул*

Г Тукай

Бар дөньяның ямен, гамен җыеп
Яна шагыйрь, ут бөрки тәннән.
Шагыйрь өчен шушы дөнья — оҗмах,
Шушы дөнья — утлы җәһәннәм.

Шаулаган да җиргә иңгән, дибез,
Ә кабердә ята тән генә,
Утлы җан ул дөрләп күккә аша,
Йолдыз була — яна мәңгегә.

Ә күкләрдә инде күпме йолдыз!
Кайсы газиз, безгә кадерле?
Дәшми әйләнәләр, үзәктә күк
Казык Йолдыз — Тукай бәгыре.

Бик биеккә менеп янсалар да,
Төшенәләр җирнең гаменә.
Йолдыз атылганда килдек җиргә,
Җаннар шул ук, бүтән — тән генә.

Баштан ашсын ләззәт, утлы газап,
Янсын бәгырь, көл калсын тәннән.
Безнең өчен шушы дөнья — оҗмах,
Шушы дөнья — утлы җәһәннәм!

## Харрас Әюпов

### Тукай клубы

Шыгрым тулы, күр, Тукай клубы...
Моңнан кузгалган олы бер йөрәк —
Тибә тыйгысыз бер тибү белән,
Чишмә төпләре тулган мөлдерәп.

Туган халкым бит сыйган бу залга,
Тарсынмый-нитми сыйган бер дәвер,
Ерак-еректан калка аһәңнәр —
Кайсы җаннарны эзләп киләдер?

Кемдер бар монда ерак даладан,
Болгар иленнән кемдер бар монда;
Калкынып куя сыман Алыплар,
Шигъри сүз чатнап очкан чагында.

Арча Кырында ничек калалсын?—
Һәр җомга саен шушында Такташ,
Ник гөрләмәсен бу шигъри табын,
Алман иленнән Җәлилләр кайткач!

Туган халкым бит бүген бу залда —
Агыла моңнар, белми туктауны,
Тын калган Казан: ишетә бугай —
Йөрәге тибә... тибә... Тукайның!..

## Фәнис Яруллин

# ФАҖИГА

хикәя



Беренче тапкыр алар кибеттә очраштылар. Әзһәр, кичә генә армиядән кайткан егет: өс-баш ыспай, буй-сын төз, Анджела Девисныкы шикелле куе бөдрә чәч. Шаян сүзләр телдән үзеннән-үзе ургылып чыгарга тора. Күзләр дә чибәр кызларны тансыклаган. Атланган айгыры — утыз ат көчле мотоцикл.

— Ай-һай ерак яшергәннәр сезне,— дип килеп керде ул район үзәгенең аулак почмагында посып утырган эчемлекләр кибетенә.— Гадәттә, әкиятләрдә генә шулай сезнең кебек чибәр кызларны дию пәриләре урлап, үзләренең җиде кат сарайларына яшереп, җиде йозак астында тота торган булганнар. Әллә сез әкияттән килеп төшкән пәри кызымы?

— Телеңә күп салынасың, егет— диде сатучы кыз. Ләкин үзе канәгатьсезлек белдермәде, киресенчә, алтын тешләрен елтыратып елмаеп куйды.

— Ике ел буена кызлар чырае күрми интектем,— дип гөрләде Әзһәр кибетнең түшәмен күтәрердәй итеп.

— Тел тегермәнең шәп тарта, анда да тик ятмагансыңдыр.

— Ю-ук,— диде Әзһәр, йөзенә гөнаһсыз бер кыяфәт чыгарып,— телем сезне күргәч кенә ачылып китте. Моңа кадәр, каршыма кызлар килә башласа, урамның икенче ягыннан үтә торган идем. И-и, оялчанлыгым аркасында үзем белән таныштырмый торам икән: отставкадагы ефрейтор Әзһәр Гимаев. Әгәр сер булмаса, әкият кызының исемен беләсе иде.

— Син кибеткә минем исемне сорарга кердеңме, әллә йомышың бармы?

— Башта исәбем кибетегездәге бар байлыкны мотоцикл бишегенә төяп китү иде, тик менә сезне күргәч, бердәнбер кайгым — сезнең исемне белү.

— Исемемне әйтсәм, адресымны сорарсың...

— Әүлия икәнсез...

— Моның өчен әүлиялек кирәкми. Бөтенегез бер чыбыктан сөрелгән.

— Егетләрне күп күргәнсездер, ахры?

— Туры килгәләде.

— Ниндирәкләрне?

— Синнән шәбрәкләрне.

— Менә монысы чип-чи ялган инде. Миннән шәбрәге юктыр, мөгаен. Әле армиядә дә, генерал булырга синең барлык данныйларың бар, диделәр: гәүдәң килгән, кәтилүгең дә эшли, монда кал, диләр. Юк, мәйтәм, маршал чиныгыз дә кирәкми, мине анда әкият кызы көтә, дим.

Әзһәр кызның исемен белүгә иреште. Сатучы кызның исеме Тәлига икән.

Тәлига, караңгы тыкрыктагы подвал кибеттә утырып, сөйләшергә сусаган булганмы, әллә Әзһәрнең шаянлыгы йоктымы — ачылып китте.

— Бу кадәр эчемлек белән нишлисен? — диде ул, Әзһәрнен эрҗәләп аракы алырга ниятен белгәч.— Әллә өйләнәсеңме?

Әзһәр сатучы кызның озын керфекләренә, кабарып торган чәчләренә яратып карады.

— Тәлига, әйдә бүген безгә! Дус-ишләр җыелышып, кечкенә генә мәҗлес ясамакчы идек. Армия тикле армиядән урап кайтуны билгеләп үтәргә кирәк бит инде.

— Авылдагы кызларың көнләшер.

— Юк, Тәлига, кызым юк минем.

Тәлига тыела алмыйча көләргә тотынды. Көлгән чакта аның битләренә, колакларына ут капты. Таң пәрдәсен аралап чыгып килүче кояш урман аланындагы ялгыз каенны ничек ялкынга ураса, Тәлиганың йөзенә дә көлү шундый матурлык бирде.

— Менә әйттем бит,— диде ул,— башта исемемне сорадың, аннары очрашырга чакырдың. Шуның белән бетәсе көн кебек ачык иде.

Әзһәрнең күңелендә андый уй юк иде. Әллә ничек, үзеннән-үзе килеп чыкты.

Күзгә күренми торган җепләр кыз белән егет күңелен тоташтырып өлгергән иде инде, әдәп өчен генә бераз ялындырганнан соң, Тәлига Әзһәрнең чакыруын кабул итте.

— Кара аны, егет,— диде ул, җитди күренергә тырышып,— кичен мине алырга килгәндә саграк кылан. Район егетләре бик усаллар. Кабыргаңны санап җибәрмәсеннәр.

— Авыл егетләре дә төшеп калганнардан түгел. Сынатмабыз.

Әзһәр авылга очып диярлек кайтты. Ул кайтуга, әнисе көтүдән алып калган сарыкны күрше карттан суйдырган, чабылган итләрне кар базына төшерергә генә өлгермәгән иде. Әзһәр йөгерә-йөгерә әнисенә булышты. Эш арасында әнисенә: «Мәҗлестә бер кунак кызы булачак»,— диде.

— Бик әйбәт,— диде әнисе. Соңыннан гына улының сүзләре аңына барып җитте.— Ничек? — дип сорады ул.— Кызларны, егетләрне күп җыям диген иден бит.

— Мин авылныкылар турында әйтмим. Бусы — районныкы.

— Ярый, ярый, улым, урын җитәрлек, тәртипле генә утырыгыз.

Әзһәр кичкә таба Ык буена төшеп мотоциклны юып менде. Бишек утыргычына өйдәге кресло өстендәге йомшак келәмне чыгарып җәйде. Соңыннан үз эшенә сокланып:

— Кара әле, әнкәй, тот та килен төшер, ә? — диде.

Ана сүзсез генә көрсенеп куйды. Улының мотоцикл тавышы ерагайгач, өсте ябылган озын өстәл артына утырып уйга бирелде.

Әзһәр атасыз үсте. Әтиләре ташлап чыгып киткәндә аңа нибары ике яшь иде. Шөкер, боек үсмәде. Яшьтәшләре арасында кимсенерлек булмады. Унҗиде яше тулган көнне әнисе аңа мотоцикл алып бирде. Әй сөенде Әзһәр бу бүләккә. «Мотоцикл акчасын барыбер сиңа кайтарам әле, әнкәй»,— дип тракторга утырды. Армиягә киткәнче бер ел буена умыртып колхозда эшләде. Алган акчасының тиенен дә кадәр әнкәсенә бирә барды. Эчү-тартуга хирыслеге сизелмәде. Армиягә үзен зурлап озаттылар. Колхоз председателе очраган саен, малаең әйбәт эшләп

китте, ялкау түгел, техникага маһирлыгы бар, армиядән кайткач, трак торның иң шәбенә утыртачакбыз аны,— дип Сәмига түтине сөендереп китә иде.

Тегене-моны караштыргалаганчы, Әзһәр кызны утыртып кайтып та житте, Тәлиганың үзен күргәч, ана бөтенләй тынычланды. Чибәр бала икән. Ярыйсы ук кыю да, ахры. Гомерендә беренче күргән кеше дип тормады, булышырга кирәкмиме дип, бөтерелеп йөри башлады.

— Кыюлык — ярты бәхет. Кыю бул, балам,— дип, Сәмига түти кызның аркасыннан сөеп алды.

Мәжлеснең игътибар үзәгендә гел Тәлига белән Әзһәр булды. Телләренә шайтан төкергән яшьләр, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, Әзһәр белән кунак кызына карата шаян сүзләр яудырдылар. Мәжлес кызды. Рюмкалар чыңлавына яшьләрнең көлү авазлары кушылды. Шунда арадан берсе, мәжлеснең икенче ягына ишарәләп, кулындагы эчемлеген эчмичә: «Нигәдер ачы булып китте әле бу, әллә кунак кызы белән Әзһәрдән баллandыртып алабызмы?» — дип әйтеп салды. Кунак кызы ни әйтер дип, һәммәсе Тәлигага таба борылды. Тәлига теге егеткә карап: «Төчесен әниеңнән сорарсың, без ачысыннан да курыкмыйбыз»,— дип, үз рюмкасындагы шәрабын соңгы тамчысына кадәр эчеп куйды. Яшьләр бердәм тынып калдылар. Телләрдән очып чыгарга талпынган канатлы сүзләр, карга күргән чебешләр шикелле, кире постылар. Шунда гына кунак кызының ярыйсы ук исереп өлгергәнлеген абайладылар. Кызны кыен хәлдә калдырмас өчен, Әзһәр, мәжлестәге бер буталыштан файдаланып, Тәлиганы ишегалдына алып чыгып китте.

— Әйдә, су буена төшәбез.

— Кирәкми, мин судан куркам,— диде кыз назланып.— Я су анасы тотып алыр.— Һәм шаркылдап көлеп жибәрде.

— Абзаң барында беркемнән курыкма,— диде Әзһәр дә шаянланып.— сине су анасына түгел, жиде башлы дию пәрие килсә дә бирү юк. Син бит минем әкият кызым.— Әзһәр Тәлиганы кочагына кысты.

— Әйдә берәр жиргә качабыз. Монда йолдызлар карап тора. Оялам.

Егет көчле куллары белән кызны күтәреп алды. Кинәт йолдызлар чайкалып китте һәм дөнья бер мизгелгә ләззәтле, саташулы, исерткеч йокыга чумды...

Шушы кичтән соң Әзһәрне алыштырып куйдылармыни? Канатланды, аяк астындагы жирне күрми башлады. Әнкәсенә карата игътибары кимеде. Сәмига түти: «Баланың үсеп житүе шушыдыр инде,— дип көрсенде.— Хәерле булсын, үстердем, тол килеш аякка бастырдым. Гомер йомгагының калган өлешен үзенчә сүтсен. Бәлки бәхете шулдыр. Өйләнәм дисә, каршы килеп булмас».

Әзһәр үзенең корыч айгырына атланып һәркөн районга чаба. Кайвакыт шактый кызмача кайтып керә. «Тәлига бүген премия алган, шуны юдык әле»,— дип аклана ул әнисенең шелтәле карашы белән очрашкан чакларда. Ананың күңеле сизенә: бернинди премия юк, көн саен нинди премия ди? Әзһәрне Тәлига сыйлый.

Улының бу мавыгулары нәрсә белән бетәр? Ана шул хакта борчылды. Армиядән кайтуына өр-яңа тракторга утырттылар. Председательгә рәхмәт, сүзендә торды. Жир жимерттереп эшлисе дә авыл кызлары белән генә йөрисе, югыйсә. Бу Тәлига каян килеп чыкты? Әнә, Гөлсинә урам аркылы гына. Әзһәр урамнан үтсә, тәрәзәдән күзен алмый. Үзе шундый ярдәмчел. Көтүең генә соңга калса да: «Әллә авырдыңмы, Сәмига апа?» — дип кереп житә. Жиләк кебек шул балага карамыйча, тот та районга чап, имеш. Дөрес, Тәлига да ямьсез түгел. Буй-сыны бар. Кыю, тик әнә шул эчкәләве генә... Кыз бала турында болай дип әйтүе дә оят бит. Ничә тапкыр Әзһәргә ияреп кайтты, һәр кайтуында сумкасында аракы. Келәттә төне буе кәеф-сафа корып утыралар.

Улының эчке дөньясына тыкшынмаска сүз беркетсә дә ана түзмәде, болай диде: «Улым, сезнең эшләрегез уеннан узып бара түгелме?»

— Юк өчен борчыласың, әни.— Әзһәр сүзнең житди булачагын сизенә иде. Туры жавабтан качар өчен хәлне катлауландырмыйча, гадәти бер нәрсә итеп күрсәтергә теләде.— Тәлига бала түгел, нишләгәнен беләдер. Мин егет кеше...

— Кыз баланың язмышы егетләр кулында. Тәлиганың әле жил кая иссә, шул якка авыша торган чагы. Вакыт узганчы уңай якка бөгәргә кирәк. Син бит көчле кеше.

— Нишләргә кушасың соң, әни?

— Я бүгеннән болай йөрүеңне туктат, я өйлән. Бәлки Тәлига, синең икеле-микеле йөрүләреңә пошынып, хәсрәтен хәмер белән күммәкчедер. Авылдашлар алдында оят.

Әйе, Әзһәр үзе дә бу хакта уйланмый түгел. Ул инде Тәлига янына бөтән бармаска булып үзен тыеп карады, ихтыяры житмәде. Тәлиганың тормышны катлауландырмыйча, гади итеп яшәргә теләве ошый Әзһәргә. Чыннан да, Тәлига һич нәрсә өчен ах итми. Ул үзенең иң кадерле байлыгын ике дә уйламыйча егет кулына сала. Тели икән, шундый ук жиңеллек белән ике араны өзә дә ала. Әзһәрнең уйлавынча, мондый кеше белән тормыш итү жиңел булыр кебек. Ул синең кулыңнан килмәстәйне таләп итми. Аның янында Әзһәр үзен көчле, гайрәтле сизә. Тәлиганы эчүдән туктатырга теләсә — бер сөлтәнүдә туктата алыр төсле тоела.

Моңа тикле Әзһәрнең кызлар белән мавыкканы юк иде. Тәлига белән уздырган төннәр аның йөрәгендә йоклап яткан көч чишмәсен уятып жибәрде. Шушы чишмә хәзер аның тамырларында ага, каядыр ашкындыра, ымсындыра, тагын-тагын үзенә чакыра. Бәлки мәхәббәт чишмәсе шушылай ачыладыр? Аны авыз иттергән кешен дөньядагы иң якын, иң кадерле кешең буладыр?

Әзһәрнең күңелендә сораулар арта бара. Аларның жавабын Тәлига гына беләдер төсле. Әйе, аның белән кистереп сөйләшергә кирәк.

Егет, шундый нияте белән мотоциклын ияртеп, районга чапты. Ул килеп житкәндә, кибет ябылса да, Тәлига кайтып китмәгән иде әле. Әзһәрне кыз шатланып каршы алды.

— Бик вакытлы килдең. Ревизия булды.— Тәлига урта яшьләрдәге бер абзыйга күрсәтте.— Таныш бул, ревизор Сәлмән абзый.

Сәлмән абзый чыра кебек ябык гәүдәле кеше. Терсәкләре белән биленнән кысып әледән-әле чалбарын күтәргәндәй итә. Әзһәр аңа теләр-теләмәс кенә кул бирде. Турысын гына әйткәндә, Тәлига тирәсендә кайнашкан ир-атларны өнәми иде ул.

— Шушымыни инде безнең булачак кияү? — диде ревизор, Әзһәрне баштан-аяк күздән кичереп.— Шәп, шәп! — Һәм ул нәрсәгәдер бармак янап куйды.— Кара аны!

Ир-атлар берничә сүз алышканчы Тәлига әржәләр өстенә газета жәеп табын әзерләде: колбасасын турап куйды, кыйбатлы консервалар ачты. Ә иң уртада биш йолдызлы коньяк утыра иде. Табын әзер булуга Тәлига кыстый башлады. Сәлмән мондый сыйлауларга күнеккән иде инде, шулай тиешле дигән кебек килеп утырды. Тамырлары зәңгәрләнеп, бүртенеп торган кулларын угалап, коньяк шешәсенә тотынды. Әзһәрнең кәефе начар иде, ул Сәлмәннең икенче яккарак борылуыннан файдаланып: «Синең белән сөйләшәсе бар иде, Тәлига»,— диде.

— Олы кеше алдында болай пышылдау килешми,— диде Сәлмән.— Мине уважать итсәгез, давайте, күңелемне күрегез. Минем белән кайсыгыз чәкештереп эчәргә тели, ә?

Әзһәр Сәлмәннең туктаусыз лыкылдавыннан котылыр өчен генә сыйны кабул итте. Ул чын күңелдән Тәлиганы жәлләде. Әзме очраша

ул шушындый сагыз кебек кешеләр белән? Һәммәсен «уважать» итәргә кирәк. Кемнең айнык килеш исерек сүзен жөпләп утырасы килсен? Эч мәс жиреннән әчәрсең...

Тәлиганың икенче шешәне китереп утыртуын күргәч, Сәлмән абзый: «Их ма! Егет тә кеше син, Тәлига!» — дип кызның аркасыннан какты. Ә бераз исерә төшкәч, сизмәгәнгә салышып Тәлиганың ачык тезенә кулын салды. Аның бу кыланышларына ачуы чыккан Әзһәр үзен чак тыеп утырды.

Ярыйсы ук мәлҗерәп төшкән Сәлмәнне алар, икесе ике яктан култыклап, өенә озаттылар. Шуннан соң гына Әзһәр җиңел сулыш алды.

— Синең бу эшең ошамый миңа — диде ул Тәлигага.— Җыен исерек арасында. Аларның бөтенесен «уважать» итсәң, үзеңне уважать итми башларлар.

— Сүзеңнең башы миңа акыл өйрәтүдән башлангач, ахырында нәрсә сайрарсың икән?

— Менә нәрсә... чык миңа кияүгә! Бу эшеңне ташларсың. Колхозда бухгалтер кирәк. Чут эшен әйбәт беләсең.

— Мин әлегә үз эшемнән канәгать. Иргә чыгарга җыенмыйм.

— Соң болай ярамый бит инде, Тәлига. Кача-поса дигәндәй йөргәнче, ачыктан-ачык торыйк.

— Ә мин беркемнән дә курыкмыйм. Әниеңнән шүрлисең икән, пожалысты, минем янга килеп йөрмә.

— Алай түгел, Тәлига. Барыбер ялгызың гомер итеп бетерә алмассың.

— Ни өчен мин кияүгә чыгарга тиеш? Синең тракторда майланып каткан киемнәреңне юып, кайтуыңа аш пешереп торыр өченме?

— Тормыш коруга алай гына карарга ярамый инде.

— Бик акыллы булсаң аңлат: кешеләр ни өчен өйләнешәләр?

— Минемчә, һәркемнең җирдә үз дәвамын калдырасы килә.

— Минем калдырасым килми,— диде кыз, әллә чынлап, әллә егетне үртәр өчен.— Мин үзем генә яшәргә телим. Мин бүгенге көн кешесе. Гомерлек бәхет барыбер юк ул.

Әзһәр Тәлиганың сүзләрен исе китеп тыңлады. Дөресен әйткәндә, «нәрсә ул бәхет?» дигән сорауга үзенең дә җавап таба алганы юк. Башта мәктәптә укыды, аннан армия. Анда бәхет дигән фән укытмыйлар. Үзе ятим үскәнгәме, бәхет төшенчәсен ул бары тик атаң-анаң тигез булуда дип исәпли иде. Этиләре үз малайларын янныарына утыртып йөргәндә яки бер-берсенә су чәчрәтә-чәчрәтә елгада коенганда Әзһәр аларга көнләшеп карый иде.

— Гомерлек бәхет бармы-юкмы, анысын белмим, синең бер көнлек бәхетең белән килешәсем килми,— диде ул, мөнәсәбәтләре шактый тирәнгә кергәнлеккә ишарә ясарга тырышып.

— Ихтыярың. Карашларымны көчләп такмыйм, без берни белән дә бәйләнмәгән.

— Бәйләнгән! Шуннан артык ничек бәйләнергә мөмкин тагын?

— Мин сине современныйрак егет дип уйлаган идем.— Тәлига өйләренә кереп китте.

Шушы сөйләшүдән соң Әзһәр кызны бөтенләй күңеленнән сызып ташларга теләде, янына бармады. Кинәт исенә төшеп йөрәгенә кайнарлык йөгерсә, ярсуын басар өчен эшнең авырына тотынды. Тик никадәр онытырга теләсә дә, оныта алмады. Тәлига Әзһәр күңелендә бер җәрәхәткә әйләнде. Әзһәр ул җәрәхәтне күмәр өчен башка кызлар янына да баргалап карады. Ләкин Тәлиганы оныта алмады. Җитмәсә, районга барган һәр кеше Тәлига турында берәр хәбәр алып кайта. Кайберәүләре әллә юри, әллә чын: «Ай-һай җилле кызны кулдан ычкындыргансың, кыз гына түгел, дөрләп торган учак ул»,— диделәр. Икенчеләре

«Шундый хатының булса, дөньяң җәннәткә әйләнер иде малай»,— дип Әзһәрнең җанын газапладылар.

Әзһәр кыз турындагы житез аяклы гайбәт сүзләре барып җитмәслек берәр җиргә китеп олагу хакында уйлап йөри башлады. Теләген әнисенә дә чишкән иде, әмма ана кеше:

— Кайда егылсаң, шунда торырга кирәк, улым,— дип Әзһәрнең бу уен хупламады.

— Кушылып әйбәт кенә торып китсәгез, бәлки эчү белән шаяруларын ташлар иде. Алай бозыклыкка чыккан балага охшамый үзе,— дип сөйләнде ана Әзһәрдән бигрәк үзен тынычландыру өчен. Күңеле белән ул Тәлиганы якын итеп бетерми, әмма улының газаплары аның җанын талый иде. Ә улы: «Ул миңа отказ бирде, кияүгә чыгарга җыенмыйм, теләмим, диде»,— дип әйткәч, улын читкә тибәрүе ананы бик рәнҗетте. «Ай-һай горур нәрсә икән. Гүәрдин кебек егетне борып җибәр, имеш. Типсә тимер өзәрдәй егет тә ярамагач...»

Горурлыклары тапталган ана белән ул нинди чара күрергә белми йөргәндә Тәлигадан: «Әзһәр минем янга килеп китсен әле»,— дигән хәбәр алынды.

— Нишлибез? — дип каршылады егетне Тәлига.— Бала булырга тора.

— Соң, бик әйбәт,— диде Әзһәр сөенеп.— Бүгеннән өйләнешәбез и бетте-китте. Нәрсәгә баш ватарга.

— Врачларга барган идем, соң инде диделәр.

— Нинди врач? Син нәрсә сөйлисең? — дип җилтерәтергә тотынды аны Әзһәр.— Мин сиңа өйләнешик дип кайчаннан бирле әйтә киләм.

— Теләсәң-теләмәсәң дә шуңа кайтып кала инде,— дип көрсенде кыз.— Тик алдан ук кисәтеп куям: эшемнән күчмим. Анда сезнең председателегез кубызына бисем юк.

Туйлар узып, кызларын калдырып киткәндә, Тәлиганың әнисе болай диде: «Без кызыбызны мохтаҗлыкта үстермәдек. Ни сораса шуны алдык. Мәхәббәт дигән нәрсәдә дә без кызыбызны үз иркенә куйдык. Хәзер заманы шул, бөтен нәрсәгә үз ирке...»

Хатынның сүзен ире бүлдерде:

— Ә шулай да, әнкәсе, кызның бер теләгенә каршы килдек бит.

— Нәрсәне әйтәсең?

— Институтны әйтәм.

— Ә-ә. Әйе шул. Үзегез уйлап карагыз: институтта селкенеп йөреп, нигә биш ел гомерне суга салырга? Кыз бала өчен биш ел гомер — дөнья бәясе. Хәзер кешенең белеменә түгел, кулында нәрсә барына карыйлар. Без үзебез прастуй кешеләр, әмма кулыбызда мал житәрлек. Дипломлы бырачларын, прафисырларын әйбер кирәк саен, бүреген салып, безнең каршыга килә. Кызыбызны да шуның өчен кибеткә керттек. Кибете эт оясы чаклы гына булса да, кешеләр алдында дәрәҗәсе зур. Кызыбыз практичный. Югала торганнардан түгел. Яшь белә...

— Анысы шулайдыр да,— диде Сәмига түти.— Тик менә Тәлиганың бер ягы... — Ул сүзен әйтергә уңайсызланып калды.— Кызыгыз ни...

Сәмиганың ни турында тел тибрәтергә ниятләвен кодагые тиз аңлады. Ул, бик гадәти нәрсә әйткән шикелле, кул гына селтәде: — Һи, кодагый, хәзер заманасы шуның белән бара. Сер итеп кенә әйткәндә, мин үзем дә ул яктан бик изге түгелмен. Әз-мәз капкаламасаң, бу дөньяның мәшәкатьләреннән ничек арынмак кирәк? Эчә белеп эчкәндә, файдалы гына ул, кодагый. Тәлига өчен борчылма. Бераз шаярыр да ташлар. Бер дә ис китәрлек нәрсә юк монда, зарплатасын эчми бит ул...

Туйдан соң Тәлига бераз вакыт тәртипле йөрде. Ял көннәрендә кайнанасына булышты. Хәтта сыер саварга алынып карады, тик сауган сөтен берничә мәртәбә чиләге-ние белән сыеры тибеп очыргач бу эшкә кул селтәде. Ул гел шулай: яңа эшкә дәртләнеп тотына, ләкин беренче

каршылыкка очрау белән дәрте сүнә. Әгәр эше һичнинди каршылыксыз барса, тирә-юньдәгеләр аны адым саен мактасалар, мавыгуы озаккарак сузыла. Икенче берәр кызыклы нәрсә килеп чыкканчы...

Ә сатучы һөнәрен, киресенчә, ул башта яратмады. Көн саен бер эш. Кибете нинди тагын — аракы кибете бит. Тәлига берничә мәртәбә: «Бүтән аяк басасым юк»,— дип тә кайткалады. Андый чакларда энисе кызын йомшак кына сыйпап юмаларга тотына иде. «Өйрәнерсең, кызым, өйрәнерсең. Яман сүз әйтүчеләргә син үзләреннән дә яманрак сүз белән җавап кайтар. Шул чагында ыржаюдан туктарлар. Әшәке сүз аракы белән бер ул: беренче ишеткәндә генә куркыныч тоела».

Әзһәрләргә килеп өч ай торуга, Тәлига декрет ялына чыкты. Кайнанасы көне буе фермада, Әзһәр тракторда. Ялгыз яшәргә өйрәнмәгән Тәлигага өйдә күңелсез иде. Әниләренә барды — анда ямь тапмады, урамга чыкты — анда да якын итеп сөйләшер кеше очратмады. Кул эше белми иде. Йорт-бакча эшләренә чирканып карады. Уч тутырып декрет акчасы алып кайткач кына кәефе шәбәйде. Килененең болай ачылуын күргәч, кайнана, ходага шөкер, безгә ияләшә, безне тиң итә башлады, дип сөенде. Ләкин аның сөенечләре күпкә бармады. Беркөнне, кирәге чыгып, келәт сайгагын ачып караса, сайгак астында, анасын имәргә җыелган чучка балаларыдай, ап-ак шешәләр тезелешеп ятканын күрде.

— Килен, бу эшең һич килешә торган нәрсә түгел. Үзең авырлы...

Тәлига аңа сүзен төгәлләргә ирек бирмәде:

— Нәрсә килешә соң? Тыйнаклыкмы? Аның модасы чыкты инде.

Сәмига түти әйтәсе килгән сүзләрен эчкә йотты. Тыйнаклыкның модасы чыкты диген, ә? Тыйнаклык, инсафлык, әдәплелек гомер-гомергә кешенең иң матур юлдашы булган, җанын яктырткан. Адәмнең шушы сыйфатлары бетсә, нинди кешелеге кала соң? Тәлига ялгыша. Әллә аны кайчан да булса гөнаһсызга рәнҗеттеләр микән. Шуны кичерә алмый газапланамы? Мөмкин чаклы игътибарлырак булырга кирәк. Шундый чагы. Күңеле эресен.

Ана, үзенчә бер нәтиҗәгә килеп, бөтен авырлыкны үз өстенә алырга тырышты. Эштән арып кайттым дип тормады, суына йөгерде, аш-суны әзерләде. Кайвакыт Тәлиганың вөҗданы уяныпмы, эче пошканнанмы, казан астына ягарга утын-йомыкча ише нәрсәләр алып кергәнен күрсә: «Авыр күтәреп өзлекмә тагын. Мондый чакта сакланыбрак йөрергә кирәк»,— дип кисәтә иде.

Тәлиганың малай табуы һәркайсы өчен зур шатлык булды. Барыннан да бигрәк Әзһәр сөенде.

Ана шатлыгыннан булса кирәк, Тәлига да йомшарып киткән кебек иде. Кайнанасына беренче мәртәбә әни дип дәште. Аракы белән шаярулары да кайнанага сизелмәде. Сәмига түтинең түбәсе күккә тиде.

Бөтенесе шулай эзгә төште дигәндә, һәммәсенә шатлык татулык алып килгән сабыйда нindидер үзгәрешләр сизелә башлады. Тәлига бу хәлгә борчылып, малаен район врачына күрсәтте.

— Аракы галәмәте,— диде врач соңгы сүз итеп.— Акылы зәгыйфь.

Шушы көннән тормышларында зур фаҗига башланды. Тәлига элеккедән битәр эчүгә сабышты. Аны кайнанасының үгетләве дә, Әзһәрнең мәхәббәте дә тыя алмады. Бу фаҗигадән чыгу юлын күрми иде ул.

Әзһәр иртәдән алып кичкә кадәр эштә. Шунлыктан өйдәге хәлләрне белеп бетерми. Ә өйдә, яр буендагы өянкенең тамырларын әкренләп дулкын юган кебек, гаилә агачы агымсуга таба авыша иде. Тәлига күпвакыт кунарга да кайтмый. Аның кайда йөргәнлеген белүче юк. Әзһәр энисеннән: «Тәлига кая?» дип сораса, һаман яхшыга өметләнгән ана:— Әниләренә киткән иде, шуларда кунып калгандыр,— дип эшне тирәнгә җибәрмәскә тырыша. Бала карауны ул бөтенләе белән үз өстенә алды. Фермага эшкә киткән чакларда бала ут-күз белән уйнамасын дип,

шырпыларын әллә кайларга яшерә дә, кайткач, шуны таба алмый интегә. Ә бала үсә. Үскән саен «һөнәрләре» арта. Я бүреккә салып куйган тавык чебешләренең муеннарын борып, казанга тутыра, я мичтәге көлләрне таратып ташлый, я тәрәзә төбендәге гөлләрне йолкып ата.

— Килен,— диде Сәмига түти беркөнне сабырын җуеп,— болай тууына бала гаепле түгел. Бераз игътибарлырак бул. Балага ана назы кирәк.

— Кирәк булса, назла,— диде Тәлига.— Мина сезнең юләрегез кирәкми. Вообщем, бәйләнмәгез миңа. Берегез семья, саф мәхәббәт дип тилереп йөри, икенчегезгә тыйнаклык кирәк. Фанатиклар. Тапканнар мәхәббәт, тапканнар инсафлык. Инде исәп, балагызны да минем җилкәгә атландырмакчы буласызмы? Үзегез карагыз...

Бу сөйләшү вакытында Әзһәр дә кайтып керде. Тәлиганың сүзләренә аңа искәрмәстән кусәк белән тондыргандай итте.

— Бар, чыгып кит моннан! — диде ул ярсып.— Карарбыз.

Тәлига китте. Шул китүдән йортка эзен бөтенләй суытты.

Әзһәр башта җиңел генә «карарбыз» дисә дә, тора бара улыннан туя башлады. Малайның һәр кыланышы аны ярсытты. Ул үзен бәхетсез, мескен итеп сизде. Бигрәк тә күңеленә тигән нәрсә — улына ярдәм итә алмау иде. Күңеленнән һаман Тәлига чыкмады. Әмма ул аның тупаслыгын, вөҗдансызлыгын кичерә алмады. Аерылышып берничә ай үткәч, бәлки онытырмын дип, икенче кызга өйләнде. Алай да җанына тынгылык таба алмагач, яшь хатын белән читкә чыгып китте.

Өйдә, бу фаҗигането бөтен авырлыгын күтәреп, зәгыйфь бала белән Сәмига түти калды.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Удмурт мәкальләре һәм әйтемнәре

*Кыйнаштан соң кыю күп була.*
*Сарык булсаң, бүре табыла.*
*Чәберчек дигән нәни кош койрык белән боз вата.*
*Бер тәкәне ике суймыйлар.*
*Каурыен башта йолкалар, ә аннары — мамыгын.*
*Стенага борчак ябышмый.*
*Олы юлда үлән үсми.*
*Зур елга тыныч ага, аңлы кеше акырмый.*
*Сул кул уңны алыштыралмый.*
*Койрыгыннан кем тотса — сыеры да шуныкы.*
*Агачның да һәркайсы туп-туры булып үсми.*
*Казаныңда ашың булса, чүмеч табылмый калмас.*
*Төчегә әче дә кирәк.*
*Ипи катысыз булмый.*
*Күпме генә юынсаң да, судан чиста булмассың.*
*Сөзгәк сыер мүкләк булып туа.*
*Тегермәннән бөртек кире кайтмый.*
*Таң атмаса — кич килми.*
*Тилгән күзен тилгән чукымас.*
*Таныш юл кыска була.*
*Җансыз җырны йөрәк кабул итми.*
*Төнге юл такыр була.*
*Елның ике җәе булмый.*
*Агач үзәктән чери.*
*Сибелми торган борчак юк.*
*Балтасы күптән югалган, сабы бүген табылды.*
*Бәйләгәнеңне чишә бел.*

## Рим Идиятуллин

### Бүген минем туган көнем

Белсен бәйрәм икәнен:
Атсын таңы, иртәрәк;
Ниләр генә теләсәм дә
Кабул булсын бар теләк.

Якыннар бер-беренең
Саулыгын белешсеннәр,
Таныш түгел кешеләр
Елмаеп көлешсеннәр.

Тормышлар булсын имин,—
Туган көн бүген минем.

Телетайп, телефоннар
Җиткерсен якты хәбәр:
Тәхетләр, төрмә-зинданнар
Килде диеп зил-зәбәр.

Сызгырмасын пуляләр,
Гөрселдәмәсен пушка;
«Азат дөнья»сын мактап,
Шапыртмасыннар бушны
Илнең колак төбендә,—
Минем туган көнемдә.

Баш очымда — зәңгәр күк,
Утлы яшен яшьнәми;
Бүген... тыныч. Тик кеше
Бер көн белән яшәми.

Дөньяның иминлеген,
Тормышның бөтенлеген
Күтәреп сал җилкәңә,—
Туган көнең иртәгә!

### Яшьлек үтә икән, егетләр

Килсен ул дип мәңге китмәскә,
Без яшьлекне алдык көтепләр;
Ә үткәнен күреп булмады,—
Үкендерә бераз, егетләр.

...Таң аттырдык кичке уеннарда,—
Без талмадык, талды күрекләр;
Шыттырмыйбыз, чибәрләрне сөйдек,
Алар безне сөйде, егетләр.

Яшьли чумдык эшкә, сынатмадык,—
Кипкән чакларда да җиләкләр;
Бүген дә бит йөкнең җиллеләре
Безнең җилкәләрдә, егетләр.

Ярсып чаптык — юлда, яки чатта
Адашкандыр бәйтак өметләр;
Уйламадык аны үтәр диеп,
Яшьлек үтә икән, егетләр.

Типсен йөрәк һаман ашкындырып,
Торыр вакытмыны җебепләр;
Арык картлык безне бик тиз генә
Куып җитә алмас, егетләр.

Гомер үтә диеп, уй-сагышка
Сабышмыйлар безнең кебекләр;
Яшьлек үзе көнләшерлек итеп,
Янып яшик әле, егетләр!

## Бер хатирә

Хәтерләмим бугай хәзер сине,
Үткәннәргә күңел күнекте.
Югалтып һәм тагын-тагын табып
Була мәллә синең кебекне?!.

Беләм, син дә мине бик күптәннән
Кугансыңдыр күңел түреңнән;
Тик тамчы да гаеп тага алмыйм
һәм табалмыйм аны үземнән.

Юк, табалмыйм. Ләкин уйлыйм кайчак:
Яратуым минем үзем төсле
Булмадымы икән,— холыксыз?
Шуңадыр да бәлки, аны бүген
Хәтерләү дә хәтта икенче кат
Күргән кино кебек кызыксыз.

Күнегәдер күңел үткәннәргә,
Мин суындым сөю хисеннән;
Табыштык та тагын югалтыштык?—
Чыгардым да бугай исемнән.

Кинәт...
Еллар аръягында калган,
Мәңге кайтмас булган хатирә,
Борылмадан чыккан поезд кебек
Һаман үкереп минем якка килә...

## Малай, шар һәм узгынчы

Гадәти бер җәйге көн иде.
Әллә кайдан атылып
килеп чыккан малай
Шарын сузып миңа:
— Мәле, абый, тотып тол,— диде.

Үзе, нидер кырыр эшем нясөдәй,
Тротуарга җәелеп утырды.

Шук малайның кайдан җитсен вакыты,—
Кабалана-ашыга ботинкасын каптырды.

Вәт җебегән! Күр инде,—
Кулдагы шар күккә күтәрелеп бара,
Ә малаем,
Шардай күз яшьләре белән,
Урам яңгыратып оран сала.

— Әтинеке! Әти кителгән иде...
— Ә син кер дә тагын сора.
— Ул китте инде... Ул икенче җилдә тола.
— Үзем алып бирәм алайса.
— Юк, әтинеке...
— Морожный да алам, кирәксә.
— Юк әтинеке...
Шушы сакау тере ятимгә
Сүз дә тапма инде әйтергә?!
Үзе җәлләр иде еласам,
Тамчы да яшь чыкмый, ичмасам...

## Яңа елга кергәндә

Сискәндереп кинәт, сукты әнә
Иске елның соңгы сәгате:
Күңелемә көчә кабаттан
Могҗизалар кәтү гадәте.

Йөрәгемдә гайрәт, күкрәктә көч,
Күзләремдә өмет үстерәм,—
Иңбашыма кунган кайгыларны
Җәһәт кенә кагып төшерәм.

Мин юкта да үксез яшәмәсләр,—
Сагышларым белән хушлашам;
Аһ-зарларны куып, кочагымны
Туар шатлыкларга шар ачам.

Көләч көннәремне урлап киткән
Ялгышларны юлдан яздырам;
(Абындым, тик егылмадым, диеп
Ел чатына язып калдырам.)

Кабат кайтмасын дип озатам мин
Кысыр тойгыларның барсын да;
Тулпар аттай хәзер тып-тып итеп
Бәхет килеп басар каршыма.

Дәртләндереп кинәт, сукты әнә
Яңа елның тәүге сәгате:
Артта калды кебек бар газаплар,
Алда тора — бары әйбәте.

# БЕЗДӘ КУНАКТА: «ЗВЕЗДА» ЖУРНАЛЫ АВТОРЛАРЫ

Звезда

## Георгий Некрасов

●

Изге җир син, Нева заставасы!
Уйларыма, җанга иңдеңме?
Юкса синсез мин бар тавышыма
Горур җырлый алыр идемме?

Иң беренче адымымнан утлы
Сулыш өрдең минем язганга,
Аталарча карашыңны тойдым
Ераклардан — юлда барганда.

Күз алдында минем бар гомерем,
Ярты юлны узып барам инде...
Исемең белән бәйле һәр шигырь...

Бүген я әйт минем хакта үзең
Мөһер кебек кырыс, тик хак сүзең,
Гадел хөкемеңне... Бәя бир?!

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Всеволод Азаров

### Диңгез акчарлагы

Ак яллы дулкынга сыенып,
Акчарлак кычкыра ачынып.
Югыйсә, кай якка очса да,
Үз ирке — күк ачык, юл ачык.

Сап-салкын диңгезнең кочагы,
Туктаусыз дулкыннар куа ул.
Еракта, офыклар артында,
Канатлар кагынып туа җил.

Җылы җил тарата томанны,
Эретә гасырлар суыгын.
Акчарлак тәпие астына
Балыклар чәчәләр уылдык.

Яр буйлап бер малай йөгерә,
Белмичә сагышны, кайгыны.
...Ә диңгез төбендә төш күрә
Диңгезче бабасы каегы.

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** тәрҗемәсе

## Леонид Хаустов

### Могҗиза

Бер могҗиза булды асфальт юлда:
Калку урын башта күренде.
Иртәгесен шул төш ярылды да
Яшь үсенте өскә үренде.

Бик охшаган иде яшел нурга —
Нечкә иде, туры иде ул.
Караңгылык көчен җиңде ул да!
Хәзер үзе балкый инде ул.

Күктән кояш нурны юмарт сипсә,
Орлык төшсә әгәр туфракка —
Үсми калмый җирдә җанлы нәрсә,
Яшәү җиңә һәрбер очракта!

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәсе.

## Семен Ботвинник

●

Юк инде мәхәббәт, еракта
калгандыр учаклар яктысы.
Кайчандыр кошлары сайраган
каенлык та үзгә, ят төсле.

Кая соң мин белгән тавышлар?
Тик тынлык оеган күңелдә.
Язларның төсләре юылган,
ятимлек урманым түрендә.

Невадан исәдер дымлы җил,
агадыр болытлар биектән.
Ә минем күземә бер ни дә
күренми шикелле... Ник икән?

Үпкәле сагыштан сыгылып
өметкә сусаган бу җанны
син булсаң балкытыр идең бит —
тараеп тын калган дөньямны.

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ** тәрҗемәсе.

## Анатолий Чепуров

### «Карлыгач су»

Хабаровск, урләрендә кызу!
Август... Ә үзе — җәй челләсе:
Чиләкләп ул коя эсселекне...
Ә яңгырны әле көтәсе...
Хабаровск, үреңә менәсе...

Кызган асфальт юлдан ашыга — зәңгәр
Күкне чатыр иткән машинам...
Тауга күтәрелә... Үзе гүя
Тыны беткән юлчы... Ашыга
Кызу асфальт юлдан машинам.

Гүя кояш, ылыс исле урман,
Чишмәле бер җиләс урындай,
Хабаровск урләрендә уйлыйм,
«Карлыгач су»[1], синең турыңда,
Туктап гүя җиләс урынга.

Сусынымны бастың, җан янганын,
Түгелсең дә, юкса, агымсу...
Ерак Көнчыгышта син көч бирдең,
Исемең матур, үзең татлы идең,
«Карлыгач су», сиңа рәхмәт бу!

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Анатолий Аквилев

### Бөркетләр

Без — бөркетләр токымыннан,
Без — кыюлар, ленинчылар.
Мәңгелекне иңләп очар,
Онытылмас безнең җырлар.

Хәтерлидер Идел, Нева
Алар батырлыгын, данын,
Таңнар саклый бөркетләрнең
Яу кырында тамган канын.

Яңа буын атлый бүген
Алар җырлап узган юлдан.
Юл күрсәтеп килә әнә
Матросовлар саф алдыннан.

Гел җиңүгә өнди алар
Утка кергән байрак кебек.
Һәм Җир бездән җылы алып
Тибә уртак йөрәк кебек.

---

[1] «Карлыгач» — Ерак Көнчыгышта минераль су исеме.

Кавышкандай юллар бергә,
Елга, күлләр, киң диңгезләр,
Котыпларда, галәмнәрдә
Очраша гел безнең эзләр.

Киләчәккә якынайта
Яшь бөркетләр ал таңнарны.

БАМнар алтын тасма сыман
Кисеп үтә тайгаларны.

Без — бөркетләр токымыннан,
Без — кыюлар, ленинчылар.
— Кайнар яшьлек, канатыңда
Яңа буын юлга чыгар!

**ГОСМАН САДӘ** тәрҗемәсе

# Надежда Полякова

## Юл уртасы

Ярты юлны уздым инде —
Әле күпме барасы?!
Сине кем уйлап тапкан соң,
Чакырым баганасы?

Каерылып артка карыйм,
Бер чакырым үтәм дә...

Тау түбәсеннән күренә
Барыр юл да, үткән дә.

Үткән юллар авырлыгы
Хәзер татлы төш кенә.
...Йөгең җиңел була икән
Таудан түбән төшкәндә.

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** тәрҗемәсе

# Сергей Давыдов

## Вакыт сүзе

Кура җиләкләрен,
суын чишмәләрнең,
зәңгәр урманнымы,
сайрар кошларнымы —
бирсен дә сатмаган,
бирсен югалтмаган! —
һәрбер гөлен безгә
васыять иткән бабаң!

Курилмы, Литвамы —
күрдек без аларны,
Күрдек без Камада
аккан наратларны.
Саклыйк, әй, дусларым,
гүяки Ватанны,
урман, агачларны!

Уйлыйсың: бу — чаган...
Ә ул — Вакыт сүзе,
ул — бәйләнеш, дәвам...
Нәни Камыш кына,
ишетелә, тыңла! —
тормыш җыры аннан.

Һәм киләчәктә дә,
бер ерак мизгелдә,
шул җырдан таныйлар
оныклар безне дә!

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** тәрҗемәсе

# Вячеслав Кузнецов

## Туган туфрак

Уйный кырда арыш дулкыннары...
Чык коела нурда җемелдәп —
Уй-хыялың якты!
Хисләр хисе,
Моңнар моңы синең күңелдә.

Тамчы тама каен чукларыннан,
Нурлар ява күктән ишелеп.
Мин — җирдәмен,
Димәк, өемдәмен —
Җирем минем, алтын бишегем!

Бер уч туфрак!
Кеше иттең безне,
Үлгән чакларда да терелттең.
Кешеме син, кошмы?— һәммәбез дә
Җирнеке без, бары Җирнеке!

Зөлфәт тәрҗемәсе

# Сергей Макаров

## Шәһәр каеннары

Әй син, руда, домналарда
Әйлән сыек металлга!
Домна артында — каеннар...
Калып торам мин таңга.

Урманнан качып, каеннар
Шәһәргә җыелганнар.
Алар, ахрысы, шәһәрдә
Яшәргә җыенганнар.

Бар дип тә белми төтенне,
Яфрак яра үзләре.
Батыр, әлбәттә, каенның
Бу шәһәргә түзгәне!

Утырттым мин дә яшь каен
Нәкъ тәрәзә төбенә.
Ул инде әнә ямь-яшел
Бөреләргә төренә.

Каеньмны мин кояшның
Нуры белән нурладым.
Ә зифа кәүсәсенә дип
Ай нурларын урладым.

Ул шәһәр шау-шуларына,
Төтененә бирешмәс.
Шуңа да бирешеп тору
Ак каенга килешмәс!

Үсәр ул ташып, ургылып,
Булыр әле ул дәү дә.
Учың белән сыйпап кара:
Җан кебек кайнар гәүдә!

# Ирэна Сергеева

## Аккошлар

Берәр нәрсә баладан да
Матур булаламы?..
Очарга өйрәнә соры
Аккош балалары.
Ашыкмыйк — алар үзләрен
Сынап карар әле,
Әниләре шикелле үк
Канат кагар әле!

Ашыкмыйк — алар бер заман
Күзнең явын алыр!
Балаларны табу кыен,
Үстерү дә — авыр!

Нәни аккош баласының
Балкый соры төсе.

Бу — матур төс! Тик куркыныч
Безгә соры кеше.

Җирдә ак күңелле генә
Кеше булсын бары!
Булыр! Йөзә әнә җирнең
Ап-ак тылсымнары!

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре

# Олег Цакунов

## Йолдызлар коелганда

Әйләнеп карарга вакыт юк,
Көннәре, төннәре ашыга.
Әйтерсең, киләчәк иленнән
Бәхетләр юл чыккан каршыга.

Кайчакта уйланып ятасың...
Һавадан йолдызлар коела.
Учакта ут яна. Вакытлар
Тукталып калгандай тоела.

Тәрәзә артында кара төн
Океан шикелле чайкала.
Шәһәрләр, авыллар югала...
Югала... Бары тик ай кала.

Чайкалып океан төбендә
Йоклыйсың бер ни дә шәйләми.
Хәтерең түрендә бары тик
Күрәсең үзеңнең шәүләңне.

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** тәрҗемәсе.

# БИШ ХАТИРӘ

## Илһамия ханым хатирәсе

Күптәнге танышым Илһамия ханымның хәлен белергә дип кергән идем. Ул — профессор Үзбәк Якубович Богдановичның әнисе. Ачык йөз белән күрешеп, исәнлек-саулык сорашкач, өстәлгә таратып салынган китапларга ымлап:

— Хөсәен Ямашевның революцион эшчәнлеге турында байтак нәрсәләр язылган. Әмма Чистай шәһәрендәге тормышы, эшчәнлеге, шул тирә авылларда яшәгән ярлы крестьяннарга йогынтысы хакында берни дә юк,— диде.

Сөйләшүебез шул хакта дәвам итте.

— Мин Хөсәен абыйның хатыны Хәдичә апа белән аралашкан идем,— диде әңгәмәдәшем бераз уйланып торганнан соң,— без аның белән бер йортта тордык, бер мәктәптә укыдык. Аларның өйләнешкән көннәрен дә яхшы хәтерлим әле. Аннан соң, Казанда чакта, аларда торып укырга туры килде. Хөсәен абыйны соңгы юлга озаткан чакта да мин аларда идем...

Илһамия ханым авыр сулап куйды. Бераздан дәвам итте:

— Хәдичә апалар Чистай шәһәренең элеккеге Екатеринская (хәзерге Карл Маркс) урамындагы 48 нче йортта торалар иде. Яшелгә буялган ике катлы агач өй иде. Әлеге урамда өч кенә татар йорты бар. Без, кызлар, бергә җыелып, төрле уеннар уйный торган идек.

Әле дә хәтеремдә —1902 ел. Яз аеның матур бер көне. Бакчада китап укып утырабыз. Шулчак кемдер капканы какты. Йөгереп барып келәне күтәреп җибәрдем. Каршымда елмаеп бер егет басып тора. Кулына төргәк тоткан.

— Сеңелем, Хәдичә туташны чакырып китермәссеңме икән?— диде дә миңа шоколад сузды. Алай иткәч, ничек чакырмыйм ди инде?!

Алар бик озак сөйләшеп утырдылар. Сүзләре шактый җитди иде, күрәсең... Хәдичә апаның бите кызарып чыгуына да игътибар иттем. Егет киткәч, без аны уратып алдык.

— Кем иде дә кем иде?— дип сорау яудырабыз. Хәдичә апа бераз ялындырып торды да:

— Хөсәен атлы ул, Казаннан килгән,— диде.

...Озакламый аларның туйлары булды. Шуннан соңгы елларны Чистайга Хөсәен абый белән Хәдичә апа бергәләп кайта башладылар.

Гасыр башында Чистай шәһәрендә кечкенә-кечкенә заводлар үсеп чыга башлады. Эшчеләр саны да сизелерлек артты. Арада татар эшчеләре дә байтак иде. Чистайга килеп чыккан чакларында Хөсәен абый эшчеләр белән озаклап сөйләшә, аларның тормышлары белән таныша. Тора-бар ул патша хөкүмәтенә каршы өндәмәләр таратуга

керешкән. Ә моның өчен өндәмәләрне күпләп бастырырга җайланма һәм ышанычлы урын кирәк... «Яшел йорт»та мондый урын да табылды. Чарлакка берәү дә керми, бик тыныч җир. Хөсәен абый Хәдичә апа белән шунда өндәмәләр бастыра башладылар. Мин дә «чардак»ның үз кешесенә әйләндем. Прокламацияләрне таратуга Моисей дәдәй белән Мәхмүт хәлфә алынды.

Моисей дәдәй яхшы балта остасы иде. Аңа һәркемнең капкасы ачык. Дуслары-танышлары да күп. Мәхмүт Гайнетдинов — укытучы кеше. Халык арасында еш була. Өндәмәләрне тараткан урын — базар чаты. Сәүдә итәргә килгән крестьяннар шунда күпләп җыела. Чистай базары Лаеш, Спас, Мамадыш өязләреннән килгән сәүдәгәрләр белән дан тота иде...

Илһамия ханым бераз тын торды. Уйларын барлый, бер ноктага туплый иде ахрысы.

— Мәхмүт хәлфә Хөсәен абый белән Моисей дәдәй өендә эшчеләрнең җыелып сөйләшүләре турында еш искә ала иде. «Яшел йорт»та сәяси эш алып бару өчен тагын бер уңайлылык бар: Хәдичә апаның атасы Зариф карт заманында танылган сәүдәгәр була. Ул бөлсә дә, аны «иске» дуслары онытып бетермиләр, әледән-әле килеп хәлен белешәләр, бергәләп сөйләшәләр. Күзәтүче кеше дә юк. Хөсәен өчен дә бу йорт очрашу, сөйләшү урынын үти. «Яшел йорт» Фатих Кәрими, Нәҗип Думави, Галиәсгар Камал, Гафур Коләхметов, Риза Фәхретдинов, Габдулла Кариев кебек билгеле шәхесләрнең очрашу урынnарына әйләнә.

Хөсәен абый эшчеләр арасында аңлату эшләрен даими алып барды. Шәһәрдә генә түгел, ул еш кына якын тирә авылларга чыгып киткәли.

1908 ел иде бугай. Без, бер төркем кеше, Зариф картның Спас өязендәге утарына юл тоттык. Арада Хөсәен абый да, Мәхмүт хәлфә дә бар. Җиләк җыя-җыя шактый йөрдек. Аннан соң Хөсәен абый белән Мәхмүт хәлфә Бибай Чаллысы (хәзерге Әлки районында) дигән авылга киттеләр. Анда алар каравыл өе янына җыелган ярлы-ябагайга патша хөкүмәтенең чын йөзен ачып биргәннәр, нотык сөйләгәннәр. Бәхетле тормышны, революция ясап кына яулап алып булуын аңлатканнар.

Берничә көннән соң, шушы авылның байлары Зариф картка шаулашып килеп җиттеләр.

— Киявең хөкүмәткә тел тидерә, сафсата кора, кара аны, тый,— дип җикеренә алар.

Зариф карт кияве Хөсәенне элек тә өнәп бетерми иде булса кирәк. Алар арасында ниндидер аңлашылмаучылык күптән бар иде кебек. Бу юлы сүз тагын да зурдан купканга охшады, чөнки Хөсәен абыйлар икенче көнне үк Казанга кайтып киттеләр. Чистайга кайтулар сирәгәйгәннән сирәгәйде.

...Менә Хөсәен Ямашев белән аның тормыш иптәше Хәдичә ханымның фоторәсеме ята. Илһамия ханым минем аларга карап торуымны күргәч, түзмәде:

— Бик яратышып тордылар. Хөсәен абый Хәдичә апага еш кына: «Сине яратмау мөмкин түгел, акыллым бит син минем, фикердәшем...» — дия торган иде,— Дөрес, тора-бара Хәдичә апа Хөсәен абыйның алны-ялны карамый эшләвеннән зарлана да башлады. Хәлләре, тормышлары бик шәптән түгел иде шул. Ашарга да җитенкерәми. Зариф карт да булышмый башлады. Әмма Хөсәен абый, бернигә дә карамастан, революцион эшен ташламады. Киресенчә, тагын да кыюлана төште.

Бервакыт Хөсәен абый, туган көн мәҗлесе үткәрәбез дигән булып, кунаклар чакырды. Моңа ул ныклап әзерләнде. «Мәҗлескә» барлы-

гы җиде кеше җыйналды. Бөтенесе ир-ат. Алар бик озак сөйләшеп утырдылар, соң гына таралыштылар. Арада ябык кына гәүдәле, күзлекле бер кеше дә бар иде. Мин аның Ленинның якын дусты Свердлов икәнен бары тик соңыннан гына белә алдым.

...1912 ел иде. Хәдичә апа укуын тәмамлады, врач таныклыгы алды. Без өчәүләп бу вакыйганы билгеләп үтәргә җыендык. Хөсәен җизни Хәдичә апага бүләкләр кайтарып куйды да китап кибетенә барып киләм дип чыгып китте... һәм, озак та үтмәде, Фәхреислам ага акылга сыймаслык хәбәр китереп җиткерде:

— Хөсәен «Гасыр» китап кибетендә кинәт вафат булды...

18 нче март көнне Хөсәен абыйны җирләдек. Аны озатырга бик күп халык җыелды...

Илһамия ханым белән тын гына утырабыз. Аның күзе тагын да уйчанлана, сагышлана төшкән сыман. Аңа рәхмәт әйтеп чыгып китәм. Ә күңелемдә — Хөсәен Ямашев турында истәлекләр, якты хатирәләр яңара.



## Зәйнәп ханым хатирәсе

Беренче татар революционеры, ялкынлы ленинчы турында тагын да күбрәк беләсе, аларны башкаларга да җиткерү теләге тынгы бирми. Берничә көннән соң мин Казанда яшәүче Зәйнәп ханым Халитоваларга юнәлдем.

Аның кайнанасы Фәһимә абыстайның Чистай шәһәрендә кызларны укытып йөргәнен, Хөсәен Ямашевлар белән дә даими аралашкан кеше икәнлегенә хәбәрдар идем. Исән чакта истәлекләрен Зәйнәп ханымга да сөйләп калдырган. Мин күңелемә ул сөйләгән истәлекләрне терки барам.

— Яз ае иде. Әңгер-меңгер чак. Капка төбенә җигүле атлар килеп туктады. Күп тә үтмәстән, өйгә шаулап-гөрләп Хөсәен белән Мәхмүт килеп керделәр. Казан хәлләре, эшчеләр тормышы турында гапләшеп алдылар. Кемдер ишек шакыды. Кешеләр килүе көтелми иде. Мәхмүт ишегалдына чыгып китте дә шактый торгач кына килеп керде.

— Бутышник Гәләви килгән, акча сорый. Баш авырта дигән була, ә үзенең күзе ут яна. «Кунаклар килдемени?» — дигән була.

— Шымшынып йөри ул алайса, — диде аңа Хөсәен һәм ашыгып киенә башлады. Мәхмүт аны озата китте. Кайткач:

— Ул-бу булмады, Хөсәенне аргы якка чыгучы ямщикларга утыртып җибәрдем, — диде. Хөсәен калдырган кәгазьләрне укыгач, аларны утка ташлады...

Хөсәен бик җыйнак, пөхтә кеше иде. Шымчыларга шикләнерлек эз калдырмый эшли белә иде ул...

## Вафа ага хатирәсе

Эзләнүем мине Алабуга шәһәренә алып килде. Менә мин 85 яшьлек Вафа ага Садыйков сөйләгәнен тыңлыйм. Ул заманында Би авылында яшәгән. Хөсәен Ямашев бирсдә дә берничә тапкыр булган.

— Миңа 10—11 яшьләр чамасы гына иде әле,— дип сөйләп китте

Вафа ага бераз танышып алгач. — Без Гариф җизниләр белән күршеләр идек. Гариф җизни безнең авылга (элеккеге Уфа губернасы, Минзәлә өязендәге Сухаров волосте) хәзерге Түбән Кама районыннан килгән Мәрем апага йортка кергән. Сөйләүләренә карагандa, ул патша хөкүмәте эзәрлекләвеннән качып яши.

Елын төгәл генә хәтерләмим инде. Шулай берчакны Гариф абыйларга Хөсәен Ямашев белән аның хатыны, ачык йөзле Хәдичә апа килде. Алар бергәләп авылны карап йөрделәр. Күрше рус авылы кешеләре белән әңгәмә корганнары да истә. Ә авыл зиратында исә алар шактый озак кына басып тордылар. Анда Хәсән бабай кабере бар иде. Хәсән бабай заманында Кутузов армиясендә офицер булып хезмәт иткән. Күп батырлыклар күрсәткән. Аның алтын хәрефләр белән язылган көмеш саплы кылычы Гариф җизниләрдә озак еллар сакланды...

Уйчан йөзле, тирән карашлы, Хөсәен абыйның ак эшләпәсенә, ялтыравыклы кара батинкасына, без, малайлар, кызыгып карый идек...

Истәлекләр, истәлекләр... Аларда — ялкынлы ленинчы Хөсәен Ямашевны күреп белгән кешеләрнең күңелләрендә сакланган якты хатирәләр. Тарих өчен кадерле, изге алар.

## Наил ага хатирәсе

Казанда яшәүче Наил ага белән дә очраштым, ул миңа 1945 нче елны язучы һәм галим Гази Кашшаф белән Би авылына баруларын, халыкка сугыш турында кинолар күрсәтүләрен, лекцияләр укуын сөйләде.

— Бер кичне Фәрукша картларда куна калдык,— диде ул.— Шул карт безгә Хөсәен Ямашевны күрүен бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде. —Һәм Наил ага Фәрукша карттан ишеткәннәрен бәян кылды.

— Чистайдан Гариф абыйларга күп кенә кунаклар килә. Арада Хөсәен белән Хәдичә дә бар, мин кунак атларын тугарышырга булышып йөрим...

Кунаклар һәр көнне табигать почмагына чыгалар, байларга кунакка, аш-суга йөриләр. Тик Хөсәен ул мәҗлесләргә бармый. Ул күпчелек вакытын авыл ярлылары белән сөйләшеп үткәрә. Хөсәен Фәрукша тормышы белән дә кызыксына Аты, сыеры юклыгын, җиренең дә бик аз булуын белгәч:

— Үзгәртергә кирәк бу тормышны, үзгәртергә... — дип куя.

Бервакыт Хөсәен Хәят бикәнең управляющие Котыш белән бәхәскә керә. Болайрак була ул.

Хөсәен авыл башында бикәнең җирен эшкәртеп кайтучы көнлекчеләрне очрата. Сөйләшеп китәләр. Шулчак яхшы атка атланган Котыш килеп чыга. Кулында — камчы.

— Иртә кайтасыз, кире борылыгыз! — дип җикеренә управляющий.

Көнлекчеләр баш тарткач, ул атыннан сикереп төшә дә камчысы белән кизәнә башлый. Арага Хөсәен килеп керә.

— Алар крепостной крестьяннар түгел,— ди ул.— Аларның ял итәргә, кешечә яшәргә хаклары бар... Ә син, бар, күздән югал!..

Бу хәлне көтмәгән управляющий Хөсәенгә янап китеп бара.

Вафа карт белән Фәрукша агай сүзләренә караганда, Хөсәен Би авылында 1903—1904 нче елларда булган. Ярлы крестьяннарның

тормышын өйрәнү, аны аңлау соңыннан Хөсәенгә «Урал» газетасында эшләгән елларында зур ярдәм итә. Бу хакта ул байтак кына мәкаләләр яза...

## Гомәр ага хатирәсе

**Гомәр ага Бакиров бүгенге көндә Казанда яши. Аңа — 77 яшь. Гражданнар сугышы ветераны. Төрле җаваплы урыннарда эшләгән, аның да Хөсәен Ямашев турында сөйләр сүзләре бар.**

**— Хөсәен Ямашев турында Чистай өязе авылларында укытучы булып эшләгән Әдһәмовтан һәм әтидән еш ишетә идем.**

**Минем әти гомер буе пристаньда, икмәк амбарларында йөк ташучы булып йөргән. Әше бик авыр. Аның көлгәнен, елмайганын бер тапкыр да күргәнем булмады. Без икенче татар урамында торабыз. Әти Моисей дәдәй белән таныш, дус иде. Берчакны мин сәкедә китап укып утыра идем. Әти кайтып керде.**

**— Ни укыйсың, улым?**

**— Тарих.**

**Әти җилкәмә кулын салды да:**

**— Укы, улым. Тарихны, үзеңнең үткәнеңне белми торып, киләчәкне белеп булмый ул. Зариф карт кияве Хөсәен дә шулай сөйләде миңа,— диде.**

**ХӘМИТ БАДАМШИН**

# ЕЛЛАР ИСТӘЛЕГЕ

*«Тукай турында замандашлары» һәм Г. Тукай дүрттомлыгындагы кайбер истәлекләргә өстәмә*

Казанда 1907—1909 нчы елларда Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Вафа Бәхтияров, Галиәсгар Камал һәм башка демократик яшьләр катнашында «Әлислах» (Реформа) дигән газета чыгарыла.

Газетаның мөхәррире Вафа Бәхтияров истәлегеннән:

«1907 елның 25 нче апрелендә «Әлислах» газетасын чыгарырга Казан губернаторы тарафыннан рөхсәт бирелү белән, мәгълүм язучыларга «Әлислах»ка язышуларын үтенеп хат язарга туры килде.

Тукай минем хатка бик кыска җавап бирде. Шул ук ел октябрь уенда күрештек. Ул «Әлислах» турында, катнашучылар турында сораша башлады. Мин: «Хәзергә Фатих Әмирхан белән икәү генә алып барабыз»,— дигәч, «Алай булганда мин сезнең өченчегез булам инде»,— диде.

Тукайдан «Әлислах»ның әдәбият бүлеген алып баруын үтендек. Ул 1908 елның ахырларына кадәр «Әлислах»ның әдәбият бүлеген алып барды. Газетаның һәр номерына диярлек шигырьләрен биреп торды.

Аннан «Әлислах»ның хатын-кыз бүлеген алып бара.

Шулай итеп, 1909 елның ноябрь ахырына кадәр бергә эшләдек».

Тукай «Әлислах» редакциясенә һәркөнне диярлек кереп, яңа почтаны сорап алып, зур кызыксыну белән карап чыга торган була. Килгән шигырьләрне җентекләп укый, барырдайларын редакцияләп, чираттагы санга тәкъдим итә, бармастайларына хатлар яза.

«Әлислах» тирәсенә күп кенә демократик яшьләр туплана. Шуларның берсе булган Хуҗа Бәдигый үзенең истәлекләрендә болай дип яза:

«1907 елда Будапешт шәһәренең Көнчыгыш университеты гыйльми эшчесе ориенталист венгр Миссарош татар һәм чувашларның фольклор материалларын җыю һәм өйрәнү теләге белән Казанга килде. Мин — ул вакытта Казандагы мәдрәсәи Мөхәммәдиянең соңгы курсында укучы. Яхшырак укучы һәм шул вакытта ук татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынучы булуым сыйфаты белән булса кирәк, татар телен өйрәтү һәм фольклор материалларын җыю юлында булышу өчен әлеге гыйльми эшчегә мин тәкъдим ителдем.

Без шул елны җәй буе районда йөреп, байтак кына фольклор материаллары туплап, көз Казанга кайттык.

Мин ул вакытларда «Әлислах» газеты редакциясенә барып, басылган газеталарны хәзерләп, подписчикларга җибәрү кебек аның техник эшләрендә булышкалый идем, мәдрәсәләр тормышы һәм шәкертләр хәрәкәте турында вак-төяк хәбәрләр язгалый идем. «Әлислах» газетындагы «Мөгаллим» имзасы белән басылган хәбәрләр минеке була иде.

Бервакыт шулай «Әлислах» редакциясенә барам. Кемдер простой гына киенгән берәү, редакциянең тәрәзәсе төбенә сөялеп «Әлислах» газетасын караштыргалап тора. Газета редакторы Вафа иптәш Бәхтияров: «Син әле Тукай белән таныштыңмы?» — дип, мине әлеге кеше янына алып килде. Күрештек. Тукай миңа туп-туры карап:

— Ә, халык әдәбиятын җыючы кеше синмени әле ул? — диде. Аннан: — Зур эш башлап җибәргәнсең, инде шул юлыңда дәвам ит!

Тукай хәер-фатихасы белән Хуҗа Бәдигый үзенең барлык гомерен шул эшкә багышлый. Аның 1912—1914 елларда «Халык әдәбияты» исемендә дүрт китабы —«Мәкальләр», «Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», «Бәетләр», «Җырлар» җыентыгы, татар фольклоры тарихы һәм теориясенә караган аерым хезмәтләре, 1926 елда «Мәкальләр һәм табышмаклар» тупланмасы басылып чыга. Хуҗа Бәдигый Казан педагогия институтында укытучы, доцент һәм ахырдан профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул фольклор өйрәнү өлкәсендә үзенең остазлары итеп Каюм Насыйрины һәм Габдулла Тукайны саный.

Бу газета битләрен ачканда һәрчак аерым бер дулкынлану кичерәсең. Күз алдыннан тарих сәхифәләре үтеп киткәндәй була. Әнә әле күптән түгел генә 20 яшен тутырган егетләр, дәртләнеп, яңалыкка омтылып, халыкка аң-белем тарату нияте белән үзләренең газеталарын чыгаруга ирешәләр. Менә ул газетаның беренче, икенче саннары. Шул вакыт бу яшьләр сафына 21 яшьлек Тукай килеп кушыла. Газета мөхәррире Вафа Бәхтияров беренче очрашуда ук аннан мәкалә язуын үтенә. Тукай вәгъдәсен шунда ук үти. Инде газетаның өченче санында ук аның «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» дигән мәкаләсе, ә бишенче санында «Бер мангы тәрәккыйга» дигән шигыре басыла. Болар — Тукайның Казанда язган беренче мәкаләсе һәм беренче шигыре.

**ЗӘКИЯ РӘСУЛОВА.**

# ТӨБӘКЧЕЛЕК

Бездә жирле тарихны өйрәнү хәрәкәте кайчан башланган? Шул эзләнүләр фәнгә, әдәбият белән сәнгатькә ни дәрәҗәдә чыганак була ала? Туган якның узганы һәм бүгенгесе белән кызыксынучыларның мондый сораулары бик аңлаешлы. Җәмгыять тиз үскән саен, кешеләрнең шул үсү белән кызыксынуы да арта. Бу берьяклы кызыксынучанлык кына түгел: кеше бүгенгене аңларга тырышудан тыш, киләчәкне дә күзалларга омтыла. Ә киләчәкне күзаллыйм дисәң, үткәннәрне белү шарт.

Узганны өйрәнгән чакта хосусый мәсьәләләрнең, аерым объектларның тарихын да белү кирәк. Соңгы вакытта бу нисбәттә зур тарих фәненең төбәкчелек дигән яңа тармагы барлыкка килде. («Төбәкчелек» сүзен без «краеведение» төшенчәсенә тәңгәл дип карыйбыз, чөнки моңа кадәр кулланылып килгән «крайны өйрәнү» дигән төшенчә әлеге атаманың мәгънәсенә туры килеп җитми.) Төбәкчелек дигән нәрсә тарих фәненең бер чите түгел, бәлки бер юнәлеше. Бу бер. Икенчедән, төбәкчелек белән, профессиональ галимнәр дөньясыннан тыш, һәвәскәрләр дә күп кызыксына. Фәндә бу төр тарихны икегә — гыйльми һәм һәвәскәр төбәкчелеккә бүлеп карыйлар. Аларның беренчесен өйрәнүгә, үстерүгә профессиональ тарихчылар һәм башка төр галимнәр катнаша. Шуңа күрә бу тармак зур тарих белән тыгызрак бәйләнгән. Икенчесе исә иҗтимагый хәрәкәт дәвамында барлыкка килә, һәм аны, кагыйдә буларак, туган якны ихлас сөючеләр, аның үткәне белән тирән кызыксынучылар — һәвәскәрләр үстерә. Белгечләр төбәкчелекнең табигатен, рухын аңлауда, бурычын аңлатуда бер фикергә килеп җитә алмаганнар әле. Шуңа күрә күп очракта бу хакта берьяклы яисә бөтенләй хата фикерләр әйтелгәли. Мәсәлән, кайберәүләр аның башлангыч чорын XX гасырның беренче унъеллыкларына кайтаралар; икенчеләре бу ысул белән тупланган тарихи чыганакларны төп фәннән аерырга тырышалар. Яки фәнни тарих белән төбәкчелекне үзара каршы куялар, соңгысының гыйльми әһәмиятенә шөбһә белдерәләр.

Табигый сорау: әгәр төбәкчелек гыйлем булмаса, аны нинди өлкәгә кертеп карарга соң? Бу сорауга тәфсилле итеп җавап биргән белгеч академик А. С. Барков булды. Ул, мәсәлән, география фәне белән географик төбәкчелек арасындагы мөнәсәбәтләрне җентекләп тикшерә һәм соңгысын гыйльми ысул-алым дип раслый. Шунда ук аның ике төрен, ягъни гыйльми һәм һәвәскәри төбәкчелекне аерып күрсәтә. А. С. Барков фикерләренчә зур тарих фәненең башка тармаклары янәшәсендә — мәсәлән, чыганакчылык, иске язулар белеме (палеография), тәңкәләр белеме (нумизматика) — төбәкчелек тармагы да бар. Ул да, тегеләре кебек үк, мөстәкыйльлеккә ия: чөнки ул да үз ысуллары, үз методикасы белән эш итә.

Төбәкчелекнең мөһимлеге, кирәклеге нәрсәләрдән гыйбарәт соң? Бу сорауны башкачарак та куярга мөмкин. Татар халкының мәсәлән, крестьян хәрәкәтен өйрәнгәндә, дистәләрчә Күлле, Ташлы, Каенлы авылларының һәрберсенең тарихын белү зарури микән? Әллә шул хәрәкәтнең мәгълүм булган гомум юнәлешен төрле яклап тикшерү генә дә житкәнме? Шул авылларда туып үскән, гомер иткән һәм шунда ук җирләнгән Бәкер һәм Торна бабайлар, Пәйзи һәм Әпрәү агайларның язмышы кемгә хаҗәт соң?

Элегрәк профессиональ тарихчылар бу сорауларга ачык җавап бирмиләр, ләкин «вак тарихлардан» да бөтенләй үк читләшмәделәр, авыл-бистәләрнең үткәнен тасвирларга тотынган чакларда андый хезмәтләрдән дә файдаланалар иде. Әмма күп очракта мондый эшләрне аерым галимнәр генә башкарган. Башкалар исә, бу фәнни эш түгел, сәнгать әһелләре, әдипләр эше дип кенә караганнар. Чыннан да, монда

әдәбият һәм тарих арасындагы бәйләнешләрнең берсен бик ачык күрәбез.

Фикер тәгәлрәк ачылсын өчен бер мисалга мөрәҗәгать итик. XIX йөзнең соңгы унъеллыгында татар крестьяннарының сыйнфый йөзен ачыкларга тырышып, күп санлы махсус мәкаләләр һәм гыйльми хезмәтләр язылган. Алар төрле чыганаклардан файдаланып, тиешле югарылыкта язылган һәм хакыйкатькә туры килә. Ә инде шул чор тормышын яктырткан әдәби әсәрләр (бигрәк тә М. Галәүнекеләр) белән дә таныша башласаң, өйрәнә торган чор хакында бөтенләй икенче югарылыктагы фикер тәрешәсең. Ни өчен болай килеп чыга соң?

Чөнки гыйльми хезмәтләрдә халык тормышының икенче бер мөһим өлеше — крестьяннарның тойгы-кичерешләре, психологиясе читтә кала яисә берьяклы яктыртыла. М. Галәүнең халык тормышын бик җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә иҗат иткән «Мөһаҗирләр»е һәм «Болганчык еллар»ы татар крестьяннарының, социаль хәлләрен ачкан кебек, иҗтимагый психологиясен дә күрсәтеп бирә. Алар чын мәгънәсендәге тарихи-әдәби әсәрләр дип санала ала.

Бүгенге тарих фәне алдында да социаль, иҗтимагый психология мәсьәләләрен ачыклау таләбе куела. Бу бурычны башкару өчен махсус чыганаклар кирәк, әлбәттә. Безнеңчә, нәкъ менә шушы урында ярдәмгә төбәкчеләр, бигрәк тә һәвәскәрләр тарафыннан җыелган материаллар, төрле язмалар — башкачарак әйтсәк, һәвәскәр төбәкчелек тарихнамәләре килә ала.

Икенче мисал. Әдип үзенең тарихи темага багышланган әсәрендә «тарихка кергән» мәгълүм шәхесләрне генә гәүдәләндереп калмыйча, үзе уйлап чыгарган «ваграк» персонажларны да тасвирлый. Соңгылары әдәби әсәр өчен зарури фон булудан тыш, әлеге мәгълүм шәхесне чын шәхес иттерүче мөһим чара сыйфатында да кирәк. Язучы төп геройның тойгы-кичерешләрен чын тарихта булмаган, үзе уйлап чыгарган персонажлар ярдәмендә җанландырып тасвирлый. Гыйльми хезмәтләрдә исә сюжет «шәхессез», шуңа җансыз, схематик һәм абстракт килеп чыга.

Хәзерге тарих фәненең торышы исә моның белән килешми. Һәм галимнәр алдында үз хезмәтләрен шәхессезлек схемасыннан арындыру бурычлары куела. Дөрес, галимгә, язучы кебек, өстәмә персонажлар уйлап чыгару мөмкинлеге бирелмәгән. Ул яшәү һәм гамәлләре документлар ярдәмендә расланырлык конкрет шәхесләргә таянып гамәл кылырга тиеш. Нәкъ менә шунда төп чыганакларның берсе сыйфатында төбәк тарихнамәләре мәйданга чыга.

Төбәкчелек нигезендә язылган әсәрләрнең әһәмиятен тарих сөючеләр үзләре үк дөрес аңлаганнар. Түнтәр авылының тарихын төзүче Мөхәммәднәҗип исемле элеккеге укытучы, мәсәлән, 1927 елда ук болай дип язган: «Бу (ягъни авыллар тарихын язу — Р. Ш.) инде бик мөһим, күптән үк кирәкле эш иде. Һәр авылның тарихы язылып барылса, гомуми тарихны язарга байтак мәгълүмат бу хосусый тарихларда табылыр иде. Электән үк бу эш эшләнә килгән булса, төрки-татар тарихының байтак карангы яклары ачылган булыр иде».

Гомумән, совет галимнәре хосусый тарихларны өйрәнү буенча беркадәр тәҗрибә туплаганнар инде. Мисал итеп, Украина тарихчылары башкарган зур хезмәтне күрсәтергә мөмкин. Ана телләрендә басылып чыккан егерме алты томлык бу хезмәт «Украина ССРның шәһәрләре һәм авыллары тарихы» дип атала.

Ниһаять, игътибарны тагын бер мәсьәләгә юнәлтик. Төбәкчелек тарихнамәләренең әһәмияте, социаль тарих һәм матур әдәбияттан тыш, тарих фәненең башка өлкәләре өчен дә чыганак хезмәтен үти алалар.

Мәсәлән, Ибраһим Туйкин Зәй-Каратай авылы (Лениногорск районы) тарихына кагылышлы «Эрлек өмәсе»н тасвирлый: «Элекке елларда авылда кайбер хуҗалыклар кышның озын төннәрендә кич утырып эрлек өмәләре итәләр. XX гасыр башларында безгә якын кардәш тиешле кеше Таҗиев Галәветдиннәрдә беркөн кич эрлек өмәсе була. Аның малае Газизҗан мине өмә күрергә алып китте. Без кергәндә 6—7 карчык киндер сүсе эрли иде. Фатыйма әби коймак пешерә. Без кереп бераз торгач, Фатыйма әби өмәчеләргә чәй әзерли башлады. Шул чак Кәшшафның карчыгы Әсма әби моңлы итеп, сузып-сузып, курай уйный башлады. Ул 2—3 көй уйнагач, чәй эчтеләр. Аннары Җамалетдиннең карчыгы Хәтирә әби бармак шартлатып, эрлекне кулга күтәреп:

Әй эрлегем, эрлегем!
Бик күп эрләп борчыдым,
Ачуланма син миңа!
Шулай булган язмышың,

— дип такмаклап кубызга биеде. Аннары тагын эрли башладылар. Эрләгәндә ике карчык кушылып озын көйләргә сузып-сузып җырладылар. Тагын бер хатын килеп керде дә, курайчы кабасына утырып, аның эрлегән эрли башлады. Курайчы гел курай уйнап утырды...»

Автор тарафыннан бик тасвирлап язылган бу өлеш галимнәр өчен генә түгел, бәлки сәнгать әһелләре — язучылар, хореографлар өчен дә матур мәгълүматтыр.

Һәвәскәр төбәкчелек тарихнамәләре тел белеме өлкәсендә дә нигезле чыганак булыр иде. Безнең фикеребезчә, диалектологларга телебезнең төрле шивәләрен өйрәнгәндә бу җирле тарихнамәләр ике яклап ярдәмгә килә: беренчедән, мондый әсәрләрдә теркәлгән мәгълүматлар экспедиция вакытында тупланган фактларны чагыштырып тикшерү өчен дәлил була алалар; икенчедән, алар әлек билгеле булып, соңрак югалган фактлар турында хәбәр итәргә мөмкин.

Татар теленең көнчыгыш диалектын өйрәнгәндә Себер авылларында иҗат ителгән тарихнамәләр дә күп мәгълүматлар бирә. А. Гыйззәтуллинның «Бараба халкы. Туралы-Тобол халкы», билгесез авторның «Асылы-нәселе Сала авылының» һәм башкаларында, шулай ук шивәчелек сүзләре күп очрый. Мәсәлән: тумак — баш киеменең бер төре; кугу — ялкынсыз яну, пыску; кунгырчак — курчак, табыну курчагы; паскут йир — көтүлек һ. б. Себер җирендә төзелгән тарихнамәләрдә грамматик диалектизмнар да калку чагыла.

Һәвәскәр тарихчылар хәбәре телчеләргә сүзләр тарихын өйрәнгәндә дә ярдәм итәргә мөмкин. Кайбер авторлар турыдан-туры тел фактларын теркәп баралар.

Соңгы елларда Татарстанда тел белеме белән тарих фәненең уртак тармагы — ономастика белеме үсеп китте. Мисал итеп, Г. Саттаров хезмәтләрен атарга мөмкин. Ономастика — кеше, җир-су, шәһәр-авыл атамаларын өйрәнә. Билгеле булганча, мондый атамалар, бигрәк тә тар кулланылышта булганнары, заман үтү белән үзгәрәләр, яңалары барлыкка килә тора. Биредә Казан шәһәренең җирле атамаларына (микротопонимикасына) тукталырга мөмкин. Хәзер «Исмәгыйль хаҗи чаты», «Ристан бакчасы», «Аккомасты», «Көфер почмагы» кебек исемнәр өлкән буын кешеләренең генә исендә калды. Болар урынына яңа атамалар кулланыла. Әмма бу исемнәр Казан тарихы белән бик бәйле һәм алар башкалабызның үткәнен ачыкларга зур ярдәм итәләр. Кайчандыр кулланылышта йөргән, аннары төшеп калган шундый ук исемнәрне һәр төбәктә, һәр авылда табарга мөмкин. Андыйларны барлау, өйрәнү өчен әлеге тарихнамәләр чыганак вазифасын үти алалар. Мисал итеп, «Урманасты Шонталы авылы тарихы» (хәзерге Чистай районы) дигән кулъязманы китерергә мөмкин. Кулъязманың авторы Шонталы авылы тирәсендәге җирләрнең исемнәренә аңлатма бирә һәм бу хакта халык арасында йөргән кайбер риваятьләрне терки. К. Бикколов әсәрендә дә бөтен бер бүлек авыл тирәсендәге болын, су исемнәрен аңлатуга багышланган.

Боларның барысы да татарларда җирле тарихның — төбәкчелекнең формалаша башлавы XIX йөзнең беренче яртысына туры килүен күрсәтәләр. Моны К. Насыйриның «Археологиягә материаллар» дигән мәкаләсе дә дәлилли. Ул үз әсәрләрендә күп кенә җирле тарихнамәләргә таяна.

Хәзер Ленинград, Казан һәм Уфа архивларында биш дистәдән артык кулъязма тарихнамәләр саклана (революциягә кадәр аларның кайбер үрнәкләре басылып та чыккан). Бүгенге көндә дә шактый «авыл тарихлары»ның шәхси архивларда саклануы мәгълүм. Аларның киләчәктә исән калулары шик астында. Күпчелектә алар гарәп хәрефләре белән язылган, хәзерге яшьләргә билгесез ядкарьләр. Шуның өчен мондый чыганакларны җыйнау, барлау һәм фәнни нигездә тикшерү — хәзерге тарихыбызның мөһим мәсьәләләреннән берсе.

**РАФАЭЛЬ ШӘЙХИЕВ.**

Равил Кукушкин

# ШИГЪРИ БИШЕК

*Тукай һәм балалар әдәбияты*

Татар балалар поэзиясенең чын мәгънәсендә профессиональ үсеш алуы халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай исеме белән бәйле. Чыннан да, халык рухын бөтен нечкәлеге белән тойган һәм шигърият дәрәҗәсенә күтәрә алган Тукай кебек зур шәхеснең әдәбиятка килеп тә, балалар өчен бер шигъри сүз дә әйтми китүе мөмкин түгел... Ул үзенең беренче чор иҗатында ук нәниләр әдәбиятына ныклап күңел сала, аны тергезеп, тернәкләндереп, үстереп җибәрүче була һәм гомеренең соңгы көннәренәчә бу изге миссияне кулыннан төшерми. Моны, барыннан да элек, шагыйрьнең шәхес үзенчәлеге итеп: күңеле белән сабый җанлы булып калуы, сәнгатьчә фикерләвенең дә нәкъ менә шул сабыйлык рухына буйсындырылган булуы итеп аңларга кирәктер...

Габдулла тугыз яшенә чаклы авылда — табигать кочагында, шигъри күңелле авыл кешеләре, авыл малайлары арасында яши. Әнисе Мәмдүдә белән бабасы Зиннәтулла да шигырь чыгарырга яраталар. Шуңа ул балачакта алган тәэсирләрен гомер буена саклый һәм сагына. Аның сабый җанлылыгы шәхси бер үзенчәлегенә әверелә. Бу уңайдан, Тукай биографиясенә караган кайбер мәгълүматларга күз салыйк. Менә Ф. Әмирхан истәлеге: «Шагыйрь кайсы вакытта идарәханәгә («Әлислах» газетасы идарәсе) кесәсенә кузна тутырып килә дә, йорт хуҗаларының балаларын алып чыгып, ишек алдында бик кәефләнеп кузна уйный иде. Гәүдәсе белән үсмеррәк балалардан күп аерылмый торган Габдулла бу вакытта бөтенләй бер балага әверелә, муаффәкыятьле бер атыштан кәефләнгән сымак, муаффәкыятьсез бәрештән уңайсызланган сымак күренә иде...»[1]

Г. Камал шагыйрьнең Ф. Әмирхан «дача»сында яланаяк, яланбаш, күлмәк-ыштаннан гына, тирләп-пешеп, «ду күчереп», малайлар белән кузна уйнап йөрүен искә ала. Тукайның карусельгә битараф түгеллеге дә шагыйрьнең балачактагы үкенечле хатирәләренә барып тоташа.

Шагыйрьнең Петербургта транспорт күп йөри торган Невский проспекты аша чыгуын сурәтләгән юллар да кызыклы: «... аллага тапшырып, күзне йомам да Муса әфәнденең култыгына тотынам да, күзне ачканда ары якта булабыз. Күкрәгем куркудан шулкадәр суга ки, площадьтагы чиркәү төбендә 15 минут ял итмичә ары китә алмыйм.

Курыкмаска, ул урам — дию кебек. һәркөн үзенә бер-ике корбан алмый калмый...»

Соңыннан: «Байлар урамы ул! Шомалар урамы ул!»[2]— дип тә өстәп куя.

Күргәнебезчә, биредә дә шагыйрьнең үз-үзен тотышында һәм фикер йөртүендә балаларга хас чалымнар сизелеп китә. Әмма соңгы җөмлә безне уйга калдыра... Мон-

---

[1] Тукай турында хатирәләр. Казан, 1976, 72 бит.
[2] Тукай Г. Әсәрләр, IV том. Казан, 1977, 206—207 битләр.

дый гомумиләштерүне инде бары тик зур художниклык куәсе булган кеше генә ясый ала.

Китерелгән мисаллардан бер нәрсә ачык булса кирәк: Тукайның даһи сабыйлыгы гел үзе белән. Олуг шагыйрь булгач та ул әнә шундый сабый җанлылыгын ташламый. Һәм, бәлки, сабый җанлылыгын саклап кала алганы өчен дә олуг шагыйрьдер ул... Ни генә булмасын, Тукай балаларның үз шагыйре һәм аның самимилеге, сәнгатьчә фикерләвендәге конкретлык, образлылык сыйфатлары нәкъ менә балачактагы тәэсирләренең тирән уелып калуы һәм ачык булып саклануына бәйле.

Тукайның чынбарлыкны җисми, сиземле итеп күрүе һәм балаларча эчкерсезлек белән үзләштерүе олыларга язганда да бик ачык чагыла. Һәр нәрсәне рельефлы, тәэсирле, хисси кабул итүе, әсәрләрдә шигъри күрү, шигъри авазга әверелә:

> **Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;**
> **Һәр кара нәрсә бүре һәм һәр маяк булды карак.**
> («Буран»)

Әлеге детальләр буран сурәтен сиземле итеп кенә калмый, алар, бер үк вакытта, кеше күңелен, кеше халәтен чагылдыру чарасы да. Хәер, шигырьнең соңгы строфасында бу юнәлеш күз алдында:

> **Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә.**
> **Мин фәкыйрь михнәттә — гүя чарлагыннан бай көлә!**

Бу чагыштыруда инде табигать күренеше һәм аның кеше аңында җанлануы социаль мөнәсәбәтләрне чагылдырган картина булып үсә. Нәкъ тормыштагыча, Тукайның сабыйлыгы белән янәшәдә генә бөек шагыйрьлеге тора. Югыйсә, олылар күзеннән гадәттә читтә булган бакаларны мантыйк укыган шәкертләргә охшатып («Яз галәмәтләре»), тулы бер педагогик системаны үтергеч сатира уты белән көйдерү көче аңа кайдан килер иде...

Сабыйлык рухы Тукай әсәрләренең тематикасына да килеп керә. Аның бик күп шигырьләре — балалар өчен дә, олылар өчен дә уртак хәзинә. «Туган тел», «Пар ат», «Шүрәле», табигать, хайваннар тормышы я булмаса балачагын искә алуга багышланган башка күп кенә шигырьләр әнә шундыйлардан.

Инде шагыйрьне балалар әдәбиятына алып килгән кайбер объектив сәбәпләргә тукталып үтик.

Тукай, белгәнебезчә, 1905 елгы революция тәэсирендә, халкыбызның гасырлар буенча җыелган өмет-теләкләре хәрәкәткә килеп, билгеле бер күләмдә реальлек алып яши башлагач, татар мәдәниятенең милләт арысланнарына ихтыяҗы арткан бер чорда әдәбият мәйданына чыга. Аның әлегәчә бер эздән барган шигъри эзләнүләре бу чорда бик табигый тестә ачылып китә һәм Тукай, саф татар телендә яза башлап, поэтик иҗатында зур сикереш ясый.

Чор китергән, чор тудырган яңа агым, яңа хәрәкәт һәм яңа зарурият, һичшиксез, беренче чиратта, балаларга аң-белем, милли тәрбия бирү мәсьәләләренә килеп тоташа. Тукай, зур талант иясе буларак, бу ихтыяҗлыкка эндәшми кала алмый.

«Минем мәктәп китапларына керешкәнемне «җәл» дисең,— дип яза ул дусты С. Сүнчәләйгә.— Алай түгел. Мин мәктәпләребезнең хәл теле илә миннән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын кан белән карый алмадым. Мәктәп китаплары язарга башладым. Мин язган китапларымда (әлбәттә, хрестоматия) русларның Пушкины, Лермонтовы, Аксаковы, Майковы, Плещеевы вә башка да бик күбе булып являться итәм...»[1]

Әлеге хаттан Тукайның балалар әдәбиятына булган мөнәсәбәте һәм бу эшкә никадәр җаваплы караганлыгын күрү авыр түгел. Шагыйрь бу эшнең очраклы кешеләр кулына керүен теләми һәм ул җиң сызганып үзе эшкә керешә.

Аның мәшһүр рус язучысы И. А. Крыловтан һәм госманлы әдәбиятыннан алынып, «мөмкин кадәр татар мәгыйшәтенә борыбрак» ирекле рәвештә тәрҗемә ителгән

---

[1] Тукай Г. IV том. 113 бит.

65 исемдәге мәсәл-гыйбрәтле хикәясе 1906—1907 елларда чыккан «Әлгасрел-җәдит» журналында «Мәҗмугаи мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме астында басыла. Ул дәреслек-хрестоматияләр төзи, балалар журналы чыгару турында кайгыртып йөри... Болар барысы да әнә шул гомум бер эшнең, гомум бер омтылышның төрле чагылышлары. Әйе, Тукай балаларны ярата, аларны белемле итәргә «халык файдасын һәртөрле шәхси мөнафигыйннән... өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган» итәргә омтыла, алар язмышын уйлап тирән борчыла, «теләнче фабрикасы» булган мәдрәсәләрдәге укыту-тәрбия эшләрен яхшыртуга конкрет ярдәм-эшчәнлек күрсәтә.

Аның балаларга якынлыгы иң элек, әлбәттә, әдәби әсәрләрендә ачык чагыла. 1907 елда ук инде ул «Пар ат», «Шүрәле», «Ишек бавы», 1908 елда «Таз», «Су анасы» кебек мәшһүр әсәрләрен яза. Җитмешләп шигырь, йөздән артык кечкенә хикәя, мәсәл, балалар әдәбиятын кайгыртып язган публицистик мәкаләләр — олуг шагыйрьнең җидесигез ел эчендә балалар әдәбиятына, аның нигез ташын салышучыларның берсе буларак, керткән өлеше әнә шундый! Аның үзе исән чакта ук балалар өчен «Җуаныч» (1908), «Алтын әтәч» (1909), «Энҗе бөртекләре» (1909), «Яңа кыйраәт» (1909), «Исемдә калганнар» (1909), «Балалар күңеле» (1909 һәм 1910 еллар), «Күңелле сәхифәләр» (1910), «Күңел җимешләре» (1911), «Мияубикә» (1911), «Сабыйның укырга өйрәнүе» (1912) җыентыклары дөнья күрә.

Бүгенге көнгәчә шагыйрьнең китаплары татар, рус һәм СССР халыкларының утыз телендә, шулай ук гарәпчә 3 миллионга якын тираж белән 200 дән артык исемдә басылып чыккан. Әлбәттә, бу гомуми әдәби хәзинәнең иң түрендә балалар поэзиясенең гүзәл үрнәкләре дә лаеклы урын алып тора.

Тукайны балалар поэзиясенә алып килгән һәм аңа бу юлда зур йогынты ясаган сәбәпләрнең тагын берсе — аның тәрҗемә эшчәнлеге. Эш шунда, шагыйрьнең 70 ләп шигыре турыдан-туры балаларга багышланган һәм шуның 20 дән артыгы рус һәм дөнья поэзиясе үрнәкләреннән тәрҗемә, яисә алардан файдаланып иҗат ителгән. «Бала белән күбәләк», «Җәйге таң хатирәсе», «Җәй көнендә», «Эш беткәч уйнарга ярый» кебек кечкенәдән безнең күңелгә үз һәм якын булып кергән әсәрләрнең тәрҗемә икәнлегенә ышанасы да килми. Чөнки, алар милли аһәң белән шул дәрәҗәдә өртелгәнннәр!

Чыннан да, Тукай тәрҗемәсе — гади тәрҗемә түгел,— аның асыл үзенчәлеген билгеләү — зарури, һәм ул, мәсьәләгә конкрет тукталуны сорый.

Тәрҗемә итү, беренче чиратта, әлеге әсәрне пропагандалау, аңа тәрҗемә ителәсе телдә яңа яшәеш, яңа җан бирү. Тукайның үз иҗатында рус һәм Көнчыгыш әдәбиятына мөрәҗәгать итүе, тәрҗемәгә аларны сайлавы да иң элек татар укучысын бу әдәбиятлар яулаган биеклек белән таныштыру ниятенә бәйле. Халыкчанлык һәм реализм юнәлешенең зур үсешенә ирешкән рус әдәбияты Тукайга аеруча якын һәм уңай йогынты ясый. Тәрҗемә иткән авторларының Жуковский, Пушкин, Лермонтов, Никитин, Майков, Плещеев, Позднякoв, Крылов, Ушинский, Толстой кебек мәшһүр һәм алдынгы карашлы рус әдипләре икәнлеген исәпкә алсак, бу җәһәттән татар укучысы алдында Тукай башкарган хезмәтнең ни дәрәҗәдә зурлыгын ачык күзалларга була.

Тукай тәрҗемәләренең әһәмияте бер татар милләтенә генә карамый. Башка бик күп Көнчыгыш халыклары да Тукайны алдынгы рус әдәбияты белән арадашчы итеп таныдылар.[1]

Рус әдәбиятыннан тәрҗемә Тукай өчен чын-чынлап өйрәнү-остalык мәктәбе була, аңа шигъри осталыгын камилләштерү өстенә, балалар психологиясен һәм балалар әдәбияты спецификасын тирән үзләштерү мөмкинлеге дә ача.

Белгәнебезчә, Тукай бервакытта да төп нөсхәгә «ябышып ятмый». Киресенчә, «это глухое место» тәгъбирен «бу — чукрак урын», «жили-были дед да баба»ны «торды булды бабай да әби» дип, сүзен сүзгә «аударган» «дөрес тәрҗемә»ләрдән ул ачы көлә. Аның тәрҗемәдә остазы итеп күренекле рус шагыйре В. А. Жуковский исемен атавы очраклы түгел. Тәрҗемәләре оригиналдан кайсы ягы беләндер аерыла икән, димәк, ул нәрсәнедер, мөстәкыйль, иҗади хәл иткән. Әлеге аерымлык, үз чиратында, шагыйрьнең иҗат йөзен, иҗат үзенчәлеген, аның иҗтимагый карашын,

[1] Кара: Тукайга чәчәкләр. Казан, 1975.

идея-эстетик юнәлешен чагылдыручы бер билге булып тора. Моны без шагыйрьнең мөстәкыйль иҗатка табан булган төрле эзләнү этаплары итеп күзаллыйбыз һәм аның дүрт төрен аерып карарга мөмкин дип исәплибез.

Беренчесе — нигездә тел үзгәлегеннән килеп чыккан аерымлык. Әйтик, Крыловтан тәрҗемә иткән «Төлке һәм йөзем җимеше» мәсәлендә «Хоть видит око, да зуб неймет» тәгъбирен Тукай татарча итеп «күз күрә, җитмидер буй» дип ала. Ә инде «Да зелен-ягодки нет зрелой: тотчас оскомину набьешь» ны түбәндәгечә тәрҗемә итә:

Йөземнәр чи әле, өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр, ди,
Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә аннар, ди.

Күрәбез, рус тасвир-детальләре татарча бөтенләй башка тел чаралары, тәгъбирләр белән алыштырыла, әмма моңа карап нәтиҗә үзгәрми — әсәрнең гомуми шигъри рухы саклана, ул гына да түгел, шигырьнең эчке фикер-хис үсешеннән чыгып карaганда, моның бердәнбер юл, бердәнбер дөрес поэтик чишелеш булуына ышанасың. Гомумән, шигырьдәге сүз Тукай өчен гади сүз түгел, ул аны билгеле бер шигъри компонент, шигъри бөтеннең күзәнәге буларак күзаллый, татар телендә дә шундый ук хис, мәгънә, ассоциатив юнәлеш бирердәй эквивалент эзләп табарга тырыша. Тукай бу очракта чын-чынлап шигъри рух тәрҗемәчесе: шигъри детальләр белән оста художникларча эш итә, образлар системасының үзенчәлеген югалтмаган хәлдә тәрҗемә, әсәрне милли яңгырата.

Ләкин шунысын да әйтеп үтик, Тукайда мондый тәрҗемәләр күп түгел,— аларның оригиналдан аерымлылыгы күпчелек очракта милли тел үзенчәлекләренә генә кайтып калмый.

Икенче төр аерымлык Тукайның художестволы фикерләү үзенчәлегенә бәйле. Тукай гаҗәп дәрәҗәдә конкрет уйлый, конкрет күрә һәм бу гүзәллек аның шигъри тасвирлауларында да чагылыш тапмый калмый. Ул хәтта оригиналда абстракт тестә бирелгән төшенчә-фикерләрне дә күз алдына конкрет итеп бастырырга омтыла. Оригиналда билгеле бер күләмдә конкретлык алган тасвирларны шагыйрь тагын да тулыландырып, сиземлерәк итеп бирергә омтыла. Әйтик, «Стояла лестница однажды у стены» («Лестница», А. Е. Измайлов) юллары Тукай «Баскычында»:

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар — бик авыр һәм дә озын баскыч.

— рәвешендә бирә. Хәер, шагыйрь аның тышкы рәсемен генә тулыландырып калмый, хәтта андагы басмаларның үзара сөйләшүләрен дә ишетеп ала. Күп төрле тәфсилләүләр, синоним сүзләрнең әсәрдә шактый мул кулланылуы да әнә шуның белән бәйле.

Мәсәлән, А. М. Федоровның «Рассвет» шигырендәге:

От сияния победной
Алой утренней зари
Грустно меркнет месяц бледный...

юлларын Тукай:

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата,

дип тәрҗемә итә. Синоним сүзләрнең саналып китүе бирелә оригиналны тулырак җанлырак күзалларга булыша.

Тукай — табигате белән гаять тәэсирләнүчән һәм нечкә күңелле шагыйрь. Үзе тәрҗемә итәргә алынган әсәрдән дә ул, күрәсең, бик нык тәэсирләнгән. Шуңа күрә ул еш кына текстны, андагы образ-детальләрне тасвир итеп кенә калмый, ә бәлки үзе тойган, үзе күзаллаган рәвештә әсәрнең юлара мәгънәсен дә ачып салырга ом-

тылыш ясый. Әлбәттә, бу гади аңлатып бирү түгел. Тукай моны тасвирның потенциаль көчен арттыру исәбенә эшли.

Конкретлык ул образлылыкның нигезендә ята, ә образлылык исә сүзгә өстәмә поэтик мәгънә бирү дигән сүз. Тукай моны бик яхшы аңлап эш итә. Әйтик, А. В. Кольцовтан тәрҗемә иткән «Мужик йокысы»нда ул үзлегеннән «синең йортта аш юк туярлык таракан» юлларын кертеп, конкретлаштырып җибәрә икән — бу «синең ашарыңа юк» дигән фикерне әйтер өчен генә кулланылган деталь түгел. Әйе, биредә гипербола рәвешендә бу фикер дә ассызыклап әйтелә. Әмма конкретлык образга өстәмә мәгънә дә китереп өсти: ашарына булмаса да — өе тараканлы икән әле... Шагыйрьнең балалар поэзиясенә мөрәҗәгать итүе белән, әлеге иҗади өйрәнү тагын да катлаулана төшә. Биредә тәрҗемә авторының конкретлыкка омтылуы да, төп нөсхәдән читкә китүе дә балалар психологиясенә бәйле төс ала.

А. Н. Майков:

**Полноте, дети, его мы сберем,**
**Только сберем золотистым зерном**
**В полных амбарах душистого хлеба.**
(«Летний дождь»)

Г. Тукай:

**Тиз ул алтыннарны амбарга төярбез барчасын.**
**Тик җыярбыз юл буе шыгрым тулы йөкләр көе,**
**Бар келәтләр туп-тулы хуш исле орлыклар көе!**
(«Яңгыр»)

Күргәнебезчә, «юл буе шыгрым тулы йөкләр көе» детален Тукай үзе өсти. Әлеге җанлы сурәтнең нәкъ менә бала күңеленә юнәлдерелгән булуы, нәкъ менә аның психологик үзенчәлекләрен истә тотып кертелүе бәхәссез.

Тукай тәрҗемәләренең композицион үзгәреш алган төрләрен дә билгеләп үтәргә кирәк. Бу үзгәреш шигъри күләм, структурада, әсәрдәге образлар системасының төзелүендә ачык күренә. Шул уңайдан, Тукайның «Кышкы кич» шигырен һәм аның оригиналы булган «Зимний вечер» (А. Н. Плещеев) әсәрен чагыштырып карыйк. Иң элек күзгә ташланган аерымлык — Тукай тасвирлавының конкретлыгында, тәрҗемә ритмикасының тәфсилле, салмак яңгыраш алуында.

А. Н. Плещеевта:

**Пусть гудит сердито**
**Вьюга под окном.**
**Хорошо вам, детки,**
**В гнездышке своем.**

Г. Тукайда:

**Тышта иссен ачы җилләр, тузсын карлар,**
**Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,**
**Суыклыктан очар кошлар очалмасын,—**
**Сезнең урын җылы, әйбәт, — ни кайгы бар!**

Күргәнебезчә, татарча текст, Тукай тәрҗемәләренә хас булганча, синоним-тәфсилләү, өстәмә шигъри детальләр исәбенә шактый киңәя, тулылана. Әмма аерымлык моның белән генә чикләнми. Әйтик, оригиналда ярлы һәм ятим балалар тормышына капма-каршы кую нияте белән тасвирланган гамьсез күңел ачу, уен-көлке күренешләрен (16 юл) Тукай бөтенләй төшереп калдыра һәм алар урынына — «татар тормышына борып» тасвирланган үз шигъри детальләрен кертә: аның нәни геройлары — гади крестьян балалары, нәкъ менә кызганыч әкият тыңлагандагыча, басынкы-уйчан, хыялый һәм эчкерсезләр. Янәшәдә генә — «яшьле күзле, моңланганнар, әә зарлылар»... һәм алар бу йортсыз-җирсез ятимнәрне — бәхетсезләрне, шагыйрь абыйлары әйткәнчә үк, күңелләреннән ярата һәм юата да башлаганнардыр сымак...

Шулай итеп, Тукай, реалист шагыйрь буларак, милли тормыш үзенчәлекләре җирлегендә герой һәм аның эчке кичерешләре үсешенә дә шактый гына үзгәрешләр кертә. Бу исә, үз чиратында, тәрҗемә һәм оригиналның композицион аерымлыгын тудыра. Без моны «Җәйге таң хәтирәсе», «Сәрләүхәсез» шигырьләрендә ачык күрәбез. «Баскыч» шигырендәге Наполеонга нисбәтән тасвирлаган соңгы дүрт юл да төшереп калдырыла һәм баскычка бәйле аллегорик мәгънә, гомумилеген югалтмыйча, үзенең шигъри яңгырашын укучыга тулырак, колачлырак итеп җиткерә.

Тукай тәрҗемәләре белән оригинал арасындагы тагын бер төр аерымлык аның беркайчан да оригиналга «ябышып ятмавында». Үз иҗат интересларына, үзенең иҗтимагый һәм эстетик карашларына аз гына җавап бирмәгән очракта да ул шундук аңардан читләшеп, мөстәкыйль иҗатка күчә. Оригинал исә аңарга билгеле бер юнәлештә үсү мөмкинлеге тудырган этәргеч көч, шигъри башлам булып хезмәт итә. Чөнки, ул тәрҗемәгә сайлаганда ук күпмедер дәрәҗәдә үз зәвыгына якын әсәргә тукталырга тырыша.

Әйтик, аның «Карлыгач» шигыре И. С. Никитинның «Гнездо ласточки» исемле әсәреннән файдаланып язылган. Оригиналда су тегермәне һәм анда он тарту күренеше, тузанга-онга баткан исерек карт тегермәнче тормышы, аның хатынын, балаларын кыерсытуы, этенең качып китүе һ. б. тасвирлана. Шуннан соң гына сүз карлыгачка күчә. Менә ул строфа:

**Одна певунья-ласточка**
**Под крышей обжилась,**
**Свила-слепила гнездышко,**
**Детьми обзавелась.**

Әмма шигырьнең моннан соңгы үсеше яңадан тегермәнгә бәйле тестә дәвам итә. Тукайда исә бу шигырь беренче юлыннан ук бөтенләй икенче яңгыраш ала:

**Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын**
**Оя итте минем сөйгән карлыгачым...**

Биредә әсәрнең сюжет-композициясе дә, образлар бирелеше дә гел икенче яссылыкта, икенче юнәлештә. Әлеге шигырьнең файдаланып язылуын да кайбер очраклы детальләр аша гына сиземләргә мөмкин. Тукай тәрҗемәләренең күпчелеге әнә шундый мөстәкыйль яшәеш алган — «файдаланып язылган» әсәрләр. Аларның еллар үтү белән төссезләнмәве, озын гомерле булуы үзләренә салынган потенциаль шигъри көчнең зурлыгына һәм чынлыгына бәйледер, күрәсең.

Тукайның балалар өчен язган шигырьләре, балалар фольклоры кебек үк, төрле һәм күпкырлы. Аларның бу үзлеге, шул чор шагыйрьләренең әсәрләре белән янәшә куеп караганда аеруча нык күзгә ташлана. Тукай чордашлары нәниләр поэзиясенең (бу — шигырь үзенчәлекләренә дә, бала психологиясен ачуга да карый) тәгәяки бу өлкәсенә генә мөрәҗәгать иткән бер вакытта, Тукай, зур талантларга хас булганча, чынбарлыкның шигъри чагылышын тулысы белән колачлап алырга, аның һәр тармагын үз иҗатында тигез дәрәҗәдә үстерүгә омтыла.

Тематик яктан Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен дүрт зур төркемгә берләштереп карарга мөмкин: табигать күренешләрен тасвир итү; нәни укучыны җәнлек, кош-корт, йорт хайваннары белән таныштыру; балаларның үз тормышларын чагылдыру; Ватан, халык, милләт кебек тарихи-социаль эчтәлекле әсәрләр.

Шигъри әсәрләрне дә әлбәттә, әлеге гадидән катлаулыга таба үсә барган тематик бүленеш, тематик системада анализлау уңай булыр иде кебек. Ләкин Тукайда без, киресенчә, гади табигать күренешләрен тасвирлаган шигырьләрнең шактый катлаулы поэтик структуралы булуын, ә катлаулы социаль темаларның чагыштырмача гадирәк шигъри образлар системасы аша бирелүен күрәбез. Тематик анализ белән генә чикләнгәндә, әсәрнең эстетик кыйммәте, авторның балалар психологиясен нинди дәрәҗәдә үзләштерә алуы кебек иң мөһим үзенчәлекләр ачылмый калыр иде.

Безнеңчә, алар авторның балалар шигыре алдына куйган максаты һәм аңа ирешү юлларын күзаллаганда гына тулырак чагылырга мөмкин. Бу уңайдан, Тукай шигырьләренең ике төп максатка буйсындырылуын, аларда шигъри танып-белү һәм тәрбияви юнәлешнең өстенлек алуын күрергә була.

Шигъри танып белү турыдан-туры баланың танып-белүгә булган омтылышы һәм танып-белү үзенчәлекләренә нигезләнеп барлыкка килә.

Көз көнендә һәр төрле яшеллекләр: үлән-агачлар, хәстә төсле, сары төскә керә. Әмма арада төс үзгәртмәс берсе бар... Нәкъ табышмактагыча! Әлеге сораубилгесезлек баланың белем-тәҗрибәсен, зирәклеген сыный. Ул сорауның җавабы исә әсәрнең шигъри чишелеше булып китә:

**Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.**

Әлеге табышмак принцибын, ягъни проблемалы ситуация аша белем-мәгълүмат бирүне без авторның «Елның дүрт фасылы» шигырендә дә очратабыз:

**Ашлыклар үсте,**
**Башаклар пеште;**
**Кояш пешерә,**
**Тиргә төшерә.**

**Халык ашыга,**
**Китә басуга,**
**Урагын ура,—**
**Бу кайчак була!**

Биредә исә җавап әлеге мозаик сурәт, җәйнең характерлы сыйфатларын берләштергән шигъри картинадан килеп чыга. Ягъни, бала җавап табу өчен иң элек күңелендә, аерым билгеләрен бергә җыеп, җәй сурәте тудырырга тиеш була. Әсәрнең төп эстетик кыйммәте дә әнә шунда — дөньяны шигъри танып-белүдә, күрәсең. Әсәрнең җиңелчә ритмы, янәшә рифмалар, сурәтнең киеренке хәрәкәтне тоюга буйсындырылуы, образлар системасының шигъри бизәкләрне җыюга корылуы — барысы да балалар психологиясе үзенчәлекләрен истә тотып эшләнгән.

Тукай еш кына төп игътибарын чынбарлыкны шигъри күрүгә юнәлдерә. Бу очракта реаль дөнья балага үз төсендә тәкъдим ителмичә, шигъри призма аша яктыртыла.

Менә аның «Ай һәм Кояш» шигырен алып карыйк:

**Һималай тау өстендә алтын бишек,**
**Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп;**
**Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп,**
**Оядагы йоклап яткан кошчыклардай.**

Планета — йолдызлар дөньясы биредә, кеше тормышы аша җанландырылып, балалар күзалларлык хыялый картина рәвешендә тәкъдим ителә. Тукайның табигать турындагы шигырьләре, гомумән, әнә шундый шигъри күрүгә нигезләнеп туа. Пәрдәдән чыккан ямь-яшел кыр һәм япан, сандугачлардан яңгыр кебек яуган мәдхияләр, әлеге табигать күркен күрергә тукталган «аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме» («Җәйге таң хатирәсе»), «ап-ак балыклар күк», иртәдән кичкә кадәр судан чыкмаган балалар («Җәй көнендә»), «язга чаклы уйкуга талган һәм тәмле төш күреп йоклап яткан җир» («Җир йокысы») һ. б. әнә шуның мисалы.

Әлеге шигъри детальләрнең нигезендә сәнгати шартлылык, дөньяны хыялый күзаллау ята. Гади генә табигать күренешләренең дә шундый тылсымлы, серле яшәеш алуы, һичшиксез, бала күңеленә бик хуш килә.

Үзенең әкиятләрен язганда да Тукай баланың нәкъ әнә шушы хыялый үзенчәлегенә таянып иҗат итә. Биредә инде әсәр, әлбәттә, баштанаяк әкияти шартлылыкка корылган. Әмма шунысы кызыклы, Тукайның балалар өчен язган күп кенә шигырьләрендә реаль чынбарлык шартлы сурәт аша чагылыш тапса, аның әкиятләре, киресенчә, гаҗәеп реальлек белән сугарылган. «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Су анасы» һ. б. әкиятләрнең әкият икәнлегенә һич ышанасы килми. Тукай әсәрләрендәге шартлылыкның шундый синтетик характерлы булуы кайчакта әдәбият га-

лимнәрен дә аптырашта калдыра. Аларның теге яки бу әсәрне әле романтик әсәр дип, әле реалистик дип бәяләргә омтылулары очраклы түгел.

Әкиятләрнең реаль төсмер алуы, күрәсең, халык фантазиясенә, аның меңнәрчә еллар дәвамында үсеп, баеп килгән шигъри хыялына нигезләнү белән бәйледер. Тукай иҗатында алар яңа шигъри биеклек алалар.

Тукай чынбарлыкны үзләштерүдә хисләр гармониясенә дә зур әһәмият бирә. Аның лирик кичерешле, хыялый-моңсу, кызгану-теләктәшлек тойгылары белән өртелгән шигырьләренә еш кына юмористик аһәң килеп керә. Җитдилек көлү-шаяру, шигъри уен белән үрелеп китә. Ул баланың оптимистлыгын, күңел күтәренкелеген, шаянлыкка булган ихтыяҗын тирәнтен аңлап эш итә. «Күңелле сәхифәләр», «Кечкенә музыкант», «Таз», «Гали белән Кәҗә», «Кәҗә белән Сарык хикәясе» һ. б. әсәрләрендә без Тукайның зур юмор остасы булуын күрәбез.

Тукайның шигъри шаярулары гадәттә халык рухы, халык фантазиясе белән сугарылган. Аларның кайберләре турыдан-туры тормышка, фольклорга барып тоташа. Әнә «Таз» шигырендәге шәкерт, зирәклеге аркасында үзен һәм иптәшләрен казый чыбыгыннан коткарып кала. Былтыр кысканга быел кычкырып көлкегә калган Шүрәлене искә төшерик. «Ишек бавы»ндагы шаянлыкның да халык гореф-гадәтләренә нигезләнүен, бала күңеленең халык рухы белән бер бөтен булып кушылуын күрми мөмкин түгел.

Юмор, әлбәттә, сюжетта гына түгел, гомумән, шигъри образлар ясалышына да үтеп керә. «Гали белән Кәҗә» шигырендә Кәҗәнең рәхмәт әйтүен бала әнә шулай конкрет деталь аша — сакал селкетүе аша күзаллый. Һәм бу балаларча дәлил бездә елмаю тудыра. Рәхмәт уку, сакал селкетү кебек детальләрнең милли үзенчәлеге шигъри күзәнәкләрдә үк яшәеш таба. Шунысы әһәмиятле, аларның һәммәсе дә бала психологиясе үзенчәлекләрен истә тотып эшләнгән.

**Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;**
**Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.**
**(«Кызыклы шәкерт»)**

Алдагы шигырьдә «рәхмәт укыган» Кәҗә дә, әлеге иркә Акбай да, асылда, баланың үзе. Аның сәнгать геройлары аша гәүдәләнгән күңел чагылышы. Шуңа да баланың Акбай белән сөйләшүе — әйтерсең үз-үзе белән бәхәсләшүе, әйтерсең ул аның эчке кичерешләре. Чын спектакльләрдәгечә: әнә ул шәкерт ролендә, әнә ул укытучы ролендә,— үзенең кайчандыр олылардан ишетеп белгән тәрбия сүзләрен әйтеп уйный:

**Ах, юләр мәэмай! Тырыш яшьләй,— зурайгач җайсыз ул;**
**Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!**

Баланың укытучы роленә кереп, хикмәтле сүзләр әйтүе шигырьдә елмайту тудыра.

Тукайның күп кенә шигырьләрендә тәрбияви мотивлар өстенлек итә. Шагыйрь бала белән күзгә-күз карап сөйләшә, төрле максаттан чыгып, бала күңеленә үтеп керү һәм тәэсир итүнең төрле юлларын таба. Шуңа ул шигырьләр я хикмәтле, я гыйбрәтле, я тасвирый-психологик картина буларак тәкъдим ителә,— гадәти сүзләр Тукайча гади һәм сәнгатьле тәрбия көченә әверелә.

«Эшкә өндәү» үзенең беренче юллары белән үк хикмәтле булып яңгырый:

**Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә...**

«Сабыйга», «Бәхетле бала» шигырьләре дә нәкъ әнә шундый хикмәтле булуы белән характерлы.

«Баскыч», «Борын» һ. б. гыйбрәтле шигырьләрдә исә гыйбрәтлелек аллегория, мәсәл рәвешендә чагылса, шагыйрьнең «Су анасы» әсәрендә ул кеше әйберенә кул тидергән малайның үкенүе, психологик кичерешләре аша тасвир ителә. Тискәре үзлекләр генә түгел, уңай, үрнәк сыйфатлар да гыйбрәтле булырга мөмкин. «Сөткә

төшкән тычкан» шигырендә, әнә тычкан зур түземлек күрсәтеп сөттә йөзә торгач, май атланып, үзенә котылу әмәлен таба. Кыю фантазия җимеше гыйбрәтле тәрбияви көч булып китә.

Гыйбрәт нигезенә алынган уңай һәм тискәре характер үзенчәлекләре еш кына кимчелектән көлү, аннан ваз кичү яисә яхшылыктан үрнәк алу кебек бер генә юнәлештә булмыйча, аралашып, бәхәс-көрәш аша вакыйга үсеше итеп бирелә. Бу очракта, һичшиксез, әсәрнең егәрлеге, тәэсир итү көче тагын да көчәя төшә. Әйтик, «Япун хикәясе»ндә Ташчының үз эшен ташлап, әле бай, әле хан, әле кояш, әле болыт, әле тауга әверелүе, ләкин ахырда кабат иҗтиһадлы эшче булып калуы— әнә шундый каршылыклар аша алынган гыйбрәт. «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырендә без гыйбрәтнең катлаулы психологик кичерешләр, баланың үз күңеле белән көрәшүе аша бирелүен күрәбез.

Шунысына игътибар итик: алда телгә алынган ике шигырьдә дә эпизод-картиналар кинокадрлар кебек әледән-әле алышынып тора. Ташчы егетнең бер сурәттән икенчесенә күчеп йөрүе, соңгы әсәрдә баланың Кояш, Сандугач һәм Алмагач белән сөйләшүе туктаусыз яңарып торган, җанлы тормыш күренешләре булып истә кала. Әлеге «чылбырлы», кумулятив сюжет сызыгы, хәрәкәт бала игътибары үзенчәлекләрен истә тотып эшләнгән һәм ул бик эффектлы нәтиҗәләр бирә.

Әлбәттә, без әлеге гыйбрәтле шигырьләрнең кичерешләрне турыдан-туры тасвирлаган монолог, я булмаса диалог рәвешендә бирелгәннәрен дә очратабыз. «Кошларга» шигырендә ул, мәсәлән:

**Курыкмагыз, кошлар, күреп сез янгызда мин барын;**
**Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым,**

рәвешендәге монолог буларак тәкъдим ителә. «Кошчык», «Туган авыл» шигырьләрендә дә шул ук хәл. Ә менә «Фатыйма белән Сандугач», «Бичара куян», «Бала белән Күбәләк», «Кызыклы шәкерт» шигырьләре кара-каршы сөйләшүгә корылган. Аларның һәрберсе үзенә күрә кечкенә бер спектакль, кечкенә бер театр. Баштагы әчесе лирик кичерешле театр, ә соңгысы уйнак-шаян рухта. Шагыйрь шулай итеп хисләр гармониясе тудыра.

Тукай иҗатында шигъри танып-белү һәм тәрбияви моментлар еш кына бергә кушылып килә һәм аларның кайсысы өстенлек итүен аерып әйтүе дә кыен, «Карлыгач», «Су анасы», «Кышкы кичтә» шигырьләре әнә шул яктан характерлы.

«Гомер юлына керүчеләр» шигырендә, мәсәлән, автор балаларны гаять катлаулы тема — яшәү мәгънәсе турында сөйләшүгә чакыра.

**Нигә, дим, изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым!**
**Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зур-зур Тукай булдым!**

«Гомер итмәк»лекнең гаять җаваплылыгын шулай әйтә, сабыйлыгын сагына шагыйрь, сабый чакның кадерен белергә һәм тырышып, ялыкмыйча белем алырга кирәклекне исбат итә.

Тукайның тематик яктан һәм хисләр гармониясе тудыру ягыннан, жанр һәм максат бердәмлеге ягыннан синтетик характерлы шигырьләре укучы баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуда да универсаль. Аның бик күп шигырьләре һәрбер яшьтә аңлаешлы, һәрбер яшьтә кызыклы. Аларның художестволы гомумиләштерү көче чикләнмәгән, «Туган авыл» шигыре дә әнә шул яктан кызыклы:

**Тау башына салынгандыр безнең авыл,**
**Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;**
**Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,**
**Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.**

Әлеге шигъри сурәт, шигъри яңгырашны без гомер буе күңелебездә саклыйбыз. Аның нигезендә геройның балачагын искә төшерү ята түгелме соң?

**Истән чыкмый минем монда күргәннәрем,**
**Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;**
**Абый белән бергәләшеп, кара җирне**
**Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.**

Әйе, биредә без балачагыннан аерылыр-аерылмас борын аның белән саубуллаша да башлаган лирик геройны күрәбез. Ул үзен олыларча хис итеп, сабый чакларын искә төшерә. Әмма аның күзаллавы, фикерләве әле балаларча. Хәер, соңгы строфада лирик герой үзе үк:

**Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,**
**Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем,**

— дип куя. Бу аның әле юл башында торуы һәм киләчәккә карап үзенчә күңеленә изге бер антын беркетеп куюы турында сөйли. Шигырь туган җиргә, туган якка шигъри караш, эчкерсез мәхәббәт хисе алып килә. Ул карашның киләчәккә төбәлгән булуы да балага үз-якын. Бүгенге туган авыл матурлыгы аша шагыйрь үткән белән киләчәкне бергә бәйли... Тукайның масштаблы фикерләве биредә бик ачык күренә. «Рус җирендә без әсәрле, әзле без», дип милләт һәм Ватан төшенчәләрен бер бөтенгә әверелдергән патриотик рухлы шигърият, мөгаен, әнә шул туган авыл чишмәсеннән саркып чыгадыр...

Ә туган авыл чишмәсен, туган җир моңын, туган як авазын ишетү иң элек бишек җырларыннан башлана. Бишек җырларыннан, туган телдән.

**Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән...**

«Туган тел» шигыре аерым бер язмышка ия. Ул беренче тапкыр шагыйрьнең «Балалар күңеле» (1909) җыентыгында басылып чыга һәм шул көннән башлап татар дөньясының иң мәшһүр шигъри әсәрләреннән берсенә әверелә. Юк, ул шигырь генә түгел, ул — халык рухының әйтеп бетерелмәгән эчке бер авазы, «халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгесе». Шуңа да аның бишектән алып соңгы сулышкача күңелне җылытып, иркәләп, нурландырып торуы гаҗәп түгел. Тарихи язмышы шулай килеп чыккан ки, «Туган тел» халкыбызны, Ватаныбызны яратуның бер символик яңгырашына әверелгән. Аның «кечкенәдән аңлашылган» шатлык һәм кайгы көен, моңын тоя белү — халкыбызның рухын аңлауда иң беренче адымдыр, мөгаен. Мондый бәхетле язмыш теләсә кемгә һәм теләсә нинди әсәргә бирелми. Халык аны күз карасы итеп, намусы итеп саклый һәм күңелендә йөртә. Ә ул, үз чиратында, халыкны киләчәккә алып бара һәм аны озын гомерле итә.

# БЕЗ КЕМНӘР?

Әбугалисина кайбер сырхауларны карый да, моңа үләннәрдән ясалган дару шифа булмас, моңа күңел даруы кирәк, ди икән.

Күңел даруы... Күңелем ярсыган вакытта, моңсуланган, яисә, киресенчә, сүрелеп битарафланып калганда, мин кулыма китап алам. Менә әле дә Фәннур Сафинның яңа гына басылып чыккан «Сез кемнәр?» исемле китабы кулымда.

Җыентык беренче битләреннән үк:

**Шартлаулар, янгыннар яктыртса,**
**Барыбер караңгы ул төннәр...**
**Шул төндә яндыгыз, туганнар,**
**Менә бит сез кемнәр, сез кемнәр!**

дигән ярсулы юллары белән күңелне биләп ала, йөрәккә «гөлт» итеп ут кабына. Шушы дүрт юлны укуга, илебезнең бөтен тарихы күз алдына килә, береннән-берсе дәһшәтлерәк картиналар пәйда була. Шул ук вакытта бу шигырь — бөтен дөньяның катлаулы тарихы һәм катлаулы бүгенгесе турында да.

Әйе, үлән-яфракларны җылы яңгыр юып киткән кебек, чын шигърият белән очрашу кеше күңелен aклый, пакьли. Әгәр дә шигырьләр яшәү шатлыгын тагын да ныграк тоярга ярдәм итсәләр, кешенең рухын күтәрсәләр, хезмәт-көрәшкә чакырсалар, кеше шундый поэзия белән очрашудан икеләтә ота.

Фәннур Сафинның бу җыентыгы дүрт «бакчадан» — бүлектән тора. Бүлекләрнең берсе чынлап та «Алма бакчасында» дип атала. Калганнары: «Без кемнәр?» «Ак күбәләк патшалыгы», «Ярсу тынлык». Һәр бакчаның — үз яме, үз матурлыгы, үз җимеше. Бүлекләрнең һәрберсенә шагыйрьнең йөзен кызартмый торган, көчле, хисле, ә кайберләре, безнең карашка, иң югары таләпләргә җавап бирерлек шигырьләр кергән. Алар яшь шагыйрьнең иҗат юлында сизелерлек эз калдырыр дип ышанасы килә.

Әгәр дә киләчәк буыннар хәтерендә калсам иде дип яши икән, кеше, үз чорын узып китәргә тиеш, кешелеккә файдалы эше, уе-идеалы белән киләчәктә яшәргә тиеш. «Безнең токым» шигыре әнә шул турыда:

**Узган буын утка кергән чакта**
**Якты җиңү җырын җырлады —**
**Без очарга тиеш чорны узып —**
**Алга әйдәп гаҗәп дөньяны.**

Яшьләргә хас булганча, Ф. Сафин җете төсләр кулланырга ярата, ләкин шул төс— сүзләрдән туган рәсем-шигырь укучыны шагыйрь фикеренең тышкы катламында гына туктатып калдырмый, ә аның фәлсәфи тирәнлегенә чакыра.

Менә «Ярсу ат» шигыре. Яшел болынлы су буйлары, кичке шәфәкъ. Шагыйрь көтелмәгәнрәк тәңгәллеккә омтыла кебек: ярсып уйнаклап йөрүче ат һәм кичке шәфәкъ. Әмма, уйлап карасаң, ат үзе — туган ил символы булырлык мәһабәт җан иясе, һәм, гомумән, ышанычлы җан иясе, табигатьнең кадерле бер кисәге. Шунысы кызык, шәфәкъ сүзенең гадәттә күңелгә бераз шом салу хасияте булса да, биредә алай түгел, күңелгә һич шом-шөбһә килми, чөнки ат (гәрчә ул ярсу булса да) рәхәтләнеп уйнаклап йөри, һәм тиңлек-гармониялек күренешенә шул бер сүз — «уйнаклый» сүзе белән ирешелә дә: ат уйнаклый, шәфәкъ уйнаклый. Табигатьтәге гармония сакланса, җир дә имин булыр дигән уй күңелгә килә.

Шагыйрьләребезнең күбесенә хас бер күренеш бар: моң сүзенә мөрәҗәгать итү гадәте. Соңгы елларда моң төшенчәсенең эчтәлеге киңәя бара кебек. Бу төшенчә безнең халыкның характер үзенчәлеген күрсәтә: шагыйрьнең шигырь байлыгы — халык күңеле, барысы да шуннан килә... Ф. Сафинда әлеге моңның төсе бар: я ул ал (күбрәк), я зәңгәр, әмма һәрвакыт якты. Ә шулай да моң — моң инде ул, барыбер йөрәкнең әллә кайсы бер җирен чеметеп ала:

**...Мөмкинме соң миңа янмаска,**
**Көне буе янган кояш сыман,**
**Ал моң булып җиргә таммаска!!**

Шул рәвешле, кеше фидакарьлеге кояш фидакарьлеге белән чагыштырыла. Кешегә никадәр ышану, аны нинди югарылыкка күтәрү!

Матурлыкны бүтәннәргә караганда күп мәртәбә артыграк тою сәләте кешене шагыйрь итә, диләр. Фәннур өчен тормышта матурлык бик күп төрле, кеше хезмәт күрсәттеме — бу матурлык, шаулап язлар килсә — матурлык. Җирдә тынычлык сакланса — матурлык, җир яшәрсә, җир өс-

тендә төзелешләр күбәйсә дә матурлык. Шагыйрь матурлыкка табына, аны кешеләргә күрсәтүдә бөтен көчен куя, аңа дан җырлый:

…Матурлыкның бөтен капкаларын
Ачарга һәм алга барырга!

Бу өзек шагыйрьнең «Ильичка» исемле шигыреннән алынды. Татар әдәбиятында кешелекнең бөек титаны В. И. Ленин турында тирән лирика белән сугарылган шигырьләрнең классик үрнәкләре билгеле. Әлеге шигырь шул традицияләрнең дәвамы булып яңгырый.

Чәчәк кыры, иген кыры булган кебек, бу дөньяда гамь кыры да бар. Чын шагыйрьләр шуннан килә… Тирә-юньдәге җитешсезлекләрне, күңелне рәнҗеткән күренешләрне Ф. Сафин кешенең табигатькә мөнәсәбәте аша бирергә ярата, чөнки табигатькә булган мөнәсәбәт — адәм баласының үз-үзенә, кешеләргә, туган илгә, гомумән, җәмгыятькә мөнәсәбәте ул:

…Бу ярларны — бу талларны
кемнәр саклый алмаган!
Ә кошчыгым әндыйларны
Мактап сайрый алмый шул,
Җире өчен янмаганнар
Ил өчен дә янмый шул!

Шагыйрьне мизгел һәм мәңгелек категорияләре борчый һәм, бу борчулы уйларына үзе үк тормышчан җавап бирә:

…Эшнең башы я дәвамы гына
булып кала икән һәр нокта!

Җыентыктагы күп кенә шигырьләр («Чулпан», «Яшьлек каласы», «Кама» һ. б.) туган якка, андагы үзгәреш-яңарышларга багышланган. Бу үзгәрешләр республикабызның бигрәк тә көньяк-көнчыгыш районнарына, Чулман-Кама бассейнына карый. Биредә промышленностьның яңа өлкәләре үсеш алды, яңа шәһәрләр үсеп чыкты. Шагыйрь шул үзгәрешләрне яшьләргә хас романтик соклану белән сурәтли. Бу соклану шул кадәр якты, самими һәм туган җир өчен шундый олы горурлык хисе белән сугарылган ки, ул хис космик масштабларга күчә:

Калыкты таң балкышында
Яшьлегем шәһәрләре.
Юк иде бит әле Җирнең
Болай ук яшәргәне.

Ф. Сафин иҗатында алма, алма бакчасы образы шактый еш очрый. Халкыбыз күңелендә бу җимешнең төрле символик мәгънәләре бар. Матур кызны багалмасы дип атау; кеше эшенең нәтиҗәләлегән күрсәтеп «бакчасы җимешле» дигәндә дә алма бакчасы күз алдында тотыла. «Алма агачыннан ерак төшмәс» һ. б. Кыскасы, алма бездә аерым шигъри игътибарга лаек.

Ф. Сафин бу образга фәлсәфи мәгънә сала:

Кызыл алма ак чәчәктән
Исталек булып калган…
Синең өчен мин дә чәчәк,
И киләчәк — кузалмам!

Әйе, кешенең үткән гомере җирдә эзсез калмасын, чәчәк булып ачылган яшь кеше гомере киләчәккә кызыл алма булып барсын, җимеше-хезмәте киләчәккә ядкәрь булсын. (Ә киләчәк үзе нинди кадерле кузалмасы!) Кеше күңелен гаҗиз уйландыра торган туу һәм үлем, шушы фәлсәфи категорияләр турындагы фикерен дә Ф. Сафин алмага бәйләп әйтә алган:

Өз, сеңелем, алсу алмаларны,
Сөйгәнеңә илт син аларны.
Алмада ул таң һәм шәфәкъ күрер,
Чын сөюне аңлар аннары!

Алмада без таң һәм шәфәкъ күрәбез, ә барыннан да бигрәк алмада мәхәббәт ялкынын күрәбез. Алмага бәйләп иҗат ителгән, мәхәббәт турындагы шигырьләреннән тагын ике генә юл китерик:

Туп-туп итеп алма төшә,
«Син!» дип барсам — җил исә…

Шигырьне хәтта дәвам иттермәсәң дә була, чөнки биредә бер бөтен киерәнкелек салынган инде.

Шагыйрьнең күңеле һәрчак якты, күкләрдә оча, сабый кебек беркатлы:

Бар дөньяны тутырып киләсең, яз,
Сүнмәс ал таң булып көләсең.
Бәхет кенә кирәк миңа бүген,
Ни бәхетләр алып киләсең!

Шигырьнең аһәңе шундый табигый,— кешенең бәхет даулавы эгоистик теләк түгел, ә романтик якты хыял итеп кабул ителә.

Фәнкурның бәхет турында төпле, житди фикере халкыбызның бәхет турындагы уе белән тәңгәл килә:

Кырларда ялгызым калганда
Арышлар башымнан сыйпаган…

Бу шигырьдә гомер-гомергә игенчелек белән шөгыльләнгән халыкны хезмәте җимеше — тук башаклар чын-чынлап бәхетле итсә, икенче яктан, аның гадәттән тыш тыйнаклыгы күренә: шатлык яшьләрен дә ялгызы гына калган чагында чыгара ул. Безнең халыкта кайгыны сабыр кичерә белмәү хәтта гаептән санала бит.

Ф. Сафинның шигырьләре җиңел укылалар, күңелгә тиз сеңәләр, шул ук вакытта аларның эчке мәгънәләре тирән, аларга салынган җегәр, олы фикер укучыны озак уйланырга мәҗбүр итә:

Ныклык теләп безгә, йөрәк кушкан
Хаклык якларына чакырып,
Таш өстендә борын тәртә үлән —
Җирдән безгә дигән Яхшылык.

Шагыйрьнең уйлары тирән, еш кына борчулы, чөнки күтәрелəсе биеклекләре-

без, эшлисе, тәзәтәсе эшләребез күп. Шагыйрьнең күңелен Туган ил язмышы, алай гына да түгел, бөтен Җир язмышы били. Бүгенге буынның рухи ныклыгы турында борчылып уйлана ул. Хәзерге заманның бихисап күп проблемаларын чишә алырлыкмы бу буын? Безгә якты көн калдырып китүче көрәшчеләрнең лаеклы дәвамчысымы ул? Буыннар арасындагы бәйләнеш, аларның бер-берсе алдындагы бурычлары шагыйрь күңеленең төп игътибар үзәгендә. Ф. Сафин мәнә шул бәйләнешне драматик тыгызлыкка җиткереп бирә алган:

**Янды тән, янды кан — җан калды,**
**Шуңамы якты бу ак көннәр!**
**Һәм шуңа ни булыр җавабың!**
**Без кемнәр, без кемнәр, без кемнәр!**

**БИКӘ РӘХИМОВА.**

# СЕЗ КЕМ, ШАГЫЙРЬ?

Яшь шагыйрьнең беренче китабыннан соң алга китеш, үсеш бармы? Өметләрне аклаганмы ул? Әнә шундый сораулар белән, бу җыентыкны да сагаеп алам. Исеме үк бераз дәгъвалы: «Сез кемнәр?». Китапны ачканчы ук шагыйрь безгә: «үзегезнең кем булуыгызны искә төшерегез»,— ди сыман. Иҗатының башында ук Ф. Сафин поэзиягә матур, купшы сүзләр тезү өчен түгел, ә якты идеалларны яклар өчен килүен: «Сүз хәнҗәрен ал кыныннан — тутыкмасын! Кара эшнә туракларга курыкма син!» — дип белдергән иде.

Бу — әле җитмешенче еллар башы. Фәннур — яшь, изүләре ачык, күңеле яңалыкка сусаган чак. Яңа җыентыгында да автор үзен яшьлек (ягъни үзе яшәгән чор һәм чордашлары) җырчысы итеп таныта. Ул һаман да очу теләге, «биеккә менеп, нурлар җыеп, туган җиргә төшү теләге» белән яна. Кыскасы, шагыйрь канатлы атының тезгеннәрен бушатмаган, уй-тойгылары киеренке, офыгы киң, кояшы якты. Ләкин бүгенге көн матурлыгын раслар өчен канат кына түгел, таяну ноктасы да кирәк. Фәннур Сафин өчен бу нигез-җирлек — көрәшләрдә чыныккан буын. Каһарманнар буыны. Аларга сокланып, шагыйрь: «Менә бит сез кемнәр!» — ди, ә тынгысыз йөрәккә кайтаваз булып: «Ә соң без кемнәр, без кемнәр?..» дигән сорау әйләнеп кайта. Бу сорауга Фәннур җыентыктагы күпчелек шигырьләре белән җавап бирергә омтыла.

Моңа хәтле без аның шигырьләрен үзенә генә хас ихласлыгыннан, самимилек, җылылык, горур моңсулыгыннан таный идек. Аның лирик герое нечкә күңеллелеге, беркатлылыгы, сафлыгы, тыйнаклыгы белән үзенә тартты. Хәзер әлеге геройның җитдиләнә, кырыслана төшүе, гражданлык позициясенең дә инде ачыкланып-урнашып җиткәнлеге күренә. Шагыйрь бүген яшь буын замандашлары исеменнән сүз ала.

**Биек-биек тауларга тиң яшьлек,**
**Синең сүзең — КамАЗ, БАМнарда.**
**Офыкларда яңа биек үрләр,—**
**Безнең буын тиеш яуларга!**

Бу сүзләр астына һәркайсыбыз кул куя алыр иде. Ләкин йөрәкләрдәге изге ниятне, күңел пафосын Фәннур ни өчендер бик күп кабатланган, шактый тапталгантаушалган сүзләр ярдәмендә аңлатырга тырыша. «Офыкларда яңа биек үрләр», «узган буын утка кергән», «якты җиңү җыры» кебек мәгълүм тәгъбирләрне рифмалаштыру гына шигырьне заманча югарылыкка күтәрә аламы соң? Поэзиянең гражданлык йөзен «КамАЗ, БАМнар»ны санап чыгу гына билгелимени? Кыскасы, биредә Фәннурга хас лиризм, җылылык, эчкерсезлек җитешми. Традицияләрне дәвам итү, яшьлек романтикасы, бөек идеаллар турындагы күпчелек шигырьләр изге максат белән язылып та, катлаулы олы теманың асылын поэтик югарылыкта чишү ягыннан бүгенге поэзия казанышы булуга бик үк якын түгелләр кебек?

Шулай да туган ил, Татарстан турында язганда Ф. Сафин үзен иркенрәк хис итә.

**Кара алтын вышкаларын**
**Кулларына тотып барган**
**Сабыр җанлы батыр кебек**
**Күренәсең еракларда.**

Ул эшчән кулын киң маңгаена куеп, үзе салган калаларны читкә китеп карый... Бернинди купшылык юк, һәр сүзе табигый, гади, үтемле.

Миңа калса, әлеге циклдагы «Ике учак» шигыре дә шагыйрьнең үзәк әсәрләреннән берсе булырга хаклы. Учак образы Фәннурны элек тә үзенә җәлеп иткәли торган иде: «гүя безнең бәрәңге көя бутәннәр яккан учакта...». Әмма бу учакны яшьлек дусты белән ул үзе яккан.

**Учакларны җилләр сүндерер дә,**
**Ә күңелдә алар янар күк.**
**Күңел уты сүнсә, еллар аша**
**Ике учак бармак янар җүк!**

Образлары гына түгел, эчке мәгънәсе дә нәкъ Фәннурча. Сүз ике яшүсмернең кара төндә ике учак ягып, «кеше — кешеме соң, китсә җирдә утлар тергезми», «син кешеме, хыянәт итсәң әгәр ут алдын-

да биргән антыңа?» рәвешендәге гадәти генә фәлсәфә коруы турында бара кебек. Әмма учак, шагыйрь яккан учак уйландыра, җанны уята, бәгырьне көйдерә.

«Иптәшләр», «Күңел уты», «Яшьлек җыры» шигырьләре дә әнә шундый ихласлыгы белән матур тәэсир калдыра. «Айлы төндә» шигырендә әлеге «Без кемнәр?» дигән сорауга да җавап бирергә омтылу бар.

**Сагынып үстек шул без... әтиләрне**
**Йотты еллар, еллар талымсыз,**
**Әйттеләр күк алар: «Әтиләрсез**
**Моңлы бала булып калырсыз!..»**

Шагыйрь күңелендә — мәңгелек гамь, моң; канәгатьләнү, тынычланып калу юк анда. Әйе, дөнья катлаулы, тормыш гармониясенә ирешергә тырышу аның кимчелекле якларын да ачып сала:

**Чын кешелек җитми, сафлык җитми,**
**Хакыйкате җитми кайчакта.**

Шагыйрь иң якын кешесе — әтисе белән киңәшә, сөйләшә, күңелен бушата. «Үткән буын һәм без», буыннар эстафетасы темасы һичбер шапырынусыз, «без!» дип күкрәк сукмыйча, кешелекле, табигый ачыла. Сүз уңаенда, күңелне тырнап торган «без» турында да әйтми калып булмый. Фәннурның әлеге шигъри циклында «без» сүзе 36 мәртәбә күзгә төртелә һәм... алга таба да йөздән артык мәртәбә кабатланып ялыктыра башлый.

Кызганычка каршы, «Студент көндәлегеннән», «Томанда», «Яшьлек каласы», «Юлыбыз тиң...» кебек шигырьләр җитди һәм актуаль темага язылсалар да, шагыйрьнең кайчандыр кулына мастерок алып, азмы-күпме кирпеч салганлыгына ишарә ясасалар да, ул төзешкән яшьлек каласы кебек яңа һәм мәгърур яңгырамыйлар.

Җыентыкның «Ярсу тынлык» дип исемләнгән бүлегендәге шигырьләр Фәннурның фәлсәфи лирика өлкәсендәге уңышлы адымнарын күрсәтә. «Дөнья...», «Кара төндә әрмән кызы елый», «Моң», «Кояшка сузыла бала», «Сез кемнәр?» һ. б. шундый шигырьләрнең иң камил үрнәкләре.

**Кемдер дәшми шәһит китә,**
**Тугры калыр өчен.**
**Кемдер яши, тугры сүзен**
**Ярып салыр өчен.**

Соңгысы күбрәк шагыйрьләр токымына карый бугай. Әйе, Җәлилләр, Кәримнәр «хаклык өчен янып, ялкыннарга күмелде». Ә сине ниләр борчый, шагыйрь? Йокысыз төннәреңдә нинди гамь, нинди моң тынгы бирми? Кем син, шагыйрь?

Юл башында (һәм шул исем белән аталган китапта) Фәннур: «Гел кояшлы язлар гына күңелдә. Ничек көздән язга сикереп керергә?» — дип хыялланa иде, һәм шунда ук үзе:

**Яфракларын коя каен...**
**Күргәч калдың тукталып.**
**Барсы беткән, гомер үткән...**
**Син торасың таң калып,**

— дип югалтулар ачысын татыганлыгын да әйтеп биргән иде.

Бу җыентыкта инде ул үзен «уйчан көз» дип атый. Шагыйрь җәй белән кыш фасылларының алмашыну чоры — яз белән көзне, аеруча көзне хуш күрә. Үзеңне юмарт, алтын көз итеп тою рәхәттер ул, әлбәттә. Ләкин көз — җитлегү чоры, ә син ул югарылыкка, шигъри камиллеккә ирештеңме соң әле? Әллә ул сине әле һаман көтә генәме, дип сорыйсы килә башлый.

Ф. Сафин шигырьләрендә максат һәм аңа ирешү юллары турындагы уйлар да каршылыклы. Ул үзе биек үрләр яуларга өнди, «алда өр-яңа үрләр көтә» дип ышандыра да, кинәт «тау-тау инде, ә без — үзәннәр» дип уфтанып куя. Тик үзәндә калган шул халәтенә разый шагыйрь:

**Без ул тиеш Тукай кебек тугры,**
**Җәлил кебек батыр булырга,**

— дип ашкына аламы икән? Күрәсең, бу икеләнү, шикләнү яшь буын шагыйрьләрнең гражданлык җитлегүе, иҗади җитлегүе соңгарак калуыннан киләдер.

Ә бит шагыйрь дөньяга, кешеләргә, табигатькә чын күңелдән гашыйк:

**Төннәре дә якты дөнья бит бу,**
**Күзләреңә ява зәңгәрлек!..**
**Һәр тәүлеген аның матур итеп,**
**Онытылмаслык итеп яшәрлек!**

Мондый шигырьләрне укыгач, шагыйрь белән бергә «җиргә ямь-нур өстәп, таллар кебек яфрак ярасы» килә башлый. Ул табигатьне, туган җирнең, кешенең матурлыгын саклау кебек актуаль мәсьәләләр күтәрә. Бу тематика «Балачактан якын миңа», «Ак каурый», «Күккә атсам тияр кошка» кебек шигырьләрдә чагылыш тапкан.

Дөресен әйткәндә, «Алма бакчасында» циклының исемен укыгач ук миндә шик туды. Артык гомуми, поэтик шаблонга әверелгән нәрсә бит бу,— безнең тәрәзә каршындагы алма бакчасы. Соңгы вакытта яшь шагыйрьләр үзләрен чын-чыннан «алма караклары» итеп таныттылар кебек. Кызыл алма милли бизәк, төрле очраклар өчен әзер символ булырга дәгъва кыла башлады. «Беренче карлыгачлар»да да, аннан соң чыккан шигырь җыентыкларында да әлеге алма еш кабатланулары белән ялыктырды. «Алма һәм алма бакчасы», «Кызлар-казлар», «Каз өмәләре», болында, яки бер китаптан икенче китапка чабып йөри торган игезәк колыннар һәм ат көтүләре милли шигырь атрибутларына, ә турысын әйткәндә, шаблонга әвеределәр.

Бәхеткә каршы, Фәннур мондый кабат-

ланудан котыла алган. Аның алмалары күп төрле, һәркайсының үз тәме, исе, төсе бар. «Чын сөю», «Оҗмах», «Алма бакчасында», «Таһир буласым килә минем», «Күңел тулы ап-ак истәлекләр»... кебек шигырьләр элекке Фәннурны, үтә моңлы, үтә тыйнак-оялчан Фәннурны күз алдына бастыралар. Аның «мәхәббәт алмалары» аеруча хуш исле, бераз әчкелт, бераз татлы.

Бу циклда яшь шагыйрь иҗатының тагын бер ягы — музыкальлеге, җырга якынлыгы үзен нык сиздерә. Ул шигырьләр моң тулы, көй сорап тора.

«Сез кемнәр?» җыентыгы белән танышканда яшьләр поэзиясенә гомумән хас уңай һәм җитешсез якларны да ачык күрәсең. Аларда бүгенге поэзиягә килүче алмашның үсү авырлыклары чагыла.

Иҗат кешесе туктаусыз эзләнү юлында гына уңышка ирешә ала. «Без үзебез алга баручылар, хыял үзе килми каршыга!» дип язган Фәннурның шигырьләре дә аның туктаусыз эзләнүдә булып, шигъри талантының иң биек үренә әле менеп җитмәве турында сөйли. Шагыйрь үзендә калмасын, дөнья офыгын киңрәк күзаллау өчен биек үрләргә омтылсын, киң мәйданга чыксын иде. Аңа хас фикер ачыклыгы, шигырьләренең халыкчан яңгырашы тагын да уңышлырак әсәрләр күтәргә ышаныч тудыра.

**РАФИС ӘХМӘТОВ.**

# Укучының күңел дәфтәренә

### Удмурт мәкальләре һәм әйтемнәре

*Халык гомере — агым су, ә аккан су — матур ул.*
*Энҗе — диңгез төбендә, алтын акыл — халыкта.*
*Дөреслекнең юлы бер, ә ялганның мең төрле.*
*Торгын сулар тиз сасый.*
*Баштан югары сикерә алмыйсың.*
*Яман итеп кычкырма — авызыңа карга керер.*
*Теле үткен, кулы тупа.*
*Яхшы дусты юк кеше яман эшен аңламас.*
*Көч хезмәттә чыныга.*
*Яхшы эш яктырып тора.*
*Читән казыксыз тормый.*
*Оча белә, утырып тора алмый.*
*Кызу урак өстендә кояшны үзең уят.*
*Агач тамыр белән нык, ә кеше — дуслар белән.*
*Ат үргә менеп сынала, дус — бәла кичергәндә.*
*Үзе өчен генә эшләп бал кортлары яшәми.*
*Бергәләп этсәң — таш та тәгәри, ялгыз кешегә — ашау да кыен.*
*Бик вак ташны лай баса.*
*Бер ярмадан ботка пешми.*
*Күзләр еракка карый, акыл — тагын да арырак.*
*Баш уйсыз түгел, уй башсыз булмый.*
*Казанына күрә чүмече, юлчысына күрә чанасы.*
*Куктәге болытка карап җирдән урын сайлама.*
*Карга бассаң — эз кала.*
*Кешенекенә тимәсәң — синекен дә алмыйлар.*
*Кеше боткасы майлап та тәмсез.*
*Кеше акчасы кесәне тишә.*
*Ике күз арасындагы борынны да урлыйлар.*
*Кеше шеше сызламый.*
*Үтә саран кешенең бармагы да канамый.*
*Китеп югалган сарыкка бик күп хуҗа табыла.*
*Ак өстенә төшкән кара беркайчан да югалмый.*
*Ялкаулансаң — кашык та авыр.*
*Бер шешәне дус итсәң, бөтен дусларың бизәр.*

# СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Сәрвәр Әдһәмова дигәч тә тау-тау китап өемнәре күз алдына килә. Тау димәслек тә түгел шул: аның 300 табакка якын тәрҗемәсе барлыгы 300 меңләп тираж белән басылып чыккан!

Ничәмә-ничә буын укучыларыбыз А. М. Горькийның Сәрвәр апа тәрҗемә иткән «Балачак», «Малайлыкта», «Минем университетларым» дигән трилогиясен, «Фома Гордеев», «Артамоновлар эше» кебек романнарын, Л. Н. Толстойның «Кавказ әсире», «Балдан соң», «Алпавыт иртәсе», А. С. Пушкинның «Белкин хикәяләре», «Бөек Петр гарәбе», «Станция караучысы» һ. б. әсәрләрен, А. П. Чеховның күп кенә хикәяләрен укып үскән! Болар янына П. Бажов, М. Пришвин, П. Павленко, В. Катаев, шулар өстенә тагын дөнья классиклары хәзинәсеннән Дж. Свифт, Бертуган Гриммнар, Д. Дефо әсәрләренең тәрҗемәләрен дә китереп кушкач, шактый зур «тау» барлыкка килә.

Татар хатын-кызлары арасыннан тәрҗемә өлкәсендә шушындый зур уңышка ирешкән беренче кеше — Сәрвәр апа, минемчә.

Әдәбият даһиларын, титаннарны тәрҗемә итәргә ничек көче җиткән аның? Ничек ирешкән ул моңа? Соклангыч кыюлыкның, таң калырлык осталыкның җирлеге, нигезе турында уйланам.

Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова 1901 елның 5 апрелендә Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә туа. Аның балалык еллары шунда үтә. Башлангыч һәм урта белемне дә ул Троицкида ала.

Сәрвәр яшьтән үк әдәбият белән кызыксына. 16 яшьлек кыз үзенең «Милләтемә» дигән беренче шигырен яза. Нәкъ менә шушы чорда ул шагыйрь Шәехзадә Бабич белән таныша. «Безнең Бабич» дигән истәлегендә шул көннәрне искә төшереп, Сәрвәр апа болай дип яза: «Ул катнашкан кичәләр аеруча җанлы уза иде. Шәехзадә талантлы шагыйрь генә түгел, искиткеч оста сөйләүче дә иде...»

18 яшьлек Сәрвәрнең хезмәт юлы башлана. Ул укытучы булып, тәрбияче булып Томск балалар йортында эшли. Шунда укучылары белән сәхнәгә куяр өчен «Авыл тормышыннан бер күренеш» дигән беренче пьесасын яза.

1923 елда Сәрвәр балаларны Казанга озата килә. Бу вакытта «үземнең дә балалар өчен пьесалар язып, язучы булырга хыялланып йөргән чагым иде,— дип яза ул истәлекләрендә.— Шуңа күрә әле Татрабфакта, әле Комклубта уздырылган әдәби кичә һәм диспутларга бик кызыксынып бара идем. Гадәттә ул кичәләрдә күбрәк Шамил Усманов, Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй кебек яшь язучылар була торган иде». Әлеге очрашуларның берсендә Шамил Усманов Әдһәмовага «Авыл тормышыннан бер күренеш» пьесасын нәшриятка тәкъдим итәргә киңәш бирә. Шулай итеп, бу әсәр 1925 елда китап булып дөнья күрә.

1924 елда С. Әдһәмова «Әзер бул!» дигән икенче пьесасын иҗат итә. Аның балалар өчен язган шигырьләре, хикәяләре «Пионер каләме» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә басыла, яшь язучы үзе дә әдәби хәрәкәттә актив катнаша башлый.

Шулай бервакыт язучылар II Советлар Йортының бер бүлмәсенә җыелалар. Анда Такташ һәм тагын башка язучылар була. Кави Нәҗминең әле генә Мәскәүдән кайтып төшкән чагы. Ул VI Берләшкән татар-башкорт мәктәбеннән вәкил булып В. И. Ленин-

ны соңгы юлга озатуда катнашкан икән. Почетлы каравылда торган. Шушы тәэсирләр нигезендә юлбашчыга багышлап «Ильич» дигән поэма язган. Бу көнне иптәшләре әнә шул поэманы тыңларга җыела. Алар арасында Сәрвәр Әдһәмова да була. Әлеге истәлекле кичәдән соң алар Кави Нәҗми белән якыннан танышып, дуслашып китәләр һәм бергә тормыш корып җибәрәләр.

Әдәби кичәләрнең берсендә Әдһәмова Галимҗан Ибраһимовны да күрә. Кави Нәҗми белән тора башлагач, олы әдип белән танышлык якын дуслыкка әйләнә. Г. Ибраһимов авырып Ялтага дәваланырга киткәч тә аның янына хәлен белергә барып йөриләр. 1932 елда Ялтада очрашкач, Г. Ибраһимов:

— Укымаган булсаң, Николай Тихоновның бу китабын укып чык әле син, Сәрвәр,— дип, аңа «Сугыш» исемле повестьны бирә.— Син аны татарчага тәрҗемә ит. Бик үзенчәлекле, кирәкле әсәр...

1933 елда инде Николай Тихоновның «Сугыш» дигән повесте татарчага тәрҗемә ителеп басылып та чыга.

«Бервакыт кич белән, егерме җиденче елның башлары иде бугай,— дип яза Сәрвәр апа үзенең бер истәлегендә,— минем кухняда ашарга әзерләп йөргән җиремә Кави килеп керде дә:

— Тетрәйдергеч бит бу! — дип, кулындагы Лев Николаевич Толстой китабын күрсәтте.— «После бала» дип атала. Син дә укы әле, Сәрвәр! Кечкенә генә хикәя ул, тиз укыла...»

Әнә шулай, Кави Нәҗми киңәше белән Л. Н. Толстойның да әлеге хикәясе татарчага тәрҗемә ителә.

Үзе дә табигый сәләткә ия булу өстенә, яшьтән үк Шәехзадә Бабич кебек шагыйрь белән дуслашу, Кави Нәҗми белән бергә яшәү, Галимҗан Ибраһимов кебек олы язучы белән аралашу — кыскасы, талантлы, көчле мохиткә килеп эләгү — әлбәттә, Сәрвәр Әдһәмовага зур таяныч була һәм үз көченә ышанырга мөмкинлек бирә.

1934 елның җәендә исә, СССР язучыларның I съездында, Сәрвәр апага Алексей Максимович Горький белән күрешергә насыйп була.

«— Мин сезнең әсәрләрегезне татарчага тәрҗемә итәм, Алексей Максимович,— дип, Горький белән исәнләштем. Ул, ягымлы елмаеп, кулымны кысты, русча «о» хәрефенә басым ясагандай итеп:

— Рәхмәт! Ә кыенмы тәрҗемә итү? — дип сорады.

— Җиңел түгел, Алексей Максимович, ләкин мин сезнең әсәрләрне бик яратам һәм кулымнан килгән кадәр тырышам,— дигәч, ул тагын бер тапкыр:

— Рәхмәт! — дип, кулымны кысты».

Бөек язучының рәхмәтен ишетү яшь тәрҗемәчене тагын да тырышыбрак эшләргә канатландыра. Шулай итеп, матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итү аның төп профессиясенә әйләнә.

Сәрвәр апаның сәнгатьле тәрҗемәләре ярдәмендә йөз меңнәрчә татар укучылары рус һәм дөнья классик әдәбиятының бетмәс-төкәнмәс җәүһәрләре белән таныша. Аның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге хезмәте тулаем иҗатында хуш ис бөркеп торган чәчкәләр бәйләмен хәтерләтә. Бу бәйләмдә, әлбәттә, Горький, Л. Толстой, Чехов әсәрләре аеруча күркәм урын алып тора.

Мөхтәр Әүэзовның «Абай» романы исә турыдан-туры казакъ теленнән тәрҗемә ителгән. Халыклар арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуга булыша торган бу хезмәт чиксез хөрмәткә һәм олы бәягә лаеклы.

Зур тырышлык, күп көч таләп итә торган тәрҗемә өлкәсенә бөтен күңелен-илһамын багышлап, Сәрвәр апа Әдһәмова рус классик һәм совет язучыларының иҗат лабораториясенә тирәнтен керә алды, аларның язу формаларын һәм ысулларын, стиль үзенчәлекләрен аңлап үзләштерүгә ирешә. Җитди иҗади эзләнүләре аны тәрҗемәнең иң зур осталары дәрәҗәсенә күтәрде.

САИМӘ ИБРАҺИМОВА.

## ЮБИЛЕЙЛАР

23 январьда республикабыз җәмәгатьчелеге М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре һәм ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Н. Г. Җиһановның 70 яшьлек юбилеен тантаналы төстә билгеләп узарга җыелдылар.

Юбилей кичәсен КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачып җибәрде. Ул беренче сүзне КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы члены Р. М. Мусинга бирде. Иптәш Р. М. Мусин юбилярны олы бәйрәме белән чын күңелдән котлады, аның татар совет музыкасына керткән зур хезмәтләренә югары бия бирде һәм СССР Верховный Советы Президиумының Н. Г. Җиһановка совет музыка сәнгате үсешенә керткән күренекле хезмәтләре өчен һәм җитмеш яшь тулу уңаеннан, **Социалистик Хезмәт Герое** дигән мактаулы исем бирү турындагы Указын укыды, көчле кул чабулар астында юбилярга Ленин ордены һәм «Урак һәм Чүкеч» алтын медален тапшырды.

Н. Г. Җиһановның иҗаты турындагы доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов чыкты. Аннары күренекле композиторны түбәндәге иптәшләр котлады: РСФСР Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары В. И. Казенин, СССР Музфонды идарәсе председателе Г. И. Восканян, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе А. И. Бондаренко, ТАССР Культура министры И. Н. Алиев, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ш. Р. Агеев, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Э. И. Тумашев, композитор Р. Х. Яхин, ВТОның Татарстан бүлеге идарәсе председателе Р. А. Җиһаншина, Казан университеты ректоры А. И. Коновалов, Казан консерваториясе студенткасы Д. Абдуллина, кунаклардан К. Х. Кужамьяров (Казагыстан), С. М. Хентова (Ленинград), З. Г. Исмәгыйлов (Башкортстан), Г. М. Корепанов-Камский (Удмурт АССР), В. А. Воронов (Әстерхан), КПССның Чувашстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире О. И. Талля, хезмәт иняләре исеменнән Казан авиация производство берләшмәсе генеральный директоры В. Е. Копылов, «Камгэсэнерго»ның ташчылар бригадасы бригадиры В. С. Мәүликов һәм Биектау районының «Бөреле» совхозы сыер савучысы З. Я. Приказчикова.

Н. Г. Җиһанов үзенең чыгышында, үзен югары бүләк белән бүләкләүләре өчен, партиябезгә һәм хөкүмәтебезгә рәхмәт белдерде, моннан соң да татар совет музыкасы өлкәсендә армый-талмый эшләячәген әйтте.

Кичәдә ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретарьлары В. С. Дергунов, М. Ф. Вәлиев, Ф. А. Садыйков, Л. М. Смагин иптәшләр катнашты.

Соңыннан зур концерт күрсәтелде. Анда композиторның күпкырлы иҗаты яктыртылды, опералардан, балетларыннан өзекләр күрсәтелде, симфоник әсәрләре башкарылды, җырлары җырланды.

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында татар совет әдәбияты классигы шагыйрь Һади Такташның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Президиумда — Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, республикабызның партия, совет һәм җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, юбилей тантанасына килгән кунаклар.

Кичәне ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турындагы докладны филология фәннәре докторы Н. Г. Юзиев ясады. Һ. Такташның әдәбиятыбызны үстерүгә керткән өлеше турында шагыйрьнең улы — сәнгать фәннәре докторы, Үзбәкстан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Һ. Такташ, Татарстанның халык артисты Х. Сәлимҗанов сөйләделәр. Аннары сәнгать осталары катнашында зур концерт булды.

*
* *

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында һ. Такташның тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни конференция ачылды. Аны кереш сүз белән институтның директоры, тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмов ачты. Конференциядә Такташның поэзиядәге новаторлыгы, бүгенге әдәбиятта аның традицияләре, Такташ һәм тугандаш әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләр, шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге яңалыкларны чагылдырган докладлар һәм чыгышлар тыңланды. Чыгыш ясаучылар арасында Татарстан галимнәреннән тыш, башка союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар да бар иде.

*
* *

Казанның Ленин урамындагы 21 нче йорт алдында Һади Такташ истәлегенә мемориаль такта куелу тантанасы булды. Анда республикабызның партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, поэзия сөючеләр килгән иде. Мемориаль такта куелуга багышланган митингны кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты. Аннары язучылардан Г. Минский, М. Хәсәен, Р. Гатауллин һәм М. Галиев чыгыш ясадылар.

Авторы скульптор Нәүфәл Гаделев булган мемориаль тактага түбәндәге сүзләр язылган: «Бу йортта 1924—1931 елларда газета һәм журналлар редакцияләрендә татар совет әдәбиятының классигы шагыйрь Һади Такташ эшләде». Тактада шагыйрьнең скульптура барельефы да уеп ясалган.

Тантанада КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, Татарстан Культура министры И. Н. Алиев һ. б. иптәшләр катнашты.

*
* *

Январь ае Оренбург шәһәрендәге әдәбият сөючеләребез өчен чын мәгънәсендә Такташ көннәренә әверелде. «Южный Урал» өлкә газетасы шагыйрь турында зур мәкалә бастырып чыгарды. Егерменче елларда «Юксыллар сүзе» редакциясе эшләгән йортта хәзер Оренбург педагогия институты урнашкан. Шул институтның күптиражлы газетасында да һ. Такташ тормышының Оренбург чорына караган материаллар нигезендә язылган мәкалә басылды. Аны Оренбург журналисты Фәттах Кыргызбаев язган.

Х. Ямашев исемендәге китапханәдә, Һади Такташның 80 еллык юбилее уңае белән, шагыйрь иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә китапханә каршында эшләүче әдәбият түгәрәге җитәкчесе Зиннур Шакиров Такташның иҗаты һәм тормышы турында чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында шагыйрьнең Оренбургта яшәгән чорына да тукталды, тыңлаучыларны Такташ тарафыннан чыгарылган һәм бүгенге көнгә кадәр сакланган «Юксыллар сүзе» газетасының төп нөсхәләре белән дә таныштырды. Китапханәнең уку залы мөдире Л. Рафикова Такташ әсәрләре буенча төзелгән библиографик күзәтү ясады. Кичәгә килүчеләр арасында Такташның замандашлары, аны күреп белүчеләр дә бар иде.

Соңыннан кичәдә үзешчән «Чулпан» ансамбле чыгыш ясады, татар халык җырлары, Такташ шигырьләре яңгырады.

*
* *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле татар совет язучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшировка 80 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе булды. Бирегә республикабыз производство коллективлары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, культура работниклары, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре килгәннәр иде. Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм сиксән яшь тулу уңае белән Гомәр Бәширов Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнгән иде. Хөкүмәтебезнең бу олы бүләген, КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән җылы котлап, әдипкә ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев тапшырды.

Юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин сөйләде. КПСС-ның Казан шәһәр комитеты һәм шәһәр Советы башкарма комитеты, ВЛКСМ өлкә комитеты, Бауман район партия оешмасы, партиянең Арча райкомы һәм район Советы башкарма комитеты, ТАССР Культура министрлыгы, республика иҗат оешмалары, Татарстан китап нәшрияты исеменнән дә язучыга котлаулар әйтелде.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин иптәшләр катнашты.

Әдипнең юбилеена багышланган кичәдә республикабызның сәнгать көчләре катнашында концерт күрсәтелде.

*
* *

Гомәр Бәшировның туган ягы Арчада да язучының олы юбилее уңае белән зур тантана булып узды. Тантаналы очрашуны, барлык якташлары — Арча район хезмәт ияләре исеменнән юбилярга кайнар котлау сүзләре юллап, КПСС райкомының беренче секретаре Х. З. Зәйнуллин ачты. Язучының бай тормыш юлы һәм күпкыр-

лы иҗат эшчәнлеге турында Г. Ахунов сөйләде. Аннары трибунага бер-бер артлы терлекчеләр И. Мөхәммәтҗанов, М. Шәймуллин, мәгариф работниклары М. Ибраһимов, Ф. Халитова, Р. Галимҗанов, ВЛКСМның район комитетыннан М. Хәлилов, район культура бүлегеннән Ә. Хәсәнова, язучылар Миргазиян Юныс, Радик Фәизов һ. б. иптәшләр күтәрелде. Алар язучының иҗатына югары бәя бирделәр, яңа иҗат уңышлары теләделәр.

Кичәдә шулай ук Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, тәнкыйтьче Азат Әхмәдуллин, язучы Мөхәммәт Мәһдиев һәм Гомәр Бәширов үзе катнашты.

* * *

Казанның Менжинский исемендәге Культура сараенда СССР Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Гомәр Бәширов иҗатына багышланган кичә булды. Кичәне ТАССР Эчке эшләр министрлыгының политик тәрбия эшләре бүлеге начальнигы С. И. Кириллов кереш сүз белән ачты. Әдипнең тормыш юлы, бай иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин чыгыш ясады. Гомәр Бәширов үзенең Арча кантон эшче-крестьян кызыл милициясендә һәм халык тикшерүчесе булып хезмәт иткән чактагы истәлекләре белән уртаклашты, сорауларга җаваплар бирде.

Тантаналы кичәдә шулай ук Татарстан Эчке эшләр министрының беренче урынбасары Җәүдәт Невматов, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәгъсүм Насыйбуллин һәм композитор Сара Садыйкова катнашты.

Очрашу республиканың күренекле артистлары, һәвәскәрләре концерты белән тәмамланды.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казанда яшәп иҗат итүче чуваш язучысы Василий Юдинга 70 яшь тулу уңае белән, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында әдәби кичә булып узды. Язучының иҗаты һәм тормыш юлы турында В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты укытучысы, филология фәннәре кандидаты К. К. Петров сөйләде.

Юбилярга багышланган бу кичәдә Чувашстан һәм Татарстан артистлары катнашында концерт та күрсәтелде.

## ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Татарстан язучыларының чираттагы партия җыелышы «Азат хатын» журналы һәм язучылар» дигән темага уздырылды. Журналның баш редакторы Венера Ихсанова язучыларның журнал битләрендә ничек катнашулары, язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләде. Язучылар Гомәр Бәширов, Ринат Мөхәммәдиев, Марсель Галиев, композитор Сара Садыйкова чыгышларында журналда басылган әдәби әсәрләрнең сыйфатына тукталдылар, редакциянең язучылар белән булган яхшы элемтәсен билгеләп үттеләр.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

КПСС Үзәк Комитетының 1979 елгы «Хокук тәртибен саклау эшен яхшырту һәм хокукны бозуларга каршы көрәшне көчәйтү турында»гы карары нигезендә, тәртип сагында торучыларның фидакарь хезмәте турындагы әдәби әсәрләрнең идея-сәнгать дәрәҗәсен тагын да күтәрү максаты белән, Татарстан Эчке эшләр министрлыгы коллегиясе һәм ТАССР Язучылар союзы идарәсе шул темага язылган иң яхшы әдәби әсәрләргә конкурс игълан иткән иде. Күптән түгел махсус жюри шул конкурс йомгакларына нәтиҗә ясады. Язучы Мәгъсүм Насыйбуллинның «Алтын алка» повестена — беренче, Тәүфыйк Әйдинең «Божра» китабына икенче премия бирелде, Рәйсә Ишморатованың «Милиция лейтенанты» китабы кызыксындыру премиясенә лаек булды.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКЦИЯСЕНДӘ

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы язучы Кави Латыйпов иҗатын тикшерүгә багышланды. Озак еллар инде төрле жанрларда иҗат итеп килүче язучының иҗаты турында шагыйрь Рөстәм Мингалим сөйләде. Утырышта катнашучы Илдар Юзеев, Адлер Тимергалин, Равил Фәйзуллин, Барлас Камалов, Роберт Миңнуллин, Кыям Миңлебаев, Шамил Рәкыйпов, Әминә Бикчәнтәева, Нур Гайсин иптәшләр язучының соңгы елларда әдәби актив эшләвен билгеләп уздылар. Утырыш Кави Латыйповны бертавыштан СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итте.

* * *

Балалар әдәбияты секциясе бюросының күчмә утырышы яшь язучы Рәниф Шәрипов янында үтте. Р. Шәрипов, каты авыруына да карамастан, соңгы елларда актив иҗат итүче, үзен төрле жанрларда сынап караучы яшь әдипләребезнең берсе. Утырышта язучы Ләбибә Ихсанова, шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Кукмара районының «Аһәңле сүз» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Шаһинур Мостафин катнашты. Алар яшь әдипнең балалар өчен язылган хикәяләре һәм шигырьләре белән таныштылар, әсәрләргә җентекле анализ ясадылар, уңай һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр, балалар өчен язылган шигырьләрен вакытлы матбугатка тәкъдим иттеләр.

## БӨТЕНСОЮЗ СЕМИНАРЫ

Тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев тәнкыйтьчеләрнең Бөтенсоюз семинарында катнашты. СССР Язучылар союзы тарафыннан Мәскәүдә уздырылган бу семинар КПСС Үзәк Комитетының әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы карары кабул ителү

10 ел тулу уңае белән оештырылган ... Анда КПСС Үзәк Комитетының җаваплы хезмәткәрләре, СССР һәм РСФСР Язучылар союзының җитәкчеләре, күренекле совет галимнәре һәм әдипләре белән очрашулар булды.

## ФИЛЬМ ГЕРОЙЛАРЫ — ЧАЛЛЫДАН

Мәскәү кинотеатрларында яңа, төсле документаль фильм күрсәтелә башлады. «Атна кич саен учак» дигән бу фильмның сценарнен прозаик һәм драматург Л. Жуховицкий режиссер И. Григорьевич белән өйрәнеп язган. Бу фильм Чаллы төзүчеләренең героик хезмәте турында да сөйли. Анда замандашларыбызның бай эчке дөньялары ачыла. Аларның, Кама буенда автогигант һәм гүзәл шәһәр салуда катнашып, бар яктан да үсүен күрәсең.

*

* *

Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм шагыйрь Разил Вәлиев Түбән Кама шәһәрендә техникум, училище һәм мәктәп укучылары, төзүчеләр, эшчеләр, милиция хезмәткәрләре белән очрашулар үткәрделәр. Әдәби кичәләрдә сүз бүгенге татар әдәбияты, язучының иҗат лабораториясе турында барды. М. Хәбибуллин үзенең иҗат планнары хакында сөйләде, Р. Вәлиев яңа шигырьләрен укыды.

*

* *

Казанның 95 нче мәктәбендә язучы Разил Вәлиев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәнең беренче өлешендә укучылар Р. Вәлиев иҗаты турында сөйләделәр, аның шигырьләрен укыдылар. Мәктәпнең «Чишмә» ансамбле, 5 нче класс кызлары хоры шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкардылар. Соңыннан Р. Вәлиев үзенең шигырьләрен укыды, күп санлы сорауларга җаваплар бирде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Язучы Владимир Мальцев үзенең иҗат лабораториясе белән таныштырды. Ул хәрби темага язылган повестьлар («За чертой времени», «Обет молчания») авторы. 18 яшеннән взвод командиры булып сугышка кергән В. Мальцевның яза башлаган яңа романы да Бөек Ватан сугышы темасына багышланган. Язучы утырышта үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты, туган ягы — Енисей буйларында һәм сугыш юллары буйлап иҗат командировкасында йөргәндә алган тәэсирләре турында сөйләде.

*

* *

Техника йорты залында үткәрелгән «Яшь нефтьче клубы» кичәсендә шагыйрьләр Э. Маликов, Д. Матвеев, И. Винокуров чыгыш ясадылар, әдәбият яңалыклары турында сөйләделәр, укучылар сорауларына җаваплар бирделәр. Клара Васюхина русча үз тәрҗемәләрен (С. Сөләйманова, Г. Афзал шигырьләренең) укыды.

*

* *

Лениногорскидагы икенче урта мәктәп укучыларын оешма җитәкчесе Э. Маликов нефть төбәгендә яшәүче язучыларның иҗатлары белән таныштырды.

*

* *

Хәниф Хәйруллин, Клара Булатова Сарман районы үзәгендәге беренче урта мәктәптә, районның Азалак, Янурыс, Әлмәт авылларында уздырылган әдәби очрашуларда катнаштылар, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Алар шулай ук «Ленинчы» газетасы редакциясе хезмәткәрләре, типография эшчеләре һәм «Сарман таңнары» әдәбият-иҗат берләшмәсе членнары алдында чыгыш ясадылар. Бу очрашуларда КПССның Сарман райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Дамир Гарифуллин, «Ленинчы» газетасы редакторы Илгизәр Кушаев, әдәби берләшмә җитәкчесе Әзһәр Габиди катнашты.

*

* *

Әлмәттәге агач эшкәртү комбинатында әдәби кичә уздырылды. Кичәдә Клара Булатова, «Әлмәт» әдәбият берләшмәсе членнары Җәүдәт Исмәгыйлов, Илдар Хөснетдинов, Котдус Батыров үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

*

* *

Лениногорскидагы унынчы урта мәктәп укучылары алдында Ш. Бикчурин, Әсрар Галиев, яшь авторлар Таһир Шәмсуаров, Наил Гыйләҗев чыгыш ясадылар.

Ш. Бикчурин үзенең иҗат планнары белән уртаклашты, әдәбиятка кагылышлы сорауларга җавап бирде.

*

* *

«Әлмәт» әдәбият берләшмәсе утырышында Г. Афзал поэтик детальләр, шигырьдә образлылык хакында чыгыш ясады. Яшь авторлар И. Мәрдәншин, Р. Галиуллин, Ә. Фәтхетдинов, Ш. Хисамиев әсәрләре мисалында, ул әдәби осталыкка ирешү юллары турында сөйләде.

*

* *

Әлмәттәге беренче татар урта мәктәбендә «Минем шәһәрем» дигән темага кичә уздырылды. Шәһәр архитекторы Фаварис Мәҗитов чыгышыннан соң, Клара Булатова Әлмәт шәһәренә, төзүчеләргә һәм нефтьчеләргә багышланган шигырьләрен укыды.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Журналның киләсе айда чыгачак 5 нче санында ниндирәк язмалар булыр икән, дип кызыксынучылар өчен түбәндәгеләрне әйтеп куярга мөмкин. Хәтерегездәдер, үткән ел Татарстан әдәбияты һәм сәнгате вәкилләре, Каракалпакстанга барып, анда зур бәйрәм тантаналары уздырып кайтканнар иде. Бу очрашулар илебез халыкларының бердәмлеген, татулыгын, уртак теләкләр белән янып яшәвен тагын бер кат раслаучы күңелле бер вакыйга булды. Быел исә шул бәйрәмнең дәвамы Татарстанда уздырылачак, бездә дә Каракалпакстан сәнгате һәм әдәбияты көннәре үткәреләчәк. Кунаклар июньдә Сабан туйларына килә, «Казан утлары» журналы исә, аларны каршылау йөзеннән, үзенең 5 нче санын ук Каракалпакстан әдәбиятына багышлый. Бу сәхифәләрдә Каракалпакстанның галимнәре, прозаиклары, күп санлы шагыйрьләре катнашалар.

Сез журналның бу санында язучы Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» исемле яңа романы белән таныша башладыгыз. Киләсе айда әсәрнең дәвамы бирелә. Роман Татарстанда тантана ителәчәк зур вакыйга — нефтьчеләребезнең илгә ике миллиард тонна кара алтын бирүе уңаеннан басыла.

Май ае безнең хәтерләрдә Бөек Ватан сугышының данлы җиңү белән тәмамлануын хәбәр иткән кадерле ай булып саклана. Шагыйрьләр Г. Рәхим һәм Ә. Гадел яңа шигырьләрен җиңү көненә карата язганнар.

Публицистика бүлегенең төп материаллары КПССның XXVI съезды карарларын пропагандалауга, алар яктылыгында ирешелгән җиңүләрне тасвирлауга багышланганнар.

Журналның 5 нче санында күп кенә язучыларның юбилей тантаналары билгеләнә. Бу уңайдан аларның иҗатларына анализ ясаган тәнкыйть мәкаләләре дә, үзләренең яңа әсәрләре дә бар.

Майда күренекле революционер язучы Гафур Коләхметовның тууына 100 ел тула. Бу датага карата бирелгән язмалар арасында әдипнең хатлары, аның иҗаты һәм тормыш юлы турында уйланулар рәвешендә язылган мәкалә һәм Г. Шәрипованың «Гафурлар гаиләсе» романыннан өзек бар.

Яшь тәнкыйтьчеләр Ф. Зөлкарнәев белән С. Маннапов икесе дә мәкаләләрен шагыйрь Р. Гатауллинның «Чакыру» исемле яңа китабына багышлаганнар. Авторлар шагыйрьнең иҗат принципларына да, бүгенге көн поэзиясе алдында торган гомуми бурычларга да тукталалар.

Тәнкыйть бүлегендә болардан тыш Ф. Миңнуллинның «Тәнкыйтьче бәхете», Ф. Шәфигуллинның «Көлеп моңая, уйлап елмая» исемле мәкаләләрен укырга мөмкин булачак.

Журналның соңгы битләрендә «Безнең календарь», «Елмаеп та, көлеп тә», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» кебек традицион рубрикалар бар.

Кыскасы, «Казан утлары»ның 5 нче санын да укучылар яратып кабул итәрләр дип ышанабыз.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ